# Казан утлары

3

МАРТ-1973

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**3**

МАРТ
1973


## Бу санда


Э. КАСЫЙМОВ. Һаваларда тургай. Роман . . . 3
ЗӨЛФӘТ. Күзнең авырлыгы — алмада. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
М. ХӘСӘНОВ. Кама таңнары. Романнан бүлекләр... 29
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр . . . . . . . 61
Г. МИНСКИЙ. Синең жырың. Пьеса . . . . . 69

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. ГАЛИЕВ. Сүзләр иленә сәяхәт. Шигырьләр... . 102

ОЧЕРКЛАР

М. ЗАРИПОВ. Баһадир доньяга килә . . . . 110
М. ХӘМИТОВ. Егет булып йөрер чаклар иде . . 119

ИСТӘЛЕКЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Г. ИДЕЛЛЕ. Беренче зур сәяхәт . . . . . . 133

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

И. НУРУЛЛИН. Аяк белән йөрүгә ни житә! . . 147
М. ВӘЛИЕВ. Безнең заман геройлары . . . . 151
Ш. БИКЧУРИН. Очеркның асылы . . . . . . . 156

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. ГӘРӘЙ. Аргамаклар юлда армасын . . . . 161
С. АЛИШЕВ. Мәгърифәт нурлары эзләп . . . 164



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**М. ГЛУХОВ.** Егылмас инде сыналган җан . . . 167

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

**С. ШӘЙДУЛЛИН.** Романтик герой эзеннән . . 171

**Г. МӨХӘММӘДОВА.** Рус совет язучылары иҗатында татар образлары . . . . . . . . 180

«ЧАЯН» БҮЛЕГЕ

«Чаян»ны котлау . . . . . . . . . . . . . . 185

**Г. ГОБӘЙ.** Халык һәм дин. . . . . . . . . 186

**Г. АФЗАЛ.** Эпиграммалар . . . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189



Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь—2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.



Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**


---


Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 2/XII-1972 ел. Басарга кул куелды 12/II-1973 ел. ПФ 09053. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 84996 экз. Заказ Г-777. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман урамы, 19. 1973 ел.

Эдуард Касыймов

# ҺАВАЛАРДА ТУРГАЙ

РОМАН



Син нәрсә? Бер әмер ителгәннән мин кире кайтыйммы? Син дә кеше көлдереп монда...

Мирыч бик әйбәт белә иде: цехтан берәрсе ял йортына яки санаторийга путевка алса, әүвәлрәк профсоюз кесәсеннән, соңгы вакытларда күбрәк цех башлыгы кул астында тупланып яткан ниндидер маядан, әлбәттә, кешесенә карап һәм үзенә күрә премия-мазар рәвешендәрәк иттереп, ярыйсы гына бүлеп биргәли иде. Аның бит, җитмәсә, путевкасы да бушлай әле...

— Соң бит... Аркадий Мефодич, без бит өйдә өчәү генә, хатын да әйбәт кенә хезмәт хакы ала, улыбыз Фуатны әйтмим дә, үзем тагы... Ну, ярый алайсам, ярый. Мең рәхмәтләр инде!

Санаторийның ни рәхәтен, ни шифасын әле барып, татып караганы булмады, әмма күкрәк кесәсендәге путевканың җылысын абзыең менә бүгеннән үк бик әйбәт сизә башлады инде, һәм ул, күңеле-җаны шатлыктан кымырҗып торганын тойган хәлдә, төштән соң баш күтәрмичә диярлек басылып эшләде. Чибәр мичкәләре берсе артыннан икенчесе, шәп тартылган барабандай, даң-дың, даң-дың яңгырашкалап, урталыкка таба тәгәри торды, бер сафка тезелә-өелә барды. Чуртан әмере белән түгел, әлбәттә, абзагызның бүген әллә нинди тылсымлы көче-җегәре кузгалган иде, ахры...

## 20

Альбертны ясле дән болай иртә алганнары юк иде. Башта: «Ничек инде? Ул бит йокыдан торгач, тамагына да ашамаган әле»,— дип, кашкүз җимерделәр. Мирыч: «Миндә бик йомшак, бик тәмле печенье бар, кимерер» дигәч, янә күнмәделәр. Ахыр килеп, сәбәбен төшендереп биргәч кенә, риза булдылар.

Бүген сукмактан атлаганда куркасы юк: аяк асты катырган иде.

Инде күзне бәйләп кичке эңгер төшеп килә иде.

Сукмактан каты-котыга сөртенгәләп атлаган шәпкә дә бабасы беләи оныгының авызыннан сүз өзелмәде. Гадәтләре шулай. Малайның теле ачылып көннән-көн шомара бара — аның иң күңелле чагы иде.

Дәвамы. Башы 1, 2 саннарда.

Шулай, нпле генә сөйләшә-сөйләшә, алар, тәмам караңгы булып беткәнче, Альбертның әнисе белән барып күрешергә тиеш иделәр. Ләкин бу кичне бабасына да, малайга да анда барып җитәргә язмаган икән...

Автобус тукталышына күп калмаган иде инде. Дүртәр-бишәр катлы яңа йортларны читләтеп, тукталышка турыданрак кистереп чыкканда, әле шушы араларда гына салынып бетеп, озакламый ачылырга тиешле ике катлы зур универмаг бинасы яныннан үтәсе иде. Менә шунда бу өр-яңа бина янындарак кирпеч сынык-санықларыннан тау өеп куелган иде. Сынык-санык дигәч тә, бу зур гына өем эчендә эшкә ярардай кирпечләр дә аз күренми иде. Яслегә Альбертны алырга барган чакларында Мирыч менә шушы кирпеч өеменә күптәннән инде күз майлаңдырып йөри иде...

Аның үз хикмәте, үз уй-исәбе бар иде.

Моннан берәр ай чамасы элек, завод күләмендә зур өмә үткәрелеп, Революция тавындагы туганнар кабере тирәсенә яшь агачлар утырткач, Закир кодасы белән Гөргери карт Абуздырин:

— Анда безнең һәйбәтләп рәшәткә тотмыйча ярамый: шәрәләнеп тормасын! Синең башлыгың Аркадий Мефодич материалын, тактасымазарын аннан-моннан йолыккалап инде әзерләп тә куйган, әйдәле, кода, синең кул җиңел дә, шома да, булышсана безгә! — дип, Мирычның якасына ябыштылар.

Мирыч риза булмыймы соң! Тара цехының столярлык бүлеге бер генә смена эшли иде — менә шунда кичке уңайларда өчәүләшеп тотындылар. Мирыч үзе Революция тавы кашында торгызылачак койма-рәшәткәләрнең нечкәрәк, нәфисрәк төшләрен эшкәртергә алынып, кодасы белән Гөргери картка кисү, ышкылау кебек карарак эшләрне йөкләде. Әнә шулай җиң сызганып, рухланып ябышканнар иде ябышуын, әмма башлыклары Белобородов бер-ике кичтән соң ук боларны эшләреннән туктатты. Материал кызганудан түгел, аңарда икенче төрлерәк исәп туган икән, әйтте:

— Болай килешмәстер безгә, картлар. Агач ни ул? Черер, таралыр. Бар тырышлыгыбыз берничә елдан ук юкка чыгар. Рәшәткәсен тимер челтәрдән, баганаларын таштан куйсаң иде менә! Ул чагында безнең Революция тавыбыз күз өстендәге каш кебек күренеп торыр иде, ичмаса! — диде.

— Соң, бик шәп инде алай, әмма материалын каян, ничек табасың аның? — диеште болар.

— Кыш озын әле, язга тикле ничек тә әмәлләрбез. Тимере хакында ремонт-механика цехын үзем дыңгырдатырмын, ә ташын, кирпечен... пошынмыйк, анысы да табылыр,— диде Белобородов.

— Кышка кергәндә генә анда барыбер әллә ни майтарып булмас, баш өсте, без бик разый,— дип, шундук күнделәр картлар.

Яңа салынган универмаг янындагы кирпеч өеме турысыннан узганда, әнә шул сөйләшүләре Мирычның хәтер сандыгыннан капыл калкып чыга иде. Әйе, алар шушындый калдык-постык кирпечләрдән дә менә дигән баганалар күтәрә алалар лабаса — күңел сал да иренмә генә! Ә төзелеш-корылыш тирәләрендә азмыни мондый таучыклар? Шул уен Мирыч үзенең цех башлыгы Белобородовка да җиткермәкче иде, әмма, инде болай да тәмам эшнәләнеп беттек дип, ниятеннән кире кайтты. Ул кодасы Закир белән Гөргери картның очравын гына көтебрәк йөри иде — боларның күңеленә бер корт салсаң, әллә кемеңне күндерә алырлар кебек тоела иде аңа...

Менә хәзер куерырга торган кичке эңгердә оныгы Альберт белән универмагка якынлашып килгәндә, Мирыч атлаган җиреннән капыл туктады: теге кирпеч өеме тирәсендә яман тавыш белән үкереп-гүелдәп

бульдозер актарына иде. Абзыйның бөтен гәүдәсе буйлап кисәк кенә салкын йөгерде.

— Әйдәле, Аликҗан, кызулыйк әле, юньлегә түгел бу...

Универмаг бинасыннан артка табарак ни өчендер күмелмичә калган киң һәм ярыйсы гына тирән чокыр бар иде. Мәгәр чын: бульдозер кирпеч өеменнән өлешләп әләктереп ала да шул чокырга таба шудырып бара иде...

Мирыч җәһәт бер житезлек белән килеп житте дә ачулы гына кул болгап бульдозерны туктатты һәм, аның табак битле иясе жиргә сикереп төшүгә, күңеленнән тыныч һәм ипле булырга тырышып, әмма ярсуын баса алмыйча, аңлатырга кереште:

— Син нәрсә, агай-эне? Бу бит... монда да бит кирпеч кисәкләренең миңа дигәннәре бар, ә син нишлисең? Берәүгә бирсәң, шушынардан үзенә бик әйбәтләп гараж торгызыр иде, һич югы, миңа юл-сукмакларга түшәгәндә дә файдасы булыр иде: тез тиңентен ләжбердек ерып интегәбез ләбаса! — Мирыч бу табак битнең башына барып житмәсен шәйләп, Революция тавында фәлән нәрсәне төгән итәсе бар иде дип, нечкәләп торуны кирәксенмәде дә...

— Шундый хәзинәне күрәләтә жиргә күмәргә җаның бармы синең?

— Җан, имеш. Ә син үзең кем соң әле? Кушканнар икән, эшлим, син дә тыкшынма, белдеңме! — Табак бит, авызын ямьшәйтеп, Мирычның аяк астына төкерде.— Хәзинә, имеш... Ычкын моннан, буталып йөрмә! Югыйсә...

«Моңа арба ватылса — утын, үгезнең аягы сынса — ит, ахрысы...»

Мирыч, әле һаман да өметен җуймыйча, кире кабинасына кереп китәргә җыенган табак битнең майлы тужурка итәгенә ябышты, әмма теге:

— Син нәрсә...— дип, тимер дагалы күн итегенең үкчәсен күтәрде.

Калган хәтлесе күз иярмәслек тизлек белән булды — соңыннан Мирыч бу яман вакыйганың вак-төяген хәтерли алмады...

Бульдозер хәтәр үкерә-үкерә янә кузгалуга, Мирыч, гәүдәсендә үзенә бик таныш ямьсез дерелдәүнең кисәк кабынуын тоеп һәм үз-үзен онытып, машина юлына аркылы чыгып басты. Юк, бәлеш йөзле бәндә кисәге тукталу түгел, киресенчә, газны тагын да көчәйтеп җибәрде — бульдозер, куркыныч ялтыраган яссы пычагы белән жирне сыдырып һәм аждаһадай яман үкереп, абзыйның өстенә килә бирде. Мирыч чак-чак читкә тайпылып өлгерде...

Тайпылганда, сыңар аягы таш арасына кысылып, чалкан егылып китте — тубык тирәсе чатнап алгандай булды. Әмма, чиксез ярсуыннан, ахры, авыртуын тоймады, үз-үзен белешмәстән, жирдән калкына төште дә кулына эләккән беренче кирпеч кисәген кабинага тондырды — анда чылтырап пыяла коелды. Икенче селтәнүендә, кабинадан ухылдап сикереп төшкән бульдозерчының яньчелгән бәлеш йөзенә сылады:

— Кабахәт!..

Майлы таза куллар Мирычның пальто изүеннән эләктереп, аны таш арасыннан йолкып алды һәм бер селтәнүдә әллә кая очыртып җибәрде. Янә чылтырт итеп пыяла уалганы ишетелде. Ләкин бусында абзыйның варенье банкасы белән йөзем ширбәте тутырылган шешә генә чәлпәрәмә килгән иде.

— Таптап изәм бит, үтерәм бит!..

Ләкин артыгына юл куелмады: узгынчылардан кемнәрдер аралларына кысылды, кемдер Мирычка аягына басарга булышты.

— Сез нәрсә монда? Ни бүлешәсез, ни котырдыгыз?

Уң аягына басуга, чайкалып китте: һаман да шул сугышта җәрәхәтләнгән аягына эләксә әләгә...

Моннан шәһәр поликлиникасына нибары бер квартал үтәсе иде. Бәхетенә, хирург китмәгән икән әле. Мирычның тубык тирәсе шешеп чыккан иде, врач карады-нитте дә әйтте:

— Алай куркыныч юк, биртелгәнгә генә охшый. Ашыгып барганда, тайпылдым дисез, ә? — Мирыч аңа барын да аңлатып торсынмы соң? — Ярар, майларбыз, бәйләрбез... Алай да рентгеннан сурәтен алдырмыйча ярамас. Иртәгә килерсез...

Хирург кабинетыннан чыгуга, ни күрсен, теге табак бит, маңгаен аклы-кызыллы чүпрәк белән бәйләгән килеш,— күлмәк итәген ертып алган, ахры,— коридорда арлы-бирле йөренә иде. Зәһәр гыжлап Мирычка бармак янады:

— Кемлегеңне белдем, свулыч! Врачтан справка алыйм, судка бирәм мин сине!..

## 21

Мирыч нык аксаңкырап, әмма авыртуын онытына сиздермәскә тырышып, өенә кайтып керде.

Оныгы Аликжан белән тегеләй сөйләшкәләп, болай иткәләп вакыт уздырып яткан чакларында, ишеккә орындылар. Көткән кешеләредер дип, авызлары ерылган иде, әмма бусагада... маңгае ак марляга уралган теге табак бит пәйда булды.

— Тәки таптым бит... Безгә алай усаллану ярамастыр, Мирыч...

Сырма кесәсеннән бер яртыны чыгарып, аны алгы яктагы өстәлгә китереп куйды, үзе табуреткага утырды да майлы, таза бармакларын тез капкачында биетергә кереште.

— Әле син мине судка бирерсең дип куанып тора идем. Инде үземә йөрергә туры килер микәнни? — диде, ниһаять, Мирыч, зәһәр көлемсерәп.

— Һәй, кызган баштан гына булды инде ул, кем, Мирыч... Ярар, чукынмый, кабинаны үзем төзәтермен. Тик тагын бер яртыны инде син чыгарырсың. Әйе, без зурга җибәрмик. Как-никак, без эшче класс, ни кушылса, шуны үтәүчеләр...

— Син эшче класс? Тфу?!. Тагы казага керешмик, менә шешәң, анә ишек... ыжгырт, дим!..

Альберт биек артлы урындык артына ышыкланып, инде еламсырый да башлаган иде. Мирыч кайнар маңгаен мичнең сап-салкын төнлек тимеренә тидерде. Бусага артыннан түгел, әллә каян упкын төбеннән гүелдәп күтәрелгәндәй, янап кычкырган сүзләр ишетте:

— Кеше монда яхшылык белән, ә син?.. Әле мең үкенерсең, свулыч!..

«Кем белән киңәште, кайсы котыртты икән бу мескенне? Юк, суынырга ярамас безгә...»

— Улым, Аликҗан, әйдәле, читен булса да бер җиргә барып кайтыйк әле, акыллым.

— Кая, бабай?

— Бер абыйларга. Автобус тукталышыннан әллә ни ерак түгел алар. Сугыштан герой булып кайткан ул. Әйбәт абый.

— Герой? Ә теге әсәке абыйны кыйный алылмы соң ул? Көслеме ул?

— Бик көчле! Белер ул нишләтәсен...

...Тагын өч көннән соң «больничныен» да яптырмастан — рентген сурәтендә чынлап та куркыныч нәрсә табылмаган, әмма, алай-болай тоткарламагае тагы дип, врачка кабат күренмичә — Мирыч ерак Кавказ тарафына сәфәр тотты. Сугыш ветераны, гап-гади эшче — мичкә төпләүче Рәкыйп Мирза улы Саматовка, алдагы көннәрен уйласа, какшаган нервларын бераз дәваламыйча һич ярамый иде шул.

Киң елга өсләтеп сил килә.

Салкын. Югарыдан, зәңгәр урманлы борылыш ягыннан агым уңаена искән җил, куеннарга, тагы әллә кай төшләргә үтеп, бар гәүдәне калтырата. Тән дә, җан да мондый суыкка әле күнекмәгән.

Кыш үзен бу елны чынлап та һич көтелмәгәнчә бик иртә сиздерә башлады. Менә бит бөтен дәрья йөзен инләп сил дә шуа инде. Эрелеваклы юка боз кисәкләре бер-беренә бәрелешеп, ышкылгалап, шыгыр-шагыр уалалар, әмма тузу, таралышу өчен түгел, бәлки, киресенчә, укмашу, ныгу һәм берегү өчен уала алар. Озакламас, син күр дә мин күр, мәгърур Чулман-дәрья калын боз калканы белән капланыр.

Элекке заманнарда, техникага бик тә фәкыйрь чакларда, ничек булгандыр, ә бүген әнә адәм баласы табигать стихиясе белән көрәшеп азаплана әле. Затондагы калын гына боз кисәкләрен җимереп-ватып, баржа һәм катерларны кышкы ялга кертеп маташалар. Байтагы инде эчкәредә шыплап, тыгызландырып урнаштырылган да... Елга уртасыннан, куерып килгән силне корыч күкрәкләре белән яра-яра, үзйөрешле баржалар, төрле кыяфәттәге куәтле буксирлар үткәли. Кышның зәмһәрир сулышын тоюдан һәммәсе, озын һәм авыр чабышның азагына җиткәндәй, ашыга, кабалана...

Сыртына әллә нихәтле машина сыйдырышлы, олы һәм куәтле паромнарның икесе дә йөри иде әле. Иртәгә шуларның берсе генә калачак икән. Салкын җилдә йөзе уттай кызарган таза гына паромчы агай сәфәрчеләрне, бигрәк тә шоферларны әледән-әле:

— Эшләр болайга киткәч, иртәгә-берсекөнгә генә эшләрбез дә инде бөтенләйгә туктарбыз... Үз җаегызны үзегез белегез! — дип, кисәтеп куйгалый иде.

Ә яр буйларында, аерата уң ярда, Акбалык ягында, паромга тизрәк эләгергә ымсынган машиналарның исәбе-хисабы юк — чиратның койрык очы бөтенләй күренми дә иде. Нефтьчеләр дә, төзүчеләр дә үзләренә бар кирәк-яракны төп йортлары Әлмәт төбәгеннән китертә — юл өзеклегенә аз гына да маясыз калсыннармыни?

Госманнар, паромның беренчесенә үк эләгеп булмасмы дип, юлга шактый иртә кузгалганнар иде. Ләкин кая монда беренче паром! Ярый әле, шоферлары Сәлим уңган егет булып чыкты: тегесен узып, монысы арасына кысылгалап, ахыр чиктә, понтонга бәреп керде дә икенче паромга борын төртте. Иң кырыйда тик боларның газиклары гына сыярлык урын калган иде — бәхетләре йокламаган икән — керттеләр. Бу унайдан Рива Галиевна:

— Ай-һай, егет тә икәнсең үзең! — дип, шоферга сокланып-сөеп карады.

— Солдат всегда солдат, апаем! — диде теге, эре тешләрен елтыратып.

Паром, агым уңаена түбән таба төшеп, тар гына утрауны әйләнгәч, елга урталыгына чыкты һәм тупас, киң корсагын агымга каршы салып, шыгыр-шагыр иттерә-иттерә, куе силне изә башлады. Җил монда куәтлерәк, ачырак иде, Госман белән янәшә паром бортына таянып торган Рива иңбашларын куыргалап:

— Ай-һай ла!.. — дип, җилгә аркан борылды. Аның өстендә аксылсаргылт джерси пальто, башында шул ук төстәге күперенке берет, ә муенына йомшак, нәфис ак шарф уралган иде. Болар барысы яшь, чибәр ханымга бик килешле, аны тагы да сөйкемлерәк итә иде.

Кичүдән астарак булачак ЧулманГЭС бөясе яртылаш диярлек өелгән дә елга уртасына таба бүселеп үк кергән. Ханым шундагы тимер мачталарга, вакытлыча салынган башка нише нәрсәләргә бер мизгел төбәлеп торды да карашын яр буйлап өелгән биек дамбага күчерде.

— Тагын берничә ел үтүгә, бу төшләр, Госман Габдулыч, бары да су астында калыр инде. Ә плотина өстеннән поездлар, автомашиналар йөрер, ә ГЭС үзе берөзлексез гүләп торыр... Гаҗәп бит, иеме?!

— Әйе, Рива. Барысы да безнең күз алдында эшләнә.

— Ул чакны инде шушы җан көйдергеч паромның да кирәге калмас... Юк, чыдар чамам бетте, бигрәк өшетә лә... Керәм мин.

Рива ачы җилдән качып, газик эченә кереп посты. Шофер Сәлим дә шунда әйләнә-тирәсендәге дөньяда бөтенләй гаме булмаган кыяфәт белән ниндидер журналга чумып утыра иде.

Яр-Чулман — карт та, яшь тә кала... ЧулманГЭСның яңа йортлары биредән, елга өстеннән, бөтенләй күренми дә икән, алар кайдадыр офык артында сыман. Берәр, икешәр катлы йортлардан торган иске каланың елга ягына караган өлеше исә күрер күзгә нигәдер бик мескен, нәүмиз булып тоела, хәтта күңелдә кызгануга тартым хис кузгата иде. Яшисе гомерләре инде күп калмагандыр, бер дә бер көнне шушы ала-кола тәбәнәк йортлар урынында киң дәрьяның шаян дулкыннары чайпалыр яисә таштан, бетоннан салынган матур яр буе сузылып киткән булыр...

Тик аз гына югарыда, калку яр текәлегендә, сырлы түбәсен горур кабартып, әүвәлге элеватор калкынып утыра. Атаклы эшкуар Стахеев истәлеге. Революциягә тикле Чулман-дәрья якасында торгызылган иң олы, иң мәһабәт корылмаларның берсе булгандыр әле ул...

Госман карашын түбәнгә, су өстенә, төшерде. Ярга елышканда сил тагы да куерак күренә, ул инде бөтенләй укмашкан да кебек: паром зур авырлык белән генә, двигательләрен бар җегәренә эшләтеп, дебаркадерга якынаеп азаплана иде. Чыннан да, иртәгә ни булыр, берсекөнгә тагы?

Авыр сулап куйды: юлның иң азаплы чагына туры килделәр, каһәр. Бер уйлаганда, Бөгелмәгә — ТатНИИга сәфәрләрен, Чулман аша кышкы юллар салынганчы, берәр айга кичектерсәләр дә, зыян итмәс иде. Ник дисәң, үз тирәләрендәге нефть мәйданнарында тупланган җир асты суларының куәте хакында төпле белешмәне алар «Чулманнефть» геологларыннан инде алганнар, моның өстенә, ТатНИИ да әле күптән түгел генә шушы проблемага багышланган тикшеренү-эзләнүләренең гыйльми отчетын җибәргән иде. Химикларның бик күп нәрсәгә күзләре ачылган иде инде. Әмма күңелләрен борчып торган нәрсә дә юк түгел иде: әлеге отчетта кайбер моментлар өстән-өстәнрәк яктыртылган кебек күренә, Госманнарны аерата нефтьче галимнәрнең экономик исәп-хисап методлары кызыксындыра иде. Әмма барыннан да бигрәк, эшләр инде болай тирәнгә киткәч, күзгә-күз сөйләшеп, ике арада тагы да тыгызрак һәм якынрак мөнәсәбәтләр урнаштырмыйча ярамастыр кебек тоела иде...

— Директор машина да бирәм дип торганда, зинһар, юл авырлыгыннан куркып ятмыйк инде, суындырмыйк инде, Госман абый, — дип кымтырыклап торды Рива Галиевна, хәтта бер мәлне кыйгач кашларын җимереп, ачулы төстә янагандай итте: — Сез бик теләмәсәгез, япа-ялгызым барам, алайса...

Ханым әлеге фәнни-тикшеренү эше белән чын-чынлап мавыгып киткән иде. Ул үз тирәсенә, Зөлфәне генә түгел, соңгы араларда янә бер лаборантканы — Ася Люминаны да тартып, аның да күңеленә корт салырга өлгергән иде.

— Син хаклы, Рива, — дип, күнмичә булдыра алмады Госман. — Суындырмыйк. Бер җилләп кайтудан файда гына булыр.

Әйе, аның сәфәрдәше кем бит әле!

...Паромнан төшеп, Яр-Чулманның үзәк урамы буйлап беркадәр күтәрелгәч, Госман, шоферның иңенә орынып, аңа тукталырга кушты да, күзләрен очкынландырып, Ривага төбәлде:

— Әллә ниме... Минзәлә юлына борылабызмы? Анда бит үзегез дә беләсез, автогигант... Мондый форсат тагын кайчан килә безгә?

Күңелләре бер тирәдәрәк айкала икән, шофер Сәлимнең авызы шундук җәелеп китте:

— Үзем дә шуны уйлый идем әле. Яр-Чулманнан унике-унбиш чакрымнарда гына, ди, ул, безнең өчен айн момент...

— Анда бер таш бар, ди, аңа: «Шушында «Чулман батыры» төзеләчәк» дип язылган, ди... Аны бер күреп китсәк, бик әйбәт булыр иде шул,— дип күтәреп алды Рива да.— Ә Бөгелмәгә ничек тә өлгерербез әле...

Ләкин Сәлим «айн момент» дип шапырынса да, алай тиз генә әйләнә алмадылар.

Яр-Чулманны артта калдырып, көзге пычракларда тәмам эштән чыгып бозылган чокыр-чакырлы юл белән бара торгач, янә бер авылны үттеләр. Инде хәзер күз күреме җитмәслек томанлы офыкларга китеп кушылган киң сахра башланды. Олы юл да читтә калды. Җир күкрәгенә салынган яңарак эзләр белән әле тегеләйрәк каерылып та, болай таба сугылгалап та карадылар, әмма теге хикмәтле таш күзләренә чалынмады. Чем-кара туфрагы каезланып актарылган җиргә килеп төртелгәч, ниһаять, туктадылар.

— Ул таш турында газетадан үз күзем белән укыган идем бит, югыйсә,— диде Рива, уфтанып.

— Әйе, менә сиңа, хикмәти хода, дигәндәй, әллә җир йотканмы үзен?

Яр-Чулман каласы әллә кайда, офык читендә үк калган, аның яңа салынган ташпулатлары сыек рәшә эчендә тонык кына булып күренә иде. Ә монда, киң һәм аулак басу түрендә, анда-санда сырт кабартып салам эскертләре утыра да ачы җил генә уйный иде. Бик текәлеп карасаң гына, көньяк тарафта, моннан шактый еракта, кемнәрнеңдер, вак кырмыскалар кебек, ыгы-зыгы килеп, ни беләндер матавыклануын чамаларга була иде. Юл төзүчеләр бугай. Әйе, шулардыр: әле бу көннәрдә генә республика газеталарында, дуамал шаулап, олы төзелешкә таба юл салучыларны мактап чыкканнар иде.

Кинәт әллә каян гына, Сарман юлыннан аерылып, ахры, болай таба чаптырып килүче ялгыз автомашина күренде. Зәңгәрсу төскә буялган үзбушаткыч икән, дыңгыр-дыңгыр килеп җитүенә, шып туктады.

— Таш дисезме? Һе, минем монда килеп эшли башлавыма атна да юк әле, кайдадыр шушы тирәләрдә булырга тиеш ул,— диде шофер, җилкә сикертеп.— Үземнең дә бер күреп үтәсе килгән иде дә бит... Ә автозаводмы? Һе, сез аның тап уртасына басып торасыз ла! — Кисәк ул кулын җәеп җибәрде.— Монда күз күремең җиткән бар җирләр булачак заводныкы инде, аптырыйсы юк, туганнар!

Өчесе бердәм киң һәм тирән сулап куйдылар.

— Әлегә шыр ялангач басулар гына... Әмма тик тор... Эх, шушындый сахраларда бер ут уйнатып йөрүләре үзе генә нидер, ә?! — дип, күкрәген сыпыргалады Сәлим.

— Соң, уйнат, итәгеңә ябышкан кешең юк ич,— диде Рива, үзе дә әсәрләнеп басып торган җиреннән.— Син дә уйнатмагач, Сәлим, кемнәр тагы?..

— Яшь чак, егет чак булсамы? Минме? Һич нигә карамас идем, килер идем... Чын әгәр! — диде Госман, күз карашын бу киң сахрадан аерып ала алмыйча.

Көзнең сикәлтәле каты юллары белән әллә кайлардан әйләнә-азаплана кире асфальтка чыккач, Госман, кинәт айнып киткәндәй, кул сәгатенә күз төшереп алды да ахылдап ук җибәрде:

— О, инде хәзер җилдәй очсак та, Бөгелмәнең үзенә түгел, Әлмәткә

дә нибары төш турысында гына барып җитәсе икәнбез. Ах, сине! Куныл калырга туры килмәгәе.

— Куныл калырга? Юк, юк, нишләп инде,— дип пышылдады Рива куркынганрак тавыш белән.— Паромны төнге унга тикле йөрер диганнәр иде бит.

— Йөрсә соң! Аның азаккысына эләгүләре, ай-һай, икеле булыр шул, апаем. Нишлисең, юл юл инде ул: бер алдын күрсәтә, бер артын,— дип көлемсерәде Сәлим, тизлекне тагы да көчәйтә төшеп.— Ә куна калсагыз, миңа мач кына булыр иде: Карабашта апа бар минем. Аралар да болай якын гына кебек, машина да йөреп кенә тора, әмма күрешмәгәнебезгә биш былтыр... Куабыз дөньяның артыннан шулай иттереп...— Каршыга йөгергән юлга уйчанланып текәлгән хәлдә, бераз дәшми-тынмый баргач, егет сүзләрен чак кына суза төшебрәк, әмма бер сулыш белән диярлек әйтә салды тагы: — Завод, ах, бу автозавод! Юк, апаем, бу хакта да төптәнрәк уйламыйча ярамастыр!.

* * *

Әлмәткә барып кергәч, Госман капыл гына:

— Моннан алай җиңел генә үтеп китмик әле. Берләшмәгә сугылып, анда геологлар белән аз-маз киңәшеп чыкмыйча килешмәстер. Һич булмаса, күрешеп, танышып алырбыз. Югыйсә, тегеннән әйләнеп кайтканда соң булыр,— дип, сәфәрләренә төзәтмә кертергә кирәк тапты.

— Тик, зинһар, озакламасак иде анда,— дип үтенде Рива.

Хезмәткәрләрнең төшке тәнәфесе әле бетмәгән икән, болар да «Татнефть» берләшмәсе урнашкан бинаның аскы катындагы кафеда аяк өсли генә тамак ялгап алдылар. Аннары Госман белән Рива югарыдагы катка күтәрелделәр. Күтәрелделәр һәм... баттылар.

Берләшмәнең баш геологы боларның ни нәрсә белән кызыксынуы турында беркадәр хәбәрдар икән инде, үзе болай ачык һәм киң генә күңелле адәм икән, сәфәрчеләрне шактый тоткарлады. Ахырда, химикларның җир астындагы тозлы эремәләр белән чын-чынлап кызыксына башлавын бик тә хуплап, үзенең төпле генә киңәшләрен дә әйткәч, кабинетына өлкәнрәк яшьтәге бер абзыйны дәшеп алды.

— Кирилыч,— диде ул, керүчене мондагылар белән таныштырып һәм боларның асыл максатын аңлата-аңлата,— син ул проблема белән турыдан-туры шөгыльләнгән кеше, тирәнтенрәк беләсең, бар нечкәлекрен төшендереп бир инде үзләренә, зинһар. Бездән калмасын.

— Бик рәхәтләнеп...

Кирилыч алып кергән бүлмәдә ике-өч өстәл бар, әмма аларның ияләре күренми иде. Аулак һәм тыныч бүлмәдә үзенең тынгысыз һәм мең мәшәкатьле гомерендә бер генә пот тоз ашамаган, шул сәбәпле шактый шомарган геолог абзыкаең болар кузгатып йөргән проблемага якынаеп та, аңардан ярыйсы гына читләшеп тә, әмма һәр нәрсәне нечкә тәфсилләп аңлатырга кереште. Әмма Госман өчен иң кадерлесе бу карт геологның үз өлкәсендә балыктай йөзүе өстенә экономик исәп-хисап эшләрендә дә шактый ук мәгълүматлы булуы иде. Госман сораша торды, Рива исә үзенең куен дәфтәренә бар кирәк нәрсәне терки барды.

— Инде күзләр бөтенләй ачылып китте,— диде Госман, әңгәмәләренең ахыры якынлашуын тоеп.— Болай булгач, Бөгелмәгә барып торуның да хаҗәте шул хәтле генә...

— Юк, юк, нишләп? Алар, бәлкем, проблемага тагын да тирәнтенрәк килер. Инде бер юлга чыккач, иренмәсәгез иде. Әйе, якыннан дуслашу беркайчан да зыян итми ул. Тик ни... хәзер инде сез...— Кирилыч та, болар да, шунда гына исләренә кайтып, сәгатькә күз салдылар.— Кур, инде дүртенче киткән икән! Әйе, сез анда барып җиткәнче, аларның эш көннәре тәмамланган да булыр.

— М-мда, инде нишләргә соң?
— Иртәгә иртән барырсың. Үзем аларга шалтыратып та куярмын. Безнең монда гостиницада хәзер алай тыгын түгел кебек, үзем әйттерермен...
— Бик зур рәхмәт инде сезгә, Андрей Кирилыч! Бу тикле үк...
— Ярар, төчеләнмик, сеңелем...
Шофер Сәлим теге журналының азагына житкән иде инде, ахрысы, ул машина эчендә, йомшак утыргычка ярым чалкан яткан көенчә, мәрткә киткән иде. Рива ишек тоткасына ябышуга, егет капыл тураеп утырды, күзләрен угалады.
— Бәхеткәйләрең басты, Сәлим: безгә шушында куңып ятарга туры килә,— диде ханым, үзе әйткән хәбәргә әллә ни куанмавын аермачык сиздереп.
— Әйе. Бөгелмәгә иртәгә иртән китәргә киңәш иттеләр,— диде Госман.— Инде хәзер син үз ихтыярыңда... Без монда нефтьчеләр гостиницасында булырбыз. Син инде, Сәлим, зинһар, иртәгә иртүк...
— О, бик шәп! Карабашка искәрмәстән генә барып, анда апайны бер шаккатырыйм әле, алайса!.. Сәгать ничәгә? Җидегәме? Эһе, сигезләргә... Ялт каршыгызда булыр бу солдат!
Газик җәһәт кенә урыныннан кузгалып, артыннан сыек зәңгәр төтен бөрки-бөрки, урам чатында күздән югалуга, Госман дустанә көлемсерәп юлдашына күз атты:
— Эш бетте, көлтә жыясы гына калды... Кызык килеп чыкты әле бу, әйеме? Ярар, иң әүвәл гостиницага урнашып алыйк, аннары... хе, аннары нишләрбез икән монда? Тамак ялгарга әле иртәрәк, әллә вакытны тизрәк тәгәрәтү өчен кино-мазар карап чыгабызмы?
— Миңа барыбер. Ничек тә ярар...
Кичен, кинодан соң, гостиница ресторанына кереп утырдылар. Карыннары ярыйсы гына ачыккан булса да, ашыкмыйча, иркенәеп, тәмле ризык капкалый-капкалый, «вакыт тәгәрәтергә» тотындылар. Гәпләре һаман да әлеге дә баягы проблема, эш тирәсендәрәк булды, сүз уңаеннан үзләренә күптәннән таныш әйберне — нефтьчеләрнең киң күңеллелеген, кунакчыллыгын мактап телгә алдылар һәм шунда ук моның киресен — Мәскәүгә барсалар, мәскәүлеләрнең, бигрәк тә министрлыктагы халыкның катылыгын, бәгырьсезлеген яманлап, зар сиздерделәр. Әмма ресторан мондый нәрсәләр турында сүз җебен үреп утырырга бик үк кулай урын түгел, әкренләп телләренә икенчеләйрәк, җиңелрәк, хәтта төчерәк тә нәрсәләр килгәли башлады. Госман — шактый гына юл йөргән, тегендә-монда булгалаган кеше, төрле кызыклар сөйләп алды. Рива баштарак чибәр йөзендә уңайсызлану чалымнары сиздергәләде, ара-тирә, берәрсе күрмиме-ишетмиме дигәндәй, як-якка күз аткалап алгалады, әмма соңга табарак кыюлана төшеп, сәфәрләшенең ярыйсы гына майланган күзләренә туры караудан һич тартынмыйча, үзе дә әйбәт кенә көлдерерлек бер-ике мәзәк сөйләп алды. Ни дисәң дә, ханым кеше, житмәсә тагы, офицер хатыны...
Үзе сөйли, үзе көлдерә, үзе бер үк вакытта житдирәк кыяфәт сакларга тырышып, әмма һич кылапчыкланмыйча:
— Әллә ниләр ишетерсең бу дөньяда... Әкәмәт! — дип, алсуланып янган дымсу иреннәрен бөрештергәндәй итә иде.
Госман исә, ничектер, үзе дә сизмәстән, торган саен тәкәллефсезләнә барып, ханымның аксыл, нәфис муеныннан, дымсу кайнар иреннәре читендәге бәләкәй генә, күркәм генә миңеннән карашын ала алмыйча, күңелен-җанын әллә нинди сихер иркенә куя бирде...
Өскә соң гына күтәрелделәр. Госманның бүлмәдәше, укырга дип алган газетасын юан бүксәсе өстенә төшергән килеш, борынына көй салырга да өлгергән иде. Ә Риваның... Юк, аңа бүлмәдәш кермәгән, ул әле һаман япа-ялгызы икән. Төн уртасында гына күктән берәвесе ин-

мәстер лә инде... Ханымның бүлмә ишеге төбендә беравык басып тордылар. Госман эчкә үтәргә ымсыну сиздермәде, ханым исә дәшә белмәде.

— Башны йомшак мендәргә салыр вакыт та җитте. Әйбәтләп ялитик инде... Тыныч йокы, Госман абый!..

Ишек салмак кына ябылды. Госман бер мизгел баскан җиреннән кузгала алмыйча торды. Аннары аны зиһенен сөремләндереп айкалган хәмер парлары, тамырларында кызышып йөгергән каны баскычтан түбән таба текердәтте.

Ресторан буфетын, бәхетенә, ябарга өлгермәгәннәр иде әле. Шәрабның иң һәйбәтен сайлады, кабарга шоколад-конфет алды. Буфетчы хатын, сөрмәле керфекләрен мут сирпи-сирпи:

— Ә нишләп берне генә аласыз? Соңыннан үкенерлек булмагае,— дип кеткелдәп куйды...

— Үкенмәбез...

Рива бүлмә ишеген биклән тә алган икән инде. Бер-ике чиерткәч, Госман тынын кысты... «Йокларга ятмаган гына булса ярый ла...» Әмма шул мизгелдә үк іеге якның күңелне иләсләндергеч рәхәт, татлы пышылдавы ишетелде:

— Кем?

— Бу мин, Рива...

Ишек ачылды. Ханым, күзләрен тутырып, Госманның бер йөзенә, бер күкрәгенә кыскан нәрсәләргә карады. Үзе шул арада чәчен тузгытыбрак җибәрергә һәм күлмәк изүенең төймәсен ычкындырырга да өлгергән инде...

— Мин, Рива... син инде ни...

Рива янә күзен мөлдерәтеп төбәлде. Аның нәфис борын яфрагы кисәк тартышып куйгандай булды.

— Кирәкми, Госман абый... ярамый! Син бик әйбәт кеше ләбаса. Зинһар, сиңа хөрмәтем югалмасын инде! Без бит дуслар да... Шулай булып калыйк та инде...— Карашында инәлү-ялвару да, сагыш һәм тилмерү дә бар иде сыман...— Зинһар, дим, кирәкми, дим... Госман... Госман Габдулыч!

— Шулай дисеңме?.. Эһем... Алайса ни... гафу... гафу...

«Ахмак! Җебегән! — ди-ди, яткан җирендә ярсынып, баш астындагы мендәренә йодрык төйде Госман.— Тәбәнәк кенә, пучтәк кенә киртәне дә атлап үтә белмә, пешмәгән җан!.. Гомеремдә беренче тапкыр гөнаһлы, әмма баллы чәчәккә урелүдә үк яндым, тинтәк! Әйтсәң, адәм түгел, тавык көләр... Иртәгә ни йөз белән карармын йөзенә... Ах, Рива, Рива, иблис хатын, нишләттең син мине, нишләдем мин?»

...Иртән уянгач, өстәлдә бөкесе дә ачылмаган килеш кукраеп утырган һәйбәт шәраб шешәсе күзенә чалынуга, янә тирән ярсыну аша сукранып куйды: «Ун кат җүләр, мең кабат тиле!»

Рива белән күрешкәндә, карашын читтәрәк йөрткән хәлдә, әмма дустанә елмаерга тырышып, аңа хәерле иртә теләде. Риваның исә кәефе ал да гөл икән: бик әйбәт, бик тыныч йоклаган, җитмәсә тагы, матур гына төш тә күргән икән.

— Имештер, үзебезнең Чулман буендагы ямь-яшел болынлыкта юа җыеп йөрибез — ышанасызмы, Госман абый? Бар дөнья ямь-яшел!.. Юаның тәме ачы, авызларны яндыра, алай да ашыйбыз. Гөлҗимеш куаклары да шау чәчәктә утыра, ап-алсу, имеш! Боларының исе шундый тәмле, рәхәт!.. Тик бергә йөргән иптәшем кем иде соң әле минем? Әллә кем шунда...

Ханым, капыл телен тешләп, пешкән чия төсендәге дымсу иреннәрен бөрештергәндәй итте, хәйләкәр... Юк, төшендә бер дә «әллә кем» белән түгел, Баку тарафдарларыннан туктаусыз хатлар җибәреп, өзлексез бимазалап торган әзербәйҗан егете Җәвад белән сәйранда күңел ачып йөргән иде лә ул... Хәер, яшерсә дә үз ирегендә ләбаса!

— Минемчә, безнең бүген Бөгелмәгә барасы юлларыбыз да уңардыр, дөрес бит?

— Әлбәттә, Рива... Кеше шундый төшләр күрсен дә, юллар уңмасын, ди!..

## 23

Завод директоры Марк Львович Левин, Мәскәүдә житәкче кадрларның квалификациясен күтәрү курсларында чагында ара-тирә шалтыраткалап, мондагы хәлләр белән хәбәрдар булып торган иде. Эшләрнең ярыйсы гына шома баруын ишеткәч, әлбәттә, аның күңеле күтәрелеп китә иде. Шул сәбәпле, бик әйбәт җан тынычлыгы белән гыйлем һәм гыйбрәт җыеп ятты ул анда.

Ләкин, монда кайтып, хәлләр белән төптәнрәк танышкач, кәефе шактый кырыла төште.

Аның күңелен борчуга салган кеше баш инженер Мороз иде: ул курсларда чагында бу пошмас җан, әллә үзе теләп, әллә абайламыйча, идарә итүдә төп тезгенне партком секретаре Вероника Борисовна Савченко кулына тапшырган кебек тоелды Левинга. Ә хәзерге партком секретарена ирек кенә бир. Ирләргә тартымрак эре сөякле, салмаграк кыланышлы, кирәк чагында мөлаем һәм йомшак та, усал һәм таләпчән дә була белүче бу украин хатыны белән эш итүе, ай-һай, читен!..

Парткомда эш башында Вавилов утырган чагында күп тыныч иде. Ул юк-барга тыкшынмый, завод директорының сүзеннән чыкмый, һәр вакыт килешеп эшләргә тырыша иде. Парткомда тәрәге әйбәт иде Левинның. Әмма директорга бик тә уңай һәм кулай булган бу кеше коммунистларның күбесенә ярамаган, аны яратмаганнар икән: былтыр отчет-сайлау җыелышында: «Синең кебек пешка гомердә дә ферзь булмачак» дип, дуамал туздырып, тәгәрәттеләр үзен...

Левин, яңа сайланган партком составыннан «баш» билгеләгәндә, күңеленнән бик үк теләмәсә дә, Вероника Борисовна Савченко кандидатурасын хуплагандай итте, хәтта иң әүвәл үзе үк кул да күтәрде. «Бәлкем, иплe генә, тыныч кына эшләп китә алырбыз», дип өметләнде ул.

Өмете бөтенләй үк акланмады да түгел. Савченко үзе дә администрация белән уртак тел табып эшләүнең кирәклеген, ниһаять, чын-чынлап төшенде шикелле, дирекциягә каты бәрелүеннән ничектер тыела белеп, иплерәк һәм нечкәрәк төстә эш йөртә башлады. Бүтәнчә юньле-башлы эш кырып буламыни?

Шулай, барысын да бер дирекциягә генә өстерәргә димәгән. Завод директоры ил һәм дәүләт алдында җавап бирсә, партком секретаренын да бер дә бер көнне халык һәм партия каршысында хисап тотасы булыр — җегәреннән һәм сәләтеннән килә икән, авыр йөкне, иңгә-иң терәп, тартышсын, әйдә! Моның өчен рәхмәт сүзеннән бүтәнне ишетмәячәк ул.

Игенне дә өлгермичә урмыйлар.

Производство да шулайрак: проблемаларның пешеп өлгергәннәре бар, җитлекмәгәннәре, ямь-яшелләре бар.

Савченкога нигә инде вакланырга иде, нигә инде идарә аппараты эшенә тыкшынып, премияләр өләшү принцибына да борын тыгарга иде? Тәэминат бүлегендә тузан куптаруы тагы!.. Ә нәтиҗәсе нәрсә? Йөз чыту, ризасызлык. Ә план бүлегендә исә моның киресе: аңарчы да яңа партком секретаре көен көйләп йөргән бүлек мөдире Курочкин гына түгел, бүтәннәре дә Савченко ягына авышып беткәннәр, хәсрәт экономистлар...

Өтергә белән балык каптыралармы? Идарә аппаратында тиктомалга тишек-ярыклар чокуның кемгә хаҗәте бар, аңардан ни мәгънә?

Житмәсә тагы, шундый да киеренке ел якынлашып килгән бер чакны... Вавилов, әлбәттә, мондый адым ясарга һич кыюлык итмәс иде. Әллә бу елгыр хатынның янә берәр төрле «мөгез» чыгарырга исәп тотып йөрүе микән? Үзе әлегә ләм-мим, каһәр!.. Левин, Мәскәүгә китмәгән булса, тегеңәргә алай ук зурдан кубарга юл куймас иде, билгеле. Ә баш инженер Мороз үзенең хуҗа урындыгында утырып калганлыгын сиздереп, һич югы, дөньяда барлыгын төшендереп, тамак та кыргалый белмәгән, пешмәгән җан...

Ләкин күңелендә айкалган уй-хисләрне партком секретарена житкерергә җөрьәт итмәсә дә, Морозга мөнәсәбәттә үзенең үпкәсен сиздереп, аңа ера-тирә төрттереп алгалаудан тартынмады.

* * *

Бүген Левин баш инженерга шактый ук каты бәрелде. Бер уйлаганда, алай сүзгә үк килердәй житди мәсьәләне хәл итмиләр дә иде, югыйсә...

Мороз директор кабинетына гадәтенчә салмак кына килеп керде дә йомшак кәнәфигә тезгә-тез чәнчеп утыргач, кулындагы галәмәт калын папканы өстәлгә куеп:

— Әхмеровлар хезмәте. Китап чыгармакчылар... Күз салсагыз иде, Марк Львович,— диде.

— Китап?! — Левин, аптыраганрак кыяфәттә папканы чишеп, аның титул битенә күз төшерде һәм эре хәрефләр белән басылган сүзләрне укый башлады: — «Барий һәм сульфит тозлары производствосында анализ методлары»... «Кхем, кара син!» «Төзүчеләре техник фәннәр кандидаты Г. Әхмеров, инженер-тикшеренүче Р. Смелькина һәм М. Галләмова...» Менә сиңа хикмәт, үз белдекләкләре белән, ә!..

— Әйе, үз инициативалары...

Марк Львовичның капыл исенә төште. Бер мәлне, әле ел башында ук, Госман Әхмеров аңа: «Үзәк лабораториягә көн саен диярлек Советлар Союзының төрле җиреннән хатлар килеп тора, һәркайсы бездәге анализлар методикасы белән кызыксына, җавап җибәрә-җибәрә йөдәп беттек инде. Һич югы, берәвебез көн дә шуның белән шөгыльләнә,— дип зар белдергән иде. Зар түгеп кенә калмады, үзенең уйнияте белән дә уртаклашты: — Барын бергә җыеп, китап итеп чыгармыйча котылып булмастыр. Безнен эше лабораторияләрне әйтмим дә, фәнни институтларда да ихтыяҗ зур андый китапка...»

Әхмеровка заводның үзәк лабораториясендә мондый хезмәт белән шөгыльләнеп ятарга рөхсәт бирелдеме-юкмы, бу хәтлесен Левин хәтеренә китерә алмады.

— Басылып чыккан тәкъдирдә, кулга тотардай китап буласы икән. Күр, чытырдатып, җиренә житкереп, завод исемен дә куйганнар: Кызыл Байрак Орденлы... Кай арада өлгерткәннәр диген!..

— Алар өчәү бит. Язып утырганнар, аннары җәй-көзләрен... Кичләрен дә калып эшләштергәләгәннәр бугай...

— Соң... бездән ни?

— Дөньяга чыгаруны юллыйсыдыр. Әхмеров үзе Акбалык типографиясендә белешкән дә икән: булдыра да алмыйлар, теләмиләр дә, ди: ярардай шрифтлары юк, имеш... Соң, ни инде, Казандагы китап нәшрияты, яисә Татполиграф белән бәйләнешкә керергә кирәктер. Заказной итептер, билгеле... Без китап чыгарган кешеләрмени?

— Анысы алай да, Иван Семеныч...

Левин, чәнти бармак очы белән генә мыегын кашыштырып алгач, ияген учлады. Әле кичә генә Госман Әхмеров, менә монда керен, Бөгелмәгә ясаган сәфәрләреннән бик күңелле һәм уңышлы булуы турында бәйнә-бәйнә сөйләп утырган иде. Аның күтәренке рухы Левинга

ла йогып, директор үзәк лабораториянең берәр хезмәткәрен Пермьдәге бром заводына командировкага җибәрергә дә күнгән иде. Ләкин Әхмеров, ни сәбәптәндер, шушы китабы турында авызыннан бер сүз чыгармады. Иң әүвәл баш инженерның фикерен ишетәсе килде микәнни?

— Кайчан кертте ул сезгә? Бүгенме?

— Түгел. Өч атналар бардыр инде. Теге айда...

— Өч атналап! — Левин, күзләрен зур ачып, Морозга төбәлде. Баш инженерның кыяфәте үтә ваемсыз һәм гамьсез кебек иде. Таш та таш, бу да таш... Кисәк Левин күкрәге түрендә саруы кайный башлавын тойды. Бу яман нәрсәне басарга теләгәндәй, урыныннан торып, өстәл тирәли йөренеп алды.— Соң ул чагында мин Мәскәүдә идем ич. Берәр шалтыратканда әйткән булсагыз, үзем йөри башлаган булыр идем. «Химия» нәшриятында белешеп чыгар идем, бәлки, юньләбрәк сөйләшсән, кульязманы алырлар да иде. Эх, Иван Семеныч!

— Онытылган. Эш бит, эш... Әле менә, авыртмас башка тимер тарак дигәндәй, үзебездә табигатьне саклау җәмгыятенә җитәкче итеп тә куйдылар тагы.

— Белеп торам: харап та җимертерсез инде анда да!..— диде Левин көлеп. Бу мизгелдә Госман Әхмеровлар хезмәтен яклаудан битәр, каршысында утырган таш йөзле адәмне ничектер авырттырырлык итеп чемету теләге уянган иде Левинда... Тыела алмады — кадалды: — Китапның титул битендә сезнең үз исемегез дә булсамы? О, ул чагында? Язылмас борын ук әллә кемнәрне кузгатыр идегез. Мәскәүдә таныш-белеш аз түгел бит сезнең, Главканың үзендә дә...

— Зинһар, шәхескә кагылмыйчарак, Марк Львович!

— Туры әйткән — туганына ярамаган, диме? Ярар, кагылмыйм... Алайса болай: бүген-иртәгә үк «Химия» нәшриятына һәйбәтләп хат язасыз. Кучермәсен, бәлкем, Главкага да җибәрерсез. Үзегезнең кулдан килми икән, ПТОда аны гына язардай кеше бетмәгән. Имзаны үзем дә салырмын... Э-э, юк, сезнең фикер барыбер кирәгер, төпле, объектив сүзегез... Үзләренә премия биргәндә сезнең фикер нигез булыр.

— Премия?! Соң алар завод лабораториясендә, аш арасында бит...

— Әлерәк кенә үзегез үк: «Кичләрен дә калып эшләгәннәр»,— дидегез ләбаса... Ах, Иван Семеныч, Иван Семеныч! Ярар, эш арасында булган, ди... Ә китапның кирәклеге? Авторларның даны янсә завод маркасы өчен гонәменi?.. Бик белэсегез килсә, Иван Семеныч, шушындый хезмәткә берәр фәнни институтта тотынсалар, әллә ничә кеше әллә ничә ай буена, бәлкем, ел буе, хезмәт хакы алып утырыр иде. Премиясен дә тамызмыйча калмаслар иде... Ә болар бит бер тиен дә сорамыйча!.. Бөтенләй бушлай!.. Аз гына оят та кирәктер лә безгә!

— Ярар, премия икән — премия...

Иңбашлары салпыланып төшкән олы гәүдә атлаганда паркет идән, авыртудан ыңгырашкандай, шыгыр-шагыр итеп торды.

Мороз чыгып киткәч тә әле, Левин карашын тиз генә ишектән аерып ала алмады... Артык картаеп киттеме бу? Әллә элек тә шулай идеме? Бәлкем, Левин үзе алга таба азмы-күпме адым ясагандыр да, Мороз бер урындарак таптанып калгандыр?

Әйе, карар тескә чибәр абзый, бик тә солидный абзый, хәтта акыллы кебек үзе. Әмма...

Мәскәүдә курсларда укыткан бер зур белгеч, дәрәҗәле лектор, ничектер сүз арасыннан сүз чыгарып, аларга: «Беришe җирләрдә. чуртак график ничек тә өстерәп чыгарыр әле», дип черек принципка таянып эш кыйратучы хәсрәт җитәкчеләр дә аз очрамый бездә», дип ычкындырган иде. Шул сүз исенә төшеп, Левин үзе өчен зур ачыш

ясагандай булды: «Ә мисалы әллә кайда түгел, тап үзебездә икән ич: Мороз — нәкъ менә шул тип, умыртка сөяге йомшарган бер бәнда шунда. Куәләтә каршылык та кылмый. Чатнап торган консерватор да түгел... Әмма нярдән төшәсе килми, кылычы күгәргәнлеген белми. Олы яуда мондыйлар куркынычрак та түгел микән әле? Ни жак, ни кан...

Ничә ел Мороз белән кулга-кул тотынышып эшләү дәверендә беренче тапкыр: «Алда тагы ни җимертербез икән без? Ичмаса, пенсиягә китәргә җыенса икән, аю!.. Югыйсә, телевизор карый-карый, рәхәтләнеп бармак суыра-суыра ятасы гына бит инде аңа үз өендә» дип, ачыну һәм кызгану аша тырән көрсенеп куйды Левин.

## 24

Сагынып-зарыгып көткән кешеләре — Госманның үз әнисе Зөләйхабану апа — кыш башының салкын һәм матур бер кичендә, ниһаять, боларның кочагына кайтып сыенды.

Карчык тагы да кечерәебрәк калган шикелле. Ул каударланып әле оныклары Ләйлә белән Рөстәмне иркәләргә үрелде, әле улы Госман белән килене Зөбәрҗәткә сыенырга итенде. Куанычлы кабаланудан, ахрысы, кавышканда әйтәсе сүзләрен дә юньләп әйтә алмады. Бер мәл шулай азапланганнан соң, сулышы ачылып, киңәеп китте бугай, сүзләре, бер мәрҗәнгә тезелгәндәй, ягымлы яңгырады:

— И бәбекәйләрем. Мәгез әле, мә — җылы учларыгызга тотырыгыз! Бусы — тупсадан атлап кергәчтен, аяк өсли генә бирә торганы. Күчтәнәчнең зуррагы тегендә, чомаданда әле... Бераз хәл алыйм да бирермен, яме, балакайларым!

— Рәхмәт, әбкәй! Без сине сагынып беттек!.. — ди-ди, Ләйлә белән Рөстәм әбекәйләренә янә сарылдылар.

Аннары Зөләйхабану апа, башындагы йомшак мамык шәлен төзәткәләп һәм плюш бишмәтенең төймәләрен ычкындырып, урындыкка утырды да пышын-пышын дога укып алды.

Җәелгән иреннәре арасыннан алтын нурлар чәчеп торган Госман, әнисе битен сыпыруга, үпкәчел тонда әйтә куйды:

— Нигә инде болай, әни? Юлга чыгуыгызны әйтеп телеграмма суккан булсагыз, ичмаса, Можгадан җиңел машинада, йончымыйча, рәхәтләнеп кайтыр идегез. Каршы алырга, менә балаларны да утыртып, үзем барган булыр идем.

— И улым,— диде Зөләйхабану апа,— кул астында машинаң булса иде. Аннары, эштәге кеше бит син. Мәшәкатьләмик инде үзен, дидем. Автобуслар йөреп тора... Юллары да алай тыгын түгел икән. Юк, юк, Зәфәр белән без бер дә җәбеп калмадык.

Зөләйхабану апаны кызы Нурҗиһанның өлкән малае озата килгән икән. Зәфәр — какча йөзенең яртысын диярлек зур күзлек каплаган, юка гәүдәле буйчан гына егет. Үзе чытырдап торган кыюлардан да түгел. Монда килеп кергәч тә, ул барысы белән дә тыйнак кына күрешеп чыккан иде, менә хәзер, ни кылырга белмичә, олы гына төенчек һәм чемоданнар арасында, бу шау-шулы очрашу галәмәтенең тизрәк бетүен көтеп, мыштым гына басып тора иде.

— Автобуста әбекәйне мин иң алдагы урынга утырттым,— диде Зәфәр, саран гына елмаеп.

— Ни көттек бит, ни көттек!.. Кая, әнкәй, өс-башынны үзем салдырыйм! — ди-ди, Зөбәрҗәт карчык тирәсендә бөтерелергә кереште.— Менә аякларыңа йомшак башмак киеп ал... Түрдән үт, әнкәй, син дә, Зәфәр — төкле аякларыгыз белән! Хәзер чәй куеп җибәрәм, табын да әзерлим. Инде сине сагынуларыбыз! Рөстәм белән Ләйлә, кайчан кайтыр инде әбекәебез, дип йөдәтеп бетерделәр... Октябрь

бәйрәме үткәнгә дә биш былтыр бит. Әллә бер-бер хәл булдымы икән дип, шөбһә дә кергән иде. Ни хат, ни хәбәр...

— Соң, булды инде, килен, булды, гаеп бездәндер...— Зөләйхабану апа, авыз эченнән генә бисмилласын укый-укый, олы бүлмәгә узды да диван-караватының почмагына килеп сыенгач, янә бер тапкыр дога кылды. Аннары, үзе югында боларда нинди рәк үзгәрешләр булды икән дигәнрәк сынаулы бер караш белән, бай һәм матур җиһазлы бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Канәгать төс белән тамак кыргалады.— Соң, килен, юлга кузгалабыз дип торганда гына, уйламаганда салкын тидереп, сырхаулап киттем. Картайгачтын саулыкка туеп булмый икән шул. Ул да түгел, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, олы киявебез, менә Зөфәрнең әтисе хәвефкә юлыкты тагы...

— Нинди хәвеф? Ни булды Шәрәф җизнигә? — дип сорады Госман.

— Җиде кат җир астында эшли бит алар. Күмер чапканда, улым, беләсең инде, килеп чыккалый ул хәтәр хәлләр... Үлем-җитем булмады булуын, ходага шөкер. Шәрәф җизнәңне балтыр сөяге чатнаган килеш менгерделәр. Аннары туп-туры больниска. Тагы икәвесен шулай...

— Алай куркыныч түгел үзе,— диде Зөфәр, боларны тынычландырырга ашыгып.— Шушы араларда аягыннан гипсын да алырлардыр инде.

— Ием, алла кушса, үз аяклары белән, берни булмаган шикелле, иплә генә йөреп тә китәр, бәлкем... Гөнаһлы бәндәләрдән түгел икән, Нурҗиһанның да, сабыйларның да бәхетләре бар икән. Алдагы көннәрендә дә рәхим-шәфкать бирсен инде үзләренә... Тик ни, җир астына бүтән төшмәстер, өстә генә эшләштереп йөрердер, инде җаныбыз тынычланып калырдыр, шәт, дисәк, «Юк, барыбер төшәм, минем чабасы күмерләрем чабылып бетмәгән әле», дип ята бит...

— Тизрәк сихәтләнеп, аягына басса күрсен инде... Әнә бит нинди хәлләр булган, тиккә генә күңелебез шомланмаган икән,— диде Зөбәрҗәт, кулларын күкрәгенә кушырган хәлдә.

Карчыкка инде әллә кайчаннан ук балалар ягында, аерым бүлмәдә урын-җир хәстәрләп куелган иде. Аңа, юл килгәннән соң, шунда бер мәл хәл җыеп ятып алырга тәкъдим иттеләр. Ләкин Зөләйхабану апа монысына әллә ни кабынып китмәде.

— Бик рәхмәт инде, килен, сиңа да, улым, сиңа да... Тик юл газабы — гүр газабы дисәләр дә, кырын ятарга исәп итмим әле. Хәлем әйбәт, шөкер. Менә бит күз алмаларым — янымда. Алар икесе дә нәни чакларында минем куллардан төшмәде лә. Ипидер, сагындым үзләрен! Аз гына булашыйм инде үзләре белән, берүк,— дип үтенде.

Әбине үз иркендә, дөресе, балалар хакимлегендә калдырдылар.

* * *

Иртән торуларына карчык өйдә юк иде. Кухняда ялгызы гына чәй эчеп алган. Моннан алты-җиде ел элек авылдан улы янына күченеп килгәч тә, газ плитасы белән эш итүнең бар хикмәтләрен өйрәнгән иде инде ул. Җитмәсә, песи шикелле тавышсыз-өнсез генә йөри дә белә иде. Әлбәттә, берәр эше булса, таң белән торып, җиң сызганып тотынып иде, ә монда ни эш, ни мәшәкать аңа?!

Аптырамадылар: карчыкның бу хикмәтен күптән беләләр иде.

Зөфәр исә диван-караватта озынаеп яткан җиреннән ялт кына калкынды да, спорт трикосын киеп куйгач, Госманга ишегалдында «селкенеп керергә» тәкъдим ясады. Абыйсы көлемсерәп: «Эшкә ашыгам»,— диде. Ул инде тышта «селкенеп керүләр»не күптән оныткан иде...

Госман, эшкә барырга чыккач, әнисен челтәрле җил капка төбендә

очратты. Улының йомшак кына эндәшүенә дә сискәнеп киткәндәй күренде... Әнисе инде бер-ике урамны әйләнеп кайтырга да өлгергән икән.

— Хафаланма, улым, саулыгым да шөкер, кәефем дә әйбәт,— диде ул, ягымлы елмаеп. Аннары, әйләнә-тирәсенә, баш өсләренә күз йөртеп чыккач, сокланган төстәрәк әйтә куйды: — Инде сездә дә һавалар шактый ук сафланган шикелле, иеме?

— Әйе, әни. Тик җил завод ягыннан искән чакларда алай да бераз сиздерә әле. Әмма озакламыйча һаваны тагы да сафландырачакбыз, шуңа таба бара эшләр.

— Ә Мортта?!. Һай, үз авылыбызның сихәтле һавасы! — Карчык мамык шәленең очын сыпыргалап алды да башын күтәреп, улы Госманга үтенгән бер төс белән төбәлде.— Улым, син, зинһар, ачуланма инде: мин бүген авылыбызга кайтып китәргә исәп иттем әле. Бүген үк! Зөфәр белән икәү... Син машина дигән идең бит әле. Хәер, ярый, мәшәкатьләнмә, автобуслар бар чагында... Тукта, ул хәтле үк кашыңны җимермәсәнче, улым!

— Машина булыр, табармын, ләкин хикмәт андамыни? Ничек инде? Без сине шул тикле зарыгып көттек тә инде хәзер, ай күрде, кояш алды, дигәндәй... Балалар да монда...

— Иплэп кенә аңлатырмын үзләренә. Пошынма. Әле бергә-бергә яшисе бит.

— Анысы алай да...

— Сезгә хәбәр итмәсәк тә, мин авылга кайчан кайтасымны ачык әйтеп, Нурдидә түтиеңә хат язып салдырган иде. Ике күзен дүрт итеп көтә торгандыр.

Госман көзге пальтосының якасын күтәреп куйды.

— Ә син, улым,— диде Зөләйхабану апа, кинәт моңсу пышылдауга күчеп.— Әтиеңнең кайчан вафат булганлыгын хәтерлисеңме?

— Хәтерләмичә... Кырык дүртенче елның ноябрь азагында...

— Әйе, улым. Герман җиренә барып кергәч... Төп-төгәл чирек гасыр әүвәл... Авылга кайткач, дим, туган-тумачаны, карт-корыны дәшеп корьән чыгартмыйча булмас, дим. Анда үзебезнең өй юк инде югын... Нурдидә апаларында үткәрербез инде. Үзе ул ризамын, бик ризамын дип хәбәр иткән иде миңа. Турысын әйткәндә, шуңа күрә ашыгам да, улым...

Госман, аптыраган хәлдә, җилкәсен сикертте. Мөселман кешесе якты дөньяны куйгач, аның «өчесен», «җидесен», «кырыгын», ә ел тәүлеге тулуга «елын» уздыруларны ул бик әйбәт белә иде. Авылда аны ишетеп тә, күреп тә үсте. Ләкин монда бит «чирек гасыры»... Анысын да үткәрәләр микәнни? Ул, сигарет алмакчы булып, пальто кесәсенә тыгылды: әмма кулын шундук кире чыгарды: әнисе алдында тәмәке тартырга ул әле һаман да тартына иде.

— Нурдидә түтиләрнең өе иркенлеккә иркен инде. Килене Миннур да — бик уңган хатын. Әйе, акча ягын үзем карармын, чыгымнарны үзем күтәрермен, әни.

— И улым, менә анысын карамасаң да ярый: үземнең дә маям бәләкәй түгел минем. Өстәвенә, тегендә Нурҗиһан апаң белән Гөлфия сеңелкәшең дә мул гына тоттырды. Шахтер кияүләрем үзләре тагы...— Карчык, улының шулай ансат кына күнүенә бик тә канәгать булып, җанлана төште. Аның үтенече алда әйткәне белән генә бетмәгән икән әле: — Инде, улым, алай риза булгачтын, бусына да күнәрсездер, бәлкем: монда да карчык-корчыкны җыярга ниятем бар ие минем. Авылдан әйләнеп кайткач, дим. Ипле генә, үзебез белгән корьән аятьләрен укып кына бер утырыр идек, ичмасам. Зөбәрҗәт килен дә, шәт, каршы килмәстер...— Госманның кыяфәте капыл төкселәнеп китүен Зөләйхабану апа шундук абайлап алды һәм, улына шөбһәле карашын

төбәгән килеш, сүрәнрәк тавыш белән элеге үтенеченең бер дә тикмәгә түгел икәнлеген аңлатырга кирәк тапты.— Соң ни... шушындагы завод җире дә әтиеңә чит-ят булмаган ич. Бер генә килеп аяк басканмыни ул монда? Үзең дә, улым, бик беләсең: яшүсмер чагында, синең дә әле катмаган вакытта килеп эшләгән. Гомеренең чәчәктәй вакытларын суырып алган лабаса синең бу заводың...

Госман җавап кайтарырга ашыкмады. Әйе, әтисе хакында белә иде ул: заманасында ярым-йорты крестьян, ярым-йорты «пролетариат» булган шул аның әтисе... Ләкин бу мизгелдә Госман ерак Балтика буенда билгесез бер кабердә ятып калган әтисе турында түгел, бәлки, янәшә басып торган, җанына иң кадерле әнкәсе турында уйлый иде... Нилектән бу кадәр диндарлыкка сабышты соң әле ул? Элек, эшкә һәм нужага муеннан батып, газап кичергән көннәрендә намазны бар дип тә белмәде шикелле, тик ара-тирә ураза тотар һәм дини бәйрәмнәрне хәленнән килгәнчә бәйрәм иткәләр иде. Туган туфрагыннан аерылып, читкә китүләре сәбәп булдымы әллә!? Тегендә, Кизелдә, әнисенең, шулай ук туган якларыннан кендек җепләрен өзгән үтә диндар корткалар белән дуслашып, әвеш-түеш кылануларын ишеткән дә, сизгән дә иде Госман...

— Улым, ник тынып калдың әле? Берәр нидән шигәясеңме, курkасыңмы әллә?

— Шикләнмим дә, курыкмыйм да, әни. Бары да син теләгәнчә булыр,— диде Госман, тирән сулыш алып, һәм кулын җил капкага салды.— Әйдәле, керик әле: Зөбәрҗәтне дә күндермичә булмас бу хәлләргә...

Зөбәрҗәт, үз өендә карчык-корчыкны җыюга куанып ризалашса да, кайнанасының менә шушылай капыл гына авылга китеп баруына гөптән кубып, каршы күтәрелде. Ләкин үпкәсе бетеп, җаны беркадәр тынычлана төшкәч, ничектер, карчыкның күз карашындагы тирән нәүмизлек һәм сагышны күреп, күнмичә булдыра алмады. Зөфәр исә, кырт кисеп, авылга кайтудан баш тартты.

— Җәй булса иде. Мондагы заводны әйбәтләбрәк күрәсем килә,— диде ул.

Төш тирәсендә тыныч һәм аулак тыкрыкта утырган шәп коттедж янына, Зөләйхабану апаны авылга алып китәр өчен, җиңел машина килеп туктады.

## 25

— Әтисе дим... сиңе... Иван Николаич сорый бугай.

Госман өстәле янынан бик иренеп кенә купты да телефонга килде. Дәрестән дә, Тиунов карт шалтырата иде. Гөлдер-гөлдер хәл-әхвәл белешкәләде дә Госманны балыкка барырга чакырды.

— Соң, Иван Николаич, минем бер нием дә юк бит.

— Хафаланма, корал миннән. Син инде, туганкай, җылырак киен дә кабарга тегесен-бусын алырга онытма. Кемнәр беләнме? Машинага утыргач күрерсең. Иртән сәгать алтыда капкаң төбендә булырбыз.

Госман, телефон трубкасын куйгач, ике куллап бөеренә таянды һәм башын кыңгыр салып хатынына карады. Аның авызы колагына җиткән иде.

— Урыс әйтмешли: «И хочется, и колется...» Тун каян табасы икән? Кышкы пальто өстеннән кияргә зуррак плащ-мазар булса иде, ичмаса... Тукта, күрше Миңнехан абыйның бар бугай... Ә син, әнисе, каршы түгелме соң? Балыкка барсам, дим?

— Бар, бара гына күр! Монда көне-төне, фән дип, шайтан дип, бөрәзлексез баш катырып, сөрсенеп ятканчы.

— Иртәгә лабораториягә Зөлфә белән Рива килергә тиеш, бераз утырып алырга сүз куешкан идек. Ашыгыч карыйсы нәрсәләр бар

иде. Иван Николаичны да әйтер идем: көндезен күрешкән идек бит, югыйсә. Тегеләрне кәкре каенга терәткәндәй килеп чыга лабаса.

— Терәтсәң сон. Үзем шалтыратып аңлатырмын. Ял көне бит! Ичмаса, бер арып-талып кайтсаң, йокың әйбәтләнеп китәр иде. Балык шулпасы да сагындырды. Хәер, анысына өметләнәсе дә юк.

— Ә бәлкем, менә мондый-мондыйларны эләктереп куяр абзаң, ә?..

Ирле-хатынлы шаркылдашып көлеп җибәрделәр.

— Һи, кысыр хәсрәт, сиңа тагы! Кесәңә акча тыгып барсаң гына инде... Тукта, кабарыңа ни алырсың икән?

Госман вакыт соң дип тормады, пижамы өстеннән пальто гына элде дә күршесенә чыгып китте, ә Зөбәрҗәте кибеткә «очты».

Иртән ул торганда сәгать дүрт тә тулмаган иде әле.

Кухняда чаж-чож бәрәңге белән колбаса кыздырып, тамагын туйдырды, чәй эчте. Моның соңында, күршесе Миңнехан биргән «котыпка барырдай» жылы нәрсәләрне киеп алды.

Һава шактый ук салкын иде. Кала тирән йокыда әле. Туйма ягында завод цехлары турысында төтен һәм парга сеңгән сыек кына яктылык балкышы беленә. Чулман-дәрья тарафында исә дөм-караңгы. Күк гөмбәзен юка болыт каплаган, ахры: йолдызлар сирәк күренә һәм тоныкжемелдииде. Анда, баш өстендәге төпсез караңгылыкта, самолет гөрелтесе ишетелде, һәм менә инде ул, кызыллы-яшелле утлары белән генә күренеп, узып та китте.

Ниһаять, янәшә урамда нур көлтәсе сирпелеп, йорт түбәләрендә, алма һәм чия агачларының шәрә ябалдашларында биеп алгалагач, болай таба борылды да кинәт бөтен тыкрыкны яктыртып җибәрде.

Газик, аның янына килеп җитүгә, шып тукталды.

Госман, капыл ачылып киткән арткы ишеккә карап үтә көр аваз белән сәлам биргәч, беркадәр һаваланган сыман:

— Ә мин сезне әллә кайчаннан бирле көтәм инде монда,— дип куйды.

— Молодец! Чын балыкчы шундый түземсез булырга тиеш! — дип кеткелдәде карлыкканрак бераү.— Без сине хатының кочагыннан йолкып ала алмабыз дип курыккан идек әле.

Һа, Тиунов картның юлдашлары бер дә әллә кемнәр түгел, завод түрәләре икән ләбаса: шофер Сәлим янында алда Левин җәелеп утырган, ә монда, арттагы утыргычта, Тиуновны янга кысрыклап, Мороз җәелгән. Әмма монысына, олы гәүдәсен тарта төшеп, җыйнакланырга туры килде.

— Әйдә, хәерле сәгатьтә!..

Киченнән бераз кар явып алган иде. Биек үр сырты буйлап сузылган асфальт юлга нефтьчеләрнең төнге вахталары сырлы эзләр салып үтәргә дә өлгергән. Фаралардан төшкән нур көлтәсе караңгылык пәрдәсен сызып бара бирә. Ян якларда тимер челтәрле ЛЭП терәкләре ялтырап куйгалый, кара-кучкыл телеграф баганалары артка таба чабыша...

Алда үр битенә салынган Сәйтәк авылы һәм аннардан шактый арырак нефтьчеләрнең промысел базасы, термо-химик установкалары электр утларында коенып утыра. Җинел машина выжылдап чаба бирә, утлар әкрен генә якыная бара. Ул да түгел, уң тарафта чиксез караңгылыкта анда-санда сибелгән газ факеллары калкынды...

* * *

Левин кая гына барса да мәзәккә баеп кайта. Шома гына сөйли дә белә. Бу юлы да курслардан ишетеп кайткан мәзәкләренең берничәсен сөйләп, көлдереп алды. Аннары бераз тын гына утыргач, юантык муенын янә артка таба кыйшайта төште. Ләкин монысында ул

болар һич уйламаган нәрсәне әйтеп, Госманга ару гына сукты-рып алды:

— Әсин, Госман Габдулыч, безнең «комиссар»ны сырт йоны унае-на әйбәт сыйпый белгәнсең, ахрысы: синең самоотводны ничек яклап чыкты теге, ә!.. Тәки парткомнан төшеп калдың бит, әй! Оста, галәмәт оста!..

Әле ике-өч көн элек кенә заводта партия оешмасының отчет-сай-лау конференциясе булып үткән иде. Левинның шул унай белән, сон-гарып булса да, кылчык чәнчеп азаплануы иде. «Бавырына таш булып кунган, ахрысы. Ник яратмыйлар болай заводка ходай үзе бүләк иткән ул алтын хатынны?» дип, әрнү аша уйлап алды Госман, әмма теленә юньле җавап килеп өлгермәде:

— Комиссармы, түгелме, үз акылындагы хатын,— дип кенә мы-гырданды.

— Комиссарның да комиссары! — диде Мороз, директор сүзенә куәт биреп.— Өстенә күн тужурка кидерт тә биленә каеш будыртып, наган тактырт... аннан инде строй башына! Җир йотсын, «Оптимисти-ческая трагедия»дәге теге чая хатыннан артык булмаса, кимен куймастыр!

— Дөрестән дә, беришә кәҗә тәкәләренең койрык асларына кы-чытканны әйбәт кыстыра белә ул безнең Вероника Борисовна! — диде Тиунов карт, ачы кеткелдәп. Аның кем бакчасына таш ыргытуын юрап та торасы юк иде: Мороз утырган җирендә авыр кымшангалап куйды, Левин исә йөнтәс бүрек кигән башын тун якасы эченә сендерде. Ләкин аларга үткен, үтергеч җавап угын очыртырга насыйп булмаган икән, хәйләкәр карт сүзне капыл үз уңаена борып җибәрде: — Балык, балык... әләгергә тиеш лә инде ул безгә бүген! Әнә анда Чулманда су да ишәя төшкән, имеш...

— Белмим, рәт чыгар микән, Иван Николаевич? — дип, шик бел-дерде Госман, сүз сөрешенең икенче төс алуына сөенеп.— Минем бе-лән берме-икеме тапкыр барып карадыгыз бит инде. Ә ни кырдык? Әллә ничә йөз кармаклы подпускага көч-хәл белән генә ухалык чүпли алдык, анда да күбрәге шыртлака!

Газик кинәт кенә уңга таба борылып, асфальт юлдан читкә кае-рылды.

Сикәлтәле басу юлыннан ава-түнә бара торгач, ниһаять, үзәнлеккә төштеләр. Юл монда тигезрәк һәм ничектер йомшаграк кебек иде. Тиунов карт, алгы утыргычка таба авыша төшеп, күз карашын фа-ралар яктысына төбәгән хәлдә, Сәлимгә юлны өйрәтә барды.

— Булды, килеп җиттек! — дип гүелдәп алды ул, ниһаять, турая төшеп.— Егет кеше икәнсең, Сәлим дус, рәхмәт! Машинаңны әнә каршыдагы тал куагы төбенә арты белән куярсың...

Апын-тәпен җиргә сибелештеләр. Гәүдәләрен яздылар. Бер-икесе тәмәке кабызды. Көнчыгыш тарафта күк чите аз гына яктыра төшсә дә, әле һаман күз бәйләнерлек иде. Якын-тирәдә кара-куркыл чүмәлә-ләр тезелешкән — тал куаклары. Түбәндәрәк, яр астында, аксыл-сор-гылтланып киң генә тасма җәелеп ята...

— Ни бу, күлме?

— Әүвәле күл иде. Аргы башы Чулманга тоташкан хәзер: нефть-челәргә дамба өйдерүче земснаряд шуннан ертып кергән иде,— дип аңлатты Тиунов.— Тап вакытына килеп җиттек. Хәзер тишкәли баш-ларбыз, аннары ипләп кенә керешербез...

Беравыктан ярларын купшы таллар бизәгән борынгы күлне дан-дон бөз ваткан тавышлар тирән йокысыннан уятты...

*Ахыры бар*

## Зөлфәт

### Көзнең авырлыгы—алмада

Тупырдап алма коела
Кош очып үткән саен:
Көзнең бөтен авырлыгы
Алмададыр, мөгаен.

Алъяпкычка алма җыеп
Чыгып килешең иде,
Бакчагызның бер алмасын
Татып карыйсым килде.

Алдым, каптым, ал икән шул,
Эче тулы бал икән,
Кабынмастай булсаң гына
Сылуга күз сал икән.

Кабынмассың! — Яшьлеккә мең
Янгын сыенып тора:
Кошлар очып үткәнгә дә
Алма коелып тора.

...Чишмә ярында — икебез,
Чишмә акты да акты,
Күз дә йоммады йолдызлар
Таңнар атканга чаклы.

Таңга табан әкрен генә
Йолдызлар бетте сүнеп,
Хуш исле авыр алманы
Икәү ашадык бүлеп.

Җаннар шундый якты иде,
Бу дөнья җылы иде,
Йөрәкләр көзге алмадай
Тойгыдан тулы иде.

Ни ул сөю? Әйе, дөрес,
Гомернең ямедер ул,
Икәү булып ашаган шул
Алманың тәмедер ул.

Нишләрсең, җирдә яратып,
Сөеп гомер иткәндә,
Коелыр алма калмаса,
Хәтта давыл үткәндә?..

## Каюм

Кара төндә калган халыкларны
Кояш читләп узган чагында
Гел күрмәсә иде, күргәч — авыр,
Бигрәк авыр «сукыр» Каюмга.
Язмый Каюм, язмый —
чыра телә,
Самавырчы малай шикелле.
Чыра түгел —
сүзләр яна, сүзләр! —
Яктыртмакчы алар бу төнне.
Чыра телә Каюм, сөялләре
Канап чыга хәтта, түз генә.
Фанатик шат:
— Төнне таңре биргән,
Һәм шул таңре, сак бул, сукыр мөртәт,
Төкерәчәк синең йөзеңә!
Бөек Мәрҗанинең кәвешләрен
Кадак белән какты идәнгә —
Фанатикка кызык: — Нишләр галим,
Мәтәлмәсме кәвеш кигәндә? —
Мәрҗани дә һәм Каюм да белә
Заманнарның таңга агасын,
Томананы
тузган кәвеш итеп
Тарих идәненә кагасын.
Бишегеннән алып
ләхеткәчә,
Үз күзләре йомык хәлендә,
Насыйридан көлә шул томана:
— Юл яктырта сукыр пәйгамбәр, — дип, —
Җыен хаерчеләр илендә.
Әрнүләрдән арган кайнар башын
Салган чакта кайнар учына,
Кемдер дәшә сыман караңгыдан:
— Күк капусы, галим, ачыла!
Насыйриның авыр карашлары
Балкып китә кинәт:
— О, бөек
Әбугалисина килгән икән,
Бармы, Әбу, сиңа җиңеллек?
— Нихәл, Каюм? Яктыртабыз, димәк?
Еллар кара синең Казанда...
— Авыр миңа, авыр, Әбү-Гали,
Кайчагында язам, язам да
Уйлап куям, нигә кирәк язу,
Ипи кирәк чакта заманга?

Ләкин халкым... Ул барырга тиеш
Җылы язга, якты язларга!
Халкым рухы ачка тилмергәндә,
Аһ, язарга кирәк, язарга...
Ипи җитми, рухи азык җитми...
Икеләтә халык ачыга...
...Караңгыдан ерак җавап килә:
— Күк капусы, галим, ачыла!..
Әллә ниләр күрер иде халык,
Чорлар шундый кара чагында
Кулларыннан алып
яктылыкка
Сөйрәмәсә «сукыр» Каюмнар.
Урам теле түгел —
оран теле
Иҗат иткән халкы алдында
Барысын да күргәнлектән авыр,
Ифрат авыр «сукыр» Каюмга.
Шул яктыга карап,
забойларда
Сукыр калган сабыр Алыптай,
Замананың кара шахтасыннан
Югарыга менгән халыклар.

## Ай һаман дәү

Сезнең баскыч култыксасы...
Акбай, өреп куркытмачы! —
Я, сыйлан да тын гына тор:
Йолдызлы күк нинди якты,
Ай нинди дәү, нинди матур!
Сабыр, Акбай, тик кенә тор...

Ә син, ишек, ачыла бел,
Шыгырдама, тик кенә тор:
Йолдызлы күк нинди якты,
Ай нинди дәү, нинди матур!

Чыкты ишек шакыганга,
Бик ерак бит әле таңга;
Йолдыз сүнәр, кояш балкыр,
Бер гаеп юк: күк йолдызлы,
Ай нинди дәү, нинди матур!

Чыккач башын игән икән,
«Сөям, нишлим?» — дигән икән —
Улмы кыю, минме батыр?
Шыгрым тулы күктә йолдыз,
Ай нинди дәү, нинди матур!

Чыккач башын игән икән,
Иренгә ут тигән икән —
«Янам, янам!» дияр чактыр...
Абау, күзләр — йолдызмыни,
Карашы — ай! — нинди матур...

«Синеке бу язым!» — диде,
Саубуллашып башын иде...
— Онытмамын, сау булып тор,
Ай-йолдызлы сөю көге,
Сөю көге нинди матур.

Гомер кыска, юллар озын,
«Нишлим?» — дигән моңсу кызның
Хатирәсе җанда, хактыр...
Һаман йолдыз яна күктә,
Ай һаман дәү, һаман матур.

Их, син, язмыш, куркытмачы!
Таныш баскыч култыксасы...
Кабат кайттым юллар йөреп,
«Нишлим соң?» — дип, ялгыз торам.
Акбай гына чыкты өреп,
Дәү айны һәм мине күреп...

Таныш баскыч култыксасы...
Акбай, өреп куркытмачы,
Сыен миңа, тын гына тор,
Ник өрмәдең башкаларга?
Һаман йолдыз яна күктә,
Ай һаман дәү, һаман матур...

## Адашкан болыт

— Әни, мине кайдан таптың?
— Басудан, улым, арыш арасыннан...

Авыл капкасына җитәр-җитмәс
Машинадан төштем... Я, ходай! —
Басудагы һәрбер алтын арыш
Түбәсеннән чумган яктыга.
Ул тургайдыр! —
Камыл төпләреннән
Зәңгәр күккә кадәр, мөгаен,
Кыллар зыңлый —
шул кылларга тиеп
Оча
Минем авыл тургае!
Арыш арасында ятам ялгыз,
Басу төпләреннән ургылып
Күккә аша җылы.
Күктә исә
Адашкан да йөри бер болыт.
Ишетәм күк:
каш өстенә учын
Куйган килеш
Ерып арышны,
Килә әни! —
Әллә мине шулай —
Улын шулай эзләп барышы?..

Мин керфек тә какмый әны кетәм,
Табар микән мине, юк микән?
«...кайсы юлда улым... нинди елда...
...тамаклары гына... тук микән?..»
— Мин биредә, әни!
Күк астында!
Җир өстендә, әни, мин һаман!
...Гел онытам күптән киткәнеңне
Без яшәгән якты дөньядан.
Арыш арасыннан гына түгел,
Тын авылдан, шаулы каладан —
Җиде юлның чатларыннан хәтта
Табарсың күк мине яңадан.
...Үткәннәргә китте,
үзе һаман
Миңа карый сыман борылып.

Зәңгәр күзләремнең төбендә үк
Адашкан да йөри бер болыт...

## Офыкларда төн канаты яна

ЦИКЛ

Таныш сагыш камыш тавышында,
Таныш тавыш камыш сагышында,
Дулкын-дулкын булып ага җәйләр,
Бар гомерем — сулар агышында.
Кире кайтмый сулар, кабатланмый.
Сиңа салкын бугай.
Сыен миңа.
Бер карасаң, дөнья — тоташ сугыш,
Бер карасаң — гади уен гына.
Иңнәремә салып кулларыңны
Тынып калдың. Сулар ага, ага...
Сулар акмый —
без китәбез гүя
Күз күрмәгән төбәкләргә таба.
Сүзсез генә сөйлик. Сүз кирәкми.
Газап — сөю каны, ә бит бу кан
Хасил булган тып-тын гөрелтедән
Һәм гөрелдәп торган зур тынлыктан.
Офыкларда төн канаты яна,
Пәйгамбәрләр йоклый тарихларда.
Сүзсез генә сөйлик.
Ага еллар
Сүзсез генә бәргәләнеп ярга.
Мизгел саен тәмамлана җанда
Үткәннәрем,
янә
мизгел саен
Киләчәгем шуннан юлын ала,
Шуңа елыйсыңдыр син, мөгаен...
Елыйсыңдыр,
шушы мизгел аша

Атлап чыгып, килер көннәремә
Китмәсеңне белеп,
каласыңны
Үткәнемдә...
Ятып иңнәремә
Елыйсыңдыр...
Күзләреңнән үбәм.
Бу — хыялдыр, бәлки, әйт, яшермә!
Тик хыялый иреннәрем яна
Йолдыз сыман кайнар күз яшеңнән...
Бер карасаң, дөнья — тоташ сугыш,
Бер карасаң — гади уен гына...
Үткәнемдә сиңа салкын булыр.
Сүзсез генә сөйлик.
Сыен миңа.
Күзләр булып ян да җылыт мине —
Үткәнеңдә калам бер ялгызым.
Бик куркыныч булыр бер үземә.
Гомер нинди кыска!
Нинди озын!..

* * *

Көзге учакларда сәер моңсулык бар,
Бигрәк үзгә икән көзге моңсулыклар!
Китү чоры шул бу — килү чоры түгел,
Китү җыры шул бу — килү җыры түгел.
Китә поезд, китә моңсу гудок биреп,
Китә ерак, якты офыкларга кереп.
Китә кошлар, китә, урман өсләреннән,
Чаялыклар китә дулар хисләреңнән.
Иреннәрдә калды үбү эзе — дөрли!
Яшәгәнмен бик күп, туймаганмын берни.
Күңелләрдә калды зур ачыну — дөрли!
Аһ, чәчкәнмен бик күп, җыймаганмын берни.
Дөрләр чагым булган утлар булып кына,
Сайрар чагым булган талга кунып кына,
Очар чагым булган биек-биекләрдә,
Ыргыласы чорлар алтын киңлекләргә!
Күз күреме җитмәс ярга йөзәр чаклар!
Бәйдә килеш мине көтеп калган чаптар.
Һәммәсе дә киткән...
Кырда учак дөрли,
Сөйләгәнмен бик күп, әйтмәгәнмен берни...
Көзге учак — йөрәк,
аһ, бу моңсулыклар!
Көзге учакларда сәер моңсулык бар...

* * *

— Аңлагызчы мине! —
Ялваруммы,
Ачынумы икән бу сүздә?..
Аңлагызчы, яңгыр чүлгә кирәк,
Кирәк түгел яңгыр диңгезгә!

— Аңлагызчы мине! —
Кеше тора,
Бер ялгызы тора ни көтеп? —
Җирдә аның меңләп өмете бар
Һәм юк аның һичбер өмете.

Кулы белән чигәләрен кыскан,
Соң түгел бит, коткар син аны:
Җирдә аның меңләп иманы бар
Һәм юк аның һичбер иманы.

Сандугачы киткән тирәк кебек
Моңсыз калган аның йөрәге:
Җирдә аның меңләп терәге бар
Һәм юк аның һичбер терәге!

— Аңлагызчы мине! —
Туганың бит,
Кан туганың — кеше эндәшә,
Имгәнерлек егылмый бит кеше
Әгәр артык биек менмәсә!

Биеклекләр өчен туган хыял
Хәлсезләнеп башын игәндә,
Каршы тауда уйный якты буран...
Тын кысыла ләкин түбәндә!

Җан әрнүе белән дәшә икән —
Егылган ул, димәк, биектән.
— Аңлагызчы мине!
Аңлагызчы мине!
Аңлагызчы миңе —
Мин көтәм...

Бихисап бит безнең сүзләребез,
Нигә саран соң без бер сүзгә?
Аңлагызчы: яңгыр чүлгә кирәк,
Кирәк түгел яңгыр диңгезгә...

## Мәхмүт Хәсәнов

# КАМА ТАҢНАРЫ

Романнан бүлекләр



Фаҗигале хәбәр буласын күңелем сизенгән иде аны. Югыйсә, өлкә партия активы җыелышыннан «Сезне срочно телефонга!..» дип чакырып алырлар идемени?

Шулай ук күңелемә: «Әллә төзелештә бер-бер хәл булдымы икән?» — дигән уй килде. Алай дисәң, миннән ике-өч кенә кеше аша Кама автомобиль заводының генеральный директоры утыра, иң элек аңар мөрәҗәгать итәрләр иде.

Аяк очларыма гына басып, чакырырга кергән ханым артыннан иярәм. Сәхнә артыннан бераз үтүгә, мин ияргән ханым ачык ишекләрнең берсе янында туктап, «Рәхим итегез!» дип эчкә күрсәтте. Карасам, бүлмә эчендә тагын бер ханым. Йөзе житди. Кулындагы телефон трубкасын миңа бирү белән, яман хәбәргә шаһит булырга теләмәгән сыман, читкәрәк тайпылды.

— Тыңлыйм!..— дидем.

Таныш тавыш. Мин җитәкчелек итә торган информация-хисаплау үзәгендә эшләүче яшь инженер Даниал Ризванов. Ул башта активтан чакыртып чыгарганы өчен гафу үтенде, аннары, әйтәсе сүзен әйтеп бетерергә өлгерә алмавыннан курыккан кебек, тезә дә башлады:

— Имам Хисамович... Зур бәхетсезлек. Автомобиль катастрофасында... Зинаида Ивановна һәлак булды...

«Ничек? Кайда?.. Кая барганда? Нинди машинада?..»

— Кайчан?..— дидем.

— Әле яңарак кына больницага китерделәр үзләрен...

— Ничек «үзләрен?»

— Шоферыгыз Нургали белән икесен. Сезнең машинада, Каманың боз ярлы астына очканнар...

«Кая барганда?.. Катастрофаның сәбәбе нәрсә?..» — дип сорау бирмәсыз иде. Шуңа күрә, сүзне озакка сузмыйча: «Хәзер кайтырга чыгам»,— дидем дә трубканы куйдым.

Нәкъ шул вакытта тамашачылар залыннан кул чапкан тавышлар ишетелде. Ул да булмады, театр заллары давыллы хәтерләткән гөрелте белән тулды...

Типовой проект белән яңарак кына салынып беткән больницага килдем.

Тәрәзәләренең аскы өлгеләре акка буялган, тәбәнәк бинаның ишегеи ачып, ярым карангы салкын бүлмәгә алып керделәр.

Ак халатлы ир кеше миңа күз карашы белән генә якынрак килерг кушты. Үзе стенадагы кнопкаларның берсенә басты. Астан, салкынлы бәреп торган караңгы люктан, ак җәймә белән капланган мәет кутә релде.

Җәймәне ачып карадым. Зинаида ята. Сары чәчләре ян-якка тара лып төшкән. Авызы чак кына ачык: тешләре күренеп тора. Бәлки, жа ачысы белән кычкырган булгандыр...

Башым әйләнеп китте. Җәймәне кире яптым.

Күрше бүлмәгә чакырдылар. Анда мине ГАИ сотруднигы белә милиция хезмәткәрләре каршылады. Медицина үз сүзен кыска әйткән гражданин Нури Вафин, гражданка Зинаида... текә ярдан очып төшег һәлак булганнар. Аракы эчкәнлекләре исбат ителгән. Миннән гражданка Зинаида Ивановна белән кайчаннан бирле торуымны сорап, язып алды лар, мәрхүмнең шөгылен, холык-фигылен сораштылар, аннары Вафин йортына алып киттеләр.

Иске Чаллыда тора иде ул. Быел сүтеп алынырга тиешле урамга килеп кердек. Менә бер якка авыша төшкән өй. Аскы каты, таштан салган өлеше, тәмам җиргә иңгән. Туктадык. Машиналардан төштек. Ишегалды аннан-моннан кадакланган алачык-сарайлар белән тулы. Аска таба төшә торган сөзәк баскыч буйлап караңгы өйалдына барып кердек.

— Өйдәләрме?..— дип кычкырып сорады суд тикшерүчесе.

Түрдә бер ишек ачылып китте. Шул яктылыкка таба атладык. Кер юып маташучы урта яшьләрдәге хатын каршылады безне. Чит-ят кешеләрне күреп сагайды, эшеннән бүленеп терсәгенә кадәр сызганган куллларын биленә буган алъяпкычына сөртте. Итәкләрен тарткалап төзәтенгәндәй итте.

— Түргә узыгыз...— диде, аптырап калуын яшерә алмыйча.

— Рәхмәт...— диде суд тикшерүчесе. Фуражкасын салып кулына тотты.— Сез Нургали Вафинның хатыны буласызмы?

— Әйе,— диде хатын, нидер сизенгән сыман.— Әллә... андый-мондый хәл булдымы?

— Әй-йе, булды,— диде суд тикшерүчесе.— Ирегез белән бәхетсезлек булды... Бу сезнең балалармы?

— Әйе...

Бүлмәдә ике бала бар иде. Берсе — өстәл кырыена утырып китап өстенә иелгәне — кыз бала. Укучы булса кирәк. Икенчесе — биш-алты яшьләр чамасындагысы — малай. Идәндә утыра. Ул да эшсез түгел, алюмин чыбыкны бөгеп буш кәтүкләргә керткән дә машина ясаган. Кузов урынына дүрт кырлы консерва банкасы куйган...

Суд тикшерүчесе ике сүз белән генә Нури Вафинның нинди шартларда үлгәнлеген, мәрхүмнең гәүдәсе үзәк больницада булуын әйтте.

Ярым караңгы бүлмәгә күз ияләшеп өлгергән иде инде. Хуҗа хатынына карыйм. Юк, бу яман хәбәрне ишетү белән шактый ук төс салган ак чырайлы хатын кутәрелеп бәрелмәде, алып та орынмады. Үзәкне өзеп карый торган моңсу зур коңгырт-кара күзләр генә, ничектер, бер мәлгә сәер ялкынланып куйдылар. Ләкин бу да бер мизгелгә генә. Шунда ук, мондый фаҗигале хәбәрне көткән кеше сыман, чак кына читкә борылгандай, кул селтәп куйды. Ул да булмады, бәхетсезлекнең бөтен ачысы берьюлы аның күзләрендә чагылды.

Аннары кинәт йомшап, ярдәмгә бик тә мохтаҗ кешедәй тилмереп, кабат безнең якка тутырып күз салып алды да, өстәп тагын ни әйтсәк дә шуңа ризалыгын, күнәчәген сиздерергә теләгәндәй, тагарагы янындагы озын эскәмиянең буш өлешенә килеп утырды. Өстәл янындагы кызы да тавыш-тынсыз гына килеп әнисенә елышты.

Тәбәнәк түшәмле ярым караңгы квартирдагы бу күренеш, тән ярасы кебек күңелне әрнетеп, бимазалый башлаган иде инде. Мин, сүз тикшерүчесеннән рөхсәт сорап, бүлмәдәгеләрнең игътибарын җәлеп итмәскә тырышып, тавыш-тынсыз гына чыгып киттем.

* * *

Мәрхүмнәрне җирләгәч, мин җанымны кая куярга белми, әрле-бирле сугылып йөрдем. Зинаида Ивановнаның миңа карата бигүк турылыклы булмавын сизенә идем мин, әмма уеннан уймак чыгар дип, фаҗига белән очланыр дип башыма да китерми идем.

Җанымны кая куярга белми йөрткән тагын бер сәбәп бар иде әле: партия активына китәр алдыннан бер атна элек кенә мин өч бүлмәле яңа квартир алган идем. Хәзер шул болын чаклы квартирда япа-ялгызым, тол ир булып торып калдым.

Миңа ул квартирдан котылырга, бер бүлмәлене генә сорап алырга, һич югы, алыштырырга булыр иде. Ләкин минем юлыма аркылы төшкән хәл — һәлак булган Вафинның семьясы ярым подвалда яши бит, әнә шул зиһенемне чуалтып тора. Квартирны болай гына алыштырсаң, алар кызганыч, инде ике бүлмәсен аларга биреп, үзем берсендә генә калсам, алар белән янәшә яшәргә, фаҗигале үлемне һәм хыянәтне көнелдә яңартып, көн саен Вафин семьясы белән очрашып торырга туры киләчәк иде.

Бер-ике көн тегеләй дә, болай да хәл итә алмый аптырап йөрдем. Кем белән булса да киңәш-табыш итсәм, бу янә дә фаҗигане искә төшерү булыр дип курыктым.

Ул арада КамАЗның ашыгыч эшләре килеп чыкты, үлгән ике бәртек кеше гигант төзелеш фонында телгә дә менеп җитмәс борын сүнде, без үлемне түгел, киләчәк көнебезне уйлап яшәргә тиеш идек.

Мин завод заказлары белән бер атнага Киевкә китеп бардым, бор-
чулы уйларымны үзем белән ияртеп йөртмәс өчен, квартирның ике
бүлмәсенә ордерны һәм бер ачкычны Вафин хатынына биреп кал-
ıырдым.

Инде менә атна дигәне үтеп тә китте, соңгы рейс самолет белән
Чаллыга кайтып төшкәч, мин тагын уңайсыз хәлдә калдым...

Урамнарда хәрәкәт бөтенләй тынган. Соң булгангамы, шофер авто-
бусны кем кайда тели шунда туктатып, пассажирларны төшерә. Мин
дә, үзебезнең урамга җиткәч, шофер егеткә рәхмәт әйтеп төшеп кал-
дым. Аның каравы, өйгә кайтып җитеп, ачкычны барлау өчен кесәмә
кулымны тыгып подъезд ишеге аша аякны атлагач кына, стенага килеп
бәрелгән кеше сыман туктап калырга мәҗбүр булдым...

Беренче туган уй: «Күченделәрме икән әле?» Аларны мин югында
үршем Алексей Фомич күчерергә тиеш иде. Ордерны да мин аңа би-
еп калдырдым. Ә күндәм, сүз тыңлаучан Фомичка йомыш куштың-
ы — үтәлгән дип сана. Баскычтан төшеп тәрәзәләргә күз салдым.
арыйм, ут күренми. Бәлки, зал ягында ут янадыр дип уйлап, урам
кка да чыгып карадым. Анда да шул ук хәл. Берьюлы берничә төрле
й: бәлки, ташынып өлгермәгәннәрдер? Өй тулы әйбер дип, хәзер үк
үченүдән баш тартканнардыр? Хәер, күченеп килгән тәкъдирдә дә
окларга яткан булулары мөмкин. Соң бит инде хәзер...

Яңадан ишегалдына узып, подъезд янына киләм. Тәрәзәләргә кабат
үз салам. Карасам, кухня тәрәзәсендә чак кына яктылык сирпелә ке-
ек. Коридорда янган ут кухня аша шулай төшә түгелме соң?

Подъездга кердем. Өскә күтәрелдем. Ишеккә колак салып тыңлап
арыйм. Юк, ул-бу ишетелми. Бары тик кайсыдыр квартирда радио-
ы, телевизормы шау-гөр килә.

Ишек төбендә таптанып торып булмый, звонок-фәлән биреп тормыйча, инглиз ачкычын борып, ишекне ачтым. Коридорда ут. Ә кухня ишеге төбендә өстенә озын җинле ап-ак кофта кигән, коеп куйгандай зифа буй-сынлы яшь кенә ханым басып тора. Кулларын күкрәк турысына кушырган. Чәчләрен бик пөхтә итеп арттан җыештырып куйган горур башы чак кына минем якка борылган. Кем булыр бу?

— Мөмкинме икән?..— дидем, үземне чит кеше йортына басып кергәндәй тоеп.

— Рәхим итегез! — диде ягымлы тавыш.

Бусага аша атлап кереп, бары тик игътибар беләнрәк карагач кына таныдым үзен. Бу беркөнге хатын үзе ич. Танымыйча торуымны күрә инде, ә! Әнә бит, шул ук уйчан бер кыяфәт, йөрәкләрне өздерерлек моңсу караш. Тик ул узган юлы миңа шактый ук төс салган, йончыган, дөнья мәшәкатьләреннән тәмам арыган хатынга охшаган иде.

— Саумы сез!..— дидем мин, портфелемне идәнгә куеп.

— Исәнмесез!..

Шул минутта мин үземне куян өмет итеп барып та аюга юлыккан сунарчы кебегрәк хис иттем.

— Сез мине, зинһар, гафу итә күрегез,— дидем мин, акланырга җыенган кеше сыман итеп.— Соңгы рейс белән кайтырга туры килде.

— Нигә акланып торырга? Сез бит үз өегезгә кайттыгыз.— Тавышы коры, кыяфәте кырыс иде аның.

Миңа кичекмәстән нинди дә булса адым ясарга кирәк иде. Йомарлап тоткан балоньи плащымны сул беләгемә аркылы салдым да:

— Мин китим әле, булмаса...— дип, кабат портфелемә үрелдем.

— Беркая да китмисез! — Хатын юлыма аркылы төшәргә җыенган сыман алга таба кискен хәрәкәт ясап куйды.— Бу вакытта кая бармакчы буласыз?..

— Гостиница-фәләнгә... Я эш урыныма, кабинетыма,— дидем мин, үземне бераз гына кызгандырып алырга теләп.— Ә сез, зинһар, борчыган өчен гафу итә күрегез...

Хатынның җавабы катгый иде.

— Беркая да бармыйсыз!

Мин буйсындым. Җил-давылдан, тузан-пәпектән саклану өчен үзем белән йөртә торган плащымны ишек катындагы чөйгә элдем. Чәчләремне сыйпаштырдым.

— Без бит әле сезнең белән таныш та түгел,— дидем мин түргә узмыйча гына.— Мине Имам Хисамович дип йөртәләр. Фамилиям Котдусов...

Хатын да исемен әйтте. Һәдия атлы икән. Исеменең минем беренче хатыным Нәҗия белән аваздаш булуына игътибар итмичә булдыра алмадым.

Тирә-якка күз салдым. Залның ишеге ябык. Минем кабинет та әйберләр белән терәтеп куелган. Шунда ук холодильник янында ике чемодан, төенчекләр. Кухня ягына күз төшердем. Шаккаттым. Мине шулай аптырашта калдырган нәрсә балаларның кухня идәнендә йоклап ятулары иде.

— Сез нәрсә?..— дидем мин, гаҗәпләнеп.— Нигә вокзалдагы кебек яшисез? Алексей Фомич, квартир сезнеке, дип әйтмәдемени соң? Балаларны кухняга салырга ярый димени! Анда бит газ...

Хатын зал ишеге ягына баш кагып, телгә килде.

— Фатир тулы әйберләр... Түргә узарга базмадык. Кеше әйберләре бит. Өстәлдә кәгазьләр, язу-сызулар... Бала-чаганы үзегез беләсез...— Һәм шунда ук икенче төрле тавыш белән, хәтта чак кына кабат кырыслана төшеп куйды.— Фатир дигәч, мин әллә берәр буш куыш дип уйлаган идем... Килмәс иек, подвалда яшәү дә туйдырды...

Бу сүзләрне әйткәндә аның йөзенә күләгә сарылып кына калмады, тавышына кадәр үзгәрде, ничектер бу тавышта кимсенү дә, түбәнсенү дә чагылды кебек.

Мин аны тынычландырырга тырышып карадым.

— Сез, Һәдия ханым, юкка борчыласыз. Квартир сезнеке. Ә мине исә үтеп баручы бер мосафир дип кенә санагыз. Минем көнем төзелеш-тә уза.

Анар карап Һәдиянең йөзе ачылмады, кыяфәте дә үзгәрмәде. Монсу йчанлык ярылып ята иде бу йөздә.

Кабат кухня ягына күз салдым. Анда үтеп, өстәл янына утыру мөмкинлеге юк иде. Уемны хатын сизенде, ахрысы, җәһәт кенә кухня ишеге янына якынайды.

— Балаларны хәзер, менә монда, коридорга күчерермен...— диде ул, чак кына каушап калган кыяфәт белән.

— Юк, коридорга түгел. Үз урыннарына илтеп салыгыз аларны,— дидем мин әмер биргән тавыш белән.— Әйдәгез әле, үзегез әйтмешли, хатирыгыз белән таныштырыйм...

Зал ягына үтеп, люстраны кабыздым. Урта бер җирдә торган зур өстәл өстендә газета-журналлар, сызым-чертежлар чәчелеп яталар. Җәһәт кенә җыеп алдым үзләрен...

— Боларны җыеп кабинетка да кертеп куеп була иде ич...

— Ничек куелган, шулай торсыннар, дидем. Язу-сызу бит ул...

Икенче ишекне ачып җибәрдем.

Ана кеше беренче булып таралып йоклаган улын кулына күтәреп алды. Ул түр якка чыгып киткәч, минем дә кыз баланы күтәреп аласым килде. Тик чит кеше баласына тотынырга яхшысынмадым. Әнә ул, нәзек беләкләрен як-якка атып, рәхәтләнеп йоклап ята. Йоклаган булса да күренеп тора: нәкъ әнисе, суйган да каплаган. Минем дә гомерем буе шундый берәр кыз бала үстерә алмавыма үкенеп.

Һәдия ханым кызын да урнаштырды. Идәндәге урын-җирне дә җыеп алды. Ялгыз калдым. Ашыйсы килеп китте. Казан аэропортында да ресторанга-фәләнгә керергә өлгерә алмадым шул.

Шул вакыт ишектә Һәдия ханым күренде.

— Бәлки, сезгә чәй куяргадыр? — диде ул.

— Борчылмагыз, Һәдия ханым. Үзем генә куярмын...

Ул арада Һәдия кухняга үтеп, чәйнеккә краннан шаулатып су агызып, газ плитәсен кабызып җибәрде.

Мин кабинетыма кердем. Өстәл лампасын кабыздым. Олы диванга кырын җәйдем. Шул чак, нинди хикмәттер, күңелемә җылы дулкыннар йөгергәнен хис иттем. Баксаң, шушы түбә астында ялгыз түгеллегемне, кемнәндер аша гына җан ияләренең барын тою рәхәте икән ләбаса!

Чәй өлгерде. Кухняга чыктым. Тәлинкәгә йомшак күмәч турап куелган. Шикәр, конфет. Җыйнак кына таш савытта ак май.

— Үзегез дә утырыгыз,— дидем мин, өстәлнең түрге башына урнашып.

— Рәхмәт. Без баянак кына ашап-эчкән идек.

Шулай да Һәдия чыгып китмәде. Минем алга чәй ясап куйганнан соң озынча өстәлнең ишек катындагы башына килеп утырды. Тикмәгә генә утырмавы йөзенә чыккан. Сүзе бардыр дигән уй килде башыма. Әмма ул сөйләшүнең бик үк күңелле булмаячагын тоеп торам.

Киеренке тынлыкка әллә ни исем китмәгән кыяфәт белән чәй эчәм. Бутерброд ясап ашадым. Инде булды дип, рәхмәт әйтеп урынымнан да торып китмәкче идем, Һәдия ханым, кулы белән тыйнак-әдәпле генә ишарә ясап, урынымда калырга кушты.

«Менә, башлана...» дип уйлап куйдым мин.

— Миңа бер генә сорауга җавап бирегез әле...— Эчке бер сыкрану белән тирән итеп ухылдап алды да дәвам итте: — Сез бит акыллы кеше...

Мине уйламасагыз, үзегезне уйлар идегез. Сез бит олы, дәрәҗәле, исемле кеше. Сезне бит бер генә дә белмәүче юк...

Билгеле, әллә ни рәтле сүз көтми идем мин. Әмма шулай кискен борылыш ясап, шактый ук ачы сүзләрдән башлар дип тә көтмәгән идем.

Сизеп торам: ике бала белән калган ялгыз бу хатынны тынычландырырга, һич югында, юату сүзләре әйтергә кирәк. Шул ук вакытта рәнҗетмәслек тә булсын ул сүзләр. Кычкырып елыйсыңмыни, андый сүзләрне таба алмыйча газапланам, иза чигәм.

Ул да булмады, һәдия ханым, терсәге белән өстәлгә таянып, кулларына йөзен яшереп, тавышсыз гына елый башлады. Бу хәл бөтенләй әллә нишләтеп җибәрде мине. Монда инде нинди дә сүзләр әйтеп кенә мәгънә чыгарып булырлык түгел иде. Менә бит, ә! Бу хәлләрнең азагы турында нишләп уйламаганмын соң мин? Ничек соң әле шушындый гап-гади хакыйкать тә минем башыма килмәгән?

— Ярар, һәдия ханым. Мин аңладым сезне...— дидем мин, ишеккә таба юнәлеп.— Мин китәм... Шулай да бер үтенечем бар сезгә. Баштарак миңа гостиницада яшәргә туры килер. Мин бүлмәмне алыштырганчы, әйберләр сездә торып торсын инде. Хәзер үк алып, кая куйыйм аларны?..

һәдия ханымның үксүдән тетрәнгән җилкәләре тынган кебек булды. Менә ул башын калкытты. Учы төбендә әвәләүдән бармак башы кадәрле генә булып калган кулъяулыгыннан күзләрен алмыйча гына әйтте:

— Беркая да китмисез!.. Квартир сезнеке. Без китәбез... Мин инде бүген дә шәһәрне әйләнеп кайткан идем, тик кулай фатир гына белешә алмадым. Ә искесенә, үзебез машинага төянгәндә үк, дүрт балалы гаилә кереп калды. Хәзерге Чаллыда торак мәсьәләсенең ничеклеген үзегез дә яхшы беләсез ич.

һәдия ханым, минем буйсынуны күреп, кофтасының беләзеге турысында төймәләнгән җиңнәрен тарткалап, төзәтенеп куйды да шактый тыныч тавыш белән әйтте:

— Ярар, барыгыз, ял итегез. Сез бит юлдан кайткан кеше... Минем сүзләремне авырга алмагыз. Йөрәк әрнегәннән...

— Сез алай бетеренмәгез. Менә күрерсез, бар да әйбәт булыр,— дидем мин. Нәрсә уйлап әйттем мин бу сүзләрне? Урынлымы алар, юкмы, бу минутта барыбер үз-үземә хисап бирә алмаган булыр идем.

һәдия бу сүзләргә әллә ни игътибар итмәде: — Ярар, ял итегез,— диде дә түргә үтеп, үз артыннан ишекне япты. Шунда ук залдагы ут сүнде.

Баскан урынымда үрә катып калдым. Тыныч йокы, дип тә әйтә алмадым хәтта.

* * *

Тәмам яктырып беткәч кенә йокыга киткәнмен. Уянып күзләремне ачканда, бүлмә эче тулы кояш. Күнел күге дә чак кына аязланып киткән сыман. Ләкин андый тойгы озакка бармады, күз алдыма беләкләренә капланып елаган һәдия ханым һәм аның рәнҗеп әйткән сүзләре исемә төшү белән төнге халәтемә кайттым да куйдым.

Чү-ү!.. Якында гына кемнәр чыркылдаша? Игътибар беләнрәк тыңлап карагач төшендем: балалар уянган икән. Сәгатемә күз төшерәм. Әйе, җиденче киткән икән шул инде.

Җәһәт кенә тордым. Селтәнгәләп зарядка ясагандай иттем. Юындым-киендем.

Аннан-моннан сөртенгәндәй итеп, чәчләремне тарадым да янадан кабинетыма кереп киттем. Нәкъ шул вакытта зал ишеге ачылганлыгы,

рридорда кайсыныңдыр аяк тавышы ишетелде. Ул да булмады, ана шенең: «Әкренрәк атлагыз, шауламагыз... Ах-х, сезне!..» дигән тавышы ишетелде.

Шул вакыт телефон шалтырады. Балаларны җил тузгыттымыни, ундук түр бүлмәгә кереп качтылар. Кинәт тып-тын булып калды. Телефон кабат хәбәр салды. Трубканы Һәдия ханым алды. «Әй-йе!» — де ул тыныч-басынкы тавыш белән. Һәм шунда ук русчалап: «Хә-р...» дип, телефон трубкасын тумбочка өстенә куйды. Ул да булмады, ың ишекне шакып: «Сезне телефонга чакыралар»,— дигән тавышы ишетелде.

Мин, рәхмәт әйтеп, коридорга чыктым. «Хәерле иртә!..» дип исәнштем. Бары тик шуннан соң гына телефон трубкасын кулыма алдым.
— Тынлыйм!..— Леонид Борисович икән. Минем ниләр җимертеп йтуым белән кызыксына.

Хәлләрне сөйләдем. Монда нинди яңалыклар булуын сорадым.

Яңалык булган. Беренчедән, бүген үк иртәнге унда, аның кабинетында производство киңәшмәсенә җыелабыз. Шуның өстенә миңа бер көннән яңа сәфәргә җыенырга кирәк. Сәяхәт итү бик күпкә китте телме? Мин инде: «Төп эшемне кайчанрак эшләрмен соң?» — дип, директорның сүзенә каршы да төшмәкче идем. Әмма шунда ук: «Мена, дияне квартирда калдырып тынычландырырга сәбәп тә булды», диикенче бер уй күңелемнән узды.

Минем өзеп җавап бирергә ашыкмавымны сизенгән директор: омандировкалар бик ешайды дип авырсынсагыз, башка берәр иптәш җибәрербез»,— диде.

Командировканың кая һәм нинди йомыш белән булуын сорашм. Мәскәүдән икән. Безнең «КамАЗ» чыгарасы машиналарның икен партия үрнәкләренә сынау эшләре төгәлләнгән. Автомобиль промышлности министрлыгында шул мәсьәлә тикшереләчәк икән. Бу миңа ыдан-туры кагыла, мин вәкаләтле комиссиянең бер әгъзасы. Беренпартия машиналарны сынау нәтиҗәләрен тикшергәндә дә катнашкан м. Ул юлы җитди генә кимчелекләр табылып, күп кенә детальләрне, та аерым узелларны өр-яңадан хәзерләргә дигән катгый карар кабул лган иде.

«Калган кадәресен заводта сөйләшербез...» — дип, Леонид Борисоәңгәмәне өзеп телефон трубкасын куйды.

Һәдия исә ниндидер гадәттән тыш шик-вәсвәсә ишетергә җыенган ан, күзләрен зур итеп ачып, минем ни дә булса әйтүемне көтеп а иде.

— Безнең генеральный директорыбыз иптәш Василов. Нинди яңалар алып кайтуым белән кызыксына,— дидем. Сизеп торам, аңа ем бу сүзләремнең кирәге юк.— Яңадан сәфәр чыгарга кушалар,— ем мин, аны тынычландырырга теләп. Шул вакыт чак кына ачылган ишеге ярыгыннан берьюлы дүрт күзнең карап торуын күреп ым.

— Әй-й, егетләр, кызлар! Ник бу якка чыкмыйсыз? Әйдәгез, һич маса, танышып алыйк...

Беренче булып дүрт-биш яшьләр чамасындагы йомры башлы ма чыкты. Өстендә төсен югалткан ак күлмәк, кыска штан. Аягына ике ле оекбаш киеп алган. Әллә каян күренеп тора: малай борча кебек ан булырга охшый.

Иң элек малайның, аннары кызның исемнәрен сорашып белдем. и белән Нурия.

— Ай-һай, исемнәрегез матур икән!

Малай чәчрәп алга чыкты.

— Ә синеке?

Әнисе ялт тегенең муен тамырына.

— Зурлар белән «син» дип сөйләшәләрмени? И-и, агач тел!.. Аяк ларына нәрсә киден?.. Күзен кайда? Бар хәзер үк алыштыр!..

— Зарарлы түгел,— дип яклагандай иттем егетне.— Уңы белән су лын бутамаска әйбәт була ул, нйеме, Һади?..

Әниләре ачулана дип, малай да, Нурия дә тур якка кереп китмәде ләр, минем янда калдылар.

Һади яңадан алга чыкты:

— Бу синең әйберләрме?

Мин аңламаганга сабыштым.

— Нинди әйберләр?

— Менә бу...— Һадиның имән бармагы холодильникның «Татар стан» дигән сүзенә төртелде.— Аннары телевизор?..

Миннән чынлап торып сорау ала башлаган ташбашның сүзен Һади булде.

— Ярар, ярар, җитте сиңа! Юклы-барлы сүз белән абый кешене эчен пошырма,— диде ул.

Әнисенең кулы астыннан бөтерелеп чыккан Һади яңадан минем каршыма килеп басты. Ә инде әнисе кухняга чәй куярга дип кереп кит кәч, яңадан сорау ала башлады.

— Ә теге уйный торган?..

Егеткә ярдәмгә ашыктым:

— Пианиномы?

— Әйе. Аны син уйныйсыңмы?

— Юк.

— Кем уйный соң?

— Менә Нурия уйнар... Музыка мәктәбенә йөри башласа, аңа бик кирәк булачак ул.

— Һы-ы,— дип куйды ташбаш. Искәрмәстән генә апасының шун дый зур бүләкле булуына чак кына көнләшүе иде, ахры. Ләкин ул аны шундук онытты, яңадан сорау яудыра башлады:

— Син кайда эшлисең?

— Завод төзим.

Малай аякларын тагын да җәя төшеп, башын артка ташлап, мин нән күзләрен алмый. Ике кул да бөердә.

— Зурмы ул?

— Нәрсә?

— Шул завод инде?

— Бик зур.

Һади күзен-башын җыергалап алды. Бик әһәмиятле, гаять катлау лы сорау бирергә җыена булса кирәк.

— Ә аннары?..— дип куйды ул.

— Нәрсә аннары?

— Завод төзелеп беткәч?

— Аннары ул заводта зур-зур автомашиналар ясарбыз.

— Ә бәләкәйләрне?

— Бәләкәйләрне дә ясарга була.

— Бик-бик бәләкәйләрне дәме?

— Бик-бик бәләкәйләрне дә.— Бу юлы инде мин үзем сорауга кар шы сорау белән җавап бирергә булдым: — Син, Һади, автомашинала ны бик яратасың, ахры? — Беренче тапкыр очрашканда да машина яса утырганыңны күргән идем, дип өстәмәкче дә идем, әмма андый яма хәбәр алынган көнне кабат исләренә төшерәсем килмәде.

Заводның «бик-бик бәләкәй» автомашиналар да эшли алачагы нән Һадины тәмам җилкетте, күзләре гел миндә.

— Тиз ясаламы?

Юри аңламаганга сабыштым.

— Нәрсә?

— Машиналар.
— Бик тиз, син бит юган арада бер машина ясалып та бетә.
Ташбашның күзләре түгәрәкләнеп килде.
— Шулай тизме?!.
Бу юлы бер читтә торган Нурия дә түзмәде, сүзгә кушылды.
— Ул бит рәтләп юынмый,— диде кызчык, һади ягына ым кагып.— Кулын чылатып борын очын гына юешли дә...
Йомры башка шул сүз җитә калды.
— Кем чылата?.. Әйт әле, кем чылата? Минме?.. Үзең чылатасың син!..
Бәхәс ни белән беткән булыр иде, шул вакыт баш очыбызда гына звонок шалтырады. Балалар, каушап калып, җәһәт кенә түргә, ишеккә таба тартылып куйдылар. Әниләре, карагыз аны, кеше барында күзгә-башка чалынып йөрисе булмагыз, дип кисәтеп, колакларына киртләп куйган булса кирәк.
Ишекне ачтым. Телеграмма китергәннәр икән. Кул куеп алдым. Җиңел майка белән трико чалбар киеп алган спортсменкага охшаган яшь-яшь кыз саубуллашып китеп баргач, телеграмманы ачтым. Улым Исламнан. «Үтеп барышлый булабыз, каршы алырга әзер тор», дигән.
Мондый хәбәр минем өчен иң зур шатлыкларның берсе була торган иде. Чөнки ул минем бердәнберем, шатлыгым да, куанычым да, юанычым да. Хәтта горурлыгым да. Без бит аның белән кирәгеннән артык сирәк очрашабыз. Елына күп дигәндә ике-өч тапкыр. Анда да дүрт-биш көнгә генә. Исламның «кайтам» дигән хәбәрен алгач, башларым күккә тия, шатлыгымнан нишләргә дә белми торган идем. Шунда ук эштән берничә көнгә ял алып каршылау хәзерлекләрен күрә башлый торган идем. Әмма бу юлы, ничектер, шундый зур куаныч иkенче төрлерәк хис белән алышынды... Берьюлы берничә төрле сорау туды, проблема хасил булды. Кая урнаштырырмын? Җитмәсә тагын, үзе генә дә түгел... Кем белән кайта икән? Әллә башлы-күзле булдымы икән?.. Андый очракта аларны тулай торакка урнаштырып булмаячак... Инде нишләп карарга? Бу хәлдән ничек чыгарга? Хәзергә бит әле мин үзем дә җир белән күк арасында.
Карасам, кухня ишеге катында һадия басып тора. Күзләребез очрашты. Аның карашы гадәттәгечә моңсу, шул ук вакытта сораулы. Минем шулай икеләнеп, чак кына югалып калуымны ул да сизенгән, ахрысы.
— Улымнан...— дидем мин, телеграмманы күрсәтеп. Ләкин «Кайтабыз, каршы ал» дигән сүзләрен әйтмәдем.
Ләкин бу хәбәр һадия өчен яңалык булмаган икән.
— Кичә дә шалтыраткан иде...— диде ул, үз чиратында уңайсызланып.— Новосибирскидан.
— Әйе, ул Себер Академиясендә...
һадия мине бүлеп аклана башлады.
— Рәтләп сөйләшеп булмады... «Сез кем? Әтинең кеме буласыз?..» дип, бик төпченә башлагач, трубканы куярга мәҗбүр булдым. Аннары инде, кабат-кабат шалтыратсалар да, трубканы алмадым. Гафу итегез!..
— Зарар юк...— дидем мин, һадияне тынычландырырга теләп.
Чәй әзер иде. Ана кеше, соңрак ашап-эчәрләр дип, балаларны табын янына утыртмады. Кичәге кебек, ишек катындагы урындыкка һадия дә килеп утырды. Нәрсәдер әйтергә җыена булса кирәк. Минем үз хәлем хәл. Уйлана торгач, бәлки, кунакларны монда гына алып кайтырга-дыр? дигән фикергә килдем. Чыннан да, кая алып барасың ди аларны? һәм ни булса шул булыр дип, бу турыда һадия белән дә киңәшеп карарга булдым. Озак баш ватып тормадым, әйттем. Күп булса бер-ике

көн торырлар, дип өстәргә дә онытмадым. Телеграммадагы: «Үтеп барышлый» дигән сүзгә чытырдап ябыштым.

Бәхетемә каршы, Һәдия моны бик гади кабул итте: «Монда кайтмыйча кая кайтсыннар тагын»,— дип кенә куйды.

Бу хәл мине бөтенләй канатландырып җибәрде. Сүз уңаенда хәтта кунакларны каршы алырга ярдәм итешүен дә үтендем. Рәхмәт төшкере, моңа да күнде. Миннән дә бәхетле кеше юк иде бу минутта. Шунда ук кадерле кунакларны ничек итеп каршы алу турында үзебезчә планнар да кора башладык. Аш-су әзерләргә Һәдия ханым риза булды.

— Акча менә монда...— дидем мин, кухня шкафындагы ваза сыман савытны өстәлгә алып куеп.

— Кайчанрак кайтырлар икән соң алар?..

Бик урынлы сорау иде бу.

— Хәзер беләбез аны.— Шунда ук аэропортка шалтыратып, телеграммада күрсәтелгән рейс самолетының кайчанрак килүен сораштым. Көндезге икеләр тирәсендә, диделәр. Һәрхәлдә, Һәдия ханыма ул кадәр үк ашыкмаска да була иде.

Заводка иртәрәк киттем. Көн матур, кояшлы. Тротуардан барам. Уйлыйм: «Кайтабыз» дигән сүзе үзе бер табышмак. Әллә өйләндеме икән? Алай дияр иде, шундый зур адым ясаганда минем белән киңәшер, һич югында, туена чакырыр иде. Ул да булмый, икенче бер уй башын калкыта. Монысы инде хәвефлерәк... Өйгә кайтып керүгә Ислам Һәдияне күрәчәк. «Кем бу?» «Каян?»

Мондый уйлар минем башымда тикмәгә генә тумадылар, әлбәттә. Минем инде кайчандыр шундый аңлашуны, дөресрәге, сорау алуга дучар булуны башымнан кичергәнем бар. Ул вакытта инде минем хатыным — Исламның әнисе Нажия үлгән иде. Зинаиданың беренче тапкыр буларак минем янга Горькийга килгән елында булды ул сөйләшү. Ислам да искәрмәстән генә кайтып төште.

Зинаиданы күрү белән:

— Бу кем? — диде.

— Якын танышым...— дидем мин, җинаять өстендә тотылган кеше сыман.

— Икенче төрле итеп әйткәндә: гетера. Шулаймы?

Мин дә авызымны йомып калмадым, хәлемне аңлаттым.

Әмма аның үз туксаны туксан иде.

— Мин сине аңлыйм...— диде ул, кырт кисеп.— Әмма аклый алмыйм. Син, әти, билгеле кеше. Аңла, минем өчен син Монблан кебек идең, әллә каян күренеп тора идең... Горурлана идем мин синең белән. Өйрәтә дип уйлама, әти. Мин сине якын күргәнгә, үз иткәнгә күрә генә әйтәм бу сүзләрне. Синнән башка кемем бар минем?.. Син мине, зинһар, дөрес аңлый күр. Мин синең өйләнүеңә каршы түгел. Һич юк! Тик бу адым һәр яктан үлчәнеп, тирәнтен уйланып эшләнергә тиештер. Син бер хәлне исеңнән чыгарма: репутация дигән нәрсә бар. Әнием мәрхүмә аны: абруй, ди торган иде...

Яңадан шуңар охшашлы сөйләшү көтә түгелме соң мине? Мин үземнән бигрәк Һәдия өчен борчылам. Ислам саксызрак сүз ычкындырып, ансыз да китек күңелне бөтенләй рәнҗетеп куймасмы?

Зина исә ул вакытта да әллә ни югалып калмады. Исламның үен, үзенә карата булган мөнәсәбәтне аңлап, ир-ат белән хатын-кызның һәр яктан тигез булуы турында фәлсәфә сатты.

Шундый уйларга бирелеп, автовокзалга килеп җиткәнемне сизмичә дә калганмын.

Төрле төстәге зур автобуслар, тирә-якка төтен-сөрем бөркеп, бер-бер артлы кузгалып, төрлесе төрле якка таралып торалар.

Мин дә маңгаена «КамАЗ» дип тамга суккан автобусларның берсенә кереп утырып, заводка китеп бардым.

Кунакларны каршы алырга аэропортка Алексей Фомич барды.

Күршем аларны, нәкъ мин әйткәнчә, эш урыныма алып кайтты. Улым Ислам белән кочаклашып күрештек. Әллә ни үзгәрмәгән. Һаман а шул ук торыш-кыяфәт. Уртачарак буйлы, әнисенә тартым тар җилкә. Бары тик күзлеген генә алыштырган. Борынына галәмәт зур ялтыраыклы кара күзлек киеп куйган. Җигәвенгә охшап калган.

Ислам чыннан да ялгыз түгел иде. Бергә эшләгән якын дустын, стон егетен, ияртеп кайткан. Яшь галим дип таныштырса да, юлдашын яше, һәрхәлдә, утызның өстендә булырга охшаган иде. Исеме Янис, фамилиясе Калнынич. Кирәгеннән артык озын, Ислам кебек үк андыр, тар җилкәле. Иң күзгә бәрелеп, ташланып торганы — кин ангайлы ак чырае һәм ияк очында гына калдырган җыйнак сакалы. ксыл озын чәче, шундый ук төстәге сакалы үзенә килешеп тора. Аның орна кебек эре-эре атлап өстәл янына килүе, бик илтифатлы итеп өгелә-сыгыла исәнләшүе, җәелеп елмаюы шундук үзенә җәлеп итә.

Ул арада Алексей Фомич: «Әйдәгез, өегезгә кадәр озатып та куям»,— ип, безне җилтерәтә дә башлады.

— Улым!..— дидем мин, Алексей Фомич һәм Янис белән ишеккә аба юнәлгән Исламны туктатып.

— Нәрсә, әти?

— Бер генә минутка тукта әле... Менә нәрсә, өйдә хатын-кыз күеп гаҗәпләнмә...— Әйтә алмадым, ахры. Ислам ирен кырыйлары белән лмаеп, хәтта мыскыл иткән кебек төрттереп куйды.

— Таныйм әтине!..

Янис, безнең кыстауга буйсынып, чикерткәнеке сыман озын ботын ырпайтып, алга — Алексей Фомич янына кереп урнашты. Без Ислам елән артка утырдык.

Машина завод идарәсе яныннан кузгалып китеп, цех корпуслары расыннан алга ыргылды. Бераз сөйләшмичә бардык. Ислам белән әтләп аңлаша алмавым тәмам пошаманга төшерде. Машинада чит-ят ешеләр алдында ул турыда сүз кузгатуы кыен. Шуның өстенә әле егетәр бөтен игътибарларын шофер Алексей Фомичка юнәлдергәннәр. алыкка бару турында әңгәмә корып җибәрделәр. «Балык тоту — безең хобби»,— ди эстон егете, Фомичка таба борыла төшеп. Новоибирск тирәсендә алар балык тотмаган елга, айкамаган күл калмаін, янәсе. Алар бүген үк, я иртәгә иртүк Камага балыкка төшү турына план коралар.

Ислам аеруча түземсезләнә. Бүген үк төшү ягын каера. Без бары ік ике генә көнгә кайттык, ди. Аның шул «ике генә көнгә» дигән сүендә дә ниндидер киная бардыр кебек тоелды миңа.

Авызыма су капкан төсле утыруымны килештермичә, мин дә сүзгә ушылдым. Алексей Фомич белән: балыкка кай тирәгәрәк барсак хшырак булыр икән? — дип киңәш-табыш иттем.

— Инженер Гургенидзенең туган көнен уздырган җирдән дә һәйәтрәк урын булмас,— дип башлады ул.— Беренчедән, балыклы урын. өбе дә чиста, комлык. Бик аяк асты да түгел. Шуның өстенә, машина әлән су буена ук төшеп була. Менә дигән чиста сулы чишмәсе дә шун-а гына... Аннан да кулай урын булмас.

Алексей Фомич ул урынның отышлы якларын тезепме-тезде. Селит кирпеч заводының беренче директоры балыкка гелән шунда йөри рган булган. Машина белән төшеп йөрерлек булсын өчен бульдозерәр белән юлны да ул ачтырган. Һәр көн, таң белән, эшкә барганчы, алык каптырырга яраткан.

— Безгә дә, Алексей Фомич, сезнең ярдәмегез кирәк булыр инде,— идем мин, балыкка төшүнең мең төрле мәшәкатьләре турында уйлап.

— Кадерле кунаклар хөрмәтенә барысын да эшләрбез,— диде унган, һәрвакытта да көндәм күршем.
Кайтып җитеп подъезд төбендә туктадык. Алексей Фомич җәһәт кенә машинадан чыгып, багажниктан кунакларның чемоданнарын алып бирде. Үзем кертешим дип әйберләрне күтәреп тә алган иде инде, әмма егетләр уңайсызланып, ашыгып чемоданнарын үз кулларына алдылар.
Алексей Фомичны өйгә чакыра башладык. Тик ул: машинаны илтеп куясым, кичектергесез эшләрем бар, бәлки, соңрак сугылып чыгармын дип, тиз генә китеп тә барды.
Ишекне Һадия ачты. Бөтен өй эче минем өчен гаять тансык булган таба ашы исе белән тулган. Һадиянең дә өстендә яңа күлмәк. Кайнар плитә янында озак булгангадыр, йөзләре алсуланган. Чәчләрен артка таба җыеп, ак косынка белән бәйләп куйган. Билендә — алъяпкыч.
Шау-гөр килеп танышу, исемнәрне әйтеп кул кысышулар башланды. Янис бөгелеп-сыгылып баш иеп кенә дә калмады, Һадиянең кулын да үбеп алды.
Авызларын ачып бер читтә торган балаларны да бөтереп алып, кулларын кыскалап, аркаларыннан сөйделәр.
— Әти, ник өйдә балалар барлыгын әйтмәдең? Машинаны берәр магазин янында туктатып, күчтәнәч-фәлән алып чыккан булыр идек...
Исламның шушы юк кына сүзе дә күңелләремне җилкендереп, җан өргәндәй итте.
— Соң түгел әле,— дидем мин, кунакларның сүзен куәтләп.— Һадиң, әнә, автомашина бик ярата...
— Шулаймы? Ниндирәкләрне яратасың соң? — Бу сорауны да Ислам бирде.
— Рульле машинаны...— диде йомры баш, куллары белән машина йөрткән хәрәкәтләр ясап.
— Бик һәйбәт! Алабыз аны...— диештеләр кунаклар.— Рульле кирәк икән, рульлене алабыз.
Ул арада Һадия зал ишеген тагын да киңрәк ачып, кунакларны түргә үтәргә кыстый башлады. Ә андагы ындыр табагы кадәрле итеп киңәйтелгән өстәл өсте газеталар белән капланып куелган иде. «Тәки өлгергән...» дип уйлап куйдым мин.
Янис шактый ук үзенчәлекле кунак булып чыкты.
— Әгәр дә рөхсәт итсәгез, мин иң элек бер генә минутка салкын душ астына кереп чыгар идем,— диде ул.
Мин аның бу үтенечен шунда ук башкарырга әзер икәнлегемне белдереп, кунакка душны күрсәтергә булдым.
— Рәхим итегез! — дидем мин.— Суның салкыны да, кайнары да бар...
— Рәхмәт! Бик зур рәхмәт...
Утларны кабызып кунакны ваннага озаткач, яңадан коридорга чыктым.
— Менә, Һадия ханым, минем улым шушы була инде.— Аларны якыннанрак таныштыру иде минем максатым.— Ә бу, Ислам, минем фатирдашым. Җәй башында гына аларның гаиләсендә зур бәхетсезлек булды, ире автомобиль катастрофасында һәлак булды. Зинаида Ивановна да шул ук машинада иде. Бу турыда мин сина хәбәр иткән идем бит инде.
— Әйе.
— Әле дә ярый, Ислам, телеграммагыз бик вакытлы килде. Ике-өч көннән мина да командировкага.
— Кай якка?
— Мәскәүгә.
— Алайса, юлдашлар булабыз икән.

Һәдия ханым кухняга кереп киткән арада Исламның үз эшләре, ормышы белән кызыксынып куйдым.
— Андый-мондый үзгәрешләр юкмы әле? — Сүзнеерактанрак башарга иде исәп.
— Хәзергә юк,— диде Ислам.
— Диссертация ничек? Һаман да якламадыңмы әле?
— Юк.
— Ник сузасың?
— Вакытны әрәм итәсем килми. Икенчедән, оппонентларны, гыйльи советларны, ВАК[1] членнарын борчыйсым килми. Өлгерермен әле. ...ннары бит, белгәнеңчә, гыйльми исем алу җаваплылыкны да арттыра. ...л бит түләнергә тиешле вексель алу белән бер... Мин болай да өлкән ...кытучы, тагын ни җитмәгән?..
Ул арада шау-гөр килеп, юеш чәчләрен тарый-тарый, ваннадан ...нис килеп чыкты.
— Һай-й, шәп!..— диде ул, кирәгеннән артык канәгатьлек алган ке...едәй.— Җилкәләрдән тау төштемени, җиңеләеп калдым.
— Мин дә тиз генә кереп чыгыйм әле, алайса,— дип, Ислам да ...әһәт кенә ванна бүлмәсенә кереп бикләнде.
Янис белән минем кабинетка кердек. Ул тәмәке тартырга рөхсәт ...рап, сигарет чыгарды.
— Рәхим итегез, хөрмәтле Янис,— дидем мин, алдына көл савыты ...итереп куеп.— Иркенләп тартыгыз,— дип, тәрәзә ачып җибәрдем.
Кунак, уф-ф, рәхәт! дигән булып, йомшак креслога килеп утырды ...а тартәләрен сузып куйды. Шунда ук сигаретын кабызып, тирән итеп ...ырды, башын артка ташлап, түшәмгә таба бер-бер артлы боҗралар ...ибәрде...
— Ташлыйм, ташлыйм дип, ничә мәртәбә омтылып карадым, юк, ...лмый. Тәмәкесез яши алмыйм,— диде ул, акланырга теләгән сыман.
Читләтеп кенә эти-энияләре, туган-тумачалары, хезмәте турында ...раштыра башладым. Ишетергә теләгәнем Исламның эше, шәхси ...рмышы иде, әлбәттә.
Эти-энияләре исән-саулар, Таллин янындагы кечерәк кенә бер шәһәр...ктә яшәп яталар икән. Ә инде СССР Фәннәр академиясенең Себер ...үлеге турында сөйли башлагач, бик хәбәрдәр кеше булып чыкты, ис...итмәле саннар, фактик мәгълүматлар китерде. Бүгенге көндә анда ...легә якын фәнни-тикшеренү учреждениесе, аларда утыз меңгә якын ...ше эшли икән. Эстон егете үзләренең фән мастерскоенда, фәнне ясау...лар арасында яшәүләре турында бик тәфсилләп сөйләргә керешге.
Сүз һаман да Исламны читләтеп уза. Әңгәмәне уку-укыту мәсьәлә...ренә борып карыйм. Педагогның эше җиңеләйгәндер, чөнки бит хәзер ...арга кибернетика, «укыта» торган машиналар килүе турында бер-ике ...з кыстырып куям. Сизеп торам: кунак өчен кызыклы тема түгел бу. ...улай да әдәп йөзеннән генә, бары тик минем сорауга җавап бирергә ...рәк булганга гына сүз башлады.
— Әйе, файдаланылалар,— диде ул, сигаретының көлен кагып.— ...экин бит шул кадәресе дә бар: безнең академия гадәти уку йорты тү...л. Анда бары тик физика, математика кебек фәннәрдән бөтен Союз ...импиадаларында җиңеп чыккан сигезенче, тугызынчы, унынчы класс ...учылары өчен махсус программа белән укыталар. Анда, безнең уе...ызча, киләчәктә безнең фәнебезнең данын тагын да югарырак күтә...чәк булачак Эйнштейннар, Жолио-Кюрилар, Ландаулар укый... Шун...ктан бездә белем бирүнең үзенчәлекле яклары бар. Бәлки шуңа ...рәдер, бездә уку-укыту эшендә кибернетика, «акыллы» машиналар ...ллану, тәҗрибә күрсәткәнчә, тиешле нәтиҗәләрне бирмәде. Гомумән,

---
[1] ВАК — высшая аттестационная комиссия.

мин ул «акыллы» машиналарны фетишизировать итү ягында түгел. Кибернетика, «акыллы» машиналар һичкайчан да, хәтта киләчәктә дә тере кешене, галимне, тәрбиячене алыштыра алмаячаклар. Бигрәк тә педагогика өлкәсендә... Кибернетика психолог һәм физиолог була алудан хәзергә бик ерак тора әле.

Янис шул чак үзенең дә нәкъ Ислам кебек шул махсус программа белән белем алучылар арасында педагог булып эшләп караганлыгы турында сөйләп китте. Күп түгел, ике ел чамасы гына укыткан. Бөтен йөзе белән елмаеп, урынсыз сүз әйтергә җыенган кеше кебек күз карашын читкә алып, өстәп куйды:

— Аннары китәргә мәҗбүр булдым... Фауст әйткән бит: «Педагог буларак беттем, тагын шайтанга әйләнәм...» дигән. Мин дә фәнни эшкә күчтем. Яхшы педагог булып туарга кирәклекне бары тик шунда гына аңладым мин. Грекларда: белем бирү укучылардан түгел, ә укытучылардан башлана, дигән мәкаль дә бар.

Ниһаять, үзем теләгән сүзләрне дә ишеттем. Исламны профессиональ лектор дип атады, табигый талант, диде. Аның лекцияләрен бик яратулары, аның дәресләренә яшьләрнең бик теләп йөрүләре турында сөйли башлады. Аны нечкә психолог, эрудит, бүгенге яшьләрнең характерлы, үзенчәлекле сыйфатларын гына түгел, аларның хыял-омтылышларын да тоя белүе, аларның уй-фикерләрен, акыл-зиһеннәрен генә түгел, йөрәкләрен дә кузгата белүе турында мавыгып тезде дә тезде.

Ванна бүлмәсеннән чыгып килүче Исламны күреп алдым. Янистан сүзен бүлгән өчен гафу үтенеп, урынымнан күтәрелдем.

Шау-гөр килеп, кысташып, табын янына утырдык. Кунаклар да ачыккан икән. Утырышу белән алларындагы тәлинкәләрне салат, колбаса, редиска белән тутырып та куйдылар.

Тамадалыкны, өлкән кеше буларак, үз кулыма алдым. Һәдиянең, эшем бар дип, табын янына утыруга аяк терәп каршы торуы мәҗлеснең ямен җибәрә язды. Ислам белән Янис хәтта урыннарыннан сикерешеп тордылар, беренче рюмкаларны барыбыз да бергә күтәрәбез дип, Һәдияне кулыннан җитәкләп диярлек өстәл янына утырттылар.

Ниһаять, табын түгәрәкләнде.

— Я, җәмәгать!..— дидем мин, рюмканы кулыма алып.— Беренчесен кунакларыбызның исән-саулыклары өчен күтәрергә дигән тәкъдим бар.

Һәдия коньяк салган рюмкасына иреннәрен генә тидереп алды да, эшем бар дип, кухня ягына чыгып китте.

Кунаклар бик җәһәт керештеләр. Ул арада Һәдия безгә кайнар шулпа чыгарды.

Аштан соң өчпочмак килде. Бу кадәресен инде мин дә көтмәгән идем. Кунакларның да күзләре ут булды. Эстон егете исә: «О-о, менә, ичмаса!..» дип, тәлинкәсен ике куллап күтәреп үк алды.

Чыннан да, өчпочмаклар исләрең китәрлек иде. Йөзләре килгән, һәркайсы бер штамп астыннан чыккан сыман тип-тигезләр. Ит, суган, борыч, лавр яфракларының татлы хуш исләре борыннарга бәреп керә.

Тема да, кискен борылыш ясап, икенче юнәлеш алды. Сүзне телеграммадан башладым. «Кайтабыз» дигәч, әллә өйләндеме икән, дип уйлавымны әйттем. Һәм шунда ук:

— Сиңа, Ислам, утыз тула түгелме соң инде? — дип сорап куйдым.

— Шулай бугай,— диде ул, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән. Аннары ашыкмыйча гына кулъяулыгын чыгарып, калын кара кысалы зур күзлеген салып сөртте. Кулын алга таба сузып, тәрәзә ягына куеп карады: күзлек яхшы сөртелгәнме? Аның шулай минем сорауны гамендә алмавы күңелемне кытыклап куйды. Тукта, тагын бераз төрттергәндәй итим әле.

— Мин синең кебек чакта сиңа, беләсеңме, ничә яшь иде? Үнны тутырып килә идең, дүртенче класс укучысы идең.
— Соң син бит, әти, особый индивидуум.
— Ә сез, хөрмәтле Янис, өйләнгәнме әле?
— Юк, мин дә буйдак,— диде ул, сакалын чеметкәләп. Аннары берьюлы Ислам өчен дә җавап биргәндәй, елмаеп, өстәп куйды; — Һаман да шул бер бәла: вакыт җитми...
— Болай булса, электрон-хисаплау машинасына мөрәҗәгать итмичә булдыра алмассыз. ахры,— дидем мин, тегеләрне дә үз чиратымда кытыкларга теләп.— Тотасыз да: миңа хәзер фәлән-фәлән яшь, фәлән җирдә эшлим, фәлән сум хезмәт хакы алам, өйләнергә телим, дип мөрәҗәгать итәсез...
— Ә нигә? — дип элеп алды Янис.— Бу мәсьәлә буенча безнең республикада дискуссия оештырылды. Беләсезме, Германия Демократик Республикасында: «Яшем егерме икедә, аксыл-сары чәчлемен, буем 1 метр да 72 сантиметр, күзлек киям. Яхшы характерлы урта яшьтәге берәр иргә тормышка чыгар идем», кебек белдерүләрне газета-журнал битләрендә очратырга мөмкин.
Ә мин, Лейпциг шәһәрендә халыкара ярминкәдә вакытта, шулай электрон-хисаплау машинасы ярдәмендә барлыкка килгән гаиләдә кунакта булганымны сөйли башладым.
Юк эшне бар итеп, өстәл белән кухня арасында йөренгән Һәдия дә минем соңгы сүзләремне ишетеп: «Хакмы шундый хәл?» дип туктап калды.
— «Фюр дин» фирмасы сотрудницасы иде ул,— дип башладым мин.— Марта Фриш атлы иде. Башта бер егет белән очраша. Инде өйләнешәбез дип торганда, ни сәбәптәндер, теге егет ташлый моны. Фрау Марта, үзенең әйтүенә караганда, бик авыр кичерә бу хәлне. Көзге шыксыз кичләрнең берсендә, япа-ялгыз өйдә утырганда, газетадагы белдерүләргә игътибар итә бу. «Тол ирмен,— диелгән була анда.— Хатыным үлде. Үземә 34 яшь. Өч һәм биш яшьлек ике балам бар. Зурысы кыз бала, кечесе малай. Үземә турылыклы хатын, балаларыма һәйбәт ана булырлык кешегә өйләнер идем. Тәкъдимнәрне һәм фотоны «Дивоч» почтасына, фәлән-фәлән номерлы ячейкага җибәрергә». Марта ни булса шул булыр дип, фотосын һәм үзенең кем булуын язып, күрсәтелгән адрес белән җибәрә. Үзенең адресын да күрсәтә, әлбәттә. Җавап озак көттерми. Тол ир башта ике баласын алдына алып төшкән фотосын җибәрә. Марта фотодан күрә: ата балаларын ярата. Ә бала яраткан кеше киң күңелле, тулы мәгънәсе белән чын кеше була. Икенче хатта инде очрашу урынын билгелиләр. Үзләренең нинди рәк киемдә булачакларын язалар. Һәм, ниһаять, фрау Марта тормыш юлдашы буласы кешесе белән Көнчыгыш вокзалның платформасында очраша. Менә дигән гаилә корып җибәрәләр. Фрау Марта беренче очрашу моментын искә төшергәндә көлмичә булдыра алмый. «Ирем әле дә булса минем оялып, таш сын кебек катып калуымны мәзәк итеп сөйли»,— ди ул. Сүз арасында: «Баштагы бәхетсезлек булмаса, бәлки, мин бу бәхеткә ирешә дә алмас идем»,— дип өстәп куярга да онытмый Марта.
— Ләкин ул адым, сез уйлаганча, механик рәвештә генә эшләнми.— Бу сүзләрне Ислам әйтте.— Ул турыда язып, сөйләп, колакларны тондырып бетерделәр бит инде... Перфокарталары туры килгән кешеләргә җавап җибәргәләгәнче, бу мәсьәлә кабат-кабат, бик җентекләп тикшерелә. Тикшерү эшендә, кагыйдә буларак, психоаналитиклар, графологлар, физиономистлар, социологлар, экономистлар катнаша. Гаять зур һәм вәкаләтле комиссия эшли анда. Хәер, гаҗәп тә түгел, никахта, русча әйткәндә, бракта брак җибәрергә ярамый...
Табын янынан кузгалып, Ислам мине туктатты да:
— Әти,— диде, кеше ишетеп калудан курыккан кебек,— ишек ягы-

на күз төшереп алганнан соң.— Эти... Сезденме икән, Һәдия ханым кай ягы беләндер әниемә охшаган...— диде.
Тәнем эсселе-суыклы булып китте. Ул да булмады, яңак-битләремә кайнар дулкын бәрде.
Бер дә исем китмәгән кыяфәт белән:
— Ул кадәресенә игътибар итмәдем,— дигән булдым мин.

* * *

Ниһаять, балкон астында без көткән машинаның сигнал тавышы ишетелде. Барыбыз берьюлы балконга ташландык.
— Салют, Фомич!..— дидем мин.— Безнең хәлләр ничек?.. Булдымы?
— Булды, Имам Хисамович! — Күршем җаелеп елмайды.
— Анысы да яраган. Ә хәзер, Фомич, әйдә, кереп чык әле...— Баш бармагым белән чәнчә бармагымны тырпайтып күрсәттем.
— Хәзер ярамас, Имам Хисамович. Служба. Сез балыктан кайткач, уха ашарга керермен...
Без дәррәү кутәрелеп, йөгерә-чаба, әйберләрне машинага ташый башладык. Минут та үтмәгәндер, машина тирәсе капчыклар, сумкалар белән тулып өлгерде. Өеп-тезеп куйган әйберләрне күргәч, барыбыз да рәхәтләнеп көлештек.
— Бер машинага гына сыймас бу кадәрле әйбер, грузо-такси да яллыйсың калган, эти,— дип куйды Ислам.
Ансыз да үзен киеренке тоткан Һәдиягә шул җитә калды.
— Бәлки, безнең йөрисебез юктыр...— диде ул.
— Юк сүз сөйләмәгез, Һәдия ханым.— Урынсызрак сүз ычкындыруын Ислам үзе дә сизенде, ахрысы.— Сездән башка без анда ике кулсыз булачакбыз... Минем сүзләремне чынга алмагыз тагын. Бер юлга сыймасак, машина үз кулыбызда ич...
Һәдияне без болай да инде кырык алла, илле мулла ярдәмендә генә безнең белән балыкка барырга күндергән идек.
— Газ плитәсе алабызмы? — дидем мин.
— Һич кирәкми! — дип каршы төште Янис.— Уханың бар тәме аның төтен исе сеңүдә, янган учактан чаткылар чәчрәп төшүдә. Һәм кара күк гөмбәзендәге йолдызларның шәүләсе чагылуда. Соң бит, Имам Хисамович, янган учак янында утыру үзе бер гомер, үзе бер шигърият...
Балалар уянды. Бөтен өй эче хәрәкәт белән тулды. Һәркем үзенчә болгана-тулгана. Нурия әнисенә әйберләр биреп тора. Җыелган кашыклар, савыт-сабалар, чиләк-чүмечләр үзе бер ат йөге булыр. Шуның өстенә, әле берничә сумкага дыңгычлап тутырылган азык-төлек...
Нәкъ менә шул чакта килеп җитте дә инде Алексей Фомич. Әйберләрнең иләмсез күп икәнлеген күргән күршем: «Сездән эш чыкмас» дигән кыяфәт белән үзе үк төенчекләребезне тутырыша башлады. Палаткалар, матраслар, балта кебек нәрсәләр багажникка сыйды. Аннары барыбызга да машина эченә кереп утырышырга кушты. Аяк аслары, аллар яңадан әйберләр, төенчекләр белән тулды...
Мин рульгә утырдым. Янымa Ислам белән нәни ташбаш урнаштылар. Ә артта: Янис, Һәдия һәм Нурия.
— Менә булды да,— диде Фомич, ишекләрне һәйбәтләп ябып чыкканнан соң.—Ярар, җәмәгать, хәерле юл сезгә. Суалчан-кортлар банкаларда булыр... Машинаның чехолы да шунда, багажникта. Кояш астында бик кыздырмаска тырышыгыз.— Аның машина өчен янып-көюен беләм мин, шуңар күрә дәшмим. Менә ул соңгы күрсәтмәләр бирде дә: — Ну-у, ни пуха, ни пера! — дип, кабат кул изәде...
Кузгалдык. Түзә алмаслык бөркү. Шуның өстенә тагын бик кысын утыралар — селкенерлек тә хәлләре юк, тирә-якларына шыплап әйберләр тутырылган.

Олы юлга чыгу белән тизлекне арттырып, тәрәзәләрне ачып җибәрм. Яңа алды көне булгангамы, юлда хәрәкәт әллә ни зур түгел. Бераз-ң олы юлны читтә калдырып сулга борылдык. Арыш басуы башлан-ы. Беренче күргәндә яшел хәтфә кебек кенә булып җәйрәп яткан ыш хәзер инде баш кыса башлаган. Елга ягыннан искән талгын җил-ул чайкала, иге-чиге күренмәгән басу өстеннән, ерагая барган саен сләрен үзгәртеп, дулкыннар йөгерешәләр...

Бераздан офыклар ачылып, киңәеп китте: Кама өстенә килеп чык-ык. Машинадагыларга да җан керде.

— Да-а!..— дип сузып куйды Янис.— Чыннан да мул сулы зур елга эн.

— ГЭС плотинасы төзелеп беткәч, икенче як ярлары бөтенләй күрен-мячәк,— дидем мин.

Машинаны саклык белән генә текә яр астына алып төшәм. Су йлап бераз баргач, аны куе әрәмәлек каплаган, өскә авардай булып рган чамадан тыш биек кыя астында туктаттым.

Ишекләр дәррәү ачылды. «Уф-ф та уф-ф!» диешеп, барысы да маши-дан коела башладылар. Янис, үзе тотып килгән зур сумкасын бер ткә куйды да, кулларын алга таба сузып:

— Күрегезче, зинһар!.. Нинди матурлык, нинди хозурлык! Ә һава-!.. Юк, юк! Биосфераны харап итәбез дип коткы салучыларга ышан-ыйм мин. Күр син бу хикмәтне!..

Чыннан да искитмәле иде бу тирәләр. Ярларына сыеша алмыйча ама ага. Яшел яр буйларына гына күз сал син! Беренче тапкыр мон-а аяк басканда гына да бу тирәләр ул кадәр үк ямьле түгел иде. Хәзер ыяга охшашлы текә яр битләре гөлҗимеш, карлыган, зелпе куаклары лән капланган. Чак кына читтәрәк, үзәнлек башланган урында, куе ллык. Инженер Гургенидзеның туган көнен уздырганда табын хәзер-нгән урын, үзенә бер ярус булып, шактый өстә калган. Астарак тип-гез алтын-сары комлык ачылган.

Балык тотарга керешкәнче иң элек палаткаларны корып, утын әзер-п, казан асу өчен урыннарны җайлап куярга булдык. Күлмәк-майка-арны салып атып, машинадагы әйберләрне яр буенарак ташый баш-адык.

Ниһаять, казан асу өчен таган ясалды, палаткалар тартылды, атраслар өреп тутырылды, кирәк кадәр утын әзерләнде, ут ягылды, шмә суы белән мөлдерәмә итеп тутырылган чиләк учак өстенә элен-. Бары тик шуннан соң гына шау-гөр килешеп суга сикерештек... Іездек, су чәчрәтештек, чумып, төпнең ниндилеген тикшердек. Балалар урында әйткән дә юк, суда чупырдап рәхәтләнәләр генә.

Бер Һәдия генә коенмый. Учак янында кайнаша, палатка буенда бын әзерләп маташа. Яр буена якынаям.

— Һәдия, сез нишләп коенмыйсыз? — дим, аның тартынуын яхшы елсәм дә.— Көннең кыздыруын гына күрегез, чыдар чама юк.

Һәдия:

— Соңрак, эш беткәчрәк коенырмын,— дип җавап кайтарды.

Иң элек Һади кармаклы булды. Аңар ипи йомшагы изеп, ничегрәк теп кармакка утыртырга кирәклекне аңлатып, балык тота торырга уштык.

Янис безне дә эшкә кушты. Яр буйлап озын җепләр суздык. Бишәр-тышар кармак тагылган закиднушкалар ясадык. Бер башына курга-ыннан коелган батыргычлар бәйләп, ярдагы сыек колгага чорналган ашына кыңгыраулар куйдык. Аннары, кармакларга суалчаннар утыр-ып, берничә закиднушканы суга ыргыттык. Балык кабу белән кыңгы-ау безгә хәбәр салырга тиеш иде.

Кояш баю ягына авышса да, бик бөркү. Күлмәк-майкаларны кию к. Үзебез ялан аяк. Аяк астында коры комның кызу кайнар челлә

көндә кар шыгырдагандай сызгырып калуларын тою рәхәт тә соң!

Бераздан без дә кармаклар белән коралланып, өскәрәк, тирән урынгарак барып, балык чирттерә башладык. Бер салдык, ике салдык, балык бер дә кабам дип әллә ни атлыгып тормый.

Мин учак ягына күз салгалыйм. Әле яңарак кына Һәдия белән Нурия, кулларына сөлге тотып, су коенырга дип борылыш артына киткәннәр иде.

Әледән-әле пароходлар, баржалар, тиз йөрешле «Ракета», «Метеор»лар үтеп торганлыктан, су өсте тыныч түгел. Шунлыктан калкавычны күзәтүе бик кыен. Бөтенләй чиртмәгән дә кебек, ә кармакны чыгарып карасаң, җимнән җилләр искән.

Күзем палаткалар ягында. Әнә, Нурия, йөгереп килеп, ут янына чүкте. Бераздан борылыш артыннан чыгып килүче Һәдия дә күренде. Сөлгесен җилкәсенә салган. Туфлиларын сыңар кулына тоткан. Дулкыннар уйнаган яр буйлап су ерып килә ул. Әле яңа гына узып киткән зур пассажир пароходының эре-эре дулкыннары Һәдиянең аяклары тирәсендә шаулый... Ә ул чәчрәгән су чылатмасын өчен буш кулы белән чак кына күлмәк итәкләрен күтәргән. Читтән караганда Һәдия әле яңа гына буйга җитеп килә торган кыз баланы хәтерләтә. Бик тә төз, җыйнак гәүдәле, зифа буйлы ул.

Калкавычыма күз салам. Бер мәлгә су өсте тынып калган сыман булды. Шул чак минем аклы-кызыллы калкавычыма җан керде, башта калтыранган кебек бер урында биеп алды, аннары чак кына янтаеп читкә таба тартылды. Мин ялт кармакны үземә таба... Бар! Балык... Бармак кадәрле генә булса да бөтен ярны бер итеп:

— Булды!..— дип кычкырып җибәрдем.

Барысы да минем янга ташландылар.

— Нинди?..— дип сорап куйды Янис.

— Менә дигән комки,— дидем мин.

Янис ике сикерү белән минем янда иде инде.

— Монда бирегез, Имам Хисамович... Мин аны зур кармакка утыртып донкага салам.

Ул арада Ислам да: эһә-ә! дип аваз салды. Шул вакыт кояшның соңгы нурларында ялт-йолт килеп яр өстенә уч төбе кадәрле дәрән чабак очты.

Күп тә үтмәде, Һади да бөтен яр буен бер итеп: «Балык!..» — дип чырылдап җибәрде. Бармак кадәрле генә маймыч эләккән үзенә. Малайны: молодец, менә дигән балыкчы икәнсең, дип мактап күккә чөеп ташлау өчен шул маймыч бик җиткән иде.

Кояш баю ягына борылгач, балык та күңеллерәк чиртә башлады. Әмма бер генә дә менә, ичмаса, бу балык дип әйтерлеге капмады. Икеөч нәни алабуга белән биш-алты шыртлака өстәлде.

Ул арада сүрелә башлаган кояш кургашын төсенә кергән мул сулы Каманың теге яктагы үзәнлекләренә барып төште. Чык төшкәнгәме, тирә-як тötенли башлап, ак күләгә хасил булды. Су өстендә дә ефәктәй юка ак томан тирбәлә башлады.

Шул вакыт кулына шактый олы коштабак тотып, Һәдия килеп җитте.

— Кая балыкларыгызны бирегез,— диде ул.— Күз бәйләнгәнче чистартып куйыйм.

— Әни, менә минем балык,— дип, иң элек Һади үзенең елтыр маймычын савытка китереп салды. Аның янына безнең вак-төяк өстәлде.

Һәдия күзләре белән генә елмаеп куйды.

— Камада хәзер балык юк дип әйттем бит мин сезгә.— Аннары кабат биш-алты вак балык салынган коштабакка күз төшереп алды

да, Ислам белән мине чын күңелдән көләргә мәҗбүр иткән сүз ычкындырып куйды.— Минем әти дә балыкчы иде... Аның: «И-и ходаем, мәрхәмәтеннән ташлама, шундый балык тотсам иде, аның турында үлгәнче сөйләрлек, алдаламыйча сөйләрлек булсын иде», дигән сүзләрен еш кына ишеткәли идем...

Бу кызыкны Яниска да тәрҗемә иттек. Ул да рәхәтләнеп көлде. Шунда ук балыкчылар белән аучыларга бәйле булган берничә мәзәк тә сөйләп алдык.

Һадия ханым киңәш-табыш иткән сыман:

— Бәлки, ашарга башка әйбер әзерләрбез? — дип сорап куйды.

— Юк, уха пешерәбез...— дидем мин, кармагымны кабат суга ташлап.— Балык булырга тиеш. Менә тагын берәр тапкыр чиртсен дә...

Күзләрем калкавычта. Юк, чиртергә уйламый да. Кармагымны чыгарып җибәреп колгага чорнадым да яр өстенә аттым. Үзем туфлиларымны ялан аякка гына элеп алып, машина янына юнәлдем.

Багажникны ачып, почта ящигы кебек кенә бәләкәй суыткычны чыгарып, юк-бар балыкны чистарта башлаган Һадия янына килдем. Суыткычтан һәркайсы ким дигәндә килога тартым өч чөгә, бер кара-канат, олы гына бер сыла балыгы чыкты. Бу хәлне күргән Һадия ханымның күзләре шар булды. Балыкның шәплекләрен күреп мин дә: «Молодец, Алексей Фомич!» — дип, эчемнән генә мактап куйдым.

Кояш баеды. Елга ягыннан дымлы салкынча сулыш бөркелә. Өсләребезне киенергә мәҗбүр булдык. Ул арада анда-санда маяклар кабынды. Пароходлар, буксир-баржалар да төрле төстәге утларга төрендeләр. Төнге караңгылык торган саен куерганнан-куера барды. Каманың без урнашкан бу яктагы текә ярлары бераздан кап-кара тоташ урманга охшап калдылар. Калыкканда ничектер теләр-теләмәс кенә җемелдәшкән йолдызлар кинәт яңа көч белән дәррәү җемелди башладылар. Тирә-як тынлыкка чумды. Каманың бу яктагы текә ярлары артыннан, талгын гына агып яткан дәрьяны күрергә ашыккандай, искәрмәстән генә, ялт итеп, бөтен җиһанга нур сибеп, тулы ай калыкты. Тирә-як кинәт яктырып та, киңәеп тә киткән сыман булды...

Шул вакыт Янис, елан чаккан кеше сыман, искәрмәстән генә «ай-й!» — дип кычкырып җибәрде. Җәһәт кенә атылып торды. Башта нәрсә булды икән дип каушап калдык. Һадия дә ялт итеп безнең якка борылды.

— Ишетәсезме?.. Балык ич бу!..— Янис кыңгырау чыңы килгән якка торып йөгерде. Без дә аякланып Янис артыннан караңгылыкка ташландык.

Без килеп җиткәнче Янис инде җилканы кулына алып: — Бар!.. Балык бар... Сөкәне бирегез тизрәк!..— дип кычкырып, аяк терәп балык белән тартыша иде.

Ислам сөкәне эзли йөгерде.

— Нәрсә... Әллә миннән алган комкига капканмы?..— дидем мин.

— Юк. Зур гына ак корт утыртып салган идем. Тирес корты... Ай-яй, тарта!.. Кая, тизрәк бирегез инде сөкәне...

Ислам караңгыда әрле-бирле йөгеренсә дә, сөкәне таба алмады.

— Юк ул монда...

— Ай-һай!..— дип өзгәләнде Янис.— Бик көчле йолкына. Сөкәсез алу икеле булыр моны...

Мин дә яр буйларын караштыргалагандай иттем, әмма берни дә күренми. Моңарчы кирәге булмагач, кая булса да ташлангандыр инде.

— Хәерле булсын, тәвәккәллим...— диде Янис туфлилары белән суга кереп.— Чыгарып карыйм... Читкәрәк китегез... Дөпелдәмәгез...

Күз тәмам ияләшкән иде инде. Шул вакыт ярдан биш-алты метр чамасы читтәрәк зур гына балыкның су өстенә чыгып шапылдап сикергәне ишетелде.

— Әллә киттеме?..— Бу сорауны өне алынган Ислам бирде.
— Юк бугай... Тартыша,— диде тәмам тыны кысылган Янис.
Ярга якынлаша төшкәч, балык кабат суны бик яман шапылдатып алды.
— Ай-яй, яман кылана, хәерсез...— дип куйды тәмам хәлдән тайган Янис.— Җәен баласыдыр, ахры...
Көрәшә-тартыша торгач, Янис балыкны сайга, аннан яр өстенә комлыкка өстерәп чыгарды. Һәм яшен тизлеге белән балыкка ташланды. Алдан тезләнде, аннары табышы өстенә сузылып ук ятты...
Өч-дүрт кило чамасы зурлыгындагы кушбаш балыгы иде бу. Үзебез дә кала алган кешеләр сыман кыландык. Башта, балыкны кая куеп торабыз дип, байтак вакыт сүз көрәштердек, аннары инде катгый бер карарга килеп, саңагы аша тимер чыбык уздырдык та, суга җибәреп казыкка бәйләп куйдык.
Шуннан соң гына тыныч күңел белән уха ашарга утырдык.
Ятар вакыт җитте. Кемнең кайда йоклаячагы турында сүз кузгаттык. Зур палатканы Һәдия белән балаларга бирдек. Минем өлешкә кечкенә палатка тиде. Ислам белән Янис исә машина эчендә йокларга булдылар. Без шулай урын бүлешкән арада нәни Һади Ислам абыеның касыгына башын куеп йокыга да киткән иде инде. Һәдия аны: «Үскәнем лә! Эшләп арыган ул», дип күтәреп алып палаткага кертеп урнаштырды. Нурия дә шунда чумды. Бераздан табынны җыештырып, азык-төлекне палатка янына урнаштырып, күләгә кебек тавыш-тынсыз гына йөргән Һәдия дә юк булды. Без дә хәерле төннәр, тәмле йокы, матур төшләр теләшеп йокларга дип таралыштык.
Палаткада ятам. Аяк очымда гына вак дулкыннар чулт-чулт килә-ләр. Алар шулай үзләренә бер төрле бетмәс-төкәнмәс моң көйләгәндәй ярга кагалар. Сирәк-мирәк кенә пароход гудоклары ишетелеп куя. Ул да булмый, яр буенда эре-эре дулкыннар шаулашырга, чынлап торып актарылып ярга ыргылырга тотыналар. Димәк, янарак кына аскамы, өскә табамы пароход яки үзйөрешле зур баржа узган. Андый вакытта якында гына кыңгырау чыңлаган авазлар да чыгып куя кебек. Мин бөтен игътибарымны шул якка юнәлдерәм. Әмма дулкыннар басылу белән өзек-өзек кенә булып ишетелгән кыңгырау авазлары да тына сыман.
Ә уйлар, талгын гына аккан елга кебек, бер-берсенә ялганып кына торалар... Баянак килгәндә кайчандыр Зинаида белән бергә утырган урыннан узарга туры килде. Машинаны ул тирәдә туктатырга ничектер күңелем тартмады. Әмма күз салмыйча үтеп булмады... Учак күлен күптән инде җилләр тузгыткан, янгырлар юган. Бары тик шашлык кыздыру өчен тезеп куелган ташлар гына кара көеп яталар...
Әйтүләренә караганда, Зинаидаларның һәлак булган урыннары да шушы тирәдә генә. Ул да булмады, Зинаның моргта яткан мәете күз алдыма килде. Җан ачысы белән кычкырганга охшап авызы ачылган. Ап-ак тешләре күренеп тора. Кай җиредер түзә алмаслык булып сыкрап-әрнегәнгә охшап, чырае сытылган...
Минем уйларымны исәпкә алып барган счетчиклар сыман, аяк очындагы вак дулкыннар чулт-чулт итәләр...

* * *

Икенче мәртәбә командировкадан кайтканда, квартирым буш булып чыкты. Һәдия хат язып калдырган.
«Имам Хисамович! Ничек кенә булмасын, мине кичерерсез дип уйлыйм. Нишләмәк кирәк, кинәт кенә үзгәрә, кинәт кенә икенче кеше

була алмадым шул. Гафу итегез. Сезгә исә барысы өчен дә чиксез зур рәхмәт. Ярдәмегез зур булды. Малайны бакчага урнаштырдым. Кайчандыр алган һөнәрем дә үземә ярап куйды, кадрлар хәзерләү комбинатында буяучылар бригадасы белән җитәкчелек итәм. Дөресрәге, яшь-яшь кыз балаларны мастерок тотарга өйрәтәм. Тормышыбыз шулай тернәкләнеп китәр, ахрысы. Нургали өчен пенсия бик чамалы чыкты. Хәерле булсын инде, исән чагында да ул кеше кайгысын күрә дә, ишетә дә белми иде, үлгәндә дә адәм рәтле үлә алмады...

Ярар, Имам Хисамович, исән-сау булыгыз. Үз-үземне белешмичә катырак бәрелгән булсам, кабат үтенеп сорыйм сездән, зинһар, кичерә күрегез.

Ярар, хушыгыз. Тормышыгызда тынычлык, авыр хезмәтегездә зур уңышлар һәм какшамас сәламәтлекләр теләп калабыз.

Һәдия һәм бәләкәчләр».

Шушы ике-өч авыз сүздән торган язу бөтен барлыгымны айкап ташлады. Үземне нахакка рәнҗетелгән кеше сыман хис иттем. Тормышымның бөтен яме, максаты, мәгънәсе югалды. Һәдиянең бу адымы ничектер бик зур гаделсезлек булып тоелды.

Язуны кабат кулыма алдым.

Бары тик шунда язуның язылган көненә игътибар иттем. Моннан биш көн элек язылган. Димәк, мин командировкага киткәч әллә ни озак тормаган. Минем күздән югалуымны гына көткән...

Ниндидер бер томана «бәхетле картлык» дигән сүз чыгарган. Картлыкның кайчан бәхетле булганы бар? Картлыкның тыныч яки борчулы булуы мөмкин. Әгәр дә кеше картайгач та тирә-юньдәге кешеләрнең ихтирамын югалтмаса, тормышы, яшәү үрнәге белән үзеннән соң каласы буынның мәхәббәтен казанса, мондый картлыкны — сүз дә юк — тыныч картлык дияргә мөмкин.

Аннары тагын бер хакыйкатьне ачтым кебек мин: кырыкның аръягына чыккач, гомер дигәнең, ай-һай, тиз уза, күз дә ярми икән!

Башта, үзәгемне өзеп, балыкка баруыбыз исемә төште. Аннары барыбыз бергә җыенып сәфәр чыгып киткән көн күз алдыма килде. Һәдиянең шулай искәрмәстән кабаланып чыгып китүендә әллә Ислам гаепләме икән? Инде кузгалабыз дип кенә торганда, ул: «Минем Һәдия ханымның үзенә генә сер итеп әйтәсе сүзем бар», дип, чак кына кылангандай итеп, Һәдияне бер читкә алып киткән иде. Менә шунда Ислам Һәдиянең тиз җәрәхәтләнүчән йөрәгенә, килде-китте сүз әйтеп, агу салмадымы икән? Мин бит беләм, Ислам бер сүз белән кешене өнсез итә ала. Моны мин үз җилкәмдә татып караган кеше.

Һәдияне күрергә, аның белән кабат сөйләшергә дигән карарга килдем.

Иң элек кадрлар хәзерләү комбинатларына шалтыратып белешә башладым. Андый комбинатлар берничә монда. Ниһаять, ташчылар, штукатурчылар һәм буяучылар хәзерли торган комбинатта мастер булып эшләвен белдем. Икенче сменага чыгачак, диделәр.

Кичке сигезләр тирәсендә мин кадрлар хәзерләү комбинатының өчәр катлы корпуслары янында идем инде. Көннең әле сүнеп тә бетмәвенә карамастан, олы тәрәзәләрнең барысында да диярлек утлар яна. Аскы каттагы тәрәзәләргә күз салсаң, башлар... Шыплап тутырганнар диярсең.

Машинаны җибәрдем дә әчкә үтү өчен ишегалдына кердем. Түрдәрәк, ак таштан салынган мастерскойлар тирәсе мең төрле техника белән тулган. Анда моторлар гөрелтесеннән җир тетрәп тора. Егетләр, кызлар мәш килә. Булачак һөнәр ияләре.

Үземә кирәк корпуска кердем. Озын коридор. Тынлык. Аудиториялардән җиңелчә гөрелте ишетелә. Ишекләрдәге язуларга күз салам.

Менә буяучылар классы. Туктыйм. Ишеккә якыная төшеп, колак салып тыңлыйм. Юк, ир-ат тавышы.

Беренче катны йөреп чыкканнан соң икенчесенә күтәреләм. Карасам, укытучылар бүлмәсе. Машинкада баскан тавыш ишетелеп тора. Кердем, исәнләштем. Секретарь хатын эшеннән бүленеп урыныннан ук күтәрелде.

— Сезгә директор кирәктер инде? Кызганычка каршы, ул моннан ярты гына сәгать элек киңәшмәгә китте.

— Миңа бәлки сез дә ярдәм итә алырсыз? — дидем мин.

— Рәхим итегез! — диде ханым.

— Миңа Һәдия Вафинаны күрергә кирәк иде.

— Рәхим итегез! Хәзер табабыз аны... — Секретарь ханым ярты стенаны билэп торган расписание янына килде дә бармагын өстән аска шудырып төшерде.— Хм-м... Бүген ул практик занятие үткәрә икән шул.

— Практиканы кайда үтәләр соң?

— Автоградта, төзелештә.

Саубуллашып чыгып киткәнче кабат сорадым:

— Автоградка барсам таба алырмынмы?

Ханым зур пыялалы күзлеген рәтләп куйды да елмайды.

— Бик ашыгыч кирәк идемени соң? — дип сорап куйды.

Ханым миңа ярдәм итәргә җыенган кыяфәт белән җәһәт кенә тәрәзә янына барды, бер якка каерыла-каерыла ишегалдын караштырды. Аннары куанган тавыш белән: — Монда!..— диде.— Аларны төзелешкә илткән автобус монда. Хәзер шоферны табам да белешәм... Бәлки әле илтеп кайтырга да риза булыр...

Секретарьның коридор буйлап йөгереп үткәне аермачык булып ишетелеп торды. Бераздан алар шофер егет белән килеп керделәр.

— Николай,— диде ханым,— менә иптәшкә бая син автоградка илткән группаның мастерын күрергә кирәк. Ничегрәк табарга икәнлеген аңлатып бирсәңче...

Изүләрен чишеп җибәргән, базык гәүдәле егет ике авыз сүз белән әйтте дә бирде.

— Тугыз катлы торак йорт ул. Табуы бик җиңел... Аны Вазих Мавликов җитәкчелегендәге комсомолец-яшьләр бригадасы сала...

Секретарь Николайны бүлде.

— Анда бит, Николушка, йөзләгән бригада...

— Мавликовны белмәгән кеше юк. Комсомол съезды делегаты, ВЛКСМ Үзәк Комитеты члены дисәң теләсә кем әйтә дә бирә...

— Бәлки синең кешеләрне алырга барасың бардыр?

— Юк. Кайтканда алар өченче сменаны илткән вахта машиналары белән кайталар.

— Кара әле, Коля...— диде секретарь ханым, кабат шоферны бүлеп.— Иптәшне бәлки илтеп кенә кайтырсың, ә?..

Егет ут икән. Бераздан инде без автоградка таба элдертә идек.

Иске Чаллы артта калды. Алда ут дингезе. Анысы инде автоград. Юлда тоташ ташкын булып машиналар агыла.

Яңа калага кергәч, әллә ни ерак бармадык, шаулап торган төзелеш мәйданы каршында, тау-тау өелгән тимер-бетон плита, блок өемнәре янында туктадык.

— Менә шушы йорт,— диде Николай, салынып беткән тугыз катлы бинаны күрсәтеп.

— Бик зур рәхмәт сиңа, Николай. Минем дә бер файдам тиярга язсын.

— Сау булыгыз!

Сәгатемә күз салам. Унынчы ярты булып килә. Әле бит эзләп табасы да бар... Йортның подъездлары ишегалдында. Кызу-кызу атлап шунда юнәләм. Монда да шау-шу, көндезге кебек итеп яктыртылган ише-

галдында моторлар гөрелтесе. Балчык измәсен шланглар ярдәмендә югары катларга биреп торучы агрегатлар шулай шаулый.

Буяучылар дүртенче катта эшлиләр икән. Барысы да хатын-кызлар. Киемнәрендә акбур-измә таплары. Пумала тоткан житез-өлгер куллары күз иярми. Карыйм, ду китереп эшләүче буяучы кызлар бер дә инде практикантларга охшамаганнар. «Әллә өйрәнчек яшьләр кайтып киттеләрме икән?»

Ул да булмый, рәхәтләнеп көлешеп алалар. Шул вакыт аермачык итеп Һәдиянең тавышын ишеттем...

— Күрденме! — диде Һәдия, соклануын яшерә алмыйча.— Әнә, буяу ничек тигез ятты...

— Юк, юк, Нурия!.. Алай түгел. Астан өскә таба сыпырырга кирәк. Тукта!.. Тигезләгечнең өске өлешен чак кына, ярты гына сантиметрга күтәр. Югыйсә, әнә, күрәсең ич, «сөздереп» барасың.

Шул вакыт кызларның берсе мине күреп алды. Җәһәт кенә терсәген уйнатып: «Кара әле, кем бу?» дигән сыман күршесенең касыгына төртте.

Нәкъ шул секундта Һәдия дә миңа таба борылды. Кинәт үзгәрде, каушап калды. Ул да булмады, йөзенә кызыллык йөгерде. Өстендәге киемнәренә чәчрәгән измә тапларыннан берьюлы арынырга теләгәндәй, сыпырынгалап алды. Аның бу халәтен күргәч, шулай искәрмәстән генә килеп чыгуыма чын-чыннан үкенеп куйдым.

— Исәнмесез!..— дидем мин, бер-ике адым алга таба атлап.— Исәнмесез, яшь төзүчеләр... Кешеләргә куаныч бирүчеләр!

Кызлар дәррәү җавап кайтардылар.

— Рәхмәт, абый. Үзеңне монда бирсен!

Ул арада үзен кулга алырга өлгергән Һәдия дә, җиңел тужуркасының җиңен каерып, сәгатенә күз төшереп алды.

— У-у, кызлар!..— диде ул.— Ун тулып килә икән ич инде.— Бүгенгә җитәр... Инструментларыгызны җыеп куегыз да кабаланмыйча гына автобуска чыга башласагыз да ярый...

Кызлар: «Рәхмәт, Һәдия апа!.. Сау булыгыз!..» кебек сүзләр әйткәннән соң, чырык-чырык килеп, бөтен баскычларны бер итеп аска таба йөгерештеләр.

Буш зур бүлмәдә икәү генә калдык. Сизеп торам, мине күрү Һәдияне куандырмады.

— Бәлки, килеп дөрес эшләмәгәнмендер?..— дидем мин.

— Зарар юк. Безгә начальство килеп тора...— дип, тыныч кына җавап кайтарды Һәдия.

— Эшегез беттеме әле? Әйдәгез, автобуска чыгыйк. Юлдаш булырбыз...

Һәдия уңайсызлана калды. Аннары ирен чите белән генә елмаеп, өсбашына, измә чәчрәгән туфлиларына күз төшереп алды.

— Кыяфәтем нәкъ сезнең белән янәшә генә йөрерлек...

Шулай да автобуста янәшә утырабыз.

Һәдия минем белән таныш икәнлеген белдерергә теләмәгәндәй, таш сын кебек, карашын алга төбәгән.

Шулай, авызга су капкандай баруны килештермичә, үзем сүз башлап, балалар турында сорашырга булдым.

— Рәхмәт. Хәзергә исән-саулар,— диде Һәдия.

Әңгәмәбез янадан өзелде. Ул арада Һәдия: мин кайтып җиттем дип, минем белән саубуллаша да башлады. Ике-өч кенә кеше чыккан тукталышта мин дә төштем.

— Вакыт бик соң, озатып куйыйм...— дидем мин.

— Һәдия...— дидем мин, тавышымның ничектер калтыраныбрак чыгуын үзем үк тоеп.— Әйтергә теләгән сүзем шул минем... Нишләп алай

иттегез сез? Исәнме юк, сау булыгыз юк... Тотыгыз да, качкын кебек, китеп барыгыз, имеш. Алай кирәкмәс иде, минемчә.

Һәдия җавап бирергә ашыкмый. Бу минутта ул очы-кырые күренмәгән уйга бирелгәнгә охшаган иде. Тар күпер өстеннән янәшә атлап барабыз. Аннан-моннан каккалап куйган култыксалары булмаса, бу басма аша янәшә атларга һич кенә дә җөрьәт итмәс идең. Аякларыбыз астында кипшегән такталар дөпе-дөпе килеп, күңелле генә шаулашып калалар. Ниһаять, күпер бетте. Җиргә аяк бастык. Шунда ук тирә-як сәер тынлыкка чумды.

— Сезнең шулай искәрмәстән, кисәтү-мазарсыз китеп баруыгызга Ислам сәбәпче түгелдер бит? Саубуллашканда Сезгә нәрсәдер әйтте ул... Бәлки, хәтерегезне калдырырлык берәр сүз ычкындыргандыр?

— Юк, Имам Хисамович! Гөнаһлы була күрмәгез.

— Нәрсә диде соң ул? Чакырып алып...

Һәдия башын иде, кабат күзләрен аяк башларына төбәп, әкрен генә атлап кутәрелә башлады.

— Гаҗәп кеше сез, Имам Хисамович,— диде Һәдия, минем белән бер аяктан атларга ниятләнеп.— Кешене таныш-белү өчен әллә ни күп тә кирәкми. Мин дә сезнең турыда уйладым. Күп уйладым. Төрлечә уйладым. Ахыр чиктә: безнең арада үтә алмаслык упкыннар ята, дигән нәтиҗәгә килдем.

— Упкын? Нинди упкын?

— Упкын диюем, искә төшкәндә генә дә чиркандырып җибәрә торган, җан кайтаргыч вакыйганың кара күләгә булып ятуы ул. Сезнең шулай ялгыз калуыгызда минем дә гаебем бардыр кебек.

— Гаҗәп!..— дидем мин, аны бүлдереп.— Ә мин тагын ул вакыйгада мин гаепле дип йөри идем...

Һәдия дәшмәде. Бермәлгә икебез дә тынып калдык. Ул арада үргә менеп тә җиттек. Янә туктадык. Тауның иң башында торабыз, тирә-як уч төбендәге кебек. Кала ягында утлар, утлар...

Өзелеп калган әңгәмәне мин ялгап җибәрдем. Бу юлы «упкыннар» дигән нәрсәләрнең күплек санында әйтелүен Һәдиянең исенә төшердем.

— Анысын да әйттерәсезмени инде?..— диде ул, яңадан бу темага кире кайтырга теләмәгән сыман итеп.

— Әгәр дә кыенсынсаң, берәрсен бәлки мин әйтермен...

Һәдия ялт минем якка.

Әйтеп карагыз, алайса.

— Упкыннарның чираттагысы — минем шактый өлкән булуым, шулаймы?

Сирәк була торган күренеш, Һәдия чын-чыннан елмаеп куйды. Тирә-як яктырып та, ачылып та киткән сыман булды.

— Теләгән сурәттә сез әле япь-яшь кызга да өйләнә аласыз... Сезнең үлгән иптәшегезне дә япь-яшь, дөньяда бер сылу булган дип сөйлиләр. Ә мин нәрсә? Шуның өстенә әле, кем әйтмешли, «ике баласы белән, бәләкәй арбасы белән...» Шулай булгач, Имам Хисамович. Сез дә, үзегез әйтмешли, төптәнрәк уйлап карагыз әле...

— Ул турыда уйладым инде,— дидем мин.

— Нindirәк фикергә килдегез соң?

— Дөресен әйтимме?

— Әйтегез.

— Хосусый милек өстенлек иткән заманда ир белән хатын бер-берсенә бәйле булганнар. Итек басучы өйләндеме, хатыны да шул ук эшкә алынган: йон теткән, су кайнаткан, кирәк-яраклар әзерләгән. Хәзер заманалар үзгәрде. Бер үк эш белән шөгыльләнгән, бер үк урында эшләгән ир белән хатынны табуы кыен. Булсалар да андыйларның тормышлары кызык түгелдер, минемчә. Эштә дә, өйдә дә бер үк нәрсә турында сөйләш, имеш. Кешеләр, минемчә, бер-берсен тулыландырып,

фикер байлыгы естәшеп яшәргә тиешләрдер... Менә, мәсәлән, бүген мин үзем өчен гаять зур ачыш ясадым. Билләһи дип әйтәм, бүгенге көннән мин маляр булып эшли алыр идем төсле.

Һадия сүрән генә елмайды да:

— Көләсез...— диде.

— Юк, Һадия. Чын күңелемнән әйтәм бу сүзләрне. Син бит төзүче. Төзүчедән дә борынгырак, төзү эшеннән дә изгерәк хезмәт бармы дөньяда? Юк! Безнең илебездә бүгенге көндә һәр тугыз эшченең берсе — төзүче. Төзүче — дөньяның тоткасы. Мисал өчен безнең, инженерларның, хезмәтен генә алып карыйк. Аның барлык хыял-максатларын, еллар буе эзләнеп тапкан ачышларын, гомумән, бөтен фән казанышларын тормышка ашыручы кеше — эшче.

— Сезнең белән сүз көрәштереп буламы соң? — диде Һадия дә.

Күк гөмбәзен кискәләп бер-бер артлы йолдызлар атылды. Нишләптер еш атылалар алар. Моңарчы андый хәлне күргәнем юк иде.

Бер мәлгә тынып калдык.

— Нишләп туктап калдык соң әле без? — дип сорап куйдым мин.

— Чөнки кайтып җиттек...

— Шулаймы? Кайсы йорт соң?

— Менә монысы.— Һадия яр читенә үк китереп салынган җыйнак кына бер өйгә төртеп күрсәтте.

— Маякчылар өенә охшаган икән,— дидем мин.

Һадия чак кына гаҗәпләнеп:

— Шулай дип әйткән идеммени? — дип сорап куйды.

— Юк, син түгел. Бу турыда миңа Фомич әйткән иде.

— Һәйбәт кеше ул. Сәлам тапшырыгыз үзенә.

— Гомумән дөньяда әйбәт кешеләр күбрәк.

Бу фикер белән Һадия дә килеште.

— Шулай булмаса, яшәп торуның мәгънәсе дә калмас иде.

Аяз күк гөмбәзен сыегайтып, дәррәү ялтырап җемелдәгән йолдызларның йөгертелгән көмешен юып, бөтен офыкны иңләп таң беленде.

— Һадия...— дидем мин, аның саубуллаша башлавын көтмичә үк.— Әйт, тагын кайчан күрешәбез?

Һадиянең йөзендәге мөләемлекне кинәт кенә җил тузгыттымыни! Элеккеге монсу-боек кыяфәтенә кайтты да куйды. Аннары теләр-теләмәс кенә әйтте:

— Кирәк булырмы икән?..— диде. Әмма бу сүзләрнең хәтер саклап кына әйтелүен аңлау кыен түгел иде. Тел төбендә исә аның: «Килеп йөрмәвегез хәерлерәк булыр», дигән мәгънә ята иде.

— Алай димә, Һадия...— дидем мин.— Бәләкәчләрне.... күрүдән мәхрүм итмә мине... Минем бит әле Һадигә автомобиль дә алып бирәсем бар. Алып кайтам дип вәгъдә иткән идем ич.

Үгетли торгач, киләсе атнага, Һадия беренче сменада укытканда, килергә рөхсәт алдым. Һәм без тыныч йокылар теләшеп, куллар кысышып аерылдык.

Һадиянең җиңел тактадан гына эшләнгән капкадан кереп киткәнен көтеп тордым. Аннары инде үземдә җиңеллек тоеп, таудан түбән таба төшеп киттем...

Бу вакытта инде Кама өсте беленә башлаган таң яктысыннан алсукөмеш төскә кергән иде.

Буләк «автомобильне» машинага салдык та, юлга кузгалдык.

Күршем алдан ук әйтеп куйды:

— Өйләренә кадәр илтәм дә кире борылам. Кереп тормыйм...

— Ник алай?

— Шулай.

— Гаебең юктыр бит?

— Бар...— диде Фомич, минем якка күз салмыйча гына.— Бар. Сезнең сүзегез белән мин аны, теге вакытта, яшәп яткан җиреннән куз- гаттым... Аннары атналар буе килеп сарып йөрергә мәҗбүр булды.

— Аңар карап урамда калмаган бит.

Дәшмәде. Күзләренең агы белән генә минем якка карап алды да, машинаның тизлеген арттырып, үргә күтәрелә башлады.

— Әйтергә онытып торам икән әле, Алексей Фомич... Һәдия сиңа сәлам әйтергә кушкан иде.

Күршем җәһәт кенә минем якка борылды.

— Кайчан?

— Моннан атна-ун көн генә элек.

— Һы-ы!..

— Эх-х, Фомич!.. Белсәң иде икән... Аны күргәннән бирле әллә нәр- сә булды миңа. Әйтерсең лә талгын җил ун-унбиш ел элек гомеремне артка чигендерде дә куйды! Риза булса, мин аңар бүген өйләнер идем. Аңлыйсыңмы син шуны?..

Күршем сүз катарга ашыкмады. Әмма йөзенә карап: сезне мин мо- нарчы шактый ук акыллы кешегә санап йөри идем, дигән кыяфәтне укуы әллә ни кыен түгел иде. Аннары инде машина, олы юлга чыгып, тагын да җиллерәк алга ыргылгач, үзалдына сөйләнгән кебек кенә итеп фәлсәфә сатып алды.

— Әй-йе, әйбәт хатын! Чытлык адәм түгел. Шулай да бәхетле бул- маячак ул.

Аның бу сүзләре мине сагайтты, күңелемә шом салды.

— Туктале, Фомич... Ник алай дисең?

— Нилектәнме?

— Әйе. Мин: яратам, дигәннән чыгып әйтми торгансыңдыр ич?

— Юк, аннан әйтмим.— Күршем яшерен сер ачкан кеше сыман дәвам итте.— Күз карашына гына игътибар ит... Тел белән әйтеп аң- латып булмый торган моңсулык бар.

— Булса ни була?

— Безнең заман изге Мәрьям-аналар заманы түгел.

Ул арада без таш күперне узып, элеватор урнашкан районга барып чыктык. Якынайган саен дулкынлануым арта. Ничегрәк каршы алыр- лар икән? Бәләкәчләр өйдә булса гына ярар иде...

— Сулга!..— дидем мин, эре таш җәелгән тыкрыкка күрсәтеп.

Минем бик белдекле кыяфәт белән биргән бу әмерем Алексей Фо- мичны чынлап торып гаҗәпләндерде.

— Сез нәрсә? Аларда чыннан да булдыгызмы әллә?..

— А как же!..— дидем мин.— Минем кайчан шаярып сөйләшкәнем бар?!

Алексей Фомич сүзендә торды: Һәдияләргә кермәде.

Иң беренче булып мине кура җиләге, карлыган куаклары тирәсен- дә чуалган өлкән яшьтәге апа кеше күреп алды. Җыйнак кына гәүдә- ле, җиңел хәрәкәтле хатынга карап, йорт хуҗасы Гөлҗиһан түти дигән- нәре шулдыр инде, дип уйлап алдым мин. Ул да булмады, апа кеше кулындагы коштабагын җиргә куйды да, кулларын алъяпкычына сөр- тә-сөртә, баскычтан капкага таба илтә торган киң сукмакка чыкты.

— Ии-и, күрми дә торам! Кунак бар икән ләбаса!.. Ул башта өй- алды ишеген ачты, аннары: «Һәдия!.. Һәдия дим... Нишлисең дим... Нишлисең анда, чык тизрәк... Кунак бар...» дип шәррән ярды.

«Һәдия өйдә икән...» дип уйлап та бетермәдем, өйдән Һәдия үзе дә килеп чыкты. Аңар Нурия дә ияргән. Алар да миңа таба юнәлделәр.

— Исәнмесез!..— дидем мин, барысы белән дә берьюлы исәнләшеп.

Һәдия бу юлы ачык йөз белән каршылады. Чәче пөхтә итеп артка җыеп куелган. Өстендә, беренче тапкыр күргәндәге кебек, күз явын алырлык ап-ак кофта.

— Әйдәгез, рәхим итегез,— диде ул, безнең янга ук килеп.
Гөлҗиһан апа безгә авыз ачарга да ирек бирми.
— Әйдәгез әйдә, туганай, фәкыйрьлегебез йогар димәсәгез. Рәхим итеп өйгә узыгыз!..
Мин балалар коляскасы чаклы автомобильне баскыч янында җиргә куеп: «Һади кайда?» — дип сорадым.
— Әле янарак кына бакчадан алып кайткан идек үзен. Чыгып чапкандыр,— диде Һәдия.
Гөлҗиһан апа һаман үз дигәнен итә:
— Адәм әүлиялары икәнсез, туганай! Нарасыйларны сөендергәнең өчен ходай сөендерсен үзеңне!
Шау-гөр килеп өйгә кердек. Ишек тәбәнәк иде, иелеп узарга туры килде.
Без Гөлҗиһан апа белән аны-моны сөйләшеп алганчы Һәдия самавыр куеп җибәрде. Аны тышка чыгарып утыртты. Ян тәрәзәдән ишегалдына күз салам. Самавыр морҗасыннан чыккан зәңгәрсу төтен ефәк тасма булып, яртылаш корыган алмагачка сарыла...
Бераздан Һәдия бушады. Кунак кешенең үзен генә калдыруны яхшысынмыйча, өстәлнең икенче башына — минем каршыма килеп утырды. Күзләренә карыйм. Шул вакыт җанга рәхәт өстәрлек итеп оялчан гына елмаеп куйды. Һай-й, бу елмаю!.. Юк, Алексей Фомич! Бер ни дә булмаган бу күз карашларына. Өметсез моңсулык күрмим мин аларда. Кара син аларны, ничек нурланып балкыйлар!
Чәчләренә күз салам. Чаларган чәчләр күрергә өметләнәм. Гаҗәп хәл: баксам, күнелем белән чал чәчләр булуын телим икән! Менә бит хикмәт. Юк, күрә алмадым. Күз нурлары киселгән шул инде, картаю галәмәтедер. Шулай да, ут яктысында сыпылып чыккан кайбер чәч бөртекләре, бигрәк тә чигә тирәләрендә, чаларганга охшап җемелдиләр. Әмма бу җемелдәү, чаларган чәчтән битәр, сүрелә башлаган күмер өстенә утырган көлне хәтерләтә иде.
Нәкъ шул вакыт, капканы келәсеннән бәреп төшерердәй җилтерәп, Һади кайтып керде. Атылып керү белән баскыч төбендә торган автомобильне күреп хәйран калды. Шунда ук кочагына алып күтәрергә теләгәндәй, кулларын җәеп машина өстенә иелде.
— Егет кайтты,— дидем мин урынымнан кубып.
Кай арада машина эченә кереп утырган да кай арада рульгә ябышкан диген син аны! Әмма машина тиз генә буйсынырга теләмәде аңа, кәҗәләп торды.
Иң элек кул биреп күрештек. Аннары машинаның ни сәбәпле кузгалып китә алмавын ачыкларга кереште. Бөтен бәла аякларның педальләр белән идарә итә белмәвендә икән. Бу хәл бик тиз төзәтелде, Һади биш-алты минуттан бөтен ишегалдын бер итеп, түгәрәк ясап чабып йөри иде инде.
Чәй эчәргә чакырдылар. Һади чәйне иштергә дә теләмәде. Машина руленә ике куллап чатырдатып ябышып алган да, «тр-р-р!..» дип, моторын «кабызып» урамга ук чыгып китте.
Бу хәл Һәдияне борчуга төшерде.
— Бар әле, кызым, караштырып тор, теге ташбаш олы юлга чыкмадымы икән?..— диде.
Табын янында утырабыз. Өстәл өстендә, Гөлҗиһан апа әйтмешли, хәзинәдә бары. Урта бер җирдә өстенә яшел суган сибелгән йомырка табәсе. Атлан мае, ике-өч төрле вареньесы, башка төрле тәме-төме. Кура җиләге белән карлыган. Аннары тагын якты чырай, такта чәй...
Тик менә әңгәмәне генә ялгап алып китә алмыйбыз. Сүз җае чыксын дип, Гөлҗиһан түтинең бакчасын мактадым.
— Бакча болай ару иде дә, тик менә алмагачларның гына яме китте,— дип әлеп алды өй хуҗасы.— Узган кышта койма буена салган

көрт өстеннән күрше кәҗәсе төшкән... Ул алла каргаган мөртәтнең теше түгел, тыны гына тисә дә агач заты шундук корый. Шулай да, әнә, бераз яңарып-тернәкләнеп киткәндәй иттеләр. Нәрсә булыр тагын.

Сизеп торам, Гөлҗиһан түтинең дә әйтергә җыенганы «алла каргаган» күрше кәҗәсе түгел.

Бераз, дәшми генә, җиңнәрен тарткалап утыргач, ул тагын сүз башлады.

— Көн артыннан көн уза, ай артыннан ай уза дигәндәй, зерә дә заяга уза гомер. Мин үзем дә яшьли тол калдым. Ялгызлыкның нәрсә икәнен яхшы беләм. «Эх-х, инне иңгә куеп янәшә атлар кешең булсачы!..» дигән чаклар булды. Сине дә ялгыз дип ишеттем. Түгелгән тулы булмас, ди бит. Бик яман нәрсә. Ә ир-атка ялгыз яшәү аерата авырдыр инде ул...

Һәдия, ут кебек кызарып, миңа күтәрелеп карады да ишегалдына чыгып китте.

* * *

Ниһаять, көз дә килеп җитте.

Тагын командировкадан кайтып килән...

Дөресен генә әйткәндә, юлда булулар, күңелне баскан ялгызлык туйдырды инде. Министрлыкта яки главкада андый-мондый зурырак эш килеп чыктымы: сөйләшә беләсең, сүзең үтә дип, мине юлга озаталар. Хикмәт «сүз үтүдә» түгел, ялгыз башы, гаиләсе-фәләне юк, дип уйлыйлар.

Львовтан берьюлы ике телеграмма килеп төште. Берсенә Автомобиль промышленносте министрлыгы вәкиле, икенчесенә Украина Фәннәр академиясенең кибернетика институты директоры кул куйган. Телеграммаларында «КамАЗ»дан инженер чакыралар.

Казаннан Чаллыга самолет очмый иде. Вак яңгыр ява. Елга портына шалтыраттым. Тагын ярты сәгатьтән Чаллыга бердәнбер «Метеор» китәчәген әйттеләр.

Мин причал янына килеп җиткәндә, Чаллыга бара торган «Метеор»ның траплары алынган, двигателе дөпелди башлаган иде. Йөгереп килүемне күргән матрос, ябылган ишекне ачып, палубага сикереп төшәргә ярдәм итте.

Идел уртасына чыккач, «Метеор» бик җилле элдертә башлады, артында күбекләнеп су гына кайнап кала иде.

Идел өстен тутырып чал башлы дулкыннар йөгерешә. Шыксыз җил исә. Идел өстендә үк көзге болытлар йөзә. Көз көзлеген итә. Ярларның да яме беткән, моңаеп калганнар.

Мин Һәдияне уйлап барам.

Соңгы вакытларда без еш очрашабыз. Күбрәк вакытыбызны Кама буенда уздырабыз. Һәдия минем белән кинотеатрга чыгарга теләми. Гомумән, калада бергә күренүебезгә теше-тырнагы белән каршы тора. Шунлыктан без тотабыз да алар янындагы тыкрыктан елга буена төшеп китәбез.

Мин бу командировкага китәр алдыннан гына Кама буенда йөрдек. Искиткеч аяз, җылы, тымызык кич иде. Һәдия Исламның әнисе — Наҗия турында сөйләвемне үтенде. Ничек танышуыбызны да, бергә эшләвебезне дә бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Наҗия белән без бер азылнык идек. Әти-әниләребез, туганнар кебек үзара йөрешеп, бик тату яшәделәр. Әти үлгәч, әни дә чирләп урын өстенә яткач, безне тоттылар да кавыштырдылар. Икебез дә яшьләр. Чамасыз кыен, ифрат авыр еллар булса да, тормышның ул күләгәле ягына әллә ни игътибар итмибез. Бары тик бала туу, шуның артыннан ук әнинең үлеп китүе генә тормышка җитдирәк карарга мәҗбүр итте. Яшәгән барагыбыз искерде,

тәмам эштән чыкты. Аны җылыта алмыйча иза чигә идек. Бала тугач Нәҗия эштән чыгарга мәҗбүр булды. Карточка системасы. Бәрәңгене капчыклап яки потлап үлчәү юк, берәмлекләп санала... Акчаның да арзанайган чагы. Айлык хезмәт хакына базарда өч-дүрт бөтен икмәк ала алмыйсың. Шуның өстенә әле, эштән арып-талып кайту белән кичке институтка чыгып йөгерәм. Ягарга утын юк. Юлда такта-фәлән, бүкән башы очраса, калдырды юк. Нәни малайны плита өстендә тотып җылытабыз. Ул да, шайтан, белә, арты чак кына җылыны тою белән — елаудан шып туктый...

Ничек кенә авыр-кыенлыкта яшәсәк тә, Нәҗия, мәрхүмә, зарлануның нәрсә икәнен белмәде. Гел бер сүзне кабатлар иде: «Менә, укуыңны тәмамлап инженер бул әле, бар да рәтләнер». Ә үзе күзгә күренеп ябыкты. Шуның өстенә, бала имезә.

Шул чорда булып алган бер вакыйганы сөйләгәч, Һәдиянең күзләренә яшь килде. Көннәрнең берендә бик кирәкле сызымнарны өйдә калдырганмын. Яшәгән барагыбыз заводтан әллә ни ерак түгел иде. Мастердан рөхсәт сорап өйгә йөгердем. Минем искәрмәстән кайтып керүемне күргән Нәҗия кинәт каушап, югалып калды. Һәм җәһәт кенә, эленеп торган тастымалны йолкып алып, алдындагы кастрюльне томалады да куйды. Аның бу кискен хәрәкәте, капылт сикереп торулары мине дә сагаерга мәҗбүр итте. Мин моның серенә төшенергә теләп кастрюльгә таба атладым. Кулына бала тоткан Нәҗия: «Кагылма... Карама, Имам... Ризалыгым юк»,— дип, юлыма аркылы төште. Бу хәл миңа ошамады. Нәҗияне читкәрәк этәрдем дә, тастымалны йолкып алып, кастрюль эченә күз салдым. Баскан җиремдә телсез калдым. Ул бичара, мине ашатып-эчертеп эшкә озатып җибәрә икән дә үзе бәрәңгенең кабыгын пешереп ашый икән... «Нишлисең син, ә!..» дип кастрюльне идәнгә тондырганымны белешмичә дә калганмын... Ул көнне эштән соң өйгә кайтмадым, туп-туры тимер юл вокзалына киттем. Көз көне иде. Мин дә бер артельгә кушылып, пульман вагоннардан бәрәңге бушатырга ялландым. Төне буе эшләдем. Ә иртәнге якта, беренче трамвайлар кузгалу белән, ярты капчыктан артыграк бәрәңге, ике-өч баш кәбестә асып өйгә кайтып кердем. Икенче көнне дә заводтан туп-туры вокзалга киттем... Тик Нәҗия генә: әгәр дә укуыңны ташласаң, риза-бәхил түгел, ачка үлсәм үләм, ә бәрәңгеңә кагылмыйм, дип ультиматум куйды. Мин инде ул вакытта, укуны дәвам итеп булмас, институтны ташларга кирәк, дигән фикергә килгән идем. Нишләмәк кирәк, китап-дәфтәрләремне җыештырып эштән соң яңадан институтка барырга туры килде.

Һәдия Нәҗиянең ничек үлүен сорады. Барысына да шул фәкыйрьлек, хәерчелек гаепле. Яңадан бала булудан куркып, бик еш больница юлын таптарга туры килде анар. Рак авыруы башланды. Институтны тәмамлаган идем инде, тормышыбыз чын-чыннан җайга салынган иде, кайларга алып бармадым мин аны, нинди генә врачларга күрсәтмәдем, файдасы тимәде. Соң, диделәр. Үлгәндә дә: син, Имам, укыдың, инженер булдың. Ул яктан җаным тыныч. Тик менә Исламның гына үсеп җитеп, укымышлы кеше булуын күрә алмадым, шунысы үкенечле, диде.

Бу сүзләрне ишеткәндә, Һәдия елый иде булса кирәк. Миннән йөзен яшерә төшеп:

— Нинди олы, чын ярату булган!..— диде.

Ул көнне без Кама өстендәге маяк утлары тоныкланып, тәмам күздән югалганчы йөрдек.

...«Метеор» томырылып, зураеганнан-зурая барган дулкыннарны үткен борыны белән челпәрәмә китереп, һаман алга ыргыла. Тирә-якка мул булып тамчылар, су фонтаннары гына чәчрәп кала. Әллә болытлар

куерды, әллә карангы төшә башлады. тирә-юнь әнгер-мәнгер белән уралды. Сәгатемә күз салдым. Дүрт тулып килә. Хәер, караңгы төшүе дә гаҗәп түгел иде инде.

Ике яктагы ярлар да ерагайганнан-ерагая барды. Ул да булмады, алда тоташ утлар тезмәсе күренде. Димәк, Кама тамагына якынлашабыз...

Тиз йөрешле судноСЫЗ, чабыштан килгән ат сыман, ярсуын тиз генә баса алмыйча, зур гына бер дебаркадер янына килеп туктады. Бар курыкканым «Метеор»ның монда — Кама тамагында куна калуы иде. Юк, озак тормады. Бер-ике пассажир алды да янә юлга чыкты...

Бераз юл алгач, ялт итеп салоннарда, мин басып торган иркен коридорда утлар кабынды. Шуны гына көтеп торган кебек ярлар да юк булды, кайнап торган су өсте дә караңгылыкка чумды. Аның каравы, дулкыннарның шаулавы, көчәйгәннән-көчәя барган гөрелтесе аермачык, тагын да яманрак булып ишетелә башлады. «Метеор» дулкыннарның ярсып-ярсып китереп бәрүеннән чайкалып кына калмыйча, таралып китәрдәй булып тетрәнеп куйгалый. Вакыт-вакыт ул борыны белән бинһая зур дулкынга барып төртелә дә алгы өлеш кинәт кенә өскә чөелә... Ул да булмый, бер дулкын өстеннән очып үтеп бөтен авырлыгы белән икенчесе өстенә нәкъ буш тагарак кебек шапылдап барып төшә. Андый вакытта винтлар судан чыгып, яман шаулап, судноның бөтен корпусы таралып китәрдәй булып дерелдәп, тетрәп куя. Шулай зуррак дулкыннар арасына кереп чумар да, бүтән калка алмыйча, су төбенә китәр сыман тоела. Зинаны искә төшерәм, миңа ул барып туктар ярын таба алмый, дулкыннар эчендә югалган кебек тоела. Без берберебезне бәхетле итә алмадык...

Шул вакыт, уйларымны бүлеп, миңа утырырга ярдәм иткән матрос күренде. Өстән төшешли минем янда туктады да дусларча елмаеп:

— Бик чайкамадымы?..— диде.

Ул аска, машина бүлегенә төшеп, күздән югалды. Башымда ирексездән: әллә таныймы икән? дигән уй чагылып китте. Кабат сәгатемә күз салдым. Җиде тулып килә. Шул чак алда яктылык балкышы күренде. Якынайган саен бу балкыш көчәя барды. Бераздан инде ул бөтен офыкны иңләп, күк гөмбәзенә үрләп, таң атуын хәтерләтә башлады. Анда еллар белән, вакыт белән ярышып, батыр хезмәт белән барлыкка килгән Зәй ГРЭСы, Түбән Кама ГЭСы, автозавод һәм химкомбинат ТЭЦлары...

Якынлашкан саен йөрәк тә урыныннан кубып үзенә бер төрле сәер, шул ук вакытта рәхәтлек дулкыннарында тирбәлә башлады.

«Метеор» һаман алга ыргыла. Ниһаять, Яр Чаллы пристаньнарының, тау башына урнашкан ГЭС поселогының электр утлары да күренә башлады. Ул утлар, дәррәү кабынгандай, кинәт кенә ишәйделәр. Һәм безнең тиз йөрешле судноСЫЗ, яктылыкка килеп чыгып, сузып-сузып берничә тапкыр сигнал бирде.

«КамАЗ» эшли башлагач, заманча корылган матур, яшь автограднын егермешәр, егерме дүртәр катлы йортлары салынып файдалануга тапшырылгач, нинди рәк булыр икән бу тирәләр? — дип уйлап куйдым.— Ул чагында Каманың бу төбәгендә, гомумән, төн булмастыр...». Күрер идеммени мин шул дәррәү җемелдәгән Чаллы утларын, Кама таңнарын. Шатлыгымның тагын да зуррагы шул: мин бит һәдиялар янында ук төшәчәкмен. Хәзер әле соң түгел, сугылып чыкмыйча барыбер булдыра алмам. Билгеле, юл ватты ватуын, сакал-мыеклар да җитенке бугай. Шулай да...

Менә причалга да килеп җиттек.

Ашкынып-кабаланып тауга күтәреләм. Юл белән менәргә түземлегем җитмәде. Юлдан чыктым да, сыңар тәрәзәдән яктылык бәреп торган якка карап, турыдан гына күтәрелә башладым. Шундый текәлек,

ялгыш шуып кире төшеп китмәс өчен туфлием үкчәсенең кырыны белән, жиргә батырыбрак басарга тырышам...

Ниһаять, Һәдияләр йорты торган мәйданга күтәрелдем. Ут янган тәрәзә каршына килдем. Тәрәзәләрдә пәрдәләр. Бәлки әле ятып та бетмәгәннәрдер. Капкага киттем. Бикләнмәгән. Келәсен артык шалтыратмаска тырышып, ишегалдына уздым. Ишеккә кактым.

Ишеттеләр.

— Кем бар? — Һәдия тавышы.

— Бу мин, Һәдия...

Ишек ачылды да шундук ябылды. Караңгы өйалдында Һәдиянең кулын тоттым, кочагыма килеп сыенды.

— Озакладың...— диде пышылдап.

Өйгә кердек. Гөлжиһан түти дә йокламаган икән әле.

— Безнең югалган мосафирыбыз кайткан!..— диде Һәдия, куанычын яшерә алмыйча. Йөзе нурланып балкый иде..

Гөлжиһан түти дә, чаршау белән генә бүленеп куелган икенче бүлмәдән: әллә торыйммы? дип тавыш салды. Әмма мин: хәзер китәм, хәлегезне генә белергә кердем дип, аны бу уеннан кире кайтардым.

Караңгы бүлмәдән кыска штан, майкадан гына Һади килеп чыкты. Мине күрү белән яныма ташланды.

— Ник озак килмәдең?..— диде ул, муенымнан кочаклап.

— Көттеңме соң?

— Әй-йе!..

Малайның әле яңа гына юрган астыннан чыккан жылы гәүдәсен кочагыма кыстым. Нарасыйның бу жылылыгы кайнар дулкын булып йөрәгемә кадәр йөгерде. Әйтерсең лә мине ниндидер көч яңадан яшьлегемә кайтарды: гүя минем кулымда нәни Ислам, ә каршымда бердәнбер Нажия тора...

— Бар, улым, йокла... Соңыннан сөйләшерсез...— Һәдия малайны кулымнан күтәреп алып икенче бүлмәгә кереп китте.

Ул арада мин портфелемне ачып, өстәлгә апельсиннар, лимоннар чыгарып куйдым.

— Гөлжиһан түти,— дидем мин, йоклаган балаларны уятмас өчен ярым пышылдап.— Менә, мин сезгә монда бераз күчтәнәч алып кайттым...

Гөлжиһан түти шунда ук минем сүземне бүлде.

— Нинди күчтәнәч ди ул, туганай! Син үзең безгә...

— Һәдия!..— дидем мин аның үзенә генә ишеттерерлек итеп.— Озат мине...

Һәдия баш кагып ризалыгын белдерде. «Озатып куям...» дип Гөлжиһан түтигә дә әйтте. Тегесенең: барыгыз, бар... Рәхәтләнеп йөрегез...— дигән сүзләре ишетелде.

Гөлжиһан түтигә тыныч йокы, тәмле төшләр теләп ишегалдына чыктым.

Шундый рәхәт!.. Кайтып житүемә ышанасым килми. Гомумән, Һәдия белән очрашканнан бирле әллә нәрсә булды үземә: эшләве дә рәхәтрәк, яшәве дә күңеллерәк.

Тәрәзәдәге ут сүнде. Ул да булмады, өйалды ишегеннән ялт итеп, башына ак шарфын бәйләп, өстенә жиңел пальтосын киеп алган Һәдия күренде.

Урамга чыктык. Култыклап алдым үзен.

— Сагынып үлә яздым үзеңне...— дидем.

Һәдия дә миңа таба йөз биреп сорап куйды:

— Ничек кайттың? Самолетлар очмый иде ич...

— Белешкән идеңмени?

— Көн дә...

Үземнең жиде-сигез сәгать буена дулкыннар арасында чайкалуымны сөйләп бирдем.

Турыдан гына төшеп, тар күперне кичтек тә, Иске Чаллы урамнарына барып чыктык. Йөрүчеләр сирәгәйгән. Тыкрык башында җиңнәренә тасмалар бәйләгән бер төркем дружиначылар күренде. Араларында кызлар да бар.

ГЭС поселогына илтә торган асфальт юлга барып чыктык. Тротуар буйлап атлыйбыз. Аяк тавышларыбыз әллә кайларга ишетерлек булып яңгырап кала.

Шәһәр башланды. Як-ягыбызда бишәр катлы йортлар. Сирәк-мирәк кенә уникешәр катлылар да очрый. Урамнар ялт итеп тора. «Чулпан» кинотеатрында яңарак кына соңгы сеанс беткән булса кирәк, яныбыздан төркем-төркем булып яшьләр узып киттеләр.

Балалар турында, аларның киләчәге турында сүз алып барабыз. Тиздән музыка мәктәбе ачылачак. Нурияне шунда хәзерләргә кирәк. Берәр музыкант табып, өйдә дәресләр алгаламыйча булмас...

Менә безнең урам. Безнең йорт. Ишегалды. Штакетка белән уратып алынган бакчага яшь юкә агачлары утыртылган. Алар хәзер ярым шәрәләр. Аяк асты тулы коелган яфрак. Көннең көн буе бала-чагаларның чыр-чуы тынмый бу бакчада. Карты-корысы да шунда чыгып, эскәмиягә утырып, сөякләрен кояшта җылытырга яраталар.

Кайтып җиттек. Баскычтан күтәрелеп, квартира ишеге янына килеп туктадык.

— Әйдүк, Һәдия! Картлар әйтмешли, төкле аягың белән... тулы хокуклы хуҗа булып атлап кер. Шулай да бер шартым бар: бүтән ташлап китмәслек булсаң гына...

## Равил Фәйзуллин

# *ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР*

* * *

Әмәттә дә шул ук кояш,
Әлмәттә дә шул ук ай.
Тик гомерем язы гына
җәйгә авышты бугай.

Якын дуслар, күнче ятлар
бар анда да, монда да.
Кайда да җыр. Ил күңеле
дәрткә дә бай, моңга да.

Рухи байлык сөендерә.
Сиздерә юклыгы да.
Кайда да кирәк таяну
вөҗданың ныклыгына.

Бүген фейерверк чәчеп
фанфаралар уйнап та,
киләчәгең турында син
карамасаң уйлап та...

Нинди мәгънә буш иҗаттан,
бүгенге рәсми синнән,—
әгәр киләсе буыннар
чирканса исемеңнән.

Халык белән булсаң гына
хаклыкны танып була.
Янар йөрәгең булганда
кайда да янып була.

Кайда да кирәк шул вөждан,
иманыңның ныклыгы.
Яшермим, сиздерә кайчак
фидакарьләр юклыгы.

Үзгәрдемме? Сагынаммы?
Сагынмый буламыни!
Ялгышкан чаклар да булды,
абынмый буламыни!

Хыялларның да беразы
киселеп калды бугай.
Ул урынны күңелемдә
исәп, гамь алды бугай.

Әмәттә дә шул ук кояш,
Әлмәттә дә шул ук ай.
Мин генә бераз үзгәрдем
һәм олыгайдым бугай.

* * *

Еллар китә...
Чайкала-айкала
Иделдә ай кала.

Без китәбез...
Җир — бирә,
Җир — ала...
Озатып җыр кала.

* * *

Могҗизага яшьрәк чакта ышан.
Гөл асылын җәен өз икән.
Язгы эзләр белән килгән идем,—
сезнең урамда да көз икән...

Бер вакыты җиткәч кай җирдә дә
пәрәвез җепләрен җил өзә.
Әй, авыр, кайтмаска киткәнгә —
«озак йөрмә, тиз кайт!» — дип кул изәү...

* * *

Урсал тавында

Үрсәләнеп үрдә, һай, яна ут!
Шәфәкъка да карый, таңга да.
Бар януның мәгънә төсмерләре,
аңлый алсаң, барсы бар анда.

Барыбер түгел бөтен кешегә дә
килер буыннарның язмышы.
Җаны януларын шушы утка
тиңләп йөрүчеләр азмы соң!

* * *

**Кем шакымас толлар ишеген...**

Шакыдылар. Син ачмадың. Китте...
Корт иледәй купты бар шигем.
Ачу тынгач, аек акыл әйтте:
кем шакымас толлар ишеген!

Ни уй белән килеп, кем шакымас —
яхшылардан азмы яманы!
Толлар яше ачылана бара,
матурайган саен заманы...

Ирле хатыннарның кайгылары —
таңдук эрер җәйге бер кырау.
Толлар күңеле — тышы мәңге бозлы,
ә эче гел ут булган утрау.

...Әй, ул язгы төнге тамчыларның
котыртып һәм көлеп тамуы.
Урын җәйгән чакта бер мендәрнең
артык булып моңаеп калуы!

Сантый телләр әйтә: толлар бай ул,
алтыннан, ди, ишек төбе дә.
Толлар исә — ана назын биреп,
гөл үстерә тәрәз төбендә.

Ачу — бик тиз. Хөкем итү — җиңел.
Ирлек кирәк дөрес аңларга.
Толлар күңеленә рәнҗү салмас
ялгызлыкны татып караган!

...Хәзер менә кемдер шакып китте.
Ни уй белән килгән ул бәндә?
Икебезнең дә башлар иелгән,
нидер югалган күк идәндә.

* * *

**Мин диңгезгә таба китәм, дидең...**

«Мин диңгезгә таба китәм!» — дидең.
Гөрләвекләр буйлап йөгердең.
Нәфис иңнәреңне миңа кадәр
нинди җилләр кочып өлгерде...

«Мин диңгезгә таба китәм!» — дидең.
Гөрләвекләр буйлап йөгердең.
Ул еллардан бирле күргәнсеңдер
байтак матурлыгын бу Җирнең.

«Мин диңгезгә таба китәм!» — дидең.
Гөрләвекләр буйлап йөгердең.

Нигә дип соң әле кире кайттың,
чәчәк чагы үткәч гомернең?

Син диңгезгә каршы киткән чакта
озатып калган идем берүзем.
Яши торгач, һәркем бу дөньяда
таба икән үзенең диңгезен.

Тик шулай да килә синең белән
гөрләвекләр буйлап чабасы.
Үткәннәргә кайтып, син эзләгән
шул диңгезне килә табасы.

* * *

Яшьлегеңне, гомереңне
миңа багышладың да,
хәзер инде гел әзер тор
яңа сагышларыңа.

Мине яз дип белдең, ахры,
мин бит ноябрь сыман.
Кояшым аз, күгем тулы —
салкын яңгыр да томан.

Мин үзем дә белми торган
бер сәерлектә яшим.
Чиләләрдә кайчак өшим,
кышларны ярып яшьним.

Үзем дә кайчак төшенмим
күңелемнең хәлләрен.
Көтәм җылы ләйсән яңгыр,
чыга зилзиләләре.

Шулай барам мин таңнарга,
шулай чыгам мин язга.
Үземнең наз юк, ә үзем
шашам, туялмыйм назга.

Хисләр үзгә. Мәхәббәтне,
шәхесне аңлау үзгә.
Күпләр кебек гомер итеп,
тыныч яшәү юк безгә!

Мин, ахрысы, сабыйлыктан —
җырдан китә алмамдыр.
Сине беркайчан да тулы
бәхетле итә алмамдыр.

Мин әле син уйлаганча
тугры да түгелмендер.
Син белмәгән яралары
бар бугай күңелемнең.

Яшьлегеңне, гомереңне
миңа багышладың да,
өзер тор кайгыларыңа,
яңа сагышларыңа.

* * *

Зәй буенда сугыш уены.
Ак халаттан бар да ак карда.
«Сугышчылар» хәзер бүленми
кызылларга яки акларга.

Бер сүз — «дошман» — һәр як өчен дә,
«дошманыңны» юк ит, из, тапта!
Юри сугышуны бик җитди
командирлар күзәтә «штабта».

Бер вахтадан кайткан егетләр
Бер-берсенә каршы йөгерә.
Беренчесе «терелә» алганчы,
икенчесе «атып» өлгерә.

Берсе «газ!» дип, яман кычкыра,
сигнал бирә ракета чөеп.
Кайсы ава, кайсы йөгерә
башларына маскалар киеп.

Зурлар уйный, зурлар мәш килә.
Тавышлары җитә Бигәшкә [1].
Малай-шалай килгән карарга,
күбесенә булыр ун яшьләр

Авызларын ачып торалар,
онытылган чана шуасы.
Зурлар булып зурлар уйнагач,
малайларны ничек тыясың?

Малайларга кызык: «Урра!»лар
тәэсир итә әле, җилкетә.
«Сугыш» бетеп, өйгә кайтуга,
йомшак күмәч, җылы сөт көтә.

...Карт солдатлар бара азаеп.
Солдат уенында — яңалар.
Әллә инде сугыш зәхмәте
буыннарга күчеп ярала?..

Зәй буенда сугыш уены...

---

[1] Бигәш — авыл исеме.

* * *

Чабылгач та, таң атканда
чыклар белән кем көлә?

...Хәер, без үлән генә,
җирдә бер келәм генә!..

Кояшка дип, күккә багып
үскән идек гел үргә.
Яшәргәнне күрсәләр дә,
корган чакта кем күрә?

Хәер, без үлән генә,
җирдә бер келәм генә!..

* * *

Бала чакта — зур буласы,
кояш нурына тотынып,
тизрәк үсәсе килә.

Хәзер — язгы тамчы буйлап
гамьсез сабыйлык иленә
кире күчәсе килә...

* * *

**Бер хатирә**

Без Болгарда төн үткәрдек.
Йолдызлар якын иде.
Көймәгә түшәлгән печән
хуш исле, салкын иде.

Сихри төнге авазлар,
ахры, камыштан иде.
Без ул чак — яңа табышкан,
яңа кавышкан идек.

Яшь идек. Һәр таң безгә
көч алып килә иде.
Көлә идек! Безгә кушылып
дөнья көлә иде!

Таң алдыннан су коендык
аксыл томан эчендә.
Миннән башка ак тәнеңне
күрмәде бер кеше дә...

Сине тибрәткән дулкын да
миңа бик якын иде.
...Яр буенда безнең учак
һаман ялкынлый иде.

* * *

## Бер дуска

Син, әлбәттә, бездән акыллырак.
Бәлки үзең дә беләсеңдер.
Ә без менә һаман элеккечә —
күрәсеңдер.

Бездә әзрәк дуамаллык,
бераз баламишкинлык.
Аңа да риза. Алмасын тик
мушкасына — мескенлек.

Безнең балаларчарак шул
исәп тә, куаныч та.
Күпме кирәк бу дөньяда
без — коры куанычка!
Югарочтан сызгырсалар —
без хәзер шул ук очта!

Элеккечә — беркатлылык,
ышану, сусау назга.
Тубыклар көрткә батса да,
күзләр төбәлгән язга.
Һаман төшенеп җитеп булмый
яшәү хәйләләренә.
Куллардан бигрәк, җан белән
нык бәйләнгән бала чакның
әйлән-бәйләннәренә!

Син, әлбәттә, бездән акыллырак.
Миеңдә бар хөкемчең.
Безнең исә — шашкынлы хис
генеральный йөртүче.

Без чәчелдек бераз.
Мәхәббәттә,
эштә, уйда да.
Син, мөгаен, бездән акыллырак,
тик шулай да,
бәхетлерәк диеп уйлама!

* * *

Бай көз яхшы, тик шулай да
ярлы яз күркәмрәк.
Яз көне хаста җанның да
күңеле бүтәнрәк.

Әй, ул беренче чирәмнең
яшеле күренүе!
Бераз күшеккән күңелдә
өметләр терелүе!

Ни хозурлык — тамчыларның
кояшта көлүләре!
Әй, кызларның язгы кичтә
тәүге җилкенүләре!

Көз гел бөтен, бай булса да,
җилбәзәк яз дәртлерәк.
Язын бүтәнчә ашкыну,
язын бүтәнчә йөрәк.

Мин һәр яздан үзенә бер
яңа наз һәм ямь көтәм.
Көзге таңнарда уянып,
яз дип өмсенеп китәм.

Ишетелеп куя кебек
кайткан кошлар авазы.
Куркам тормышта җуюдан
мәхәббәт белән язны.

*1971—72*

## Габдрахман Минский

# СИНЕҢ ҖЫРЫҢ

### ӨЧ ПӘРДӘЛЕК ПЬЕСА

КАТНАШАЛАР:

Зариф — төзүчеләр бригадиры.
Зарифа — хатыны.
Мөнирә — яшь врач.
Фәрит — Мөнирәнең танышы.
Ульянцев — инженер-төзүче.
Валентина — хатыны.
Алмабикә — кранчы кыз.
Салават — колхозчы егет.
Булат — үзешчән сәнгать коллективы члены.
Зәйдүк — азгын егет.
Ибәт абзый — карт ташчы.
Станция дежурные.

Вакыйга безнең көннәрдә, яңа төзелешләрнең берсендә бара.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

#### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Тынлы оркестр гөрелтесендә пәрдә ачыла. Тимер юл станциясе алды — мәйдан. Буй-дан-буйга: «Коммунизм төзелешләре безне көтә!» дигән лозунг сузылган. Баганада — электр сәгать. Шау-гөр килеп, юл капчыклары аскан, гармун, гитара тоткан егетләр-кызлар төркеме уза. Бер кулында чемодан, икенче кулы белән хатынын кочып җитәкләгән Зариф керә.

Зариф. Я, наный, аерылышу минутлары җитте!

Зарифа. Ул ниткән сүз тагы?! Аерылышу? Телеңә тилчә!

Зариф. Бөтенләйгә димим бит мин!

Зарифа. Әй, ходаем... (*Яшен сөртә.*)

Зариф. Елама. Монда еларга ярамый. Әнә, «Елаган өчен биш тәңкә штраф» дип язып куйганнар...

Зарифа. Кайда?! Нишләп ярамасын икән? Вокзал булсын да ярамасын. Елыйсың килгәндә еламыйча түзеп кара әле син...

Зариф. Түзәм ич менә.

Зарифа. Яратмыйсың. Яратсаң түзә алмас идең.

Зариф. Ну, Зарифа! Сөйлисең сүз! Көл дә, ела да...

Зарифа. Ә син көлмә. Ела. Мин жәлке түгелмени!

Зариф. Жәлкесен жәлке дә бит... Сугышка китмим лә!

Зарифа. Яраткан кешеңнән аерылышу сугышка озатудан да кыен ул. Кем карар?

Зариф. Кайгырма, карчыгым, зарплатны аккурат җибәреп торырмын.

Зарифа. Үземне әйтмим мин. Сине кем карар анда? Пөрерсең ачлы-туклы...

З а р и ф. Йөрмәм! Чит илгә китмим бит. Кала салырга барам! Яхшы кешеләр аз дисеңмени андый төзелештә?

З а р и ф а. Кара аны, Зариф, яхшы кешеләр арасында берәр җан көеге табыла калса игелек көтмә. Барам да калагызга ут төртәм.

З а р и ф. Зарифа дим! Уйлап сөйләш. Кеше ишетсә ни дияр?!

З а р и ф а. Йөрәгем янгач әйтүем инде. Әйттем исә кайттым. Андый ярамаган эш эшлимме соң, аллам сакласын!

З а р и ф. Менә шулай. Яшеңне дә сөрт. Елама.

З а р и ф а. Елагач җиңел була.

З а р и ф. Сиңа җиңел дә бит... Миңа авыр менә. Синең күз яшеңне күрсәм, бәгырем телгәләнә. Прәме агу эчәрлек булам.

З а р и ф а. Шушы бер! Дурак сүз сөйләмә! Ярый, бетте. Әйбәт кенә барып җит, яме? Фатир алуга миңа телеграмм сук, яме? Бер кумыт булса да җиткән безгә. Очып барырмын. Минем өчен борчылма. Үзеңне кара. Ачлы-туклы йөрмә.

З а р и ф. Үзеңне дә онытма син. (*Кисәтүле.*) Кара аны, наный, сиңа хәзер ике кеше өчен ашарга, ике кеше өчен яшәргә кирәк!

З а р и ф а. Онытмам, җаным, онытмам. (*Аңа сыена. Тирә-ягына каранып берәүне дә күрмәгәч, Зарифның кулын алып корсагы өстенә куя.*) Сизәсеңме?

З а р и ф (*елмаеп, башы белән ымлый*). Дәвәйгән бу, әкәмәт!

З а р и ф а. Я, бар, кичекмә.

З а р и ф. Хуш, наный. (*Кочаклашып үбешәләр. Зәйдүк керә.*)

З ә й д ү к. Әй, Йосыф-Зөләйха! Вагонда ялашырга да калсын.

З а р и ф. Үзең болай әйбәт кенә күренсәң дә, эчтән бозыла башлагансың, ахры.

З ә й д ү к. Эчемә кереп чыктыңмыни?

З а р и ф. Күренеп тора. Тышыңа чыккан.

З ә й д ү к. Үлчәп сөйләш!

З а р и ф а. Мин сине шулай үлчәрмен... Бар, юлыңда бул!

З ә й д ү к. Китәм, китәм. Минем елап калучым юк бит. Аннары юлым да ерак түгел. Әнә, «Буфет» дигән язуны күрәсезме?! Әйдә, «өч борынга» кушылмыйсыңмы?

З а р и ф а. Бирермен мин сиңа «өч борын!»

З ә й д ү к. Ша! Аңлашыла. Усал хатыннардан ерак булуың яхшы, дигән Сократ Хәким исемле бер иптәш. (*Китә.*)

З а р и ф а. Әйдә, проводнигыңа ук илтеп тапшырыйм әле үзеңне.

Әйберләрен күтәреп чыгып китәләр. М ө н и р ә белән Ф ә р и т керә. Егетнең кулында бәләкәй матур чемодан. Кызның кулында сирень чәчәкләреннән букет.

Ф ә р и т. Нәрсә дип ашыга бу сәгать. Йөрми, чаба! Әллә инде менеп телләрен туктатырга?

М ө н и р ә. Сәгать телен туктатып кына вакытны туктатып булмый шул, Фәрит. Күп калдымы әле поезд китәргә?

Ф ә р и т (*ачу белән сәгатькә күрсәтеп*). Әнә ич — 10 минут.

М ө н и р ә. 10 минут!.. Ә аннары?..

Ф ә р и т. Ә аннары. (*«Дулкыннар» романсына импровизация ясый.*)

Минутлар, минутлар,
Ник болай чабасыз,
Ник болай ашыгып,
Кайларга барасыз,
Минутлар, минутлар!
Ник болай ашыгып,
Агыласыз атлыгып.
Очарга талпынган
Канатлы кош кебек.
Минутлар, минутлар...

Эх, канатлы кош булсаң иде...

Мөнирә. Нишләр идең?

Фәрит. Очар идем! Әкияттәгечә сине канатыма атландырып идем дә әллә кайларга алып китәр идем.

Мөнирә. Матур әкият.

Фәрит. Ә мин тормышыбызның да матур булуын көткән идем, Мөнирә.

Мөнирә. Монысы нинди җырдан?

Фәрит. Көләсең?!

Мөнирә. Көләргәме, әллә еларгамы?..

Фәрит. Соңыннан еламас өчен тынла киңәшемне! Вакыт әле узмаган. Минутлар әлегә безнең файдага йөри. Тагы биш минуттан — соң булачак. Китмә! Кал монда, иркәм...

Мөнирә. Монысы да таныш җырдан.

Фәрит (*аңламыйча, ачуланып*). Нинди җыр?!

Мөнирә (*әкрен көйләп*):

Син кал, иркәм, бездә, китмә, китмә
Дустың сине сөеп иркәләр.
Монда атсын синең бәхетең таңы,
Монда үтсен матур иртәләр.

Фәрит. Соң, мин нәрсә дим?! Мин дә сине шул бәхетле иртәләргә чакырам бит...

Мөнирә. Мин дә сине чакырам. Киттек бергә!

Фәрит. Аңла, Мөнирә, анда бәхет иртәсенә ерак әле. Анда бәхет кайгысы түгел, анда торак кайгысы. Брезент чатырларда, кысан вагоннарда яшиләр анда.

Мөнирә. Күп калдымы?

Фәрит. Нәрсә «күп калдымы»?

Мөнирә. Минутлар...

Фәрит. «Минутлар». (*Сәгатенә карап.*) Биш!

Мөнирә. Шушы кадерле биш минутта гына булса да миңа хәерле юл теләп аласыңдыр бит...

Фәрит. Ә минем хисләрем?.. Тойгыларым?.. Мәхәббәтем? Алар шушы дуамал биш минутта ишеләмени?

Мөнирә. Мәхәббәт канатлы да була бит, Фәрит.

Фәрит (*бердән өметләнеп*). Аңлыйм! Канатлы мәхәббәтең кире алып кайтыр димәкче буласың?..

Мөнирә. Киресенчә.

Фәрит. Аңламыйм.

Мөнирә. Сине очыртып алып килер димәкче булам. Килерсең бит?! Мин көтәр идем, төннәрен йокламыйча сагынып көтәр идем. Теге бер кыз кебек... Кинода... «Ал җилкәннәр» идеме әле?

Фәрит. Көтәрсеңме?

Диктор тавышы. Гражданнар, поезд кузгалырга өч минут вакыт калды!

Фәрит. Тагы минут. Ну, теңкәгә тидегез дә соң!..

Мөнирә. Хуш, Фәрит!..

Фәрит. Китте... (*Зәйдүк күренә.*)

Зәйдүк. Күрәм, яхшы ук борчылгансың син, егет. А... аңладым... Яна! Биредә (*йөрәгенә күрсәтеп*). Яна! Һей, безнең заманда йөрәк януын баса торган менә дигән бальзам бар. Әнә! Күрәсеңме?! «Бу-ф-фет» дип язылган. Йөрәк януның белөм мин нәрсә икәнен. Дошманыңа язмасын! Кем булуым кызыксындырамы? Әйтмим. Паспорт та бар минем, менә! Урак-чүкечле, шагыйрь әйтмешли. Күрсәтмим. Пычрана төшкән азрак, юарга кирәк. (*Поезд кузгала.*) Эх-ма! Киттеләр. Мин дә барам әле, кимсетелгән җанга җылы урын эзләп. (*Чыгып китә. Тимер юлчы — дежурный күренә.*)

Ф ә р и т. Китте!
Д е ж у р н ы й. Ә син калдыңмы?
Ф ә р и т (*өзгәләнеп*). Ә нәрсә эшләргә иде соң миңа?!
Д е ж у р н ы й. Анысын йөрәгең кушарга тиеш...
Ф ә р и т. Йөрәгем поездны туктатырга куша!
Д е ж у р н ы й. Һей... әйтте сүз! Эш поезддамыни? Аны туктатуы да ул чаклы читен түгел. Стоп-кранны тарттың — пажалысты! Яшьлекнең аннан да хикмәтле көче бар. Ул көч кешегә канат куя. Канат!
Ф ә р и т. «Яшьлек»... «Стоп-кран»... «Канат». Барысы да сүзләр. Сөйләргә бик өйрәндек! Ә хисләр?! Хисләр кайда? Эмоция! Сез, хөрмәтле тимер юлчы иптәш, мәхәббәт фаҗигасе кичермәгәнсез. Кичергән булсагыз, бу хәтле ансат фикер йөртмәс идегез. Йөрәк яна, аңлыйсызмы, йөрәк яна! Ничек басарга аны?!.. (*Бердән хәтерләп.*) А... әле генә теге егет нәрсә дигән иде әле?.. «Безнең заманда йөрәк януын баса торган менә дигән бальзам бар». Әйе. Барыем әле. Басып карыем әле йөрәк януын. (*Чыга*).
Д е ж у р н ы й. Күрдегезме егетнең хәлен?! Йөрәге яна... Ишеттегезме егетнең зарын! «Мәхәббәт фаҗигасе!» Көл дә, җыла да.

Кайдадыр маневр ясаучы паровоз тавышы. дежурный аңа кулындагы фонаре белән ишарә ясый-ясый чыгып китә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Тимер юлы разъезды. Зур булмаган ялгыз таш өй. Тирә-як — бушлык, дала. Вакыт таң алды. Күктә таң йолдызы яна. Ерактан поезд килгән тавыш. Тавыш якынлаша. Разъезд семафорының яшел уты кабына. Поезд тавышы һаман якынлаша, паровоз күзләреннән уты сәхнәгә тула. Поездның туктавы ишетелә һәм, минут узуга, кузгалып китеп тә бара. Сәхнәгә чемоданын тоткан М ө н и р ә керә. Артта җырлап килүченең тавышы ишетелә.

Таң таң ата,
Чулпан калка,
Таң чулпанны уята.
Кызарып таң аткан чакта
Җырлата да җылата...

Б у л а т керә. Ул Мөнирәне күрә.

Б у л а т. Здрасти!
М ө н и р ә. Сәлам!
Б у л а т. Һәй... Татар апасы икән.
М ө н и р ә. Әйбәт җырлыйсыз.
Б у л а т. Йөрәк янганда ярый шунда.
М ө н и р ә. Ник яна соң йөрәгең?
Б у л а т. Бәхет җимерелде әле, апаем, бәхет. Точнысы — җимерделәр. Төзелешкә килдегезме?
М ө н и р ә. Төзелешкә килүемне каян белдең?
Б у л а т. Бу разъездга бары төзелешкә килүчеләр генә төшә. Әлегә аны, мунча тазы кебек, номер саны белән атап йөртәләр. Әнә: «86 км». Ә килер шундый бер көн, бу разъездның даны барлык республикага яңгырар. Газеталарда да язарлар: «Элек бушлык хөкем сөргән урыннарда...» Красота!
М ө н и р ә. Алайса, сез дә төзелештән.
Б у л а т. Шулайрак.
М ө н и р ә. Нигә «шулайрак», ә «шулай» түгел!
Б у л а т. Летчиклар теле белән әйтсәк — «вынужденная посадка». Югыйсә, монда таба идемени минем юл?
М ө н и р ә. Ә кая таба иде?

Булат. Сәхнәгә! Менә кая таба!!
Мөнирә. Артист булырга теләгән идегезмени?
Булат. Була алам дип уйлыйсыз мәллә?
Мөнирә. Ә нигә? Сәхнәне сөйсәгез — булырсыз.
Булат. Шул сәхнә сөйгәнгә дә инде йөрибез, менә, су сипмәгән гөлләр кебек яныл-көеп...
Мөнирә. Төзелештә клуб юкмыни?
Булат. Төзелештә торырга урын юк, апаем!
Мөнирә. Ничек инде «урын юк»?
Булат. Ә сез сразы борыныгызны салындырмагыз. Сезгә табарлар. Палаткасы булыр. Яисә вагонда бер койка бирерләр. Берничә таш йорт өлгерергә тора. Но, анысы, мин уйлыймын ки, первым долгом, дигәндәй, кешесенә карап. Кызык та соң бу дөньяның хәлләре, ә? Берәүләр, ягъни менә мин, кала ягына ычкына алмыйча йөрим, ә икенче берәүләр, ягъни менә сез, үзегез теләп каладан далага киләсез, ә?!
Мөнирә. Коммунизмны калада гына төземиләр бит.
Булат. Беләбез лә анысын. Но, шулай да, әйтергә кирәк, кала җирендә ансатрак ул. Анда аның яртысы төзелгән дә инде. Ә монда җир казырга, таш ярырга, урман кисәргә кирәк. Төзүчеләр теле белән әйтсәк, нулевой эш әлегә монда. (*Паровоз тавышы ишетелә.*) Әнә, мин көткән тимер айгыр кешни башлады. Уралмаштан краннар килергә тиеш. Белеп кайтырга җибәрделәр. Көтәм дисәң, пажалыста, апкайта алам үзеңне.
Мөнирә. Рәхмәт, мине алырга киләчәкләр.
Булат. Ярый, алайса! Күрешербез әле. Төзелеш башлана гына. Тик сез минем баягы сүзләргә карап күңел төшермәгез. Барысы да булыр, барысы да! Мәскәүне дә берьюлы гына салмаганнар.

Поезд тавышы сәхнәне яңгыратып туктый. Булат ашыгып чыгып китә. Сәхнә иртәнге кояш нурларыннан яктыра башлый. Ирле-хатынлы икәү керә. Кулларында чемодан, төенчекләр, хатынның кулында чүлмәкле гөл.

Ульянцев. Валюша, кара! (*Кулларын җәеп тирә-якны күрсәтә.*) Нинди гүзәллек. Бу бит бөек художник — табигатьнең...
Валентина. Ах, калдыр, зинһар, Володя! Миндә хәзер художник кайгысымыни?!
Ульянцев. Валюша, синнән шундый сүзләр ишетәм?
Валентина. Ишетерсең дә! Чөнки мин хәзер йокысызлыктан миңгерәүләнгән.
Ульянцев. Аз гына түзә төш, аз гына.
Валентина. Мин утыз ел түзәм инде.
Ульянцев. Утыз ел түзгәнне утыз минут түзә алырсыңдыр бит? Тиздән безне алырга килерләр. Тиздән без үз куышыбызда булачакбыз...
Валентина. Гамьсез кеше син, Володя! «Куышыбыз», имеш. Әзерләп куйганнар, ди, синең өчен тугыз катлы өйнең тугызынчы катында квартира.
Ульянцев. Анысы да булыр.
Валентина. «Булыр». Шул «булыр» белән утыз ел син мине төзелештән төзелешкә өстерәп йөртәсең...
Ульянцев (*чыраен сытып*). «Өстерәп!» Нинди ямьсез сүз! Эх, Валюша, мин сине, шушы гөл кебек, күңелем түрендә генә саклап йөргәм бит. (*Житди.*) Валюша, дустым, син бик кирәк миңа бүген. Бик кирәк! Безнең дуслыгыбыз да Урал таулары буенда башланды бит...
Валентина (*онытылып*). Миасс елгасы буенда!.. Чиләбе трактор заводы салына башлаган көннәр иде. Мин, әле генә институт тәмамлаган кыз, әле дә хәтерлим, утыз беренче елның көзге төне иде. Чиләбе вокзалында поездддан төшеп калдым.

Ульянцев. Кем уйлаган, еракта калган шул көзге төндә, салкын Чиләбе вокзалында, мин, 24 яшендәге яшь төзүче, Валентина атлы кызны очратырмын дип...

Валентина. Син бик кузәтүчән, игътибарлы идең шул ул чакта. Әле дә хәтерлим, таң атып, шәһәр ягыннан беренче трамвай килгәнче син миңа салкын вокзалда туңарга бирмәдең, иңемә пальтоңны салдың...

Ульянцев. Ә кипяток табып китергәнне оныттыңмы?

Валентина. О... Ул көннәрне онытаммы соң!..

Ульянцев. Бүгенге көнебез тагын да матуррак! Шулай да, Валюша, мин синең әнә теге тирәләргә күз ташлавыңны теләр идем.

Валентина. Биш-ун минут кына күз йомып алуымны теләр идең, ичмасам.

Ульянцев. Йокы кирәме кешегә мондый сихерле таңда! Әйдә, Валюша, яшьлеккә әйләнеп кайтабыз...

Валентина. Синең шагыйрь буласың калган.

Ульянцев. Ә кеше, Валюша, күңеле белән шагыйрь булырга тиеш. Һәркем! Шул чагында гына без мәгънәле итеп яши алабыз. Яшәүнең күрке нәрсәдә? Бу сорауга галимнәр «хезмәттә — хәрәкәттә» дип җавап бирәләр. Килешәм. Бабайлар да бит «хәрәкәттә — бәрәкәт» дигәннәр. Хәрәкәт итү — иҗат итү дигән сүз, ә иҗат итү өчен кешегә кан тамырларыннан башка хисләр ташкыны да кирәк.

Валентина. Безгә хәзер, Володя, машина кирәк, аңлыйсыңмы, барасы җиребезгә тизрәк барып җитү өчен машина кирәк. Әнә, тегендә, лапаслар тирәсендә, ниндидер машиналар күренә башлады. Карап килим әле.

Валентина чыгып китә. Ульянцев ялгыз кала. Кесәсеннән бәләкәй тартма чыгара, ачып карый — буш, шул чагында Мөнирәне күреп ала.

Ульянцев. Исәнмесез? Хәерле иртә! (*Мөнирә утырган җирендә йокыга талган.*) О, гафу итегез, белмәдем. Йоклыйсыз икән.

Мөнирә (*күзләрен ача*). Ә... юк, юк. Болай гына. Исәнмесез!.. Сез мине алыргамы әллә?

Ульянцев. Сезне?.. Ә... әйе. Юк, мин... ни... Әлбәттә. Ягъни сез нәрсә димәкче буласыз?

Мөнирә. Мин төзелешкә килдем...

Ульянцев. А, әнә ничек икән. Бик әйбәт. Котлыйм, коллега! Бер язмыш кешеләре икәнбез...

Мөнирә. Сез дә врачмыни?

Ульянцев. Врач? Мин шулай врачка охшаганмыни?

Мөнирә. Бер язмыш кешеләре дисез ич...

Ульянцев. А... Ну, ягъни, без дә төзелешкә димәкче идем. (*Кинәт.*) Алайса, сез врач?

Мөнирә. Әйе, врач!

Ульянцев. Хөрмәтлем, сездә валидол табылмасмы?

Мөнирә. Йөрәгегез борчыймыни?

Ульянцев. «Борчыймы» дип әллә ни борчымый да, әмма бер валидол капканда зарар итмәс иде.

Мөнирә. Карап карыйм. (*Саквояжыннан таба.*) Менә, рәхим итегез.

Ульянцев. Рәхмәт сезгә. Доктор минем сезгә тагы бер үтенечем бар. Үтенеч дигәч тә, сезнең телдә әйтсәк, «врачебная тайна» кебегрәк. Эш шунда ки, минем сездән валидол сорап алуымны хатыным белмәсә икән....

Мөнирә. Хатыныгыз?

Ульянцев. А, әйе, сез йоклыйдыр идегез бит әле. Хәзер бирегә бер ханым керер. Валентина Сергеевна. Минем хатыным булыр ул. Ул белмәсен иде диюем. Югыйсә, паникага бирелүе бар. Үзегез беләсез, хатын-кыз халкы... (*Кинәт абайлап.*) Гафу итегез, хатын-кыз халкы дип, мин «әйбәт халык алар» димәкче идем.

Ашыгып Валентина керә.

Валентина. Володя, беләсеңме нәрсә, безне алырга ат җибәргәннәр!..

Володя. Әйттем ич, барысы да булыр дип.

Ибәт абзый керә.

Ибәт. Исәннәр генәмесез? Сау-сәламәт килеп җитә алдыгызмы?!

Ульянцев. Бик исән. Бик әйбәт килдек. Ә... кем...

Ибәт. Ибәт атлы булабыз.

Ульянцев. Әйбәт абзый!

Ибәт. Разыймын, Әйбәт абзый дисәң дә сүзем юк, әйе. Машина җибәрмәкчеләр иде. Каршы төштем. Ни өчен дип, мин әйтәм, хөрмәтле кешеләрне бензин сасысын иснәтеп кайтарабыз? Болын буйлап иртәнге саф һава сулап, хуш ис йотып, хозур кылып кайтуың, кем әйтмешли, үзе бер гомер бит ул, мин әйтәм.

Ульянцев. Гаҗәп тә дөрес әйткәнсез, Әйбәт абзый! Рәхмәт, алайса, болын буйлап диген, ә?!

Ибәт. Болын буйлап, җырын җырлап, һавасын сулап! Значетсе дигәндәй, сез, алайса, доктор?

Ульянцев. Мин инженер-төзүче.

Ибәт. Доктор да булыр дигәннәр иде.

Ульянцев. И... доктор?! Бар, бар! Менә ул. (*Мөнирәгә күрсәтә.*)

Валентина. Доктор?!. Аңламыйм. Сез доктор?

Мөнирә. Әйе, врач.

Валентина. Гаҗәп!.. Нишләп сез врач?.. Әллә сезне махсус җибәрделәрме?

Мөнирә. Әйе. Махсус.

Валентина. Ульянцевны каршыларгамы?

Мөнирә. Нишләп? Төзелештә эшләргә. Ирегезне мин беренче күрәм.

Валентина. Ә нишләп ул сезнең доктор икәнегезне белә?

Мөнирә. Ә без... ни... танышып өлгердек.

Валентина. Гаҗәп, гаҗәп... Танышып та өлгергәнсез. Сез, зинһар, мине ялгыш аңлый күрмәгез. Мин бит бөтенләй башканы уйлап борчылган идем.

Мөнирә. Нәрсәдән борчылырга?..

Валентина. Нишлим соң?.. Без хатын-кызлар шулай инде. Бу минем гел аның турында, аның авыруы турында уйлануымнан, күрәсең?.. Беләсезме, доктор, минем ирем авыру һәм хәвефле авыру, тик ул моны үзе белми.

Мөнирә. Нәрсә соң анарда?

Ульянцев белән Ибәт абзый керә.

Ульянцев. Валюша, бер вакытта да болай шатланганым юк иде. Беләсеңме, миндә хәзер шундый бер көч, шайтан алгыры, син минем күземә, Валюша, яшәрә барган төсле күренәсең. Йөзләрең алсуланган синең! Ә доктор чын мәгънәсендә шәфкать туташы. Шулай бит, Әйбәт абзый? Кара син аларга...

Ибәт. Таң атып кояш күтәрелгән сәгатьләрдә бар нәрсә шулай ямьләнеп, яшәреп күренә инде анысы. Табигать тә, кешеләр дә...

Ульянцев. Ишеттегезме?! Яшәреп һәм ямьләнеп!

Ибәт. Безнең яклар сихәтле. Барып ипиебезне ашап, суыбызны да эчкәч, гөл кебек ачылып китәрсез әле. Я, әйдәгез!..

Ульянцев (*шаян кыяфәттә*). Әйдәгез, карета безне көтә!

Ульянцев белән Ибәт абзый алдан чыгалар.

Валентина. Әнә шундый ул... Тынгысыз җан. (*Күз яшен сөртә.*)

Мөнирә. Нәрсә соң аңарда? Сез әйтмәдегез бит әле.

Валентина. Әйтергә дә куркам мин, доктор.

Мөнирә. Аңлыйм. Сез әйтмәкче буласыз аңарда...

Валентина (*куркып та, ашыгып та аны бүлә*). Юк, юк, мин аны әйтергә теләмим... Теләмим! Әйтмәгез сез миңа ул чирнең исемен.

Мөнирә. Ә сез нык булыгыз. Ныклык ул кешенең беренче ярдәмчесе.

Валентина. Рәхмәт. Рәхмәт сезгә, дустым!

Артта Ульянцевның тавышы: Ва-лю-ша!

Валентина. Әйдәгез, безне көтәләр. (*Чыга башлыйлар, Валентина кинәт борылып.*) Минем, доктор, сезгә бер үтенечем бар. Безнең бу сөйләшүләр ике арада калсын. Бигрәк тә Владимир Яковлевич белмәскә тиеш. (*Артта Ульянцев тавышы: Ва-лю-ша! Доктор!*)

Валентина. Киләбез!.. Киләбез! (*Чыгалар.*)

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакытлы баракларның берсендә Ульянцевлар квартиры. Уң як почмак ширма белән бүленгән, анда Мөнирә яши. Валентина иртәнге чәй әзерләү белән мәшгуль. Ул моны яратып һәм тырышып эшли. Уртада аш өстәле. Ак җәймә. Валентина үзе чәй әзерли, үзе ара-тирә тәрәзәгә барып тышны карый: «Кайтмыйлармы?» Экскаватор, бульдозерлар гөрелтесе, баракны дер селкетеп динамит шартлаган тавыш ишетелеп ала.

Валентина (*сискәнеп*). Ай! Өйрәнә алмадым бит шул шартлау тавышына. Иртә торалар да, бернигә карамый, төзелешкә чабалар. Ашау юк, эчү юк. (*Телефон шалтырый. Валентина ашыгып барып трубканы ала.*) Володя! Әгәр син мине бирегә, көн дә шулай, иртәнге чәйгә көтеп, зарыгып утырырга алып килгәнсең икән... Ничек борчылмаска?! Ничек ачуланмаска?! (*Бердән басыла төшеп.*) Кайтасыңмы? Менә әйбәт! Кайт, көтәм. (*Трубканы куя да яңадан ала.*) Коммутатор?! Медпунктны бирегез. Медпункт? Мөнирә Кәримовна? Карагыз әле, хөрмәтлем, вакытында ашап-эчүнең әһәмияте турында, ышанам, сез, докторлар, үзегез дә белә торгансыздыр? Чәйгә кайтыгыз. Хәзер үк! Бер хәбәр әйтсәм, оча-оча кайтасың инде анысы! Ә-ә, «Нинди хәбәр»ме? Хат бар! Берьюлы ике. Әһә, хәзер «кайтам» булдымыни... Тиз кайт. (*Трубканы куя. Көзгегә килә, ыспайлана.*) Хәзер кайталар. (*Ишек шакыйлар.*) Рәхим итегез!

Кыяр-кыймас Зариф керә.

Зариф. Гафу итегез, миңа Владимир Яковлевич кирәк иде.

Валентина. Владимир Яковлевич минем үземә дә бик кирәк иде, хөрмәтлем.

Зариф. Мин инде, үземчә, өйдә туры китерермен дип иртәрәк килдем.

В а л е н т и н а. Ә ул сездән дә иртәрәк чыгып китте. Ашамыйча, эчмичә! Хәер, аны аш-су түгел, бетон измәсе күбрәк кызыксындыра.

З а р и ф. Гафу итегез, Валюша апа...

В а л е н т и н а. Нинди йомышыгыз бар иде соң?

З а р и ф. Йомыш дип әллә ни зур йомыш та түгел инде ул...

В а л е н т и н а. Зур йомыш булмагач, нигә иртүк килдегез?..

З а р и ф. Эш сәгатендә вакытны алмыйм дигән идем. Аннары йомышым да минем үз йомышым кебегрәк... Казанга кайтып карчыгымны китерәсе иде.

В а л е н т и н а. Карчыгынны?

З а р и ф. Хатынымны дигән сүз, конкретно.

В а л е н т и н а. Хатыныгызны? Карагыз әле, егет, сез уйлап сөйлисезме, әллә уйламыйчамы? Ни өчен алып килергә булдыгыз әле хатыгызны?

З а р и ф. «Ни өчен» дип... Понятно инде, Валентина Сергеевна, сагыныла. Башта сагынмас кебек идем. Хатының яныннан бер чыгып киткәнче генә икән ул. Усаллыкларын да, тиргәүләрен дә, барысын онытасың. Фәрештәгә әйләнә дә кала, прәме.

В а л е н т и н а (*ачулангандай итеп*). Ә сез ирләр без хатыннарның теләге белән дә исәпләшәсезме соң?

З а р и ф. Исәпләшмичә! Мин үзем беренче йортлар салынып беткәнче сабыр итү ягында идем, юк бит, хат язган. Ну язган да инде, Валюша апа, хатны! Менә, шушы төшен генә тынлап карыйсызмы әллә? (*Кесәсеннән чыгарып хатны укый.*) «Сине сагынып сары сагышка сабыштым. Ятсам, торсам гел күз алдымда. Уйлансам уйга батам да, уйларым, күз яшенә әйләнеп, дәрья булып ага башлый». Монысын арттыра, кәнишне, ну, шулай да йөрәк өздергеч сүзләр болар. Хет китапка басып чыгар! Менә аның главные монда: «...Кечкенәбез көннән-көн үсә бара. Бик усал булыр төсле күренә. Барысын да сизеп, барысын да белеп ята. Борчылсам, каш-кабагымны җыерсам, хәзер тибешә башлый. Сиңа охшаган».

В а л е н т и н а. Кечкенәгез дә бармыни?

З а р и ф. Булачак.

В а л е н т и н а. Ай, ходаем, сез икегез дә шашканнар, аңлыйсызмы, шашканнар! Юк, егет, мин сезнең мондый дуамал эшегезне хуплый алмыйм. Владимир Яковлевичка да әйтәм: Не за что! Акылыгыз бармы сезнең?! Карчыгыгызга мин үзем хат язармын. Сез, чибәр егет, хатыныгызның кадерен белегез.

З а р и ф. Үз янымда яшәгәч, кадерлерәк булыр дигән идем шул мин...

В а л е н т и н а. Юк, юк, мин каршы бу эшкә! (*Телефон шалтырый. Валентина трубканы ала.*) Соңгарак кайтасың? Ни өчен? Хәзер кайта алмыйсың, Володя? Эш качмас. Хәзер кайт! Мин каршы... Володя!.. Володя!! (*Трубканы куя.*) Телефонда сөйләшергә дә вакыты калмый башлады бу кешенең.

З а р и ф. Без бүген «Беренче»нең этажларын сала башлыйбыз шул. Ярый, мин дә киттем инде...

В а л е н т и н а. Егет, сез миңа бер яхшылык эшли алыр идегезме?

З а р и ф. Бик теләп.

В а л е н т и н а. «Бик теләп» дисез икән, хәзер үк барыгыз да Владимир Яковлевичны эзләп табып өйгә кайтарып җибәрегез.

З а р и ф. Була ул. Тик сез миңа юкка ачуланасыз, Валюша апа. Мин бит карчыгымны китергәч, аңа да, миңа да әйбәт була. Әнә, сез ничек Владимир Яковлевичны кайгыртасыз.

В а л е н т и н а. Сез гамьсезләрне кайгыртырга да кеше кирәк бит.

З а р и ф. Мин дә шуны әйтәм ич! (*Чыга.*)

В а л е н т и н а (*ялгызы*). Ах, бу ирләр. Хәер, аларга бераз гамьсез булу да килешә кебек. Балага охшап куялар.

Мөнирә керә.

М ө н и р ә. Уф... Кѳчкә кайттым. Шундый эш күп. Я, көттермәгез инде, Валюша апа!

В а л е н т и н а. Ә мин сезне көткәндә әйбәтме? (*Ясалма җитдилек белән әмер иткән булып урындыкка күрсәтә.*) Утырыгыз! (*Мөнирә утыра.*) Эчегез! (*Мөнирә стакандагы сөтне эчә.*) Менә шулай. Бу студентка чакта, хат килсә биетмичә бирми торганнар иде. Ә миңа биетәсе урынга ашатырга туры килә. (*Ике хат бирә. Мөнирә йотлыгып хатларны укый.*)

М ө н и р ә (*хат укыган арада*). Әткәй белән әнкәйдән. Сезгә бик күп сәлам. Менә тыңлап кына карагыз: «...Бигрәк әйбәт кешеләр икән. Сине үз канат асларына алуларына без бик шат. Алар безгә туганнарча якын булып киттеләр. Бүгеннән ары Ульянцевлар безнең бик әйбәт танышларыбыз булачак...» (*Икенче хатны ала.*) Ә монысы минем кечкенә генә секретым.

В а л е н т и н а. Йөрәк серегездер әле?.

М ө н и р ә. Шуңа охшаш.

В а л е н т и н а (*бердән тәэсирләнә*). Ах, ул йөрәк сере!.. Әле дә хәтеремдә. Володя белән танышкан айларыбыз. Безнең Володя егет чагында бик юаш, оялчан табигатьле иде. Әле дә онытa алмыйм: бер вакыт, шулай, театр фойесында йөргәндә, мин моңа: «Ни өчен син мине култыклап алмыйсың?» — дип үпкәләгәндәй иттем. Егетем каушап төште. «Валечка, зинһар, ачуланма, мин бик теләп култыклар идем дә... Оялам»,— ди. Ә бүгенге яшьләр, оялмыйча, кѳпә-көндез урамда кочаклашып йөриләр. Кыяфәтләре! Сакал-мыек, попныкы кебек чәчләре, белмәссең: кайсысы егет тә кайсысы кыз. Ә безнең яшьлек... Менә Володяның шул еллардагы фотосы. (*Стенадагы фотоны алып Мөнирә янына килә, ләкин Мөнирәдә кинәт туган ниндидер көнчелсезлекне күрә.*) Күрәсеңме, нинди пөхтә ул минем Володя...

М ө н и р ә. Ул сезне... рәнҗетми идеме?

В а л е н т и н а. Мөнирә Кәримовна, ни өчен мондый сорау? Ни өчендер үзгәрдегез кебек тә... әллә....

М ө н и р ә. Ашыйсым килгәнгәдер. Ай, нинди тәмле беленнәр.

В а л е н т и н а. Володя да бик ярата беленне.

М ө н и р ә. Валентина Сергеевна, ә сез Владимир Яковлевичны бик ярата идегезме?

В а л е н т и н а. Ни өчен «идегезме»? Сезгә нәрсә булды? Нигә узган эш итеп сөйлисез?

М ө н и р ә. Яшь чагыгызда дип сорамакчы идем мин.

В а л е н т и н а. Яшь чагында кеше беркадәр тилерәк була ул. Бар ялтыраган алтын дигән кебек, барысы да мәхәббәт аңа. Мәхәббәтне, дустым, киләчәк өчен саклый белергә дә кирәк. (*Телефон шалтырый. Мөнирә трубканы ала.*)

М ө н и р ә. Тыңлыйм. Шулаймы? Ярый, хәзер, хәзер. (*Трубканы куя.*)

В а л е н т и н а. Володямы?

М ө н и р ә. Мине чакыралар. Бер яралыны китергәннәр. Ашыгыч, ди. (*Халатын, халат өстеннән плащын киеп чыгып китә.*)

В а л е н т и н а. Өзеп кенә ташлыйсы шул телефонны...

Ибәт абзый килеп керә.

И б ә т. Өйдә икәнсез, Валентина күрше!

В а л е н т и н а. Кайда булыйм соң? Мин бит өй колы.

Ибәт. Өй күрке диегез. Өйне бит аны, Валентина күрше, гөлләр үзләре генә бизәми. Кешесе дә кирәк аның. Инженер иптәш кайда соң?

Валентина. Кайтырга тиеш. Чәем әзер менә.

Ибәт. Чәйгә бал да әзер менә.

Валентина. Бал?!

Ибәт. Башкорт балы! Чәчәк балы! Шифалы зат. Владимир Яковлевичның үз заказы.

Валентина. Бал сорадымы?..

Ибәт. Сорадымы дип... мин үзем киңәш иттем. Бер көн шулай очрап сөйләшкәндә, йөрәгеннән зарланды бу. Ә минем әткәй карт андый зарның мәгънәсен яхшы белә. Исән. Туксан биш белән бара. Бала чактан умартачылыкта үскән. Хәзер дә колхозда шул эштә. Ашаганы бал. Бал кешенең йөрәк тамырларын ныгыта, ди. Ә йөрәк тамыры нык кеше озын гомерле була икән. Әткәй моны, үзенчә, бик гыйбрәтле аңлата: сәгатькә пружин ничек кирәк булса, йөрәк тә кешегә шул чаклы кирәк, ди. Пружинасы өзелеп туктаган сәгать кебек, кеше дә йөрәк тамыры өзелүдән шып туктый икән. Менә, ашасын әле. Әткәй балы бу.

Валентина. Рәхмәт инде. Күпме бирим? Бәясен әйтмәдегез бит.

Ибәт. Шифасы тисен дип биргән әйбернең бәясе булмый аның. Ярый, хушыгыз, эшкә кичегәм. Без бит бүген беренче йортны сала башлыйбыз. Беренче йортны! (*Чыга.*)

Валентина (*ялгызы*). Володя йөрәгеннән зарланган. Миңа әйтми. Мине белми дип уйлый. Шуларны уйласам, үз йөрәгем дә сызлый башлый. (*Ульянцев керә.*) Володя, кайттыңмы?

Ульянцев. Бик азга, бик азга. Бер стакан чәй эчәрлек кенә вакытым бар. Ну, ике стакан. (*Өстеннән сала, сөйләнә-сөйләнә кулларын юа.*) Беләсеңме, Валюша, мин кемне очраттым. Алмабикәне! Ну да, бу әле сиңа бернәрсә дә аңлатмый. Миңа сүзне беркадәр тарихка кайтып, 1930 елларда Чиләбе трактор заводы төзелешендә эшләгән көннәрдән башларга кирәк икән. Шул елларны, мин бригадир булып эшләгәндә, бригадамда Рамазан атлы бер башкорт бар иде. Мәһабәт буйлы, чем кара сакаллы, Спартак диярсең. Оста куллы ташчы иде. Шул кешенең Алмабикә исемле виучкасы бүген минем участокта эшли икән. Әгәр син аны күрсәң!.. Чын мәгънәсендә Алмабикә. Безнеңчә тагы да матур яңгырый: Яблонька!

Валентина. Чәең суына.

Ульянцев. Чәй?! Ах, чәй... (*Өстәл кырына утыра. Кулына стаканны ала һәм тагы онытылып сөйли башлый.*) Авыллары ерак түгел икән. Ә авылда сөйгән егете калган. Исемен дә әйтте — Салават. Матур бит?!

Валентина. Күрдеңме соң егетен?

Ульянцев. Күрмәдем. Салават булсын да матур булмасын.

Валентина. Синә бар нәрсә матур.

Ульянцев. Син тыңлап бетер. Егет кызны «кәтәм сине» дип авылга чакыра, кыз егетне — «үзең кил» дип төзелешкә чакыра. Кызык бит, ә?!

Валентина. Синең өчен кызыктыр, әлбәттә...

Ульянцев. Курәм, син нәрсәгәдер борчулы.

Валентина. Хәлемне күрә белү сәләтең дә бар икән...

Ульянцев. Валюша, беләсеңме, менә тиздән...

Валентина. Тиздән бергә яши башлавыбызга егерме биш ел тула. Егерме биш ел! Без хатын-кызлар өчен аз гомер түгел. Егерме биш ел буена син мине «тиздән» белән юатып киләсең. Кайчан бетә бу күчмә тормыш? Тиздәнме?!

Ульянцев. Син тагы иске җырны кабатлыйсың, Валюша. Тынычлан, тынычлан, минем кадерле нярченем. Юату түгел бу. Әле генә тиздән дип, беләсеңме, мин сиңа нәрсә әйтмәкче идем? Мин бит сине айга алып менәргә хыялланам.

Валентина. Җирдә булмаган урыныбыз калмады шул.

Ульянцев. Мин төзүче бит, Валюша. Төзүченең урыны төзелештә. Аер син аны төзелештән — якты көннән аердың дигән сүз. Якты көннән аерылган кеше суы кипкән күл балыгыдай тончыга башлый. Ә без тончыкмаска тиеш. Кеше бәхете өчен якты йортлар, яңа шәһәрләр үсә. Килер көн, шул килер көннең гражданнары шәһәр салучылар исемлегендә безнең исемнәрне дә укырлар. Күрдеңме, кая бара тарихның бер очы! Ә син юк өчен борчыласың...

Валентина (*яшь аркылы елмаеп*). Синең өчен борчылам, Володя. Вакытында ял итмисең, ашау-эчүеңнең рәте-чираты калмады. Кеше машина түгел. Машина тузса — алыштырып була, ә кеше тузса? Йөрәге тузса?!

Ульянцев. Йөрәк эшсезлектән тизрәк туза ул, Валюша.

Валентина. Синең кебек дөньясын онытып йөргән кешеләрнең йөрәкләре... (*Ульянцев каерылып хатынына карый, Валентина сүзен кисә.*)

Ульянцев. Нәрсәдер әйтмәкче идең, Валюша.

Валентина. Чәең суына.

Ульянцев. Чәй суына, дисең инде, ә? (*Өстәл катына утыра*). О, бал!

Валентина. Әйбәт абзый кертеп чыкты.

Ульянцев. Шулаймы?! (*Бал каба.*) Нәрсә ди?

Валентина. Владимир Яковлевич заказы, ди.

Ульянцев. Шулай диме?.. А, әйе, бер көн шулай этисенең умартада эшләвен сөйләп, балын мактагач: «Безгә дә китер», дигән идем. Рәхмәт әйттеңме?

Валентина. Акча да бирмәкче идем, алмады.

Ульянцев. Алмады? Бүләк итә, янәсе.

Валентина. Шифасы тисен дип бирелгән әйбергә акча алмыйлар, ди.

Ульянцев. Күр, нинди акыллы сүзләр! Гомумән, кешеләр һәрнәрсәне шулай изге ният тән шифасы тисен дип бирергә яраталар. Рәхәт тә соң яхшы күңелле кешеләр белән янәшә яшәү, ә?!

Валентина. Чәең суына!..

Ульянцев. Чәй суына?.. Ә, әйе, әйе. (*Валентина кухняга чыгып китә. Шул вакыт Ульянцевның күзләре өстәлдә Мөнирә калдырган хатка төшә һәм ул аны укый башлый: укыган саен аңарда үзгәреш чагыла. Укып бетергәндә кәефе кырылган була.*) Нинди чепуха! (*Урыныннан тора. Нишләргә белмичәрәк басып калгач, барып шкафтан папирос алып кабыза. Валентина керә.*)

Валентина. Володя, син тартасың? Ни булды?!

Ульянцев. Ярамаган эш эшләдем!

Валентина. Ни генә эшләдең соң ярамаслык?

Ульянцев. Кеше хатын укыдым.

Валентина (*тынычланып*). Ай, ничек куркыттың син мине.

Ульянцев. Мин бит белмәдем. Карыйм — ачык хат. Күземә безнең фамилия чагылды. Чепуха шунда. Укырга кирәкмәгән икән.

Валентина. Мөнирә Кәримовнаның йөрәк сере ул. Ә син чепуха дисең. Бер дә ярамый инде, Володя, мондый дорфалык.

Ульянцев. Дорфалык миндә түгел... бу хатны язучыда! Шундый ямьсез булып күренде миңа хаттагы сүзләр, аптырагач папироска суырганмын. Әшәке истән качкан хирург кебек.

Валентина. Безнең фамилия каян кергән соң ул хатка?

Ульянцев. Менә тыңла: «...ниндидер Ульянцевларга тап кидүен һәм аларны мактый-мактый һуштан язуын мине аз гына да кызыксындырмады. Мин үзем, мәсәлән, пенсия яшенә җиткән һәм валидолсыз яши алмаган узган заман кешеләре канаты астында, җитмәсә, «угловой жилец» хәлендә яшәр өчен институт тәмамлап, диплом алып яңа төзелешкә эшкә китмәс идем...» (*Бик каты борчылып.*) Ишеттеңме?

Валентина. Җитәр. Укыма.

Ульянцев. Әйе, җитәр. (*Хатны урынына куя.*) Әйдә, бергәләп чәй эчәбез. Менә бал белән. Мичкәсен кара син! Бер мичкә балга бер кашык дегет... (*Телефон шалтырый.*) Тыңлыйм. Әйе, юк инде, хөрмәтлем, чәйне ташлап китә алмыйм. Мин машина түгел. Машина тузса алыштырып була, ә кеше... Кладка башлау өчен мин бик кирәкмени? Бездә незаменимыйлар юк! Бригада тели? Һем... Ярты сәгатьтән. Күп! Ну, егерме биш минуттан. Тик бер шарт белән: егерме минуттан соң сез миңа тагы шалтыратыгыз. Онытып куюым ихтимал. (*Ульянцев трубканы куя. Валентина сиздермичә генә телефон шнурын ычкындыра. Чәйгә утыралар.*)

Валентина. Бригадир Зариф килгән иде.

Ульянцев. Нәрсә ди?

Валентина. Вак мәсьәлә белән Владимир Яковлевичны эшеннән аерасым килмәгән иде, ди.

Ульянцев. Нинди вак мәсьәлә икән? Берәр справка-мазар сорыймы әллә?

Валентина. Рөхсәт сорый. Кайтып хатынын китермәкче була.

Ульянцев. Шуны вак мәсьәлә диме?

Валентина. Ул бит моны...

Ульянцев. Яклама, яклама! Вак мәсьәлә, имеш. Хәтерлисеңме, мин Магниткада эшләгәндә син миңа, яныңа алдыр, дип хат яздың. Ничек алдырыйм? Бер баракта җитмеш биш кеше яшибез. Шуны әйтеп язганым өчен син ничек үпкәләдең миңа: «Җитмеш биш кешене сыйдырган барак җитмеш алтынчысын да сыйдырыр әле», дип язуыңны оныттыңмы? Ә болар вак мәсьәлә, имеш. Китерсен! Семьясыз кеше оясыз кош ул! Рөхсәт!

Валентина. Үзең әйтерсең. Шатланыр.

Ульянцев. Шатланыр дисең икән инде, ул чагында кешене тизрәк шатландырырга кирәк. (*Телефонга килә. Трубканы ала.*) Алло! Алло!.. Нишләп җавап бирми бу?

Валентина. Ял сәгатьләре ич.

Ульянцев. Коммутаторда ял сәгате булмый. Чү, моның бөтенләй жаны юк. (*Шнурның ычкындырылуын күреп ала.*) Синен эш бу!

Валентина. Минем эш.

Ульянцев. Алайса, 20 минут узгандыр да! Син мине кичектердең.

Валентина. Тагы бер генә стакан.

Ульянцев. Нинди стакан ул?! Анда тарихи акт — булачак шәһәрнең беренче йортын сала башлыйлар. Аңлыйсыңмы, булачак шәһәрнең беренче йортын! (*Өстенә плащын кия-кия чыгып китә, Валентина, аның шарфын алып, артыннан йөгерә.*)

Валентина. Володя, шарфыңны... Володя!..

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төзелеш мәйданынын бер өлеше. Артта, ерактагы яшел түбәлектә, авыл күренә. Алгы планда нулевой эш башланган урын. Кран китерелгән. Сәхнәдә — Алмабикә, эш киеменнән. Кранны эшләтү әзерлеген күрә. Авыл ягыннан башкорт композиторы Заһир Исмәгыйлевнең «Көтәм сине» көенең курайда яңгыраганы ишетелә.

Алмабикә. Туктамай бит, сабакы... (*Авыл ягына кулындагы гайка ачкычы белән яный.*) Мин һине!..

Мөнирә керә. Кулында врачлар сумкасы.

Мөнирә. Әбәү, Алмабикә, кемгә яныйсың?
Алмабикә. Ишетмәйһеңмени, ана, «Көтәм һине»не уйнай.
Мөнирә. Уйнаса?! Көткәч сагына да торгандыр.
Алмабикә. Һагынган кеше кош кеүек осоп етә ул...
Мөнирә. Ә ул анда үзе шулай уйласа? Уйламаса «Көтәм сине»не уйнамас иде.
Алмабикә. Уйнар-уйнар да килер әле.
Мөнирә (*үз сагышына бирелеп*). Килерме икән?
Алмабикә. Осоп килер. Көтә белергә генә кирәк. Ул «Көтәм һине»не уйнаһа, йөрәгеңә «һин дә көт!» тип приказ бир.
Мөнирә. Әйбәт кыз син, Алмабикә.
Алмабикә. Сез бик тә әйбәт, доктор апаем!
Мөнирә. Әгәр дә килмәсә?..
Алмабикә. Килмәһә... мәхәббәте канатһыз уның.

Аяк тавышлары.

Мөнирә. Кемдер бармы әллә бу тирәдә?
Алмабикә (*Салаватны сизеп ала.*) Ул!..
Мөнирә. Кем?
Алмабикә. Үзе инде. «Көтәм һине».
Мөнирә. Канатлы икән!.. И... онытканмын, мине ашыгыч эш көтә ләбаса. (*Чыгып китә. Салават күренә.*)
Салават. Алмабикә!
Алмабикә. Салават!.. (*Алар сагынышып күрешәләр. Аннары Алмабикә бердән кырыслана.*) Нәмә тип килдең?!
Салават. Бәй, ошондай һорау буламы? Һагынып килдем.
Алмабикә. Рабочий времедә һагынып йөрергә ярамаузы белмәйһеңме?
Салават. Асыуланма инде.
Алмабикә. Нәмә уклау йоткандай катып тораһың?! Йомошон булһа әйт. Тиззән бригада килә, эш башлайбыз.
Салават. Алмабикә, мин һинән кәнкрит яуап алырга тип килдем. Һин колхоздан киткәндән бирле әсәйем дә борсола.
Алмабикә. Аңлат әсәйеңә. Һин комсомол дабаһа. Аңлат. Коммунизм төзелешендә эшләйем бит мин.
Салават. Коммунизмдың төзелеп бетүен көтәйемме?
Алмабикә. Сеү, кыскырма!
Салават. Кыскырмаймын. Йөрәк янганда тауыш үзе кыскырып сыга инде ул.
Алмабикә. Йөрәгең янһа, әйрән эс.
Салават. Колхозда сагында арыу гына кыз инең. Салбар кейеп алгас, ямең калмаган, бахыр. Ябыкканһың да. Ашатмайзармы әллә?..

Алмабикә. Ябыкһам, чертежды уйлап ябыктым мин.
Салават. Кемде?! Ул ниндәй Сережа?
Алмабикә. Сережа түгел, чертеж. Ошо кранды яхшыртыу тураһында уйлайым. (*Салават бердән көлә башлый.*) Нәмә көләһең?
Салават. Ыскынмаганһыңдыр бит һин, ауылдаш?!
Алмабикә. Һин үзең ыскын бынан! (*Ачулана.*) Һәй, колхозсы нәмә белә ул!..
Салават. Асыуланма, Алмабикә, мин...
Алмабикә. Сеү, ана, Володя агайым килә. Кас!

Салават качып өлгерә алмый. Ульянцев килеп керә.

Ульянцев. Я, Алмабикә, кран әзерме? Бу егет кем?
Алмабикә. Был егет... Был егет... Ошо егет... Нимә... Минең авылдан... Салават...
Ульянцев. А-а, шушымыни инде ул Салават? (*Кул биреп күреша.*) Я, герой, син дә эшкә килдеңме?
Салават. Йомош менән килдем. Алмабикәгә йомош төште лә.
Ульянцев. Шулаймы? Ярый, ярый. Йомышың төшеп үзең килүең яхшы аңысы. Тик, кара аны, йомышың төшеп кранчы кызыбызны алып китәсе булма. Так что-ли?
Салават. Так, так...
Ульянцев. Мен анлаштык та. (*Кран ягына уза. Ульянцев чыгып китүгә Алмабикә пырхылдап көләргә тотына.*)
Салават. Нәмә көләһең?
Алмабикә. Так-так тип такылдавыннан көләм.
Салават. Нәчәльник кеше такмы тип һорагас, так тип яуап бирәһең инде уны.
Алмабикә. Бар, кайт, Салават. Эшкә башлау вакыты етә, ана, бригада ла килә.
Салават. Кәнкрит әйтмәнең бит әле һин, Аламабикә.
Алмабикә. Кәнкрите: һин үзең бында кил.
Салават. Нисек мин колхозды ташлап киләйем? Минә прсидәтел агайым самаход комбайны бирәбез тип ышандырзы.
Алмабикә. Улайһа «Көтәм һине» тип самаход комбайныңа йырла, йәме?
Салават. Асыуланмаһана...
Алмабикә. Асыуланмай! Мин бит һиңә самаход комбайн түгел! Кеше! Йәнем бар, йөрәгем бар...
Салават. Минең юкмы?
Алмабикә. Күренмәй!
Салават. Мин дә кирбестән яһалмаган. Салбар кейеп алган да... Талашырга килмәнем мин. Китәм.
Алмабикә. Бар кит, эшемде калдыраһың.
Салават. Китәм!
Алмабикә. Кит!
Салават. Бына китәм... Күрмәйһеңме?
Алмабикә. Хуш, һау бул! (*Берсе киткән була, икенчесе игътибар итмәгән була, ләкин икесенең дә күңеле тыныч түгел.*)
Салават. Һау бул, киттем. Киттем тим бит инде, ишетмәйһеңме? (*Чыга. Алмабикә ул киткән якка ташлана, ләкин юлы бүленә. Сәхнәгә Ульянцев, Зариф, Ибәт абзый, Булат керә. Барысы да эш киемнәреннән.*)
Ульянцев. Я, егетләр, башлыйбызмы?!
Зариф. Башлыйбыз. Менә, Владимир Яковлевич, бригаданың хезмәт йөкләмәсе бу.

Ульянцев (*йөкләмәне карый*). Егерме биш көндә?! Ну, егетләр!.. Сез беләсезме?!. Әгәр бу йөкләмәгезне үти алсагыз!.. Сез бит моның белән югары хезмәт темпын тудырасыз. Коммунистик хезмәт ударниклары мәскәүлеләр генә бер йортны егерме биш көндә салалар.

Зариф. Ә без мәскәүлеләрдән күреп шундый йөкләмә алдык та.

Ибәт. Әйе! Шуның өчен көрәшәбез дә. Бар эшне намус белән эшләргә! Графиктан чигенмәскә, бернинди хәлдә дә!

Ульянцев. Уңыш телим, егетләр!

Зариф (*сәгатенә карап*). 5 минуттан башлыйбыз, егетләр! Барыгыз да эш урыннарыгызга! Алмабикә, башняга! Булат, измәгә! Заһидулла! (*Тирә-ягына карана, Заһидулланы эзли.*) Кайда бу кеше! Заһидулла?!

Ибәт. Заһидулла!

Булат (*артка таба кычкыра*). За-һи-дул-ла!..

Зариф. Кайда бу кеше, ә? Өзә бит эшне.

Ибәт. Син нәрсә сөйлисең?!

Алмабикә. Өзә?! (*Бердән дала ягына таба кычкыра.*) Са-ла-ват! (*Ул башнядан сикереп төшә дә Салават киткән якка таба чабып чыгып китә.*)

Ибәт. Менә сиңа график.

Ульянцев (*сәгатенә карап*). График вакыты җитә!

Зариф (*ярсып*). Кайда соң бу кеше? Күрүче булдымы аны?

Булат. Эштә күренмәде ул бүген.

Ибәт (*ачуланып*). Эш кешесемени ул!

Булат. Ну, өйрәтәм мин ул көекне! Өйрәтмәсәмме, исемем Булат булмасын!!

Ульянцев. Ничек өйрәтү турында соңыннан. (*Сәгатенә күрсәтеп.*) Ә хәзер эшне башларга киңәш бирәм мин сезгә.

Ибәт. Үзем басам Заһидулла урынына.

Салаватны җитәкләп Алмабикә чабып керә.

Алмабикә. Бригадир! Володя агайым!.. Бына... Ул эшләр... Эштән курыкмай ул... (*Барысы да бу көтелмәгән хәлдән әсәрләнеп сүзсез кала.*)

Ульянцев. Күрәм!.. Күрәм!!! Эштән куркыр егеткә охшамаган бу.

Ибәт. Егетнең асылы икәнсең, улым!

Зариф (*шатлыгын яшерә алмыйча*). Алмабикә! Давай!..

Мотор гүләгән тавыш.

**БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Баракта эшче-яшьләр тулай торагы. Стенада «Коммунизмны безгә төзергә, коммунизмда безгә яшәргә» дигән лозунг, репродуктор, телевизор, бернничә плакат. Караватта, чишенмичә, Зәйдүк сузылган. Авызында папирос, кулында гитара. Репродуктордан диктор тавышы:

— Яшьләр өчен тапшыруыбызны башлыйбыз. «Хезмәттә югары күрсәткечләргә ничек ирешергә?» дигән темага репортаж тыңлагыз.

Зәйдүк (*барып радионы ычкындыра*). Ишеттек! Культуралы ял итәргә мишәйтлисең. (*Килеп урынына сузыла.*) Их, мин әйтәм, гел генә менә шулай йомшак караватта сузылган көйгә, эшләмичә акча алып ятсаң иде... Бер ягында ярты, бер ягында автомат төймәләре... Кемгә нәрсә, рәхим ит, ихтыяҗыңа карап, төймәгә басасың — ишек ачыла да йомышчы килеп керә: ни боерасыз? Балмы, маймы? Тагын төймәгә басасың...

Булат керә.

Булат. Исәнмесез!
Зәйдук. Бәй, әле килеп тә життеңмени син?
Булат. Сез дип эндәшергә кирәк.
Зәйдук. Молодец! Ошый бу миңа!..
Булат. Ә миңа сезнең ятып сөйләшүегез ошамый.
Зәйдук. Житәр! Мин алай акыллы булып күренүчеләрне яратмыйм.
Булат. Миңа сез хезмәтне дә яратмый дип сөйләделәр.
Зәйдук (*сикереп тора*). Нинди допрос бу?! Кем син?
Булат. Танышыйк, алайса, Булат атлы мин.
Зәйдук. Булат икәнсең... Әнә, аргы почмакта койка буш. Ордерың булса, ят та ябыш — итмә тавыш!
Булат. Койка кирәкми миңа.
Зәйдук. Койка кирәкмәгәч, ни дип килдең?!
Булат. Эш белән.
Зәйдук. Эш кирәксә, участокка бар. Монда тулай торак.
Булат. Мине монда жибәрделәр.
Зәйдук. Әллә комендант итепме?
Булат. Тәрбияче итеп.
Зәйдук. Кем итеп?!
Булат. Тәрбияче.
Зәйдук. Әй-й, баш катырып йөрмәсәнә! Детсадка бар, энекәш, детсадка! Монда тәрбия яшеннән узган абзыйлар яши.
Булат. Шундый абзыйлар арасында тәрбиягә мохтаҗлар да бар икән.
Зәйдук. Кем икән ул андый сакаллы сабый?!
Булат. Сезне әйттеләр.
Зәйдук. Мине?! Рәхмәт кайгыртулары өчен. Мохтаж инде анысы, бик мохтаж. Бар кеше эшкә чыгып китә дә, ятим баладай бер үзем калам. Әйбәт булган! Давай, егет, бераз гына кара әле үземне. Чәй эчәбезме? Түлке син китерәсең.
Булат. Сүз культура тәрбиясе турында бара.
Зәйдук. Культурасы житкән лә аның. Әнә, каршыбызда гына телевизор, менә, кулыбызда гитара, баш очыбызда лозунг, авызда папирос, теләсәң радио кычкырт, теләсәң папирос пыскыт...
Булат. Ә эшләргә?
Зәйдук. Анысы инде сәләтеңә карап.
Булат. Ялкаулыкка сәләтегез күренеп тора.
Зәйдук бердән үзгәрә. Ул Булат каршысына килә дә аның якасыннан эләктереп ала.
Зәйдук. Күпне күргәннең күзе чыккан!
Булат. Якадан кулыгызны алыгыз. (*Ул моны тыныч кына әйтә, теге алмый.*) Алыгыз кулыгызны! (*Бу юлы тавыш кисәтүле яңгырый. Зәйдук ничек кулын алуын үзе дә белми кала һәм шулай, кулын кая куярга белмичә, уңайсыз хәлдә басып тора.*) Бу кадәресен миңа әйтмәгәннәр иде. Әлегә ике арада калсын. Ышанам, моннан ары кул озынайту хәрәкәте кабатланмас?
Зәйдук. Нишләрсең? Кисеп ташларсыңмы?
Булат. Нигә кисәргә? Кул бит кешегә әйбәт эш эшләр өчен бирелгән. Агач утыртырга, йорт салырга, икмәк үстерергә, сөйгән кызыңның чәченнән сыйпарга. Кыскасы, бәхет корырга.
Зәйдук (*ачу белән*). Сыйпарга? Йолкырга диген.
Булат. Аңлашыла. Сезне кызыгыз рәнжеткән булса кирәк.
Зәйдук. Рәнжеткән генәме икән?
Булат. Шу-лай-мыни? Нишләгән?
Зәйдук. Мәхәббәтне кире какты.
Булат. Дөрес эшләгән.
Зәйдук. Ничек дөрес эшләгән?

Б у л а т. Әгәр кыз булсам, мин дә кире кагар идем...
З ә й д у к. Ник?
Б у л а т. Менә, бригадага бар, шунда аңлатырлар.
З ә й д у к. Беркая да бармыйм. Мин авыру!
Б у л а т. Докторга бар.
З ә й д у к. Доктор үзе килсен. Нәрсә өчен акча ала ул?
Б у л а т. Эшләгән өчен.
З ә й д у к. Аңлашыла. Комментарийның артык кирәге юк!
Б у л а т. Мин дә шулай дип уйлыйм.
З ә й д у к. Все, агай-эне, все!
Б у л а т. Әйе, бүгенгә җитәр.
З ә й д у к. Җитсә — шул: ишек, әнә, бу якта!
Б у л а т. Рәхмәт. Хәзергә хушыгыз! (*Кулын суза. Зәйдук кулын бирмичә тора.*) Я, иптәш, бир кулыңны!
З ә й д у к (*уңайсызланып та, оялып та кулын бирә*). Сагыз булдың. Ничава гына кеше, ахрысы, син, шайтан алгыры!
Б у л а т. Менә бу юлы сүзең урынлы.
З ә й д у к. Кара әле, тәрбияче, әгәр син чыннан да бик акыллы баш икәнсең, бер соравыма җавап бирә алмассыңмы?
Б у л а т. Әйтеп кара соравыңны.
З ә й д у к. Менә син: кул кешегә бәхет корырга бирелгән, дидең. Әйт инде алайса — бәхет кешегә каян килә?
Б у л а т. Каян килә дисеңме? Чү, уйлыйк әле азрак. (*Бармагын маңгаена терәп уйлаган була.*) Әһә, белдем! Каян килә дисеңме әле? Менә — ишектән! Әйе, әйе. Менә шушы ишектән. Син шулай эшләмичә генә күшәп ятканда, ишек ачыла да бәхет килеп керә. (*Кыланып күрсәтә.*) Исәнмесез, Заһидулла Курамшин иптәш! Мин — бәхет. Рәхим итеп алыгыз да булыгыз бәхетле!..
З ә й д у к. Ха-ха-ха... Артист син, артист.
Б у л а т. Эх, егет, син уйлаганча, каяндыр үзе килергә тиешле әзер бәхет юк бит ул. Бәхетне коралар аны.
З ә й д у к. Нинди материалдан? Ничек коралар? Әһә, один ноль безнең файдага.
Б у л а т. Шигырь белән җавап биримме?
З ә й д у к. Давай!
Б у л а т. Тыңла!

Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә,
Аһ, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.
Һәр олуглар эшләгәнлектән олуглыклар таба,
Уйнады дип, бирмиләр ошбу җиһанда мәртәбә.
Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел.

З ә й д у к. Килештергәнсең. Үзең чыгардыңмы?
Б у л а т (*мыскыллап*). «Үзең чыгардыңмы?» Тукай абзаң шигыре булуын мәктәп баласы да белә бит. Йөрисең шунда буй үстереп, ә үзең Тукай шигырен дә белмисең.
З ә й д у к (*бик уңайсызлана. Ояла да, гарьләнә дә кебек*). Кара әле, Булат, минем турыда тагы нәрсә диләр?
Б у л а т. Нәрсә дисеңнәр... Хезмәт сөйми, диләр.
З ә й д у к (*ярсып*). Ишеттек! Ну күрсәтермен мин аларга хезмәт сөймәгәнне!
Б у л а т. Әйе, эш белән.

Зәйдук. Салам кыстырма, яме! Ачык сөйләшик. Әгәр сезне, тәрбияче иптәш, минем дөньяга карашым кызыктыра икән, рәхим ит! Әнә, лозунгны күрәсеңме? Мин шуның икенче яртысы өчен.

Булат. Әлегә лозунгның беренче яртысы гамәлдә.

Зәйдук. Миңа ашыгасы түгел.

Булат. Ул чагында ни дип төзелешкә килдең?

Зәйдук. Җыр белән җавап биримме?

Булат. Тыңлап карыйк.

Зәйдук.

Урманда куак кына,
Яфрагы бар вак кына,
Күпсенмәгез, күп тормабыз,
Без монда кунак кына.

Булат. Кара аны, болай җырлап, соңыннан еларга туры килмәсен, кунак егете!

Зәйдук. Без елый торганнардан түгел.

*Мөнирә керә.*

Мөнирә. Сез Заһидулла Курамшинмы?

Зәйдук. Мөгезем бармы әллә? Ник аңардан сорамыйсыз? Бәлки улдыр?

Мөнирә. Булатны таныйм. Ә сезне беренче күрәм.

Зәйдук. Беренче күргәч, минем Заһидулла Курамшин булуымны каян беләсез?

Мөнирә. Сурәтләүләренә караганда, сез булырга тиеш.

Зәйдук. Давайте, иптәшләр, яхшылык белән таегыз моннан. Авыру кешене борчып йөрмәгез. Нервный система шәптән түгел минем. (*Барып урынына сузыла.*)

Мөнирә. Тикшереп карарбыз.

Зәйдук. Каян килгән доктор.

Мөнирә. Ялгышмадыгыз, мин доктор.

Зәйдук. Шулаймыни? Менә әйбәт булган. Югыйсә, докторсыз яшәве, ай-яй, читен безнең заманда. Авырыйм дисәм, ышанмыйлар. Хәзер инде сезнең справка да булгач... Печәтегез бардыр бит? (*Булатка.*) Ярый, энекәш, тәрбия сәгате бетте. Күрмисезме, мине медицина көтә. Тарттыр... тарттыр. ((*Ул Булатны озатып чыгарып җибәрә.*) Я, доктор, без культурный кешеләр бит әле. Башта танышып җибәрик: СССРның ирекле гражданины Заһидулла Курамшин. Кайберәүләр иркәләп-назлап Зәйдук дип тә йөртәләр.

Мөнирә. Нәрсәдән зарланасыз?

Зәйдук. Ошый миңа бу сорау. Турыдан-туры, яшерен-батырынсыз әйтимме? Сезнең ише чибәр дусның булмавыннан зарланам.

Мөнирә. Тегермәнне шәп тарттырасыз.

Зәйдук. Кинаягез дә ошый: янәсе, бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы. Шулай бит?

Мөнирә. Күтәрегез күлмәгегезне. Йөрәгегезне тыңлап карыйм.

Зәйдук. Тыңлагыз. Йөрәгем дә бер үк сүзне кабатлаячак: мин сезне...

Мөнирә. Сулагыз! Суламагыз! Сулагыз... Суламагыз. (*Тыңлап бетерә.*) Төшерегез күлмәгегезне.

Зәйдук. Я, ничек соң, доктор?!

Мөнирә. Сез сәламәт һәм шуның өстенә ярыйсы ук симулянт та икәнсез.

Зәйдук. Кызмагыз, доктор! Сез, докторлар, үзегез бездән салкын канлы булуны сорыйсыз, ә үзегез...

Мөнирә. Сезнең мәгънәсез сүзләрегезне тыңларга вакытым юк минем. (*Китмәкче була.*)

Зәйдүк (*аның юлына каршы чыга, кисәтүле*). Сез үз бурычыгызны үтәмәдегез бит әле.

Мөнирә. Ул нинди бурыч тагы?

Зәйдүк. Әнә өстәл. Менә автомат. Утырыгыз да авыру дип миңа справка языгыз.

Мөнирә. Мин андый справка яза алмыйм!

Зәйдүк. Мин ике әйтергә гадәтләнмәгән.

Мөнирә (*кинәт бер карарга килеп*). Ярый! Справка дидегезме? (*Яза.*) Мәгез сезгә справка.

Зәйдүк. Менә шулай. Дусларча. Тату гына. Рәхмәт сезгә, доктор! Пардон-мерси!..

Мөнирә чыгып китә.

Зәйдүк. Күрдегезме?! Мин сездән кабат сорыйм: күрдегезме? Менә шулай хәрәкәт итәргә кирәк аны. Зәйдүк абзагызның кулында справка. Ю-к, справка түгел, козырь бу, ә козырьны берни белән дә яба алмыйсың. Менә шулай!

Эшләпә кигән сакаллы абзый керә.

Сакаллы абзый. Әй син, тарттыр әле моннан арбаңны!

Зәйдүк. Чү! Бу ниткән башбаштаклык? Сез кем?

Сакаллы абзый. Комендант мин.

Зәйдүк. Ах, комендант!.. Көтеп алынган кадерле кунак! Мин сезне көтәм. Рәхим итегез!

Сакаллы абзый. Миңа сезне эшкә чыкмый дип әйттеләр.

Зәйдүк. Ә миңа сезне бик әйбәт абый дип әйттеләр.

Сакаллы абзый. Ялагайланмагыз! Сезне эштән качкан ялкау диләр.

Зәйдүк. Фу, нинди әшәке сүз. Ничек шундый сүзне әйтергә телегез бара? Үзегез алдынгы профсоюз члены. Культурный. Эшләпә кигәнсез...

Сакаллы абзый. Бездә эшләмичә ашап ятучы әрәмтамакларга урын юк!

Зәйдүк. Фу, тагы әшәке сүз. Хөрмәтле комендант, мин авыру!

Сакаллы абзый. Аны син әйтәсең бит.

Зәйдүк. Сез дип сөйләшергә кирәк, монысы бер. Ә икенчесе — мин әйтмим, ә доктор әйтә.

Сакаллы абзый. Без сүзгә генә ышанмыйбыз, син безгә доктор язуын китер. Справка!

Зәйдүк. Справка сорыйсызмы? Справка бар бездә! (*Справкасын чыгарып бирә. Сакаллы абзый справканы укый башлый һәм укыган саен җитдиләнә бара, ара-тирә кызганган төсле Зәйдүккә карый.*)

Сакаллы абзый. Әй-яй-яй...

Зәйдүк. Нәрсә булган?

Сакаллы абзый. Харап бит синең эш, егет!

Зәйдүк (*шикләнә башлап*). Нәрсә бар?

Сакаллы сабый. Ничек инде нәрсә? Язган ич менә монда. Врач әйтмәдемени сиңа?

Зәйдүк. Әйтмәде.

Сакаллы абзый. Әйтмәс тә. Врачебная тайна дигәндер.

Зәйдүк (*курка барып*). Нәрсә булган соң?

Сакаллы абзый. Харап! Харап синең эшләр!!.

Зәйдүк. Ә?! Тинтерәтмә инде, әйт!

Сакаллы абзый. Бик хәвефле чир тапкан бит синдә врач.

Зәйдүк. Нәрсә? Әллә ракмы?

Сакаллы абзый. Һәй... Рак нәрсә ул монын алдында. Менә тыңла алайса. (*Укый.*) «Бу справка бирелде Курамшинга шул хакта, аңарда табылды...» Әй-яй-яй-яй, ә? Нәрсә табылган бит! Кара әле, бәлки, укымаскадыр, ә?! Бәлки, чынлап та, бу врачебная тайна, ә? Менә, латинча язылган.

Зәйдүк. Әй газапламасана! Кая, бир әле монда...

Сакаллы абзый. Чү, үзем укыйм. Менә тыңла. «...Курамшинга шул хакта, аңарда табылды...» (*Авыз эченнән мыгырдый.*)

Зәйдүк. Нәрсә табылган?

Сакаллы абзый. Тел бармый бит, әй, тел бармый әйтергә. «...аңарда табылды башлангыч стадия тунеяттуссимулянтус...»

Зәйдүк (*берьюлы аңламыйча*). Анысы нәрсә була инде?

Сакаллы абзый. Ачык язган ич, менә. Тунеядсимулянт, дигән.

Зәйдүк. Җитәр!

Сакаллы абзый (*җитди тонга күчеп*). Юк, җитмәсен инде, Заһидулла Курамшин!

Зәйдүк (*каушап*). Ә?! Нәрсә җитмәсен?

Сакаллы абзый. Бу кылануларың!

Зәйдүк. Нишләгән соң мин?

Сакаллы абзый. Күшәп ятуың җитмәгән, хезмәт дисциплинасын бозарга булдыңмыни?

Зәйдүк. Чү, кычкырма әле ул хәтле! Ишетерләр!..

Сакаллы абзый. Кычкырмамыни? Юк инде, брат, бу справканы бөтен дөньяга ишеттереп укырга кирәк булачак безгә! Радио аркылы бөтен республикага!

Зәйдүк (*чын-чыннан өркеп*). Комендант абзый...

Сакаллы абзый. Әһә, абзый булдыкмыни?..

Зәйдүк. Комендант абзый, ертып кына ат син ул справканы.

Сакаллы абзый. Ертып ату белән генә эш төзәлми бит.

Зәйдүк. Нинди эш?

Сакаллы абзый. Ну, менә синдәге чир. Аны кызган тимер белән көйдерергә кирәк.

Зәйдүк. Нишләмәкче буласың соң?

Сакаллы абзый. Әүвәле, бүген кич, клубта кино башланыр алдыннан, үзеңне экран каршына бастырып, шушы справканы укыйбыз.

Зәйдүк (*бик нык шүрләп*). Зинһар... Кирәкмәс иде...

Сакаллы абзый. Моның белән генә бетми әле. Аннары изоляторга бикләп куябыз үзеңне. Чөнки чирең йогышлы. Башкаларга да йокмасын өчен, сине изолировать итәргә кирәк. Менә, яшә рәхәтләнеп, ялгыз башың, эшләмичә.

Зәйдүк. Кирәкми... Кирәкми...

Сакаллы абзый. Чү, әллә еларга чамалыйсың инде? Син бит кеше елый торганнардыр түгел, дип лаф орган идең.

Зәйдүк. Кайчан? Кемгә?

Сакаллы абзый. Бая гына. Миңа.

Зәйдүк. Мин сезне беренче тапкыр күрәм.

Сакаллы абзый. Ә мин икенче тапкыр! (*Эшләпәсен сала һәм ясалма сакалын ала.*)

Зәйдүк (*тәмам аптырый*). Бу сез?

Булат. Менә «сез» дидегез. Тәрбияне шушы әйбәт сүздән башлыйбыз.

Зәйдүк. Бу-ла-т!..

Булат. Я, әйт инде: бу справканы нишләтәбез?

Зәйдүк. Ертып атабыз. Дусым бул. Яртыны куям!

Булат. Шулаймы? Ярый, алайса. Ул чагында болай итәбез: бер кулыңа шушы справканы, икенче кулыңа яртыны тоттырып, рәсемгә төшерәбез дә элеп куябыз.

Зәйдүк. Шаярма инде.

Булат. Юк, туганкай, син үзең шаярма, яме? (*Бик җитди.*) Кайда синең эшче намусың?

Зәйдүк. Ярый инде... Ике арада гына калсын.

Булат. Калмасын. Син әле менә бригада алдында җавап бирергә әзерлән.

Зәйдүк. Булат, бәлки шулай гына уздырып җибәрербез, ә? Хур итмә инде.

Булат. Мин хур итмим сине. Син үз-үзеңне хур итәргә җыенгансың. Ярый әле, справкада башлангыч стадия диелгән. Бик тирәнгә китмәгән, димәк. Тик яхшы бел, егет: яшерергә ярамый моны, чирен яшергән үләр дигән халык сүзен онытма.

Заһидулла, нишләргә дә белмичә, чарасыз басып тора.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Дүртенче күренештәге декорация. Йорт стеналары шактый күтәрелгән. Әбәт сәгате. Сәхнәдә Алмабикә һәм Салават. Алмабикәнең бер кулында шешә белән сөт, икенче кулында күмәч. Салават аның каршына утырганы хәлендә курай уйный.

Салават. Бер көн гәзиттә укыдым: фермада радио-музыка уйнап торһа, һыерлар һөт тә күбрәк бирә ти.

Алмабикә. Мин һыер түгел бит.

Салават. Беләм уныһын. Һин һөтте күбрәк эсһен тип уйнайым.

Алмабикә. Һин үзең ас түгелме?

Салават. Каршымда һин булганда, мин аслыкты белмәйем.

Алмабикә. Китапта шулай язалар.

Салават. Минем тураладыр инде ул.

Алмабикә. Һинен турала. Һин бына китапка язырлык итеп эшендә эшлә.

Салават. Пажалыста!.. Эшләйбез уны (*кураен салып, кулына мастерокны һәм ящиктагы бетон измәсен алып өйрәнү өчен куелган махсус квадратны сылый башлый.*)

Алмабикә. Улай түгел, улай түгел, бына былай. (*Күрсәтә.*) Растворзы ошолай итеп алаһы ла сап итеп ябаһың...

Салават. Өйрәтү анһат ла ул.

Алмабикә. Һөйләшмә! Был производство.

Салават. Стройка. Производство булһа, завод була.

Алмабикә. Эшеңдә күр. Мине өйрәтергә алыс һиңә. (*Салават эшли.*) Калагынды кыйуырак йөрәт. Курыкма, кирбес бит ул. Мин килгәнсе ошо квадратны һылап куй.

Алмабикә чыгып китә. Салават ялгызы тырыша-тырыша раствор сылый.

Салават. Растворзы ошолай итеп алаһың да, сап итеп ябаһың. (*Зәйдүк керә, Салаватның эшен күзәтеп тора.*) Сап итеп ябаһың да...

Зәйдүк. Нәрсә син... Сапылдыйсың?

Салават. Сапылдамайым, агайым, эшләйем.

Зәйдүк. Шулай эшлиләрмени?! Яле, яңабаштан!.. (*Салават тагы сылый башлый.*)

Зәйдүк. Алай түгел! Бир әле! (*Калагын алып күрсәтә.*) Менә болай растворны салмак кына бәр, мунча ләүкәсенә су бәргән кебек; нык ябыша ул. Понятномы?

Салават. Аңлаткас понятно инде.

Зәйдүк. Кем син?

Салават. Рабуси.
Зәйдүк. Рабочийлыгың бик чамалы.
Салават. Мин өйрәнчек рабуси. Килмәй инем. Ялварып сакырас, унан һуң срочный за булгас килдем.
Зәйдүк. Кирәкле кишер яфрагы икәнсең...
Салават. Улай тимә. Мин килмәһәм график өзелә ине.
Зәйдүк. Нишләп өзелә соң син килмәгәч график?
Салават. Берсе сирләп киткән дә эшкә сыкмаган...
Зәйдүк. Кем соң ул? Кем әйткән чирләгән дип.
Салават. Дуктыр справка язып биргән, ди, тунеядес сире менән ирли дип. Һин таный торганһыңдыр уны? Заһидулла Курамшин. Таныйһыңмы? (*Зәйдүк ни әйтергә белми.*) Танымаһаң, әнә һүрәте. Беззең Чаян»га төшереп куйзык үзен. (*Зәйдүк «Безнең Чаян» плакаты янына килә. Карап торгач та, каһәрләнеп сурәтне каерып алмакчы булып кулын суза.*)
Салават. Әй, нәмә эшләйһең?!
Зәйдүк. Алып ыргытырга кирәк аны!
Салават. Окшамаймы? Мин яһаным был һүрәтте.
Зәйдүк. Син?! Адәм рәтле ясый алмас иденмени? Нәрсә бу?! Шүрәлеме? Дию парием е?
Салават. Карикатур бит был, агайым. Унан һуң тунеядес үзе дә зәм рәтле булмай тизәр.
Зәйдүк. Диярмен мин сиңа? Менә сиңа приказ: үз кулың белән сагансың икән, үз кулың белән алып ат!
Салават. Приказ булгач алабыз инде. (*Карикатураны ала.*)
Зәйдүк. Бир монда! Кара аны, исеңдә тот: Заһидулла Курамшин зеннән көлгәнне яратмый! Әгәр тагы күрсәм... (*Бармак янап чыгып итә. Салават ялгызы. Ул бик борчулы.*)
Салават. Бәй, асыуланды бит был кеше. Бинават яһамаһа ярай. Кем булды икән? Нәчәлләрдең береһе булһа? (*Ибәт керә.*) Ибәт агайым, анау кем ул?
Ибәт. Кемне әйтәсең?
Салават. Әнә, әнә, китеп бара.
Ибәт. Зәйдүк түгелме соң? Үзе ич!
Салават. Зәйдүк?! Кайһы? Заһидулла Курамшинмы?
Ибәт. Шул үзе инде.
Салават. Тунеятулла-Заһидулламы?!
Ибәт. Чү... Сиңа нәрсә булды, Салават?
Салават. Һорама, һорама, Ибәт агай!
Ибәт. Рәтләп кенә сөйлә әле, нәрсә булды?
Салават (*бердән ыргылып*). Мин уны!..
Ибәт. Әллә әбиҗәйт иттеме? Кыйнадымы?
Салават. Тукмаһын ине!.. Көсе етһә. Алданы ул мине! Көлде ул минән!..
Ибәт. Көлде?! Мыскыллап көлдеме?
Салават. Алдап көлде! Куркак йән! (*Зәйдүк керә.*)
Зәйдүк. Шулай әйтәсеңме кунелем сиздe. Кире кайттым. Мә художествоңны. Куй урынына. Миңа алмаска кирәк икән аны. Барыбер охшамаган. Менә хәзер үземә карап, охшатып ясый аласың. Давай, яса! (*Поза ала.*)
Ибәт. Шүрләдең, безобразник!
Зәйдүк. Акчаңны урлап качмаган бит... шүрләргә.

Бригада члены, Алмабикә, Булат, Зариф керә.

Зариф (*җитди шаяртып*). А... чирләгән егетебез савыккан дамы әллә? Куркыттың безне. Нинди чир ди әле? Справкаң кая? Без справ-

канны карый торганчы син, энә, кыяфәтеңне карый тор. (*Карикатура ның урынында юклыгын күрә.*) Кайда мондагы рәсем? (*Дәшми торалар.*) Кайда дип сорыйм мин сездән?!

Салават. Миндә.

Зариф. Ни дип алдың? Әллә ул алдырдымы? Әйт, ник дәшмисең? Ул алдырдымы?

Салават. Алдык әле, бригадир. Әйбәт булып сыкмаган бу һурәт. Охшамаган да.

Зариф. Салават! Син нәрсәнедер әйтеп бетермисең. Яшерәсең.

Салават. Йәшермәйем, бригадир.

Зәйдүк. Яшерә! Мин алдырдым!!

Зариф. Судить итәбез без сине бу хулиганлыгың өчен!

Зәйдүк. Итегез! Курыкмыйм судыгыздан! Ишетәсезме!? Курыкмыйм!!

**Ульянцев керә.**

Ульянцев. Кем кемнән курыкмый?

Зариф. Менә бу калай этәч. Судтан курыкмый.

Ульянцев. Кара, нинди батыр икән, ә? Заһидулла Курамшинмы әллә? (*Көлүен яшереп.*) Теге, врач справкасындагы...

Ибәт. Нәкъ үзе! (*Пырхылдап көлеп җибәрә.*)

Ульянцев. Шу-ла-й дисәнә... Судтан курыкмый икән... Ә хезмәттән курка! (*Сәхнәдәгеләр хахылдап көлә башлый.*) Ишеттем... ишеттем. Курыкмый икән шул. Булатны якасыннан алырга булып кулын күтәргән икән... Ә менә носилка күтәрергә курка! (*Басыла башлаган көлк яңадан кабына.*) Иптәшләре сүзеннән дә курыкмый икән, ә менә «Безнең Чаян» чагудан кур-ка-а!..

Салават (*борчыла барып*). Володя агайым, ул... хурлана.

Ульянцев. Ә без берәүне дә хурламыйбыз. Турысын әйтәбез. Бигрәк тә менә Курамшин кебек начар чиргә юлыгучыларга. Ә чирне яшерергә китап кушмый. Сине телгә осга дип тә сөйлиләр, егет, әйтерләр инде алайса безгә: нинди җир өстендә басып торасың син хәзер (*Курамшин ни дип әйтергә дә белмичә аптырап сүзсез тора.*) Әйтә алмасаң, мин әйтием инде алайса: коммунизм шәһәрләренең берсе салынып начак җир өстендә. Шәһәр синең яшьтәге бер егетнең исемен мәңгеләштереп салына. Ул егет тә курыкмаган! Үлемнән курыкмаган у. Ә син!.. (*Сәхнәне авыр тынлык баса, аннары шул тынлыкны уятк төсле чаң сугалар.*) Сөйләгән булыр идем мин сиңа, егет, тик вакыты быз бетте. Әнә, эш башларга чакыралар.

Бригада члennары эш коралларын алалар, эш урыннарына басалар. Заһидулла бы ялгызы нишләргә белмичә басып тора. Бердәм хезмәт башлана.

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Баракта вакытлыча ачылган медпункт. Алгы планда врач өстәле. Мөнирә рентген рәсемнәрен карап, журналына нәрсәләрдер яза.
Радиодан җыр-музыка тапшыралар.

Синнән башка бер ямь юк миңа,
Син килмәсәң бәйрәм юк миңа.

Таң балкуы кебек кил, иркәм,
Мин сине көтәм, көтәм, көтәм!..

*Мөнирә, барып, радионы өзә.*

Мөнирә. Әллә мине үртиләр инде?.. (*Репродукторны уртәп.*) Көтәм... Көтәм. Бик кирәгең бар. (*Ишек шакыйлар.*) Рәхим итегез! (*Хатыны Зарифаны җитәкләп Зариф керә.*)

Зариф. Исәнмесез, доктор! Менә карчыгымны китердем әле. Ялгызын җибәрергә курыктым. Опасно. (*Зарифа, уңайсызланып, нәрсәдер пышылдый.*) Бетте, бетте, карчык! Безнең доктор гаеп итә торган түгел ул. Хушыгыз, доктор! Эшкә барышлый гына озата килүем иде. (*Хатынына.*) Карчыгым, мин киттем, яме? (*Чыга башлый, кире борыла, хатыны янына килә һәм ярым тавыш белән.*) Минем теләк турында да әйтергә онытма, яме? Бетте, бетте. (*Чыга.*)

Мөнирә (*урын күрсәтеп*). Рәхим итегез. Нинди теләк турында әйтергә куша ул?

Зарифа. Әй... Шуларның әйткәннәренә карасаң.

Мөнирә. Нәрсә ди?

Зарифа. Нәрсә дип... (*Көлеп әйтә алмый тора.*) Малай тап, ди. Әйтерсең лә мин ул малайны камырдан әвәлим.

Мөнирә. Үзенә шулай диясең калган.

Зарифа. Дидем.

Мөнирә. Нәрсә ди?

Зарифа. Доктор белән киңәш, ди. Медицина хәзер барысын булдыра: теләсәң ир малай, теләсәң кыз малай... Бик тә теләсәң, берьюлы икесен таптыра ала, ди.

Мөнирә. Алайса, әтисе ир малай көтә икән, әйе? Ә син кемне көтәсең?

Зарифа. Әтисе көткәнне көтәсең инде. (*Мөнирә Зарифаның пульсын тикшерә, күз төпләрен карый, кан басымын үлчи, аннары фонендоскобын ала.*) Әйдәгез әле, икегезне дә тыңлап карыймчы. (*Ширма артына узалар, сәхнә буш тора. Валентина керә.*)

Валентина. Кайда икән бу кыз?

Мөнирә (*ширма артыннан*). Мин биредә, Валюша апа! Утыра торыгыз. Хәзер бушыйм.

Валентина (*аңарда эчке борчылу. Ширма ягына колак сала.*) Хатын-кыз белән сөйләшәсең түгелме?

Мөнирә (*ширма артыннан*). Булачак ана белән.

Валентина. О.. кадерле пациент икән. Менә шулай башлана инде ул тормыш дигәнең. Иң элек буш дала. Землянкалар, аннары бараклар калка. Йортлар үсә. Ул йортларга семьялар килә. Семьялар булган җирдә балалар туа. Бер көнне Владимир Яковлевич сөйләп утырды: узган елда гына да безнең Советлар Союзында биш миллион бала туган. Мәскәүдә икенче «Детский мир» магазинын ачалар икән. (*Мөнирә белән Зарифа ширма артыннан чыгалар.*)

Мөнирә. Менә шушы инде ул безнең кадерле пациентыбыз.

Валентина. Бригадир Зарифның карчыгы түгелдер бит?

Зарифа. Ул кадәресен каян беләсез?

Валентина. Мин, акыллым, сез күз кабагыгызны йома башлауга кечкенәгезнең ничек тибешүенә кадәр беләм.

Зарифа. Әнием!.. Шуларына хәтле сөйләдеме?

Валентина. Әле ничек сөйләде!..

Зарифа (*усалланган булып*). Ну мин аны!.. Кайтсын гына әле өйгә. Имансыз!

Валентина. Чү, чү, нигә ачуланырга? Сөйләсә?! Шатлыгын сөйли бит ул. Ярата!

Зарифа. Мин дә яратам шул үзен, юньсезне. Шуңа күрә, тырышып йөргән булам да инде.
Валентина. Тырыш, тырыш, акыллым. Тырышкан табар ди, син дә ул тап!
Зарифа. Зариф та шулай ди. (*Мөнирә Зарифага берничә рецепт бирә.*) Рәхмәт инде, доктор. Сезгә дә рәхмәт яхшы телегез өчен. Хушыгыз!

Зарифа китә, Валентина иркенләп көлә.

Валентина. Я, хода, нинди әйбәт кешеләр! Тырышам диме? (*Көләләр.*) Бер дә болай рәхәтләнеп көлгәнем юк иде. Кайгыларым таралып китте.
Мөнирә. Кайгыларыгыз?
Валентина. Мине бит, Мөнирә Кәримовна, сезнең кабинетка кайгыларым өстерәп китерде. Ә хәзер менә әйтерсең лә каядыр сибелеп таралдылар.
Мөнирә. Нәрсә дип инде, Валюша апа, гел борчыласыз?
Валентина. Миңа гомер-гомергә борчылып яшәргә язган, күрәсең. (*Күзләрен сөртә.*)
Мөнирә. Беләсезме, Валюша апа, борчылусыз яшәүне мин яшәү димәс идем.
Валентина. Кара нинди героиня! Нигә алай дисез? Хәер, сез яшь бит әле. Сезгә ни әйтсән дә килешә. Сез яшисе заманнар — алда. Сезнең заманда борчулар азаер, бәлки, бөтенләй булмас. Кеше борчылудан бөтенләй туктар.
Мөнирә. Кеше борчылудан, беләсезме, кайчан туктар?
Валентина. Әйтеп карагыз.
Мөнирә. Йөрәге туктагач.
Валентина (*җитди*). Мөнирә Кәримовна, бүген иртә белән Владимир Яковлевичның йөрәк өянәге булды. Шундый курыктым, шундый курыктым! Аптырагач, сезгә килдем. Сезгә, хезмәт урыныгызга, кабинетыгызга килдем. Сез минем теләгемне үтәргә тиешсез. Владимир Яковлевичка төзелештә эшләүне тыярга, хезмәттән аерырга кирәк аны.
Мөнирә. Бик читен эш кушасыз сез миңа, Валюша апа.
Валентина. Сез врач. Бу эш сезнең ихтыярыгызда.
Мөнирә. Әйе, мин врач. Яшь врач! Менә шушы яшь врачның, Валентина Сергеевна, сезнең теләгегезгә каршы килгән үз фикере дә бар бит әле.
Валентина. Ни өчен каршы?
Мөнирә. Беләсезме ни өчен? Тагы да бер биш-ун елдан кешене хезмәттән аеруны гаеп эшләүчегә карата җәза тәртибендә куллана башларлар. Ә хезмәт кешесе мондый җәзаны авыр кичерер. Әйтегез инде, алайса, инженер Ульянцевның нинди гаебе бар?
Валентина. Инженер Ульянцевның йөрәге авыру, хөрмәтлем!
Мөнирә. Владимир Яковлевичның йөрәге турында, шушы көнгә кадәр, мин дә нәкъ сезнеңчә уйлап йөргән идем, ә хәзер ул уемнан кире кайтырга туры килә...
Валентина. Сез ни сөйлисез?
Мөнирә. Бу минем үз диагнозым. Мин Владимир Яковлевичның рентген рәсемнәрен өйрәндем һәм яңасын эшләттем. Менә карагыз. Хәзер менә монысына карагыз. Әнә, бер бик кечкенә, чикләвек төше кадәр генә кара тапны күрәсезме?
Валентина. Шеш?
Мөнирә. Әйе.
Валентина (*бик нык сискәнеп*). Я, хода?

Мөнирә. Курыкмагыз. Шеш. Лэкин медицина телендә әйткәндә ...локачественный түгел.
Валентина. Нинди шеш соң ул?
Мөнирә. Шул шеш эчендә тары бөртегедәй бер нәрсә күрәсезме? ...Сәер, моны тәҗрибәле күз генә күрә ала.
Валентина. Доктор, сез мине куркытасыз.
Мөнирә. Әлегә мин ул нәрсәне ят бер әйбер — чужеродное тело — ...дип язып куйдым.
Валентина. Кайдан килеп кергән соң ул?
Мөнирә. Менә, менә, үзегез дә минем уйларыма килеп житәсез ...хәзер. Кайдан килеп кергән дисезме? Владимир Яковлевичның авыру ...тарихын өйрәнә торгач, мин шундый бер фактка туры килдем. Владимир Яковлевич 1945 елның мае башында, Берлинны алу өчен барган ...сугышларда яраланып, госпитальгә керә. Госпитальдә аңа операция ...ясап ике осколка алалар. Өченчесе, бик нәние, яшеренеп кала һәм ...шушы көнгә кадәр яшеренеп ятмакчы була. Лэкин авыруның организ...мы, көрәшә торгач, аны кысрыклап, безнең күзебезгә күренерлек ...ясый...
Валентина. Ничек кенә моңа ышанырга соң, доктор?
Мөнирә. Ышану өчен иң элек барлык ят уйларны башыгыздан ...куып чыгарыгыз.
Валентина. Чыкмыйлар! Куган саен күбәяләр генә. Бәлки, ...берәр чарасын белә торгансыздыр?
Мөнирә. Кайгы куа торган бик шифалы «дару» бар дөньяда — ...хезмәт!
Валентина. Сез миңа бетон эшенә чыгарга кушмый торгансыз...дыр бит, доктор?
Мөнирә. Безгә бетоннан башка әйберләр дә кирәк бит әле, ...Валентина апа!
Валентина. Мәсәлән?
Мөнирә. Гөлләр-чәчәкләр.
Валентина. Чәчәкләр!?
Мөнирә. Сез аларны тәрбияләп үстерә алмас идегезмени?
Валентина. Миңа Володяны тәрбияләргә дә кирәк бит. Ул шә...һәрләр сала! Ә шәһәрләр матур, төзек салынсын өчен семьяда да төзек...лек кирәк: кем дә булса барысын җайлап, көйләп торырга тиеш. Мон...дый мәшәкатьне без хатын-кыздан да түземле алып баручы юктыр, ...күрәсең. Доктор Мөнирә Кәримовна, әйтегез, зинһар, Владимир ...Яковлевич белән нишләргә кирәк?
Мөнирә. Операция өстәлenә.
Валентина. Ә?!

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук медпункт. Эңгер-меңгер чак. Мөнирә хат яза.

Мөнирә. «Әгәр дә син бу минутлардагы минем эчке кичерешлә...ремне рентген нурлары аша яктырта алсаң, миндәге үсә барган беренче ...зур шатлыкны күрер идең. Лэкин, үзең беләсең, кешенең рухи халәтен ...яктыртып күрсәтә алган хикмәтле нурлар әлегә табылмаган. Кем белә ...тагы, бәлки, андый нурларны эзләргә дә кирәкмидер, алар безнең үзе...бездә, жылы караш балкыткан күзләребездә, әйбәт теләкләр тели алган ...шифалы сүзләребездәдер, бәлки. Яшәү, үсү, иҗат итү өчен безгә кояш

жылысы кебек үк кешелек жылысы да кирәк бит. Менә мин шундый жылы хисләргә юмарт әйбәт күңелле кешеләргә юлыктым, шатлыгым хәтсез зур. Шундый кешеләрнең берсен, бер дә арттырмый әйтә алам, фаҗигадән алып кала белдем, минем диагнозым буенча ясалган операциядән соң, ул яңадан хезмәткә кайтты, я, әйт инде, алайса, шул үзе безнең өчен шатлык була алмыймыни? Шундый зур ул, минем шатлыгым, бер үзем өчен генә бик күп, мин аны иң якын кешем белән — синең белән уртаклашасым, бүлешәсем килә. Эх, хәзер менә, Фәрит, син дә булсаң иде! Ничек кирәк син миңа хәзер! Ничек кирәк! Якын дус булып кына түгел, коллега булып та кирәк син миңа бүген». (*Хатыннан аерыла да эчендәге уйларын үз алдына сөйли*).

Кызык булыр иде... Шулай, сагынып көткәндә генә килә дә керә ди, ә?! Менә кызык булыр иде. Тормышта шулай буламы икән соң? Әйе, әйе, нәкъ син өмет иткәнчә килә дә чыга ди. Менә шулай, бердән ишек ачыла...

Ишек ачыла, бусагада — Фәрит.

Мөнирә (*гаҗәпләнеп*). Фәрит?!

Фәрит. Мөнирә!

Мөнирә. Ай, Фәрит!.. Күземә күренәсең мәллә?

Фәрит. Әйттем ич мин сиңа килермен дип.

Мөнирә. Киләсеңне сизеп көттем, күрәсең,

Фәрит. Дөрес сизгәнсең. Сизгер икәнсең. Син бит миңа: «Мәхәббәтең канатлы булса очып килерсең»,— дигән идең. Алайса, бел: чын мәгънәсендә очып килдем. Самолетта. Сәгатенә дүрт йөз километр тизлектә. Кырык биш минут элек Казанда булсам, хәзер менә — синең янда.

Мөнирә. Бигрәк тизләгәнсең.

Фәрит. Безнең атом гасырында моның өчен ниндидер хыялый канатлар кирәкми икән. Самолетың булсын, таксиең булсын... һәм, әлбәттә инде, кесәңдә сәмәнең булсын!

Мөнирә (*шатланып көлә*). Матур шаярасың.

Фәрит. Юк, Мөнирә, бу юлы мин шаярмыйм. Шаярып торырга вакытым да юк.

Мөнирә. Аңламыйм.

Фәрит (*кесәсеннән бер кәгазь чыгара.*) Менә бу документ барысын да аңлатыр. (*Кәгазьне Мөниргә бирә һәм кире ала.*) Бир, үзем укыйм. Мондый документны Левитан кебек тантаналы тавышта укырга кирәк. (*Укый.*) Приказ. Врач Мөнирә Кәримовна Әхметованың гаризасын искә алып, шәһәр поликлиникасына кайтарырга.

Мөнирә. Ха-ха-ха!.. Әй, шаяртырга оста да инде. Гариза?! Нинди гариза?!

Фәрит. Синең гариза. Менә ич. Кулыңны да куйгансың. Ха-ха-ха...

Мөнирә. Әбәү, минем андый гариза язганым юк.

Фәрит. Кешеләр алдында шулай диясе булма. Мин яздым аны. Син булып.

Мөнирә. Мин булып?

Фәрит. Мәхәббәт көче бар нәрсәне дә эшләтә ала икән!

Мөнирә. Мин булып алдап яздыңмы?

Фәрит. Ташла, зинһар, шул ямьсез сүзеңне: алдап. Алдаумыни бу? Бу бер ход кына. Менә әгәр син шуны аңламасаң, ул чагында алдау була. Әйе, алдау һәм кем тарафыннан диген? Синең тарафтан. Ул чагында инде мин дә алдакчы булам. Чөнки мин сине шәһәргә күчерүнең төп сәбәбе итеп семья корырга теләвебезне күрсәттем.

Мөнирә. Фәрит!..

Фәрит. Алдап түгел, курыкма, чынлап! (*Үзенә зур бер ышаныч белән.*) Мөнирә, мин сиңа өйләнергә карар иттем! Менә шул карарым

очыртып алып килде дә мине. Минем дә бит инде теләкләрем, интереслары бар. Миңа бәхетле тормыш корырга вакыт җитте.

Мөнирә. Алайса, син бәхетле тормыш корыр өчен мине алырга килдең?

Фәрит. Самолетта! Коштай очып! Мәхәббәт шулай очыртты мине.

Мөнирә. Мәхәббәтеңне самолет канатларына тагып очып килгәнсең, алайса, ә?!

Фәрит. Ышандыңмы инде хәзер?

Мөнирә. Ә син минем тормыш төзи башлавымны белмәдеңмени? Менә, күрәсең ич.

Фәрит. Шушыны тормыш дисеңме?

Мөнирә. Нигә алай дисең? Монда мин үземнең хезмәт юлымны таптым.

Фәрит. Тагы фәлсәфә.

Мөнирә. Тормыш фәлсәфәсе!

Фәрит. Тормышка фәлсәфә аркылы түгел, ә ачык күз белән карарга кирәк, дустым! Син бит үзе килгән әзер бәхеттән йөз чөермәк буласың. Кеше ышанмас, билләһи! Я, әйт, ни өчен син минем тәкъдимемне кире кагасың?

Мөнирә. Ни өченме? Әйтмим инде.

Фәрит. Әйдә, алайса, болай сөйләшик...

Мөнирә. Фәрит... Минем берничек тә сөйләшәсем килми...

Фәрит. Менә сиңа мә! Ит яхшылык, көт яманлык булып чыкты бу. Менә, фәлсәфә нишләтә кешене. Зарар юк. Киткән бездән китсен. Аның эше генә югалтулар...

Мөнирә. Фәрит, ничек син мине шулай кимсетергә оялмыйсың?

Фәрит. Сине? Синең турыда әйтәммени мин? Самолетка, таксига киткән акчаны әйтәм. Я, ярый, ялгыз каласым килә дисең бит, чынлап та ялгыз калып уйла әле. Уйлар алар гел үзгәрә тора. Менә, бу документ та калсын. Аның сиңа бу аю өненнән ычкынырга ярдәм көче барын онытма.

Мөнирә. Фәрит...

Фәрит. Фәрит ике сөйләшергә яратмый. Гафу ит, такси көтә. Счетчик...

*Фәрит чыга. Мөнирә ялгыз кала. Ул бу очрашуга ышанырга-ышанмаска да белми аптырап тора, аннары ачуыннан приказны ерткалап ташлый һәм үксеп-үксеп елый башлый. Ишектә Зәйдүкнең башы күренә.*

Зәйдүк. Доктор, рөхсәтме? (*Мөнирә ишетми. Зәйдүк эчкә керә. Ул Мөнирәнең елавын белми.*) Доктор! (*Мөнирә бердән сискәнеп артыга әйләнә.*)

Мөнирә (*ярсып*). Сезгә нәрсә кирәк?

Зәйдүк (*гаепле кешедәй башын иеп дәшми тора*). Доктор...

Мөнирә. Нәрсә кирәк? Инде монда килдегезме?

Зәйдүк. Килдем... Йөрәк сызлагач килдем.

Мөнирә (*үзен кулга ала, урын күрсәтә*). Утыр менә монда. Нәрсә булган йөрәгегезгә? Нигә сызлый?

Зәйдүк. Сызлый дигәч тә, авыру түгел мин, доктор. Сездән гафу үтенергә килдем. Бригадада эшлим. Беренче йортны салып бетерәбез. Гафу итегез мине, доктор. Теге чакта рәнҗетүем өчен гафу итегез мин тилене.

Мөнирә. Ни өчен минем гафу итүем кирәк сезгә?

Зәйдүк. Кирәк икән, доктор, йөрәк сызлый да шабаш. Башкача ничек аңлатыйм?..

Мөнирә (*аның янына килә, кулын иңбашына куя*). Аңлыйм мин сине, егет, аңлыйм. Рәхмәт сиңа, Заһидулла Курамшин!

Зәйдүк (*бик нык гаҗәпләнеп*). Рәхмәт? Миңа?! Ни өчен?

Мөнирә. Йөрәгең сызлавы өчен.
Зәйдүк. Доктор... Сез... Бигрәк инде... Көләсезме?
Мөнирә. Әйбәт күңелле кешедән көлмиләр, Заһидулла.
Зәйдүк. Сез болай әйтеп минем күңелне үстереп җибәрдегез, доктор. Ә күңел үскәндә кеше гел яхшыга омтыла. Рәхмәт, доктор, бик рәхмәт сезгә. *(Ишеккә бара башлый, кире кайта.)* Доктор, әгәр берәрсе.... рәнҗетә-нитә калса, фамилиясен генә әйтегез, яме? Рәнҗетүче юктыр бит?
Мөнирә. Юк, юк.
Зәйдүк. Юк дигәндә дә килеп чыга ул берәр хулиган. Кешенең төрлесе була бит. Хушыгыз. (*Чыга башлый.*)
Мөнирә. Карагыз әле... Ә сез ни өчен рәнҗетү турында сорадыгыз?
Зәйдүк. Ни өчен дип... Күзегез яшьле булганга.
Мөнирә. Болай гына ул, болай гына...
Зәйдүк. Болай гына булсын. Сезнең кебек кешеләрне рәнҗетергә ярамый.

Чыга. Мөнирә ялгызы кала. Бердән аның кайгысы җиңеләйгәндәй була. Яшь аркылы елмая ул. Барып радионы тоташтыра. Чайковскийның «Сентименталь вальс»ын тапшыралар. Шул чагында ишек ачыла. Мөнирә ишеккә таба борыла.

Мөнирә. Владимир Яковлевич?..
Ульянцев. Әйе, бу мин. Ләкин мин сезгә авыру булып, ярдәм сорап килмәдем, доктор. Мин сезгә күңелле хәбәр алып килдем.
Мөнирә. Күңелле хәбәр?..
Ульянцев. Тик миңа күңелле хәбәрне әйтмәс борын, үзегез әйтегез әле миңа, ни өчен сез күңелсез?
Мөнирә. Болай гына.
Ульянцев. Болай гына бернәрсә дә булмый. Димәк, сез яшерәсез?
Мөнирә. Яшерү түгел бу.
Ульянцев. Яшерү түгел икән, яшермичә әйтегез, сездә «йөрәк сере» кузгалып алган, ахрысы, шулай бит?

Мөнирә сүзсез тора.

Ульянцев. Аңлыйм, аңлыйм. Мондый чакта әйтер сүз тиз табылмый ул. Мәсәлән, мин дә, утыз ел моннан элек, шушындый хәлемдә, әйтер сүз таба алмас идем. Мин ул хәлемне сезгә бүген генә сөйли алам. Шулай бер вакыт, хисләрем бөреләнгән көннәрдә, мин дә сезнең кебек күңелсез минутлар кичергән идем. Ул чагында дөньяда минннән дә бәхетсез кеше юк кебек иде. Бүген шуларны исемә төшерсәм, көләсем килә. Ни өчендер, Мөнирә Кәримовна, сез дә миңа шулай күренәсез хәзер.
Мөнирә. Көлке булыпмы?
Ульянцев. Түгел, бәхетле булып.

Репродуктордан диспетчер тавышы: «Инженер Ульянцевны беренчегә чакыралар!» — Тавыш кабатлана.

Ульянцев. Әнә, мине эзлиләр. Беренчедә!
Мөнирә. Владимир Яковлевич, күңелле хәбәрегезне әйтмәдегез бит әле.
Ульянцев. Ах, да... Онытып чыгып барам икән. Тыңлагыз, алайса, тиздән беренче йорт өлгерә. Булачак шәһәрнең беренче йорты! Шул тарихи йортның аскы катында сезнең өчен медпункт җиһазландырыла. Шул үзе генә дә күңелле хәбәр була алмас идемени?!
Мөнирә (*профессиональ җитдилек белән*). Хәзер сез мине тыңлагыз инде.
Ульянцев. Приказ?

Мөнирә. Приказ түгел, ә минем карарым: беренче йорт бетәр ул. Мин сезгә бик алай эмоциягә бирелмәскә кушам.
Ульянцев. Я, әйт инде, яшь дустым, эмоциясез, хиссез яшәп буламы?
Мөнирә (*кисәтүле*). Сезгә операциядән соң бик күп шатланырга һәм борчылырга...
Ульянцев. Ха-ха-ха. Эх, яшь дустым минем. Әгәр сез миңа моңый шартларны алдан ук әйтеп аңлаткан булсагыз, мин... операциягә бирмәгән булыр идем...
Мөнирә. Менә монысы инде...
Ульянцев. Гафу... гафу!
Мөнирә. Сезне көтәләр!
Ульянцев. Көтәләр?.. Кемнәр?.. Ах, да барам, барам.
Мөнирә. Шулай да минем киңәшне тыңларга кушар идем мин сезгә.
Ульянцев. Есть, тыңларга!
Мөнирә. Кайчагында сез нәкъ бала төсле...
Ульянцев. Менә... менә... Бездә, доктор, беркадәр балалык та булырга тиеш...

Репродуктордан баягы чакыру кабатлана.

Ульянцев. Барам... барам... (*Чыга.*)

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Яңа салынып беткән йорт. Арткы фонда — төзелеш панорамасы. Сәхнәдә Зәйдүк белән Салават. Алар яңа медпунктка вывеска урнаштыралар.

Салават. Ишеттеңме, Заһидулла, Володя агаем больнистан чыккан.
Зәйдүк. Ишетмичә! Яхшы хәбәр тиз ишетелә ул, брат.
Салават. Йөрәгеннән пуля чыккан, ти.
Зәйдүк. Йөрәгеннән түгел, ә йөрәккә якын иттән, аннары пуля да түгел, ә кыйпылчык кисәге генә.
Салават. Һиңа докторзың помощнигы булаһы калган.
Зәйдүк. Була алмам дисеңмени? Тырышканда, брат, помощнигы түгел, үзе булып та була. Тырышырга кирәк, Салават, тырышырга. Я, нәмә карап торасың, бир теге ярты сын.

Алар, шулай сөйләшә-сөйләшә, вывесканы урынына куеп бетерәләр. Ибәт абзый килеп керә.

Ибәт. Булдымы, егетләр?
Зәйдүк. Анысын сез әйтегез инде, Ибәт абзый!
Ибәт. Хәзер комиссия члennары килә, алар әйтер инде булганын.

Алмабикә чабып керә.

Алмабикә. Киләләр, киләләр!

Сәхнәгә Ульянцев, Мөнирә һәм аларга ияреп комиссия члennары керә.

Ульянцев. Менә безнең беренче йортыбыз! Бик тиздән бу яңа йортта тормыш башланыр. Аның бусагасыннан атлап безнең замандашлар керер. Мин, хөрмәтле дуслар, митинг ачарга җыенмыйм. Ләкин әйтмичә дә булмый. Йөрәк түзми! Дөрес, миңа моңарчы бик дулкынланмаска, борчылмаска, кыскасы, чамасыз куанмаска киңәш биреп

килделәр. Янәсе, йөрәгемә ярамый. Юк, дуслар, йөрәкләр таза икән безнең! Әгәр инде йөрәкләребездә узган хәвефле елларның кургаш тузаны яшеренеп яши икән, яныбызда оста куллы врачларыбыз булганда, анысы да куркыныч түгел. Шатлыгымны әйтергә рөхсәт итегез: мин хәзер теләгәнчә көлә дә, дулкынлана да, борчыла да, елый да, кирәк икән, җырлый да беләм. Башкача яшәү мөмкин түгел, Алмабикә, син кранчы кыз, гел югарыда — биектә очасың. Башкача яшәүнең берәр башка юлы күренмиме сиңа анда? Син моңа ни әйтәсең?

А л м а б и к ә. Мин, Володя агайым, шуны әйтә алам: безнең ауылда бер колхозсы карт, эблигациясе машина отkас, кыуанысыннан сак йөрәге шартламый калды. Сама менән кыуаныу кирәк, агайым, сама менән.

Барысы да көләләр. Валентина Сергеевна күренә. Кулында банкалы гөлләр.

В а л е н т и н а. Нәрсәдән көләсез бу хәтле?

У л ь я н ц е в. Әнә, Валюша, Алмабикә миңа чама белән генә куанырга киңәш бирә.

В а л е н т и н а. Бик акыллы киңәш! Бер дә көлкесе юк. Син бит операциядән соң торып чыккан кеше.

У л ь я н ц е в. Ишеттегезме, иптәшләр?!

В а л е н т и н а. Юк, моны син ишет!

У л ь я н ц е в. О!.. Мин, Валюша, кулыңда гөлләр күрәм.

В а л е н т и н а. Дөрес күрәсең. Син элек-электән үткен күзле идең шул. Әйе, гөлләр, яран гөлләре! Беренче йортыгызга яз яме кертсен бу гөлем...

У л ь я н ц е в. Бер гөл генә яз ясамый бит, Валюша.

В а л е н т и н а. Яз килерен хәбәр итеп башта бер гөл ачыла, ә аннары бакчалар шау чәчәк ата.

И б ә т. Дөрес, Валентина Сергеевна! Без сезне булачак яңа шәһәребезнең бакчачысы дип санарбыз моннан ары.

У л ь я н ц е в. Валюша, ишетәсеңме?! Ишетәсеңме нинди исем? *(Изүләрен ычкындыра.)*

В а л е н т и н а. Володя, әйттем мин сиңа...

М ө н и р ә. Валентина Сергеевна, тыныч булыгыз әле, зинһар.

У л ь я н ц е в. Валюша, берни булмас, дустым, барысы да узар. Ә гөлләр калыр. Без үстергән гөлләр бик озын гомер яшәр. Карагыз, нинди матур гөлләр үсә безнең тирә-ягыбызда! Әнә теге алма чәчәге Алмабикәне генә карагыз сез. Шулай бит, Салават?

С а л а в а т. Әллә, мин әйтәм, Алмагөл тип куябызмы атыңды, Алмабикә?

А л м а б и к ә. Куйырмын бына мин һиңә.

У л ь я н ц е в. Безнең гәлебез ачулана да белә икән.

С а л а в а т. Кәрәхтере шундый уның.

Ике кулына ике чемодан тотып З а р и ф килеп керә.

И б ә т. Менә беренче квартирант та килде. Үзең салган йорт — рәхим ит!

У л ь я н ц е в. Менә ачкычың, әнә квартирың, рәхим ит!

С а л а в а т. Бар байлыгың ошо гынамыни?

З а р и ф. Нишләп шушы гына булсын. Байлыкның иң зурысын карчыгым күтәргән.

З а р и ф а керә. Кулында ефәк юрганга төрелгән бала.

С а л а в а т. Вәт был байлык тиһәң дә байлык!

А л м а б и к ә. Тәк кенә тор тинем бит мин һиңә.

С а л а в а т. Тәк торып буламыни бындай сакта, Володя агайым әйтмешләй.

Ибәт. Әйдә, Зарифа килен, төкле аягың беләнǃ Әнкәсе кочагындагы нәни гражданин беренче булып рәхим итсен инде, алайса, бу яңа йортка.

Валентина (*Зарифа янына килә*). Менә без тагы очраштык. Иске танышлар бит әле без, кадерлем. Мә, ал син минем бу кечкенә бүләгемне. Ал син аны. Ямьле тормышыгызның түрендә чәчәк атсын ул.

Зарифа. Рәхмәт инде, Валентина апа.

Валентина. О, сорарга онытканмын бит әле... Кем? Кечкенәгез кем? (*Зарифа оялып та, уңайсызланып та иренә карый*).

Валентина (*Зарифка*). Әтисе, әйт, кем?

Зариф. Бу юлы кыз булып чыкты бит әле!

Мөнирә. Исеме?

Зарифа. Чәчәк.

Ульянцев. Менә сезгә тагы бер чәчәк!

Ибәт. Тере чәчәк!

Салават. Күрдеңме, карчыгым?!

Валентина. Нинди карчык ул сиңа?

Салават. Алмабикә хәзер минем бисә бит.

Валентина. Булса?! Ә нигә карчык дисең?

Салават. Яратып әйтүем инде. Бригадирдан күреп әйтүем.

Алмабикә. Тәк кенә тора алманың?!

Ульянцев. Мөмкин түгел, мөмкин түгел, Алмабикә, сез уйлаганча тик кенә торырга. Ярый, дуслар, яңа өйдә тормыш башлау сәгате җитте. Әйдәгез, бригадирның тормышын котлап чыгыйк. (*Барысы да бара башлый. Кинәт Ульянцев туктый, башкалар да туктый.*) Өстәл янында, тост күтәргәндә әйтермен дигән идем... йөрәк түзми менә!

Ибәт. Әйт сүзеңне! Шундый чакта әйткәч, йөрәккә рәхәт булып китә ул.

Ульянцев. Менә, менә! Бик дөрес, Ибәт абзый, әйтәсе сүзеңне әйткәч йөрәккә рәхәт булып китә.

Валентина. Әйт инде, алайса, Володя.

Ульянцев. Дусларым, мин сезгә бер серемне ачмакчы булам. Бу серем бигрәк тә медицинага, аеруча сезгә кагыла, минем яшь дустым — хөрмәтле доктор!

Әгәр мин берәр шатлыклы вакыйга кичереп чамасыз куансам, миңа ничектер әйбәт булып китә. Әйтерсең лә тәндәге һәртөрле чир берьюлы чыгып бетә дә, үземне сәламәт итеп кенә түгел, ә хәтта яшәрә төшкән кебек итеп тә сизә башлыйм... Менә хәзер, шушы минутларда да, мине әнә шундый гаҗәп бер кичереш биләп алды, дуслар. Менә ул беренче йорт! Карыйм да мин аңа, күңелләр ачылып китә. Юк, юк, бу рапорт-отчетларда язылганча «срогына тәгәлләдек» өчен генә дә түгел, ә шушы беренче йортның бусагасыннан атлап кергән вакытта куаначак семьялар өчен, дуслар! Менә ул безнең хезмәтебез нинди шатлык тудыра! Бу әле беренче йорт. Ә бу далада килер көннәрнең шәһәре күтәрелгәч, безнең хезмәтебез нәрсәгә әйләнер? Миллионнар шатлыгына! Менә шул чагында, дуслар, бу йортларны төзүчеләр әйтерләр: бу шәһәрне без салдык! Һәм бу гади сүзләр миллионнар өчен хезмәт җыры булып, минем дә, синең дә җырың булып яңгырар...

ПӘРДӘ.

**Шәүкәт Галиев**

## Сүзләр иленә сәяхәт

Бала:
— Сүзлек бабай,
Бай бабай,
Бик күп сүзең
Бар бабай.
Сүз иленә
Керимче,
Ниләр барын
Күримче,
Сәфәр кылып
Йөримче?
Сүзлек бабай:
— Тере сүзләр
Иле бу,
Төрле сүзләр
Җире бу.
Кызыксынган
Балага
Кызык хәлләр
Бар анда!
Белəсеңдер
Ич, балам,
Яши монда
Өч заман —
Хәзергесе,
Үткәне,
Киләчәктә
Көткәне...
Өч заманда
Берьюлы
Йөрим дисәң,
Шул юлы —
Алфавитны
Әйтеп бир,
Әйтеп бир дә,
Әйдүк, кер!
Маҗаралар,
Тылсымнар
Сиңа юлдаш
Булсыннар!..

## Мәгънәсез

Җөмлә башына эләккән
Бер Баш Хәреф мактанды:
— Мин — иң зурысы, мин — иң алда,
Сезнең урын арттан! — ди.

Әйттеләр бүтән хәрефләр:
— Бик лаф орма, Баш Хәреф,
Кара әле бездән башка
Мәгънәле эш башкарып!

Ни белән очланды дисәң
Мин-минлеккә дәгъвасе,—
Бер ялгызы гына калгач
Бетте аның мәгънәсе!..

## Ирекнең ике җиңүе

### КАРАҢГЫЛЫК ЧИГЕНДӘ

Ирек керәп
Каранды —
Бүлмә тулы
Караңгы!
Үзе болай
Тып-тыныч,
Эче тулы
Куркыныч...
Нидер килеп
Тотар кук,
Хап! иттереп
Йотар кук!..
Бетеп шунда
Чыдамы,
Атыла да
Чыга ул.

Ут кабызып
Караса —
Бүлмә буп-буш
Лабаса!
Ирек берни
Күрмәгән.
Күрмәгән, ә
Шүрләгән...
Үзен-үзе
Күндерде —
Юри утны
Сүндерде.

Куркынычын
Куркыныч,
Уйлый Ирек:
«Бул тыныч!
Юк монда бер
Нәрсә дә!»

Бик чыгасы
Килсә дә
Түзде, карый
Яхшылап —
Иялә шкәч
Яктырак!
Чигенде бит,
Чигенде,
Караңгылык
Җиңелде!

## ЙОКЫ КАЧТЫ

Ирек дәрес
Хәзерли.
Йокы килә:
«Хәзер, ди,
Куяр малай
Сабагын —
Йомдырам күз
Кабагын!»

Ирек күзен
Угалый,
Бирешергә
Уйламый.

Йокы ястык
Теләми:
«Йом күзеңне
Генә» ди.
Башны түбән
Идерә,
Өстәлгә үк
Тидерә...

Йокы тәмле...
Эш тә бар!
Ачу килгән —
Көч табар! —
Ирек тәмам
Үртәлә,
Авыр башын
Күтәрә.
Менә, кулын
Селтәде.
Сугамы ул,
Төртәме?

Тик тормыйча
Бер генә,
Әрле-бирле
Йөренә —
Физзарядка
Ясый ул.
Иңнән селкеп
Ташлый ул —
Куа шулай
Йокыны!

...Йокы качты,
Юк булды!!
Ирек оеп
Төшмәде,
Өй эшләрен
Эшләде!

## Юл ачам

Чокырларга
Җыелып,
Барыр юлдан
Тыелып,
Тора сулар
Боегып.

Тыныч сулар
Тымызык,
Тымызыкка
Юк кызык,
Җибәрәм мин
Юл сызып.

Әйдә, әйдә,
Аксыннар,
Үз юлларын
Тапсыннар,
Гел-гел алга
Чапсыннар!

## Таныды!

Тышта күзне
Чагылдыра,
Өйдә Кояш
Сагындыра.

Тәрәзәдән
Баксам, үзгә —
Салкын карый
Никтер безгә.

Танымыймы
Әллә мине?
Шунда кинәт
Башка килде:

Таплы икән
Пыялалар,
Үрмәкүчләр
Оялаган...

Ялт иттереп
Юып куйгач,
Танып күзен
Кысты Кояш!

## Паровоз, сиңа әйтәм...

Паровоз, дим,
Паровоз,
Күл-көзгегә
Карап уз;
Маңгайларың
Корымлы,
Яңакларың
Сөремле,
Юын инде,
Сөрт инде!
Юкса, җилләр
Буялыр,
Каеннарга
Уралыр...
Пычратырсың
Аккошны,
Акчарлакны,
Актүшне.
Шулай бар да
Каралса,
Ямьсез булыр
Лабаса!

Юын, юын,
Паровоз,
Без бит чиста —
Карап уз!

## Хоккей җене кагылган...

Ике малай шуалар,
Бозда алка куалар.
Тора торгач бер читтә,
Маэмай да кереп китә.
Ә малайлар алканы
Бер-берсенә төртәләр,

Ике арада йөртәләр —
Маэмайны йөгертәләр!

Узып бара бер агай
Шугалакның яныннан:
— Маэмаена хәтле, ди,
Хоккей җене кагылган!
Тик үзе китә алмый —
Ике малай, бер маэмай
Алка куганны карый...

## Стена аша...

Эре панельле өйдә
Кайчак кыенга килә:
Күрше баласы җылый —
Дәрес хәзерләп булмый.

Ничекләр туктатасы,
Ничекләр юатасы?
Әнисе дә эштәдер,
Әтисе дә эштәдер,
Ямансулап бетәдер...

Кызык булсын әле, дим,
Сарык булып бәэлдим,
Кәҗә булып мәэлдим,
Дуңгыз булып мыркылдыйм,
Тавык булып кыткылдыйм,
Күркә булып гөлдерим,
Җылатмыйм, дим, көлдерим.

Төрле чакта төрлечә
Җаен-әмәлен таптым,
Стена аша димәдем,
Әкият тә сөйләдем!

Ә көннәрдән бер көнне
Күршеләр килеп керде.
— Үскән егет син! — диләр.
Әниемә сөйлиләр:
— Стена аша ул безнең
Балаларны караган.
Рәхмәт әйтеп без аңа
Бирик быргы, барабан.
Теләгән чакта уйнар,
Безнекеләр дә тыңлар...

Эре панельле өйдә
Яшибез без шул көйгә...

## Яшь трамвай

Өсте-башы өр-яңа,
Бүген чыккан дөньяга —
Беренче кат рельскә
Тәпи басып йөреш лә!
Әй, йөгерә трамвай,
Әй, элдерә трамвай!

Кирәк җирдә туктала,
Тирә-юньгә күз сала,
Таныш түгел шәһәргә
Карый-карый кузгала.
Йөрмәгән юллар тансык,
Күрмәгән җирләр тансык!

Бер йөгереп карады,
Ике йөреп карады,
Һаман бер үк араны
Әрле-бирле урады...
Күрде лә ич ул аны!

Ул бит яңа трамвай,
 Япь-яшь кенә трамвай,
Яңа чыккан дөньяга,
Аңа бар да өр-яңа!
Туктап күпер өстендә
Карар иде елгага...
Чирәмнән чаба-чаба
Керер иде бакчага...
Китәр иде еракка —
Болытлар аккан якка,
Поездлар чапкан якка,
«Ки-и-иттек!» дип сузып,
Моңаеп дәшкән якка —
Еракка, еракка-а...
Төннәрен дә, көндез дә,
Гел бер эздән, гел бер эздән,
Гел бер эздән чап инде,
Шуннан кызык тап инде!

Өлкән трамвай абый
Елмаеп кына тыңлый:
— Әһем, әһем, әһем, ди,
Сабыр, сабыр! энем, ди.
Әнә нәни бала, ди,
Үз юлыннан бара, ди,
Синең юлыңа керми,
Рельсләр буйлап йөрми!
Нәрсә булыр, фаразан,
Чыгып безнең арадан,
Тротуар буйлап китсәң!
Тыкрыкка кереп китсәң!

һәркемнең үз юлы бар,
Үз юлыңнан туры бар!

Яшь трамвай төшенде,
Урамга күз төшерде —
Анда аны көтәләр,
Көтә ничә тукталыш,
Тукталыш тулы таныш!
Җилкенеп алып китә,
Җил кебек чабып китә,
Тип-тиешле минутта
Тип-тиеш төшкә илтә!
Нәкъ шулай тиеш тә шул —
Бик кирәкле эштә ул!

...Ә шулай да, кайчакта,
Офыклар көткән якка
Поездлар дәшкән чакта
Барып кайтасы килә
Еракка, еракка-а...

**Марсель Зарипов**

# БАҺАДИР ДӨНЬЯГА КИЛӘ

## КамАЗ КӨНДӘЛЕГЕ



«КамАЗ турында язганда вакытны «кичә, бүген, иртәгә» дип кенә билгеләп булмый, сәгате-минутына хәтле төгәл әйтеп язарга кирәк, югыйсә, иң өлгер хәбәрченең дә вакыйгалардан соңга калуы бар». Төзелешнең иң кызган чагында Чаллыга килеп төшкән бер журналист әнә шулай диебрәк әйткән иде.

Ләкин шушы бишьеллыкның иң күренекле эше, легендар Магнитка, Комсомольск, Братскиларның дәвамы булган бу төзелешнең эш ритмы шул кадәр тиз, шул кадәр кызу,— сәгатьләр һәм минутлар да артык күп булыр кебек.

Әйтергә кирәк, без бәхетле кешеләр — КамАЗның ничек башланганын күреп калдык.

Чаллыга колхозчыларның Өченче бөтен союз съезды тәмамлангач та бардык без. Шул съездда КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Л. И. Брежнев Совет хөкүмәтенең Кама буена зур йөк автомобильләре заводы салырга карар иткәнлеген әйтте. Бу төзелешкә биш ел вакыт бирелгән. Хәер, биш ел эчендә генә аның бөтен эше бетмәс, төзүчеләргә эш җитәрлек табылыр, әмма 1954 елда инде конвейердан беренче автомобиль төшәргә тиеш.

Чаллыга без декабрь аенда килдек һәм беркадәр соңга да калган булып чыктык. Көнбатыш сәүдәгәрләре, Сәмәркәнд кәрванбашлары һәм славян купецлары килеп йөргән заманнардагы байтак кына борынгы сыйфатларын саклаган кечерәк кенә бу шәһәр берничә гасыр буена үсә алмаганын менә хәзер кайтарырга керешкән сыман. Егерменче гасыр да Чаллыга дан китерми. Ул зур гына бер төбәкнең район үзәгенә әйләнсә дә, исеме әллә ни шауламый. Җәй көне әле монда килүе ансатрак: теплоходлар, «метеор»лар йөреп тора. Ә менә кыш көне Чаллыга эләгүе шактый кыен. Тимер юлдан ул ике йөз чакрым читтә, бөтен өмет самолетка кала. Ләкин самолетка ышанып бетеп булмый: көн әйбәт булса — очә, булмаса — юк.

Чаллыны танырлык та түгел хәзер: бу шәһәр, ун еллар, йөз еллар буенча урнашып килгән тәртибен онытып кебек, тыгыз, кызу, ашыгыч бер график белән яши.

Инде юллар да сала башлаганнар: өсләренә кыска тун кигән таза-таза егетләр туң җирне җылытып тигезләп баралар, киң юлның як-ягына инде беренче йортлар да килеп утырган.

Аэродромдагы кечкенә генә йортта шыгрым тулы халык. Беришеләре бирегә әле яңа килеп төшкән — «КамАЗ кайда ул?»— дип сорыйлар, икенче берләре китәргә җыена — өйләренә кайтып, монда килергәме-юкмы икәнен хәл итәсе бар. Өченчеләренең халык арасында йөрисе, тегене-моны ишетәсе, яңа хәбәрләр беләсе килә. Шуңа күрә халык корт иле кебек кайнап тора, КамАЗ турында, шәһәр турында, монда кузгалган эш турынданиләр генә сөйләмиләр! Ләкин шау-шу, гөж килү юк, тәртипле бер җыелыштагы кебек, берәү сөйли башласа, бер-ике сүз әйтсә дә, аны бүлдермиләр, игътибар белән тыңлыйлар.

Юлларына бетон җәелмәгән менә шушы гади аэродромны, андагы халыкны күргәч үк, әле кәгазьгә генә сызылган бу зур төзелешкә безнең хөрмәтебез уянды һәм күңелебездә туган беренче тойгы күп еллар яшәгән, ияләшкән урыннарыннан кубып, зур эшкә килүче кешеләргә соклану, алардан көнләшү тойгысы булды. Әйбәт кешеләр алар! Эш әле яңа гына башлана бит, рәткә-җайга да салынмаган, читенлек-уңайсызлыклары да бик күп, шулай да курыкмаганнар, җыелып монда килгәннәр. Аларның Чаллы җиренә килеп яши башлаганнарына әле бер генә атна дыр, мондагы бөтен нәрсә әле чит-яттыр, шулай да алар инде төзелешнең киң колачлы булуы белән горурланалар, «җиң сызганып эшләргә», «үзеңне күрсәтергә» җыенуларын яшермиләр.

Аннары без проектчылар белән сөйләштек. Шәһәрнең киләчәген бөтен нечкәлекләренә хәтле белә икән алар. Кичә, бүген генә монда килгән кешеләрнең эш турында, шәһәр турында шул чаклы белеп сөйләүләренә исебез китте. Завод хакында алар барысын да белә икән, авторитетлырак башка чыганакларны эзләп йөрисе дә юк.

Бу төзелешкә, Тольяттидагы шикелле үк, биш ел вакыт бирелгән, ләкин монда Идел буе автозаводындагыдан бер ярым мәртәбә артык эш эшлисе бар икән.

1980 елда илебезнең автомобиль транспорты 4,8 мәртәбәгә артачак. Моның шактый өлешен КамАЗ машиналары тәшкил итәчәк.

Кама буенда тугыз, унике катлы йортлардан торган шәһәр салыначак, аның драма театры, циркы, йөзү бассейны, институт, техникумнары булачак икән...

Төзелештә эшләүчеләрнең бар нәрсәне белүләре гаҗәп түгел. Алар бит монда турист булып сәяхәткә килмәгәннәр, эшлисе эшнең колачын алдан ук күз алдына китереп, зур җаваплылык тоеп, хуҗа булып килгәннәр.

Төзелешнең беренче эшен Татарстанның үз егете — скреперчы Аяз Насыйров башлый. Бу фактның үзендә бәйрәмчә тантаналы бер мәгънә бар. Шулай булмаска — республика үзенең яңа биографиясен — автомобиль төзү эшен башлый бит. Борын-борыннан иген игеп, мал-туар асрап, бакча үстереп кенә яшәгән кешеләр бер буын гомере эчендә самолет ясарга, каучук, полиэтилен алырга, электр генераторлары әйләндерергә, җир астыннан нефть чыгарырга өйрәнгәннәр, ә хәзер тагы бер һөнәр — автомобиль төзү эшен үзләштерәләр.

Кышның бу аена хас булганча көн салкын. Камада боз өстендә балыкчылар тезелешеп утыра, яр буена бик күп халык җыелган.

Насыйров — киң җилкәле таза егет, үзе бер дә дулкынланмый кебек. Машинасын әйләнеп узды, кем беләндер бераз сөйләшеп торды, аннары, киез итеге белән скреперының чылбырларына типкәләп алганнан соң гына, кабинасына керде. Гадәттәге эшенә тотынган кебек — исе дә китми!

Дөресен әйткәндә, биредә мондый машинаның әллә ни кирәге дә юк иде бугай. Кар әле аз төшкән, бульдозер, экскаваторларны тип-туры эшкә кушарга да мөмкин иде. Әмма бәхетле минутларны озаккарак сузмыйча да, йоланы үтәмичә дә булмый бит! Зур корабны беренче тапкыр суга төшергәндә ни өчен бер шешә шампан ваталар? Яңа йортның нигезенә ни өчен көмеш тәңкә салып калдыралар? Бәхеткә булсын

дип шулай эшлиләр. Кораб төзүчеләр берне генә түгел, унны ясыйлар, яңа йортлар да аз салынмый, ә менә КамАЗ шикелле төзелешне тагын кайчан башларсың? Шулай булгач, нигә йоланы җиренә җиткереп үтәмәскә, үзеңә бәхет-бәрәкәт теләмәскә?

Насыйров кабинага кереп утыргач та сабыр, салмак кыланды: унга күз салды, сулга күз салды, аннары үз алдына баш кагып куйды да үз машинасын ап-ак кар өстенә алып кереп китте... Аның артыннан өр-яңа өч бульдозер кузгалды, аннары төзелешнең иң яхшы машинисты Михаил Носков та экскаваторын эшкә кушты. Яр буенда «Ура!» тавышлары яңгырады. Беренче машинаның кузовына төзелеш мәйданының беренче балчыгы шыбырдап коелды. Бу хәл 1969 елның 13 декабренда булды. Бу датага әле без тагы да зуррагын — беренче автомобиль туган көнне дә өстәрбез дип өметләнәбез.

Менә без ике елдан соң КамАЗ белән тагын очраштык, 1972 елның 1 мартында дип төгәлрәк әйтик, чөнки монда вакыт исәбен еллап санамыйлар, Чаллыда хәзер вакытны айлап, көнләп, сәгатьләп исәплиләр.

Барган чакта очеркны юл килүдән яза башларбыз, Кама елгасы буендагы иске бер Чаллы каласының колач җәеп яңарып китүе, аның зур төзелеше, туганда ук гигант булып туачак заводы турында әйбәтләп язарбыз да укучыга тәкъдим итәрбез дип уйлаган идек.

Чаллыга килеп төшкәч тә иң элек телефон станциясенә керергә туры килде,— каядыр шалтыратасы булды,— һәм анда кергәч тә КамАЗ турында язачак әйберебезне алдан ук планлаштырып кую мөмкин түгел икәнлеген, аның дөрес, төгәл булмаячагын аңладык. Бу рәвешчә эш итү, әйтик, бернинди корал-приборсыз Венера белән Юпитер планеталары арасындагы ераклыкны чамаларга тырышу сыман бер эш булыр иде.

Станция әле энәдән-җептән генә чыккан, өр-яңа. Наладчиклар эшләрен дә бетермәгәннәр, чыбык очларын тоташтыралар, төрәләр, ә телефонистлар инде эшкә керешкәннәр — абонентларны тоташтыралар. Станциянең алты мең номеры бар, бу әле Чаллыны Казан, Мәскәү белән, бөтен ил белән тоташтырачак биш элемтә үзәгенең нибары беренчесе. Башка шәһәрләр белән әле телефонистлар ярдәменнән башка сөйләшеп булмый, Мәскәү белән Казанны алу исә бик ансат. Ун-унбишләп санны җыясың да теләгән кадәр сөйләшәсең.

Смена башлыгы Клавдия Васильевна Рукавишникова (Чаллыдагы телефон станциясендә кыз чагыннан бирле, егерме биш ел эшли икән инде ул), элек мин бер үзем колхозларны да тоташтыра, Казанны да ала идем, ә хәзер утыз кеше эшләсәк тә көчкә-көчкә житешәбез, ди. Станция тәүлек буе тоташ эшли, иртән кояш әйләнеше буенча Владивостокны, Новосибирскины, Свердловскины, Мәскәүне алалар, каналлардан файдалану коэффициенты — сиксән процент. Зур сан бу. Моның өчен телефон станциясенә никадәр эш башкарырга кирәклеген элемтәчеләр яхшы беләләр.

Клавдия Васильевна безгә кырый коммутаторны тыңлатып карады. Без төзелешнең кызу эш ритмын, КамАЗның бишеге өстенә иелгән зур илнең йөрәк тибешен шундук тойдык. Кама автозаводының проектын илебезнең алтмыш шәһәрендә эшлиләр. Аның заказлары Союзның бөтен җиренә таралган биш мең предприятиегә тапшырылган. Элемтә исә монда фронттагы кебек кирәк. Бер-берсеннән мең километр ерактагы абонентлар цемент, металл хакында сөйләшәләр; станок, машиналар ясауга бирелгән заказларны аныклыйлар; смета, проект документацияләре турында бәхәсләшәләр. Менә әллә кайдагы Сахалин бәйләнешкә керде, бик ерактан өзек-өзек ишетелгән тавыш: «Без төзелешкә балык җибәрергә наряд алдык,— диде.— Төзүчеләр балыкның ниндиен яраталар: йөз тонна Тын океан селедкасы җибәрикме, әллә ярты тонна кета балыгымы?»— дип сорады. Мондагылар да юморны яхшы аңлыйлар икән, шундук җавап бирделәр:

— Без дә балык ашый беләбез. Икесен дә җибәрегез,— диләр.

КамАЗ нәрсә соң ул? Чаллыга килгәч тә ачыклыйсы килгән беренче сорау әнә шул. Бернинди гомумиләштерү, чагыштырусыз, паспорты буенча гына әйткәндә — Кама буендагы автомобиль заводы ул. Әмма КамАЗ автомобиль заводы гына түгел. КамАЗ ул — илебезнең атаклы полуторкаларыннан, бөтен сугыш юлын йөреп чыккан таза «ЗИС»ларыннан башланган автомобиль биографиясе, үз илебездә һәм бөтен дөньядагы автомобиль төзү эшенең тәҗрибә сөземтәсе, киләчәктәге автомобильләрнең нинди буласын бүген үк күрә алучы талантлы конструкторларыбызның кыю фикер табышы, социалистик экономиканың зур үсеш, көч-куәт күрсәткече, узган илле елда СССРда тормышка ашырылган өр-яңа үзгәрешләр нәтиҗәсе.

Үзәк Комитетның: «Совет Социалистик Республикалар Союзы төзелүенә 50 ел тулуга хәзерлек» турындагы карарында әйтелгән: «Коммунизмның материаль-техник базасын, коммунистик җитештерү көчләрен булдыру, иҗтимагый производствоны һәр яклап интенсивлаштыру, хәзерге заманның фән һәм техника казанышларын социалистик планлы хуҗалык системасының өстенлекләре белән органик рәвештә кушу, хезмәт ияләренең материаль һәм культура тормышы дәрәҗәсен тагы да күтәрә бару, яңа кеше тәрбияләү кебек зур мәсьәләләрне хәл итү күп миллэтле совет державасыннан бөтен көч-куәтен бирүне сорый. Аның җитәрлек байлыгы, бик күп төрле ресурслары, бөтен халыкның оешканлыгы, көйләнгән бердәм хәрәкәте боларга ирешү өчен бөтен шартны тудыра»,— диелгән.

Нинди булачак соң ул КамАЗ? Бу турыда байтак язылды инде, шулай да төзелешнең никадәр зур, никадәр катлаулы икәнлеген күз алдына китерү өчен тагы бер тапкыр әйтеп китәсе килә. Автогигант үзе тулаем унбиш заводтан торачак, шуның алтысы Кама буенда Чаллыда төзелә, калганнары башка шәһәрләрдә салыначак. Чаллыдагылары йөз квадрат километр зурлыгындагы мәйданны биләп торачак. Мондый хәлнең безнең ил практикасында да, бөтен дөнья күләмендә дә булганы юк әле. Көнбатыш Германиядәге «Даймлер-Бенц» фирмасының президенты Цаан әфәнде СССР автомобиль промышленносте министры А. М. Тарасов белән әңгәмәсендә: «Бу кадәр зурлык безнең өчен «яңа җир» ачу булыр иде. Сездәге мондый комплекс төзү планы Көнбатыш Германиядәге йөк машинасы заводларының барысын бергә узып китә. Андый нәрсә АКШта да юк»,— дигән иде. Кама автозаводы халык хуҗалыгына ел саен 8, 16, 20 тонна йөк сыйдырышлы 150 мең автомашина, 250 мең дизель моторы биреп торачак. Егерме дүртенче съезд директиваларында Кама автозаводының эшли башлау срогы да әйтелгән — ул 1974 елда эшкә керешәчәк.

Без тиз арада яхшы итеп күп төзергә тырышабыз. Днепрогэс, Амур буендагы Комсомольск каласы, легендар Магнитка һәм Братскилар әнә шулай төзелде. Магнитканы төзегәндә Магнит тавыннан беренче руда кисәген куптарган корал — гади көрәк булган. Горькийдагы автомобиль заводын салу олы абзый, апайларны укырга-язарга өйрәтүдән башланган. Кама автозаводы исә алдагы елларда тупланган индустриаль, техник, социаль һәм әхлакый тәҗрибәнең сөземтәсе ул. Беренче адымыннан ук ул кызыл сызыктан, бөтен державаның куәте җирлегендә зур егәрлек белән, дәрт-тырышлык белән төзелә башлады. КамАЗның бәхете дә, кыенлыгы да шунда. Беренче елында ук инде илебез бу төзелешкә куәтле өч мең автомобиль, биш йөз экскаватор, биш йөз кран, меңләгән бульдозер, панель ташыгыч, скрепер җибәрде... Хәзерге төзүчеләрнең кайгысы укырга-язарга өйрәнү түгел,— институт, техникумнарда укый алар. КамАЗ путевкасы белән башкала вузларына автозавод эшенә өйрәнергә. Казандагы авиация институтының автомобиль төзү факультетына укырга баралар. Кем әйтмешли, заманы да башка, җыры да башка! Бу

төзелештәге эш исәбе саннарын чагыштырып карасак, үзебезнең никадәр алга киткәнлегебезне, никадәр кыюрак фикер йөртә алуыбызны, мөмкинлекләребез артканлыгын күрәбез. КамАЗны төзеп җиткерү өчен, Идел буе автозаводындагы кебек үк, биш ел срок бирелгән, әмма Чаллыда андагыдан бер ярым тапкыр артык — өч миллиард сумлык эш башкарып чыгарга кирәк. Бу сумма сигезенче бишьеллыкта Татарстанның халык хуҗалыгын үстерүгә тотылган акча кадәр.

Кама автомобиль заводының илебез экономикасында тотачак урыны турында әйтеп киткән идек инде. Аның Татарстанга, Кама аръягы төбәгенә никадәр социаль, экономик һәм культура үзгәрешләре китерәчәген аерым әйтеп китәсе килә. Безнең республика, әлбәттә, беркая да исеме чыкмаган, даны таралмаган бер өлкә җире түгел. Самолетлар ясавы, ел саен җир астыннан 100 миллион тонна нефть чыгаруы, ә җир өстендә 100 миллион пот икмәк үстерүе, изопрен каучугы, мех, төгәл приборлар җитештерүе белән кайсы як җире мактана ала?! Хәзер Татарстанның Кама аръягындагы кечкенә генә бер мәйданы,— курыкмыйча әйтик,— дөньяда иң индустриаль төбәкләрнең берсенә әйләнә. Ике зур су юлы — Идел белән Кама, аларның энергия куәсе, илдә иң бай саналган нефть промыселлары, җирле чималдан югары сыйфатлы таза изопрен каучугы җитештереп, үсеп килгән Түбән Кама нефть химиясе комбинаты, химкомбинат һәм автозавод ТЭЦлары белән бергә Братск станциясе эшләгән кадәр электр энергиясе бирәчәк Зәй ГРЭСы һәм Түбән Кама гидростанциясе — Татарстанның бер төбәгендә — Кама аръягында гына да әнә шундый экономик көч тупланачак. Инде килеп, Әлмәт, Түбән Кама, Лениногорск, Зәй шәһәрләре, бик тиз үсеп барган Чаллы каласы — болар безнең якның өр-яңа культурасы, йөз меңләгән кешенең социаль тормыш, эш-хезмәт шартлары үзгәрүе диган сүз.

Төгәлрәк булырга тырышыйк: скреперчы Аяз Насыйров төзелешкә беренче эз салганнан бирле ике ел да ике ай һәм унҗиде көн вакыт узды. Чаллыга килгәндә без заводның төзелә, үсә башлаганын белә идек, инде байтак эш эшләнгәндер дип күз алдына да китерә идек, ләкин, килеп күргәч, гаҗәпкә калдык. Билгеле, завод үзе юк әле, әмма аның төп производство корпуслары инде җирдән калкып чыккан, 1980 елда 350 мең кеше яшәячәк шәһәрнең нинди буласын чамаларга мөмкин инде. Менә төзелешнең ритмын якынча гына күз алдына китерердәй бернйчә сан. Эш әле җәелә генә башлаган беренче елда төзүчеләр 60 миллион сумлык эш башкаралар. Шуннан соңгы елда эш күләме дүрт тапкыр арта. Бишьеллыкның икенче елында исә узган ике елдагыдан кырык процентка артыграк эш эшләргә кирәк. Әйтәсе дә юк, башлар әйләнерлек кызу темп! Графикны вакытында үтәп бару өчен көн саен бер миллион сумнан артыграк акчаны эшкә әйләндерергә кирәк. Өстәвенә, бу әле эшнең башы гына, үргә таба күтәрелә башлау гына. Эш темпы көннән-көн үсә барачак, чөнки Кама автомобилен бөтен ил көтә.

Төзелеш башлыгының беренче урынбасары Евгений Никанорович Батенчук (киң колачлы эшкә өйрәнгән, Чаллыга килгәнче Вилюй гидростанциясендә, Якутия төзелешләрендә эшләгән кеше), безгә аңлаешлырак булсын дип, гадирәк итеп, көненә бер миллион сумлык эш башкару өчен ниләр эшләнергә тиешлеген аңлатты. Көн саен 3 мең кубометр бетон салырга, 2 мең кубометр тимер-бетон конструкция корырга, 100 мең кубометр балчык чыгарып ташларга кирәк икән. Моңа тагын җир асты коммуникацияләре, юллар да өстәлә. Икенче төрлерәк чагыштырып әйтсәк, бер көн эчендә унике катлы йорт салып куярга кирәк. Әйтик, иртәнге алтыда геодезистлар килеп йортның урынын тамгалап чыгалар, тәүлек бетте дигәндә инде йорт әзер булып, монда яшисе кешеләргә квартир ачкычлары өләшәләр.

Зур төзүчеләр коллективының эш үзенчәлеген, тырышлык-дәртен, җитезлек-оешканлыгын әнә шул темп билгели. Шуңа күрә КамАЗның

әле кичә генә дә практикада куллану турында уйга да килмәгән кыю фикер-табышларны сынап карау урынына әйләнүе бер дә очраклы түгел.

Әйтик, иң гади бер мисал. Гадәттә, төзелеш котловансыз, нигезсез булмый. Борын-борыннан дигәндәй, нигезне болай салып киләләр: башта җиде-сигез метр тирәнлегендә чокыр казыйлар, балчыгын читкә чыгарып ташлыйлар, шуннан соң тимер-бетоннан бинаның нигезен салалар. Аннары инде нигезгә яңадан балчык ташыйлар, йорт утырмасын өчен, балчыкны кире үз урынына төеп тутыралар. КамАЗ шикелле төзелештә исә аның зурлыгы эшнең тизлеген тоткарлый торган җитди бер мәсьәлә булып килеп баса. Миллионлаган кубометр балчыкны әвеш-тәвеш китереп кара син!

КамАЗга килеп төшкәч тә күзгә ташлана торган нәрсә шул: завод салынасы җирләр актарып-казып ташланмаган, иске хәленчә калган диярлек. Завод биналарын гадәттәге нигез белән салмыйлар, бәлки 16—30 метр тирәнлектән коеп менгезгән тимер-бетон субайларга утырталар. Бина корыласы мәйданга скважиналар бораулыйлар да, шуңа тимер арматура төшереп, бетон коялар. Субайларга бинаны күтәреп тора торган тимер-бетон ныгытмалар утырталар.

Батенчук шушы «субай идеясе» хакында ничек бәхәсләшүләрен сөйли. Моңа каршы килүчеләрнең дә фикерләре нигезсез түгел, ни дисәң дә автозавод кечкенә бер алачык кына түгел бит, шул кадәр авырлыкка субайларның түзмәве мөмкин. Исәпләп-хисаплап карыйлар — түзәргә тиеш. Шуннан соң инде бу яңа эшне тиз арада гына өйрәнеп булырмы? дигән шик туа. Эшне киметү дигән нәрсә вакыт оттыру булып чыкмасмы? Меңләгән субай коярга кирәк бит! Искечә генә эшләү хәерле булмасмы: алай авыррак булса да, ышанычлырак; әкрен киткән—тиз җиткән, дигәннәр бит. Бу идеяне тормышка ашыру производство башлыкларыннан зур инженерлык сәләте, эшне башкаручылардан профессиональ осталык кына сорап калмый, ул кадәр җаваплылыкны үз өстеңә алыр өчен зур батырлык, тәвәккәллек тә кирәк.

Бу яңа эшне өйрәнергә Виктор Кузьмин, Алексей Мартьянов, Виктор Молостов, Николай Кудрявцев бригадалары керешә. Өстәвенә, боларның берсенең дә бораулап-коеп ясалган субай хакында ишетү түгел, гомумән, төзелештә дә булганнары юк икән. Чаллыга килгәнче Кузьмин Ленинградтагы атаклы Путилов заводында автоматлар көйләүче булып эшләгән, Мартьянов — җыючы-слесарь, Кудрявцев — түбә ябучы, Молостов колхозда төзүчеләр бригадасында эшләгән. Горький заводының атаклы эшчесе — Форд заводы тимерчеләрен дә уздырган Александр Бусыгин бишектә чагында ук кулына чүкеч тотмаган бит. Ә Стаханов, Кривонос, тукучы Виноградовалар? Эшне без беренче тапкыр әнә шулай нульдән башлыйбыз. Хикмәт нәрсә эшләүдә генә түгел,—ничек эшләүдә!

Башта бер бораулау җайланмасы белән көненә ике субай эшләсәк, шәп булыр иде, дип хыялланалар. Моңа рекорд итеп карыйлар. Төзелешкә без кыш көне, иң салкын чакларда килгән идек. Борау бораулый алсын өчен, туң җирне ут өрдергечләр белән җылытып эретәләр иде. Шундый авыр шартларда Юрий Девяшкин экипажы бетон кою өчен алты скважина ясап өлгертте. Дизель производствосы төзелешендә февраль аеның беренче яртысында алдагы бер айлыкы кадәр субай ясыйлар. Скважиналарга коеп субай ясауның бик отышлы эш икәнен багана-багана саннар китереп дәлилләргә дә мөмкин. Болай эшләгәндә миллионлаган кубометр балчыкны арлы-бирле күчерәсе юк, шулай булгач, машиналар да, кешеләр дә азрак сорала, югыйсә, бу эшкә меңләгән кеше кирәк булыр иде. Шулай да иң зур отыш — вакыт, темп ягыннан. КамАЗда иң элек детальләр кою заводын сала башлыйлар, калган участокларда эшкә соңрак тотыналар. Нигезен искечә, чокыр казып салганга, детальләр кою заводы әле җирдән калка да башламаган, дизель заводында инде монтажчылар субайларга бина каркасының әзер

секцияләрен утырталар. Деталь кою заводының дизельне куып җитә алмаячагы күренеп тора!

Төзелешнең елъязмасы, чынында, әнә шундый мисаллардан җыела. Алар КамАЗның, эшчеләр коллективының, автогигантны төзешүче һәр кешенең биографиясе язылачак зур бер китапның аерым сәхифәләре кебек. Төзүчеләр бу зур горурлыкның бәясен беләләр.

«Главмосстрой» бригадиры Жигачевны эзләп йөрүебез истә калырлык булды. Әйе, Чаллыны мәскәүлеләр дә төзешә, өстәвенә, бик тиз, бик яхшы эшлиләр,— бүгенгә әнә шул Жигачев могҗизалар тудыра, диделәр безгә. Прораб бүлмәсенә кердек — анда юк, бригаданың тәмәкечеләр бүлмәсенә сугылдык — анда да күренми. Шуннан соң йортка киттек — урмандагы шикелле, беркемне табып булмый. Уникe катлы зур йортның тимер ныгытмалары буйлап өскә үрмәлибез, квартирдан квартирга керәбез, бригадирны сорыйбыз, «Әле генә шушында иде»,— диләр. Ниһаять, иң өскә менеп җиттек, бездән дә өстә инде берни юк — югарыда эшләүче монтажчылар тавышы гына ишетелә. Прораб Володя Ковалев (ул да Мәскәүдән килгән): «Жигачевны тотасыгыз килсә, тагы да югарырак менегез»,— ди.

— Тагы да югарыракта нәрсә бар соң анда?

— Җил,— ди.

Иң югарыда, чыннан да, салкын җил өрә, суыктан тунган кебек, зәңгәр төтенгә өретелгән кояш сүрән генә елмаеп тора, ә аста — төзелеш, төзелеш, төзелеш... Бер як офыктан икенче як офыкка чаклы. Кама инде күренми, аны кар каплап киткән, ул язын җәелеп-ташып агар өчен көч җыеп ята. Кама буеннан ук Түбән Кама ГЭСын төзүчеләр салган поселок башланып киткән, аннары тәбәнәк йортлары белән Иске Чаллы күренә, шуларның барысы өстеннән хәзерге заманча салынган биек биналар калкып тора. Төзелешнең икенче башында исә завод каркаслары күтәрелеп килә.

Мәскәүдә, Ленинградта, Ташкентның Чиланзарә дигән яңа районындагы, Тольятти каласындагы шикелле, уникe катлы матур-матур ап-ак йортлар тезелешеп киткән, алар якын гына, кул белән үрелеп орынып булыр кебек. Берәү, икәү... җиденче... унберенче... Магазин, газета киоскасы, ашханә бар, автобуслар йөреп тора.

Жигачев вакытын әрәм итүдән курыккан кебек, безнен янга тиз-тиз менде дә, сүзне озакка сузарга теләмәгән сыман, шундук: «Николай» дип кул да сузды.

Ул утыз яшьләр тирәсендәге тәбәнәгрәк буйлы, ябыграк тәнле бер кеше булып чыкты. Кыяфәтенә карап кына көн ярым вакыт эчендә йортның бер катын салып өлгертүенә ышанып та бетмәссең. Болай эшләү — Мәскәү төзүчеләренең графигы икән.

Жигачев белән Петр Мазур дигән икенче бер бригадир (алар «Кайсыбыз тизрәк?» дип ярышып эшлиләр) уникe катлы йортны 4 нче декабрьда сала башлаганнар. 1 нче январьда инде йортны дәүләт комиссиясенә тапшырганнар, тагы ун көннән соң бу йортта кешеләр тора башлаган.

«Главмосстрой» төзүчеләре Кама буена быел җәй килгәннәр. Тиз генә урнашып алганнар да төзү эшенә дә керешкәннәр. «Төзү» диюдән бигрәк «җыю» дисәк дөресрәк булыр, чөнки йортны соңгы кадагына чаклы Мәскәүдә ясыйлар. Башкала төзүчеләренең бик тиз эшләүләренең сере дә йортны әнә шулай тулысынча завод конвейерында эшләп җибәрүләрендә. Былтыр алар илле мең квадрат метр тапшырган булсалар, быел бермә-бер артык бирәчәкләр.

Төзелешнең колачы, ритмы турында әйткән идек инде. Иң әһәмиятлесе — кешеләрнең үз эшләренә мөнәсәбәте икәнен дә әйтеп китик, чөнки ахыр чиктә калган барлык якларны да шушы мөнәсәбәт билгели. Төзелештә руслар, украиннар, белоруссלар, татарлар, үзбәкләр, кыргызлар,

молдаваннар — илебездәге барлык милләт вәкилләре диярлек бер гаилә кебек яшиләр, бергә эшлиләр. Төзелешкә алар «чит-ят» бер җиргә эшкә килгән кебек кенә килгән булсалар, хәзер Чаллының киләчәге турында, автозавод турында туган шәһәре яки авылы кебек яратып сөйлиләр.

Өч йөз еллык гомере эчендә Чаллы 35 мең кешеле бер калага әверелгән. Ә соңгы бер ел эчендә исә шәһәрнең халкы 80 меңгә житкән. Монда табигать шартлары җинел түгел, кышын утыз-кырык градуслы салкыннар була, язын-көзен исә, трактордан башка, олы юлдан читкә чыгарлык та түгел, ә кешеләр һаман килә тора. Биредә, Кама буенда, бишьеллыкның язмышы, совет иленең иртәгәге экономик һәм техник куәте мәсьәләсе хәл ителгәнен алар аңлыйлар, зур эштән читтә калырга теләмиләр.

Төзелештә кемнәр белән генә танышырга туры килмәде: моңарчы Братскида яки Асуан гидроузелы корылышында эшләгән монтажчылар белән дә, татар авылыннан килгән тракторчы егет яки КамАЗга ВЛКСМ Үзәк Комитеты тарафыннан җибәрелгән «Дуслык» отряды членнары белән дә сөйләштек. Аларның һәркайсы Кама буенда башланган төзелешнең зур, җаваплы бурыч икәнлеген аңлап эшли.

Куен дәфтәренә теркәлгән ике-өч әңгәмәбезнең кыскача гына язмасын китереп китәм:

**Николай Жигачев:** «Монтажчы булып Мәскәүдә эшли башладым. «Россия» гостиницасын салыштым. Шул вакытта Ташкентта җир тетрәде. Җыенып, анда киттек. Алты айга гына дип барган идек — дүрт ел эшләргә туры килде. Аннары Тольяттида — Идел буе автозаводында эшләдек. Хәзер менә Чаллыга килдек. Мәскәүгә кайтасы килә, билгеле. Ташкенттан өйгә сигез тапкыр, Тольяттидан алты тапкыр кайткан идем, моннан ике генә мәртәбә кайтып килдем әле. Мәскәүдә Кызыл Пресняда минем апам яши. Кайтып бер өч көн торам да туган якка — Плавскига кайтып килербез, аннары — яңадан монда. Хәзер без биредә биш кеше — сеңелем, энем Иван, киявебез Алексей һәм жиде айлык нәни энекәш бар. Гомумән, монда безнең Мәскәү кешеләре бер мең ярымлап җыела. Эшлибез, йортлар салабыз. Шәһәрдә үзең салган йортларда кешеләр яшәвен күрүе бик күңелле икән. Яртысы биредәге халык. Без үзебез кайчандыр моннан китәрбез, ә безнеңчә — Мәскәүчә эшләү алымы калыр, кешеләр безнең график белән эшләрләр. Бәлки, бездән дә тизрәк, бездән дә яхшырак эшләрләр. Начармыни алай?»

**Геворг Геворян** — ташчылар бригадиры, Татарстан АССРның атказанган төзүчесе: «Кавказда минем бертуган биш ага-энем бар, аннары туганнан туган бер абыем — совхоз директоры. Шул әйтә: «Кайт, совхозда эш табылыр»,— ди. Тик ничек китәсең инде моннан? Минемчә, кеше илгә кайда күбрәк файда китерә — ватаны аның шунда».

**Женя Гавриленко**—монтажчы: «Безнең Белоруссиядә дә төзелешләр күп; зур, кызыклы, житди төзелешләр бар. Ләкин КамАЗ бит бер генә! Мин үзем шофер идем, үзбушаткычлы машинада эшли идем. Монда килгәч, әйттеләр: «Бездә шоферлар җитәрлек, әйдә, монтажчы булырсың»,— диделәр. Шулай итеп, яңа эшкә өйрәндем, булдырам кебек. РИЗ га — автозаводны иң беренче эшләтә башлау комплексына эләктем. Корпусы бик зур, баганалары гына да тоташ урман кебек, берьюлы биш бригада эшләде; үзебезнең пролетны без беренче булып тәмамладык...»

Аяк өсли генә дигәндәй язып алынган мондый әңгәмәләрне ике-өчне генә түгел, унлап, йөзләпне китерергә мөмкин булыр иде. Боларның барысына да туган җир өчен, ил эше өчен җан ату дигән уртак бер тойгы хас.

КамАЗның тагы кай яклары әйтелми калды? Эшчеләр коллективының иң күркәм сыйфаты нәрсә? Бу сорауга бер сүз белән генә җавап биреп булмый, чөнки коллектив ул үзенә генә хас холык-гадәтле төрле кешеләрдән җыела, тик шулай да еш кына очракларда бер кешенең, бер бригаданың аерым сыйфаты, меңләгән кешенең хезмәт девизы, байрагы

булып китә. Төзелештә хәзер иң таралган сүз — Салаховча эшләү, Салахов үрнәге, Салахов принцибы дигән сүзләр. Утызынчы елларда Алексей Стаханов исеме ничек шаулаган булса, Чаллыда хәзер Рәис Салахов исемен шулай еш телгә алалар.

Рәис Салахов һәм аның иптәшләре ни эшләгәннәр соң? Алар икәү өч кеше хәтле эшләргә, көн саен 140 процент норма үтәп барырга, бишьеллыкныкын 1974 елның 7 нче ноябрена башкарып чыгарга карар кылганнар.

Гомумән, берәр тапкыр рекорд яки югары эш үрнәге күрсәтеп мактау әллә ни кыен эш түгел. Ләкин монда хәл башкача: бөтен сәләттырышлыгыңны җигеп эшләү көндәлек бер кагыйдәгә әйләнгән. Рәис Салахов һәм аның иптәшләре бөтен кеше күз алдында көн саен, атналар, айлар буе, ике ел буена — завод конвейерыннан беренче йөк машинасы төшкәнче — үрнәк эш күрсәтергә карар кылганнар.

Хәзер һәр төрле анкета тарату гадәткә кереп китте. Әгәр социологларның: «Кама автозаводы төзелешендәге әллә ничә мең кешелек коллективның иң беренче булып күзгә ташлана торган сыйфаты нәрсә?» — дигән соравына җавап бирергә туры килсә, без: «Һәр нәрсәдә, иптәшләреннең кечкенә генә бер эшендә дә файдалы асылын күрә һәм һәр кешенең тәҗрибәсен эшкә куша белү», дияр идек. Салахов бригадасының башлангычын барлык коллективта тикшерәләр, бәхәсләшәләр, ничек итеп эшне тагы да яхшырта төшү турында уйлашалар. Кашшаф Хәмитов җитәкчелегендәге машина йөртүчеләр бригадасы һәр айның 4—5 көнен янга калган ягулык белән эшләргә карар кабул итә. Петр Камаев автоскреперчылары кыш көне норма ярым, җәй көне ике норма эшләргә йөкләмә алалар. Машина рамнары ясау заводы пролеткаларын җыючы Виктор Деребизов бригадасы монтажчылары биш еллык программаны өч ел ярым эчендә башкарып чыгарга сүз бирәләр...

Зур Идел дәрьясы кечкенә инеш, елгалардан җыелган кебек, һәр кешенең, һәр бригаданың эш планы үтәлү нәтиҗәсендә дәүләт күләмендәге зур бурыч — 1974 елда Кама автомобиль заводын төзеп җиткерү бурычы тормышка ашырыла.

Без Чаллыга килер алдыннан гына төзелештә бер хат алганнар. Аны өлкә газеталарында да басып чыгардылар. Беренче бишьеллыкларның каһарманнары Алексей Стаханов, Александр Бусыгин, Мария Виноградова, Иван Гудов, Петр Кривонос үзләренең хатларында КамАЗны төзүчеләрнең эштә кыю, тапкыр булуларын, бүгенге заманга хас булганча колачны киңрәк җәеп эшләүләрен теләгәннәр.

— Һәр буынның үз Магниткасы бар. Без сездән көнләшәбез. Утызынчы еллардагы белән чагыштырганда, сезнең — җитмешенче еллардагы яшь эшчеләрнең — мөмкинлекләре бик зур.

Яңалык ансат кына юл ярып чыкмый: шуңа күрә сезнең тырышлыгыгыз да күбрәк, адымыгыз да ныграк булырга, характерыгыз да чыныга барырга тиеш, дигәннәр алар.

## Малик Хәмитов

# ЕГЕТ БУЛЫП ЙӨРЕР ЧАКЛАР ИДЕ



Ул күпме йөгергәндер, хәтерләми. Аякларның хәле беткән, йөрәк сикереп чыгардай булып тибә... Йөгереп барган шәпкә нәрсәгәдер абынып тукталып калды, кинәт тукталудан башыннан кепкасы җиргә төште. Җир өстенә агачлардан коелган юеш яфрак түшәлгән икән. Шул чакта гына ул үзенең урман уртасында булуына игътибар итте. Төнге урман тып-тын иде. Ату тавышлары да ишетелми — әллә иптәшләрен кырып бетерделәрме, әллә ул шулай ерак китеп өлгердеме? Әмма моны ачыкларга, сугыш вакыты өчен ят булган төнге тынлык белән хозурланырга хәле юк иде аның. Дүрт көн йокы күрмәгән, дошман тылына чыкканнан бирле биш тәүлек буе һәр минут үтә киеренке хәлдә булган организм ял сорый иде. Ә йокларга һич тә ярамый. Ул автомат тоткан кулын күтәреп компаска карады. Компас теле селкенми — ватылган. Үзенең кайсы урында тукталып калуын да белми иде әле ул. Юк, кыен булса да, аякка басарга кирәк. Актык көчне җыеп булса да!..

— Встать!

Рифгат сикереп торганын сизми дә калды. Каршында бер капитан басып тора. «Сезнең разведчиклар Марьяновка авылында бит. Әйдә киттек,— ди ул, дусларча ягымлы тавыш белән.— Шунда ял да итәрбез»...

...Битне куак ботаклары тырный, баш өстенә кар ява. Аның башы үз башы түгел икән ләбаса, бала-чага кардан әвәләп ясаган Кыш бабай башы икән. Шул кадәр авыр ул...

Алда ниндидер ачыклык беленде. Шул ачыклык буйлап, эт кебек ырылдап, шар күзле ниндидер ят нәрсә йөгереп узды... Рифгат кинәт башын селкеп куйды. Игътибар белән алдына текәлде.

— Кайда соң ул?..

Инде таң беленә башлаган. Алдында чыннан да ачыклык. Ул урманны урталай кисеп үткән юл икән. Әлеге шар күзле ят нәрсә, мөгаен, машина булгандыр... Янында бернинди капитан да юк. Димәк, ул аяк өсте төш күреп килгән. Хәтта бая җирдән иелеп алган кепкасын да кияргә өлгермәгән: сул кулында — автомат, уң кулында — кепка. Әчләр юпь-юеш. Рифгат кепкасын тиз генә башына элде дә автоматын җайлап тотты, билен капшады: бер граната калган икән әле. Аннары, юлны бераз күзәткәннән соң, йөгереп аргы якка чыкты да алга таба китеп барды... Җеп өзәрлек тә хәле юк, әчтә бөре улый, суык сөякләргә кадәр үткән. Иртән кар ява иде, соңрак ул яңгырга әйләнде: кием-нәр юеш, авыр.

...Кайдандыр төтен исе килә түгелме? Рифгат туктап иснәнергә керешә, әгъйифь көнә балта тавышы ишетелгәндәй булды. Ул актык



көчен җыеп алга атлады. Тиздән балта тавышы тынды, ә төтен исе көчәйгәннән-көчәя барды.

Кечкенә генә аланлык. Аргы якта окоп казылган. Окоптан өч штык күренеп тора. Немецныкы түгелләр — өч кырлылар. Арттарак землянка морҗасыннан төтен чыгып тора. Рифгат аланны читләтеп бик сакланып кына землянкага якынлашты. Башта морҗадан чыккан төтенгә тотып кулын җылытты, аннан, автоматын алга каратып, ачык ишек янына узды. Эчтән акрын гына сөйләшкән тавышлар ишетелә иде.

— Кулларыгызны күтәрегез!

— Куй автоматыңны. Үзебезнекеләр...— Моны, яткан урыныннан да кузгалмыйча, олы яшьтәге бер солдат әйтте. Рифгат аның зәңгәр күзләрен, битен әйләндереп алган җирән сакалын гына шәйләп калды.

...Тәүлеккә якын бер дә уянмыйча йоклады ул.

Итле ботка ашап тамак туйдыргач кына землянка хуҗалары — алар өчәү иде — үзләренең кем икәнлекләрен әйттеләр. Соңгы сугышлар вакытында камалышта калган булганнар икән. Исәпләре — берәр партизан отрядына кушылу, яки, җай туры китереп, үзебезнең якка чыгу.

Рифгат тә үз хәлен сөйләп бирде.

...1943 елның ноябрь урталары иде. Совет гаскәрләре азат иткән Киев шәһәрен кабат кайтару, Днепрның уң ягындагы безнең плацдармны юк итү өчен дошман сигез танк, җиде пехота дивизиясе көче белән бу вакытта контрһөҗүмгә күчкән иде. Канлы сугыш башланып китте.

Менә шушы көннәрдә 60 нчы армия штабы каршындагы разведка группасына фронтны кичеп үтеп, дошман көчләренең туплану урыннарын картага төшерү, радио буенча алар турында командованиегә хәбәр итү бурычы куелды.

Лейтенант Василий Якимов командалыгындагы отрядта унсигез яшьлек сержант Рифгат Гайнуллин да бар иде. Арада иң яше булса да, тәҗрибәле разведчик иде инде Рифгат.

...Бөек Ватан сугышы башлангач та Иж суы буендагы Барҗы авылы егетләре Рифгат белән Гата берничә мәртәбә җәяүләп Красный Борга — район үзәгенә бардылар, военкоматка кереп, фронтка җибәрүне сорадылар. Кетәргә кушылды аларга: «Яшегез җиткәч, җибәрербез»,— диделәр.

1942 ел. Әтисе Хәйрулла агай күптән инде фронтта. Сирәк булса да хаты килеп тора. Ниһаять, Рифгат тә солдат. Кыска сроклы полк мәктәбен үткән яшь сержантны 322 нче укчы дивизиянең 1089 нчы полкына җибәрделәр. Бу вакытта, 1943 елның язында, дивизия Сейм елгасы буенда, Рыльск шәһәре янында оборонага урнашкан иде. Картрак, тәҗрибәле солдатлар тирә-яктагы үзгәрешләргә карап, тиздән һөҗүм башланасын бик тиз сизенделәр: частьлар яңа көчләр белән тулыландырыла, өйрәнүләр алып барыла. Хәтта олырак командирлар һәм политработниклар да вакытларын күбрәк солдатлар арасында үткәрә... Әнә полк штабыннан Данилов дигән өлкән лейтенант килгән. Ул разведкага кешеләр сайлый икән.

Зәңгәр күзле, әле малайлыгы да чыгып бетмәгән татар егете, сер-

жант Гайнуллин өлкән лейтенантка — полк штабы начальнигының разведка буенча урынбасарына — нәрсәсе беләндер ошады.

Менә ул беренче разведкада. Алда — Сейм елгасы. Хәзер язгы ташу вакыты. Иж елгасы да яз көннәрендә нәкъ Сейм кебек җәелә. Охшаса да охшар икән! Барҗы авылы турысында да, нәкъ биредәге кебек, өч-дүрт төштә калку урыннар — аларны авыл халкы: «Алып бабай чабата кагып киткән җир»,— диләр — язгы ташу вакытында утраулар булып су эчендә кала. Бүген төнлә Рифгат биредәге шундый утрауларның иң аргысына чыгып, дошман ягын күзәтергә тиеш. Резин көймә өрдереп куелган, маскхалат, җылы кием, кирәк-ярак кораллар, көн буена җитәрлек азык әзер. Төн җитәсен генә көтәсе бар.

...Төнге су өстендәге караңгылыкны күктәге кара болытлар шәүләсе тагы да куерткан. Разведчиклар аргы утрауга тавыш-тынсыз барып җиттеләр. Калганнары килгән юл белән кайтып китте, Рифгат, уңайлы урын сайлап, яшеренеп ятып калды.

Таң атты. Дошман ягы таулы булса да ачык күренә. Немецларның алгы сызыгы арырак булса кирәк — яр буенда хәрәкәт артык сизелми. Ара-тирә, күпмедер вакыт узган саен, дүрт немец яр буен карап китә. Бинокльдән ачык күренә: берсе офицер, өчесе солдат. Дозорларыдыр инде.

Рифгат, дошманга сиздермичә генә, аргы якка чыгу өчен җайлы урыннар билгеләде, көне буе дошман ягыннан күзен алмады. Көн хәвеф-хәтәрсез узды.

Икенче көнне утрауга бүтән разведчиклар килде. Бу юлы бурыч катлаулырак иде: дошман ягына чыгып, «тел» алып кайтырга!

Дошман ягына Рифгат билгеләгән урында чыгып, засадага урнаштылар. Әлеге дозор озак көттермәде. Алдан корган план буенча эш иттеләр: сиздермәстән килеп чыгып, өч солдатны дөмектерделәр, әмма офицер пистолетыннан атып өлгерде, пуля разведчиклар группасы башлыгы кече лейтенантның башына тиде. Бүтән атарга ирек бирмәделәр — бөтереп салып, авызына чүпрәк тыктылар. Немецлар ялгыз ату тавышына игътибар итмәделәр, ахры: алар ягында шау-шу күпмады. Һәлак булган лейтенант гәүдәсен, куллары каерып бәйләнгән офицерны көймәләргә салып, кайтыр юлга юнәлделәр...

Агентура разведкасы немецларның яңа төр противогаз белән тәэмин ителүе турында хәбәр иткән. Әллә фронтның бу участогында алар газ кулланырга уйлыйлармы икән? Моны, кичекмәстән, ачыкларга кирәк иде. Рифгатләр группасы — кабат елга аръягында. Батыр разведчиклар бу юлы да уңышка ирештеләр: противогаз гына түгел, аның иясе дә штабка китереп тапшырылды.

Оста, җитез разведчикларны армия разведкасына җыя башлагач, полк штабы приказга каршы килә алмады: Рифгат Гайнуллинны да атаклы полковник Иван Данилович Черняховский командалыгындагы 60 нчы армия штабы карамагына җибәрергә мәҗбүр булды.

Армия штабына иллеләп разведчик сайлап алынган иде. Башта алар әзерлек үттеләр: немец теле, радио белән эш итәргә, шифрлар белән язарга, укырга өйрәнделәр, немец частьларының үзенчәлекләре белән таныштылар.

Армия разведчиклары тормышы шактый үзенчәлекле икән. Монда бер-береңнең чинына, дәрәҗәсенә әллә ни игътибар ителми, хәтта хәрби кием кию дә катгый мәҗбүри түгел. Чөнки үзебезнең якка алар ялга гына кайталар. Ә «кунак»та, дошман тылында, йөргәндә хәрби дәрәҗәгә карап түгел, разведчик осталыгына, җитезлеккә, бер-береңә ярдәмгә сәләтеңә карап ихтирам итәләр. Минут саен үлем көтеп, дошман арасында, ерак дошман тылында йөргәндә, беренче чиратта, үзең турында түгел, иптәшләрең турында, куелган бурыч турында уйла — шул шарт. Ә «кунак»ка аларны гаять мөһим бурычларны хәл итәргә

җибәрәләр. Шуның өчен дә армия разведкасы да инде ул. Армия штабыннан түбәнрәк часть командованиесе белән бәйләнешкә керергә аларның хаклары юк.

...Фашист гаскәрләре Курск дугасында җиңелсәләр дә, каршылык күрсәтүләрен дәвам иттерәләр, тылдан яңадан-яңа частьлар китереп сугышка кертәләр, ташкын булып килгән совет гаскәрләрен туктатырга тырышалар. Һәр авылны, һәр калкулыкны азат итү күп корбаннар сорый.

Рифгатләр группасы, фронт сызыгыннан унбиш-егерме километр дошман тылында килеш, август аенда бер атна дәвамында һөҗүм итеп килүче безнең гаскәрләрдән алда барып, дошманның җанлы көчләре һәм техникасы турында радио аша армия штабына бик күп мәгълүматлар бирде. Ул көчләр, фронт сызыгына җиткәнче үк, безнең авиация тарафыннан таркатылдылар.

Рифгат Украинаның башкаласы Киев шәһәрен азат итү өчен барган сугышлар вакытында берничә кабат дошман тылында булды, Днепр елгасының аръягына чыгып, «тел» алып кайтты, дошман позицияләрен картага төшерде... Әйе, унсигез яшьтә генә булса да, тәҗрибәсе шактый иде инде Рифгатнең.

...Бу юлы фронт сызыгын алар уникe кеше кичте. Урманнар, куаклыкларга ышыкланып, егерме километрлар чамасы дошман тылына эчкәре үттеләр. Көндезләрен Коростышев шәһәре тирәсендәге тимер юлларны, шоссе юлларын, немецларның җанлы көчләре һәм техникасы тупланган урыннарны күзәттеләр, ә төннәрен, күзәтү нәтиҗәләрен радио аша штабка хәбәр иткәннән соң, оператив план нигезендә, урын алмаштырдылар — бер урманнан икенче урманга, аннан өченчесенә күчтеләр.

Рифгат, гадәттәгечә, дозорда — алда бара иде. Күзгә төртсәң дә күренмәслек караңгы төн. Күктә кургаш булып агылган авыр болытлардан ябалак юеш кар төшә. Кар биткә, киемнәргә сырыша да су булып ага... Рифгат алдында гына нәрсәдер шәйләп тукталып калды. Ул да булмады, кайнар сулышын биткә өреп, автомат тырылдарга кереште. Пулялар аның баш очыннан дуга рәвешендәге сызык булып сызгырышып узды. Әмма Рифгат өчен секундның ничәдер бер өлеше кадәр вакыт җитте — аның да автоматы телгә килде, немец автоматчысы аның аяк астына диярлек «гөрст» итеп җиргә ауды. Һавага ракеталар чөелде, тирә-юнь, куаклыклар күзне чагылдырырлык яктылыкка күмелде. Каршыдан бик күп автоматлар безнең разведчикларга каршы ут ачты. Рифгат җиргә ауды. Егетне үтерергә теләгән, әмма аның утыннан үзе дөмеккән немец гәүдәсенә ышыкланып, автоматыннан ике озын очередь бирде, берничә гранатасын ыргытты да ракета яктысында күренеп калган куаклыкларга таба йөгерде. Битенә куак ботаклары бәрелгәч, тукталып артына борылып карады. Разведчикларның төп ядросы булырга тиеш урын белән Рифгат арасында — нәкъ уртада — миналар төшеп ярыла башлады. Засадамы, әллә берәр хәрби объектны саклау урынымы? Якында гына немецча сөйләшкән тавышлар ишетелгәч, Рифгат килгән юлдан түгел, ә сул як читкә таба артка йөгерде. «Юк, разведчик башың белән немец кулына эләгү егетлек түгел,— дип уйлады ул, бар көченә йөгергән шәпкә.— Егетләр белән генә ул-бу булмасын иде!..» Шул рәвешчә бик озак йөгерде ул...

— Иптәшләреңне ничек табарга уйлыйсың? — дип сорады әлеге җирән сакаллы солдат.— Разведчик булгач, фронт аша юлны беләсең, иптәшләреңне эзләп йөрүдән мәгънә юк, безнең белән, әйдә, үзебезнең якка.

Рифгат моңа риза булмады. Разведчиклар алдан ук сөйләшкәннәр иде: әгәр бер-береңнән аерылышырга туры килсә, узган төн тукталган

урманга барып табышырга, алай да булмый икән, эләктәгерәк тукталышларга барырга...

Иптәшләреннән аерылганга ике көн узды бит инде. Рифгат, картасын чыгарып, үзләре узган маршрутны кабат күз алдыннан кичерде. Иптәшләре киләсе төндә Марьяновка авылы янындагы урманда булырга тиеш. Аңа тикле, турыдан, егерме километрга якын юл үтәргә кирәк. Немецлар мыжгып торган ерак тылда турыдан йөреп буламыни?!. Рифгаткә ашыгырга кирәк иде. Ул яңа танышлары белән саубуллашты да юлга чыкты. Өч солдат аңа хәерле юл теләп калды.

...Иптәшләре чыннан да Марьяновка урманында булып чыкты. Разведчиклар әлеге төндә немецлар белән бәрелешкә кереп тормаганнар. Бу бик табигый: аларга мөмкин кадәр дошманга үзләрен сиздермәскә кирәк. Шулай да мина ярчыгы тиеп Тула егете Петр Савин һәлак булган, Себер егете Агапов каты яраланган икән. Немецларның бик нык маскировкаланган корал складлары булып чыккан бу урын. Хәзер инде аның көле күккә очкан — бу турыда егетләр командованиегә радио аша хәбәр иткәннәр дә безнең самолетлар килеп бомбага тотып киткән. Яңа задание алынган...

Бу вакытта фронттагы хәлләр түбәндәгечә иде.

1943 елның 6 ноябрендә совет гаскәрләре Киев шәһәрен тулысынча азат итте. Киев шәһәре өчен сугышлар вакытында дошманның 12 пехота, 2 танк һәм 1 моторлаштырылган дивизиясе тар-мар ителде, 50 меңгә якын солдаты һәм офицеры әсир төште, меңнәрчә туплары, танклары һәм үзйөрешле орудиеләре җимерелде. 100 гә якын самолеты бәреп төшерелде. Немец-фашист командованиесе, кыен хәлдән котылу өчен, зур ашыгычлык белән бу юнәлештә көчләрен тупларга керешге. Зур көч туплап, дошман Днепрның уң ягындагы безнең плацдармны юк итәргә, яңадан Киев шәһәрен яулап алырга теләде. Һәм чыннан да немецлар контрһөҗүмгә күчте. Көчләр тигез түгел иде. Безнең гаскәрләр чигенергә мәҗбүр булды. Азат ителгән Житомир шәһәре кабат дошман кулында калды. Беренче Украина фронты гаскәрләренә (ә 60 нчы армия шушы фронт составында иде) дошманның бу контрһөҗүмен туктатырга приказ бирелде [1].

Рифгатләр — 60 нчы армия разведчиклары — дошман тылында, Житомир, Коростышев шәһәрләре тирәләрендә, нәкъ менә шушы көннәрдә хәрәкәт итте. Әлбәттә, дошманның бу һөҗүмен туктату өчен разведка мәгълүматларының әһәмияте гаять зур иде.

Дошман, ничек кенә булмасын, бу участокта инициативаны үз кулыннан ычкындырырга теләмәде. Тар-мар ителгән гаскәрләре урынына көнбатыш Европадан яңа дивизияләр китерде. Рифгатләргә бирелгән яңа задание дә шуның белән бәйле икән. Агентура разведкасы түбәндәгеләрне хәбәр иткән: фронтның шушы участогына Италиядән немецларның 2 нче Милан дивизиясе китерелергә тиеш. Разведчикларның бурычы — Житомир тирәсендәге тимер юл станцияләренә килгән эшелоннарны күздән югалтмаска! Дивизиянең кайда төшүен һәм кая юнәлүен хәбәр итәргә! Разведчикларга Милан дивизиясе солдатлары һәм офицерлары киемнәрендәге аерым билге дә белдерелде: күкрәк турысына беркетелгән свастикалы каракош башын аска төбәгән булырга тиеш.

Разведчиклар Милан дивизиясен Ильинка станциясендә эзләп таптылар. Немецлар никадәр яшерен хәрәкәт итәргә тырышсалар да, безнең разведчиклар аларны тиз таныдылар: аларның көньяк кояшында янган симез битләре бронза төсенә кергән иде. Берсен «тел» итеп үзебезнең якка алып чыгарга кушканнар иде дә, әмма аны, немецлар кырмыска кебек мыжгып торганда, 30—40 километр ничек сөйрәп йөрисең? Өстә-

[1] Бөек Ватан сугышы тарихы. 3 том. 342 бит.

венә, әле яралы Агапов та бар. Дөрес, Милан дивизиясе хәрәкәт иткән юл өстендә безнең авиация өзлексез «эленеп торды». Фронтның бу участогындагы фашист гаскәрләренә «сугышчан рух» өстәргә тиешле, Италиядә көч җыйнап, кояшта кызынып ял иткән немец солдатларының һәм офицерларының кикрикләре тиз шиңде: безнең самолетлар, төркем-төркем булып бер-бер артлы килеп, алар өстенә бик күп бомба яудырды. Фашистларның бик азы гына алгы сызыкка барып җитә алды.

Тагын шатлыклы хәбәр: 60 нчы армия, үзе һөҗүмгә күчеп, Коростень шәһәрен азат иткән!..

Әмма юлның авыры алда икән әле.

Килгән юл белән кайтырга уйладылар. Фронт сызыгына якынлашкан саен, хәл читенләште. Кая карама — немецлар. Җирнең астын өскә китергәннәр, борын төртерлек тә урын калдырмаганнар. Тоташ ныгытмалар торгызылган. Киткән юлдан читкәрәк тайпылырга мәҗбүр булдылар.

Алда шактый зур авыл. Авылда немецлар. Ә аны читләтеп узу мөмкин түгел. Төн җиткәнен көттеләр. Алар беренче ишек шакыган йорт старостаныкы булып чыкты. Илле-илле биш яшьләрендәге староста разведчикларны үз итеп каршылады, ашатты-эчертте. Юлга ипи һәм сало бирде. Хәтта бакчалар аша озатырга да барды. Әмма якындагы урманда немецларның танк часте урнашкан булып чыкты, бу урман аша узу турында уйларга да мөмкин түгел иде. Яктырып килә иде инде, кабат староста өенә кайтып, көнне уздырдылар. Көне буе авыл аша танклар, үзйөрешле орудиелар, машиналар узып торды. Караңгы төшү белән, танк часте урнашкан урман турында үзебезнекеләргә хәбәр иттеләр дә тагын юлга чыктылар. Авылда немецлар тагы да күбәйгән иде. Бакча артына шуышып чыгарга туры килде. Ике-өч километрлап баргач, Тетерев дигән кечкенә генә елгага килеп чыктылар. Елга ярлары да немецлар белән тулы. Тагы читкәрәк авышырга туры килде. Төн бик тиз узгандай тоелды. Тигез дала уртасында уйсурак бер урын таптылар. Ләкин якында гына немецча сөйләшкән тавышлар ишетелде. Әмма моннан китәргә соң иде инде, тәмам яктырды диярлек. Теләсәң, теләмәсәң дә бу чокыр сыман уйсулыктан тигез кыр өстенә чыгарлык түгел. Көнне юеш, салкын җир өстенә яткан килеш уздырдылар, хәтта кымшанырга да мөмкин түгел иде: якында гына немецларның зенит батареясы.

Төн җиткәч, юлга чыгып, көне буе селкенмичә ятып алҗыган тәннәр язылырга да өлгермәде — алда тагын кечкенә генә бер хутор пәйда булды. Хуторда безнекеләр дә, немецлар да юк иде. Хәлләр буп-буш. Юеш киемнәрне киптерергә, хәл алырга кирәк иде...

Ниһаять, алгы сызык. Әмма немецлар шул кадәр тыгыз урнашкан, кая гына барып төртелмә, ут ачалар. Тагын чигенергә туры килде.

Алда — әлеге дә баягы тагы шул Тетерев елгасы. Теге якка чыкмыйча мөмкин түгел, чөнки алар өчен хәзер сыеныр урын бары тик урман гына. Ә урман елганың каршы ягында. Якындагы авылда немецлар тулып ятканын белсәләр дә, шунда кереп азык запасы булдырырга һәм, өянкеләргә ышыкланып, аргы якка чыгарга тырышып карарга дигән уйга килделәр.

Азык-төлекне тиз таптылар. Беренче шакыган йорттан ук ипиен дә, итен дә бирделәр: фашист табаны астында җәфа чиккән совет кешеләре өчен совет солдатлары кадерле кунак иде. Әмма немецлар авыл урамнарын, елга ярларын даими рәвештә ныклы сак астында тоталар икән. Әлбәттә, аларга үз тылларында разведчиклар группасының хәрәкәт итүе билгеле булгандыр. Ярга якынлашу белән, атыш китте, күктә ракеталар кабынды. Боз өсте дә кеше авырлыгын күтәрерлек түгел иде әле — салкын суга чумарга, елга аша йөзеп чыгарга, рацияне суда ташлап калдырырга туры килде. Тагы ике разведчик каты яраланды...

Декабрь ае кергән иде инде. Җир өстен калын кар каплады. Фронт сызыгы аша үтү мондый хәлдә хәзергә мөмкин түгел иде. Җитмәсә, өч иптәшләре каты яралы. Марьяновка авылында калдырылган каты яралы Агаповны алырга да, барысы бергәләшеп, теге өч солдат янында Рифгат хәл алган землянканы табарга, җирле халык белән элемтәгә кереп, партизанлыкка күчәргә — җыйнаулашып шундый уртак фикергә килделәр.

Фашист тырнагы астында яшәсә дә, совет кешесе совет кешесе булып кала. Җирле халык Рифгатләр белән соңгы икмәге белән бүлеште, кием-салым, башка кирәк-яраклар белән ярдәмләште. Разведчиклар да тик ятмадылар: дошман техникасы еш уза торган юлларга миналар куйдылар, аерым машиналарга һөҗүм иттеләр.

Инде яңа, 1944 елга да ерак түгел... Кичке эңгер-меңгер вакыты иде. Разведчиклар чираттагы операциягә юнәлделәр. Алар Житомир — Киев шоссе юлы буйлап озак бардылар һәм, уңай урын сайлап, засадага урнаштылар.

Күп тә үтмәде, борылышта өсте ябулы зур машина күренде. Машинаны кулга төшерү өчен озак вакыт китмәде. Күчмә радиостанция булып чыкты ул. Әмма шатланырга иртәрәк иде әле — юлда тагын бер машина пәйда булды. Анысын танкка каршы граната белән шартлаттылар. Аңа немец офицерлары өчен рождество бүләкләре төялгән булып чыкты. Шоколадлар, галетлар. Ай ярым чамасы юньле ризык күрмәгән разведчикларга бик тансык иде алар... Инде монысы белән эш бетте дигәндә, каршы яктан бер-бер артлы тагын ике машина килеп чыкты. Берсе — җиңел машина, берсе — йөк машинасы. Аларының да келләрен күккә очырдылар. Шунысы кызганыч булды: күчмә радиостанция файдаланырлык түгел иде. Атыш вакытында пулялар тиеп, лампалар чәлпәрәмә килгән — шартлатырга туры килде.

1943 елда соңгы операция булып чыкты бу. 28 декабрьда разведчиклар фронт сызыгын үтәргә дип кабат юлга чыктылар. Һәм бу юлы аларның омтылышы гамәлгә ашты. Ләкин, якын итеп, колач җәеп каршы алмадылар, шикләнделәр. Сакта торучылар парольне аңламады. Коралларны тапшырырга, махсус бүлек кешеләренә барысын да сөйләп бирергә туры килде. Чөнки алар фронтның 18 нче армия биләгән полосасына килеп чыкканнар иде.

Ничек булса булды, шулай да безнең разведчиклар яңа, 1944 елны үз «өй»ләрендә каршы алдылар...

* * *

Бер «кимчелеге» бар иде Рифгатнең — «кунак»тан, дошман тылыннан кайту белән иптәшләре ыгы-зыгы килеп, «билгә җиткән» сакалмыекларыннан арынырга керешә. Бу вакытта Рифгатнең эше юк — аның сакал-мыек булырга тиеш урыннары буп-буш. Борын астында гына, бармак тидереп карасаң, берән-сәрән «бала йоннары» сизелә. Менә шуңа күрә ул үзен ничектер бик мөһим нәрсәдән мәхрүм ителгән кеше кебек тоя, язмыш тарафыннан кимсетелгәндәй сизә иде. Әйе, бик яшь иде ул вакытта Рифгат. Шул яшьлек, балалык галәмәтедер инде: һәр даим үлем белән күзгә-күз очрашуны һәм исән калуны бик табигый хәл дип саный иде ул. Гомумән, үлем турында уйлау, курку аның өчен ят бер хис иде. Разведкада йөрү, андагы вакыйгалар аның өчен бер дә искитәрлек нәрсә түгел, гадәти, көндәлек хезмәт булып тоела иде. Шуңа күрә бик табигый: бу көндәлек гади хезмәт өчен бүләкләр бирелүен Рифгат өмет итмәде. Әмма командующий дошман тылына ясаган соңгы ике рейдта күрсәткән батырлыклары өчен берьюлы илебезнең ике зур бүләген — Кызыл Йолдыз орденын һәм Өченче Дәрәҗә Дан

орденын күкрәгенә кадагач, ул чын-чынлап горурланды, малайларча мактанасы килеп китте: «Их, менә хәзер орден-медальләреңне тагып Барҗы урамыннан узсаң иде!..»

Кызыл Йолдыз ордены белән ул әлеге Житомир — Коростышев — Радомышель тирәләрендә ай ярым дошман тылында йөргәндә күрсәткән батырлыклары өчен бүләкләнде. Ә аннан соңгысы — Рифгатьне Дан орденының Өченче дәрәҗәсенә лаек иткән операция — аеруча уңышлы булды.

1944 елның январь ае. Армия штабына кайсыдыр полктан дошман контрударга әзерләнә, алгы сызыктан унике-унбиш километрлар эчтә, Шепетовка шәһәре тирәсендәге бер авылда танклар тупланырга тиеш, дигән хәбәр алына — шул дөресме? Моны ачыкларга Рифгатьләр группасына куштылар.

Төнлә полк саперлары алдан әзерләп куйган сукмактан фронт аша узу әллә ни кыен булмады. Таң атканчы, ун километрлап эчкәре уздылар.

Менә инде тәмам яктырды. Ап-ак маскхалатлар кигән безнең алты разведчик тип-тигез кыр уртасында. Якындагы шоссе юлы аша чыгарга кирәк — алар барасы объект шул якта. Юлга якынлашкач кына фронт сызыгы ягыннан җиңел машина килгәне күренде. Яшеренеп калу соң иде инде. Ни булса шул дип, машинага әһәмият бирмәгәнгә салыштылар. Бәлки, полицайлар дип уйларлар әле. Ачык ялан уртасында көпә-көндез кемнәр йөрсен тагын! Якын-тирәдә немец гарнизоннары тулы авыллар...

Әмма шулай да машинадагылар шикләнделәр. Разведчикларны куып җитәргә ике йөз метрлап калгач, машинадан ике офицер төшеп калды. Белешергә диптер инде, машина белән шоферның үзен генә җибәрделәр. Офицерлар теләсә ни уйласыннар — разведчикларның аларда эшләре юк, үз эшләре эш иде: машина яннарына килеп туктау белән, шоферга автомат терәделәр һәм, көч-хәл белән сыеп, машинага кереп тулдылар да юлны дәвам итәргә куштылар.

Берничә авыл аша уздылар, авыллардагы немецлар жандармерия офицерлары йөри торган машинаны туктату турында уйларына да китермәделәр. Алда — немец танклары тупланырга тиешле авыл. Авыл тирәсендә зур гаскәри часть булганны белдерердәй берни дә юк. Тәҗрибәле разведчик күзләре бик яшертен объектны да бик тиз аера алыр иде. Авылга керделәр, олы урам белән киттеләр. Каршыга җәяүле немецлар колоннасы килә. Жандармерия машинасында булсаң да, дөньяны онытырга ярамый. Башсыз тәвәккәллек һәлакәткә китерергә мөмкин — колонна белән очрашмаска булдылар — шоферга тыкрыкка борылырга ымладылар. Тыкрыктан авыл читенә чыгарга, турыдан гына, кыр уртасыннан, кайтыр юнәлешкә сыпыртырга уйладылар. Немец машинасы көчле, бу тирәләрдә кар тирән түгел. Шулай да авыл читендәге уйсулык аша чыкканда машина батты. Дүрт разведчикка, машинадан чыгып, артыннан этәргә туры килде. Машина бу тирәдәге немецларга яхшы таныш булгандыр, ахры, бер йортның капка төбендә сигарет көйрәтеп торган ике солдат аларга башта игътибар да итмәде. Машина баткач кына, ярдәм итәргә дип булса кирәк, урыннарыннан кузгалганнар иде, разведчиклар алар килеп җиткәнне көтеп тормадылар. Машина ике-өч мәртәбә көчәнде дә, арттан бар көчләренә эткән разведчиклар ярдәмендә, тигезлеккә менде, һәм алар юлларын дәвам иттерделәр.

Машинаны да, аның шоферын да калдырырга кызганыч иде. Машинаның фронт сызыгын чыкканда ярдәме тиюе бар, ә жандармерия офицерларын йөртүче шоферның мөһим «тел» булуы мөмкин. Тәвәккәлләделәр: иңенә пистолет терәлгән шоферга машинаны тулы тизлегенә фронт линиясенә таба куарга куштылар. Немец оборонасының икенче

эшелонын үткәндә, «хальт, хальт» дип кычкырып, туктарга кушсалар да, машина бар көченә алга ыргылды. Алгы сызыкта кычкырып кына калмадылар, узып китү белән атарга керештеләр. Ниһаять, ике арадагы нейтраль зона. Хәзер инде безнең алгы сызыктагылар да ут ачты. Ә машина һаман, берни булмагандай, алга омтыла. Разведчикларның барысының да иреннәре кысылган, күзләре алга текәлгән. Ә шофер белән рәттән утырган Рифгат, пистолетын шофер кабыргасына терәгән килеш, бөтен гәүдәсе белән алга омтылып һаман бер үк сүзләрне кабатлый:

— Шнелль, шнелль... Форвард!..

Ниһаять, безнең солдатлар атуларыннан туктадылар. Килеп туктау белән, машинаны унлап солдат сырып алды, кулларны күтәрергә куштылар. Араларындагы офицерга парольне белдергәннән соң гына тынычландылар...

Әлбәттә, алар бу операциядән дошманның җанлы көчләре һәм техникасы турында күп мәгълүмат алып кайтмадылар. Бурычлары да ул түгел иде. Ә бит кайчагында командование өчен шунысы да гаять мөһим: бу участокта дошман һөҗүмгә әзерләнәме?.. Димәк, дошман безнең командованиегә юлын табып, ялган хәбәр ирештергән...

Рифгатнең «Орден-медальләрен тагып, туган авылына кайтып, Барҗы урамнарыннан күкрәк киереп йөрисе иде»,— дигән теләге дә тормышка ашты.

...1944 елның язы озак көттереп килде. Бер җылытты, бер туңдырды. Карлар эреп бетте дигәч тә атналар дәвамында яңгыр коеп торды. Һөҗүм итеп баручы безнең гаскәрләр өчен юл бик нык читенләште. Азык-төлек, сугыш кирәк-яраклары төялгән обозлар еракта, артта калды...

Рифгатләргә эш бик күп булды бу чорда, күп мәртәбәләр дошман тылына чыктылар...

Беренче май якынлашып килә иде инде, көннәрдән бер көнне Рифгатне разведка начальнигына чакырып алдылар.

— Сине, Гайнуллин, тагын хөкүмәт бүләгенә тәкъдим итәргә уйлаган идем,— диде карт полковник. Аның күзләре нигәдер беркадәр моңсу һәм шул ук вакытта аталарча ягымлы иде.— Менә сиңа бүләкнең иң зурысы. ...Кайтасың киләме туган якларыңа?..— һәм ул Рифгаткә кәгазь сузды.— Бар, сынок, авылыңа кайтып ял ит. Кырык көнлек ял сиңа...

Рифгат шатлыгыннан нишләргә дә белмәде, устав кушканча «смирно» басты да: «Советлар Союзына хезмәт итәм!» — дип, уң кулын чигәсенә күтәрде. Устав устав инде ул. Бәлки, бу юлы уставча да кирәк булмагандыр, гади итеп, якын, туганнарча итеп рәхмәт әйтергә генә кирәк булгандыр. Хәтта инде калын кашларына да бәс кунган полковник онытылып, бер ноктага текәлгән килеш, беравык тын торды да, «Әле син һаман мондамы?» дип гаҗәпләнгәндәй, тагын Рифгаткә борылды. Хәлсез генә кулын селекте: «Юлыңда бул».

Соңыннан гына белде Рифгат: полковник өченче улының һәлак булуы турында хәбәр алган икән. Бәлки, нәкъ менә шуңа күрә, әле тормышның тәмен белеп өлгермәгән, сакал-мыек та чыкмаган Рифгатне ул, аз вакытка гына булса да, һәр минут үлем белән очрашудан читләтеп торырга уйлагандыр...

Ни булса да булгандыр, шунысы шәп: Рифгат 1944 елның Май бәйрәмен Барҗыда каршылады. Яшьтәшләре барысы да фронтта иде, әле армиягә китәргә яшьләре җитмәгән малай-шалайлар, кызлар белән ярларыннан ташып чыгып ерак болыннарга җәелгән Иж суында көймәдә йөрде, гармунга, кызларга кушылып җырлаган булды, биегән булды. Берүзе авыл тынлыгына хозурланып сандугачлы таңны каршылады. Әмма аңа мондый тынлык, сандугачларның гамьсез сайравы ят иде. Малай чакта бик тә күңелле, бик тә рәхәт тоелган тау өстендәге уеннар

да хәзер шатлык, дәрт хисләрен уята алмады. Малайлыктан чыкмас борын ук сугыш өермәсе эчендә чыныгып, табигать таләп иткән вакыт үлчәвен читләтеп, ир-егет булып әверелгәнгәдер инде — аның йөрәгендә гамьсезлек, кәеф-сафа кылып күңел ачуга урын юк иде. Ул разведчик иптәшләрен сагынды, кырыс солдат тормышын сагынды. Тагын шунысы: Төньяк киңлекләрдән, Балтик диңгезеннән Кара диңгезгә кадәр меңнәрчә километрларга сузылган фронтта Совет гаскәрләре кан коеп илебезне һәм тугандаш халыкларны азат итә, сугышларда кешелекнең якты киләчәге, халыкларның азатлыгы һәм иминлеге өчен көн саен унбиш мең совет кешесе һәлак булып тора, ә ул ерак тылда рәхәт чигеп ятсын. Юк, аның урыны фронтта. Ял итә торган вакыт түгел хәзер...

Һәм Рифгат авылда биш көн генә торды. Тиз генә җыенды да тагын фронтка дип юлга чыкты.

Армия штабы электәге урыныннан күченергә дә өлгермәгән иде әле...

Тарнополь шәһәре өчен каты сугышлар бара. Ләкин разведчиклар анда тукталып тормыйлар, алар өчен ут сызыгы — рубеж билгеләнми. Рубеж гаскәри частьлар өчен, артиллерия, танклар өчен. Азат ителәсе, сугышып алынасы җирләргә иң башлап разведчик аягы баса, иң авангард, удар гаскәрләрдән дә элек разведчик алдан бара. Башкалар дошман белән йөзгә-йөз килеп сугыша, ә разведчиклар соңгы чиктә генә моңа хокуклы.

Безнең гаскәрләр инде Польша җирендә, Краков шәһәрен немецлар һәр яклап бик ныгытканнар, шәһәрдә күп көч туплаганнар. Дөрес, әлегә ул йөз километрлап дошман тылында. Шулай да андагы агентура разведкасына бездән ярдәм кирәк иде.

Тугыз кешелек разведчиклар группасына Рифгат тә кертелде. Авыл кешеләре булып киендерделәр. Араларында бер хатын-кыз да бар. Ул — Аня, тәҗрибәле разведчик-радист, элек агентура разведкасында эшләгән. Инәсеннән җебенә кадәр барысы да исәпкә алынды. Юлның яртысыннан артыгы хәвеф-хәтәрсез генә узды. Краковка утыз километр чамасы гына калды. Аеруча сак хәрәкәт итәргә кирәк. Немецлар көндез генә түгел, төннәрен дә ыгы-зыгы килеп тора. Инде хәвеф-хәтәрсез генә каршыдагы авылны үтәсе бар.

Төн. Разведчиклар куаклыклар арасыннан сакланып кына авылга таба юнәлделәр. Авылдагы йортларның шәүләләре дә күренә башлады. Тәрәзәләр караңгы — маскировка.

Кинәт ике яклап та ата башладылар. Берничә разведчик егылды. Берничә секунд кирәк булды — Рифгат автоматыннан озын очередь бирде дә бер якка ташланып җиргә ауды. Засада... Тагын берничә очередь бирде, әмма биредә озак калырга ярамый,— читкә шуышты. Көч тигез түгел, каршы торуның мәгънәсе юк иде. Исән калучылар булса, соңрак эзләп табар әле. Кайдан белделәр икән соң? Бик сак хәрәкәт иткән иделәр бит. Әллә көндез очраган сәләмә карчык хәбәр иттеме икән? Әйе, бирedә үз илең, үз җирең түгел шул. Дошман табаны астында булса да, үз илеңдә җир кайгыртучан ана кебек дошман күзеннән яшерә, үз кешеләрең дошман коллыгында азап чиксәләр дә, соңгы кисәк икмәге белән туганнарча бүлешә, кыен хәлгә калсаң, ярдәмләшә иде. Ә бирedә ни эшләргә? Телен белмә, гореф-гадәтләрен белмә!..

Краковка берүзең баруның мәгънәсе калмады. Рация юк, тиешле адресларны ул белми. Үз-үзеңне корбан итүнең файдасы булмаячак.

Берничә көннән генә Рифгат штабка кайтып керде. Тугыз разведчиктан бары тик икәүләп — ул һәм Башкортстан егете — Тимерхан Камилев кенә исән-сау әйләнеп кайтканнар иде. Краков азат ителгәч, шул беленде: алты разведчик атыш вакытында һәлак булган, ә Аняны төреләй

кулга алганнар. Батыр разведчица, гестапода никадәр газапласалар да, берни әйтмәгән. Аннары аны фашистлар шәһәр мәйданында асып үтергән...

1945 елның башында, Беренче Украина фронтының 59 нчы һәм 60 нчы армия гаскәрләре Краков шәһәрен азат иткәч, Дүртенче Украина фронтының 38 нче армиясе белән берлектә, немец-фашист гаскәрләренең Силезиядәге зур группировкасын камалышта калдырдылар. Краков шәһәрен азат итү өчен штурм барган көннәрдә үк 60 нчы армия штабы каршындагы разведчиклар группасына яңа задание бирелде.

60 нчы армия командованиесенең алдагы һөҗүм маршруты әзер иде инде: ул, Одер елгасы аша кичеп, Силезиянең көньяк читенә чыгарга һәм гитлерчыларның көнбатыш ярдагы ныгытмаларын җимереп, Чехословакиядә ныгып урнашкан «Үзәк» группировкасына удар ясарга тиеш иде.

Разведчикларга, армия һөҗүм итәчәк маршрут буенча барып, Одер елгасы аша кичү урынын билгеләү һәм дошманның шул тирәдәге хәрби частьларын картага төшерү бурычы йөкләтелде.

Барысы да башларына эшләпә, өсләренә плащлар киделәр, плащ астыннан автомат тактылар, кесәләрдә — пистолет. Чемоданнарга азык-төлек тутырылды. Һәрберсе Польша гражданнары булу турында документлар белән тәэмин ителде.

Хәрәкәт итү планы түбәндәгечә: көндезләрен күзәтү алып барырга, төннәрен юлны дәвам итәргә. Торак пунктларын, хәрби частьларны читләтеп узарга, мөмкин кадәр дошман белән бәрелешкә кермәскә тырышырга...

Шулай өч көн бардылар. Кыш уртасы булуга карамастан, бу тирәләрдә кар юк иде. Көннәр томанлы. Моның разведчиклар өчен файдасы да, зарары да бар. Файдасы шунда: алар дошманга сиздермичә көндезләрен хәрәкәт итә алалар, ә зыяны — дошманның хәрби частьларын кирәгенчә күзәтеп булмый.

Шундый томанлы кич иде. Разведчиклар кешеләр сирәк йөргән бер ташландык юлдан акрын гына бардылар. Иң алдан поляк егете Яник Клейман бара. Аның әти-әнисен һәм туганнарын фашистлар атып үтергән, үзе, безнең гаскәрләр килгәнче, партизаннар отрядында сугышкан. Немец телен яхшы белә. Бу тирәләр белән дә яхшы таныш. Шуңа күрә аны разведчиклар үзләре белән алдылар. Шулай бара торгач, аларны ат җиккән берәү көтеп алды. Үзенә генә күңелсез булган, ахры, бу аулак урында кешеләр очраткач, елмаеп нәрсәдер әйтте. Яник Клейман аңа немецча җавап кайтарды. Атлы кеше немец солдаты булып чыкты. Яник артыннан тагын дүрт-биш кешене күргәч, ул сагаеп калды, арбасындагы карабинга үрелде. Әмма карабинын алырга өлгермәде, читләтеп, аның артына чыккан Гриша автомат белән башына сукты.

Калган юлны атка утырып бардылар. Төннәрен карта һәм компас буенча урманнан урманга күчтеләр. Көндез, ышанычлы урыннарга яшеренеп, дошман позицияләрен, ныгытмаларын, фронтка бара торган юлларны күзәттеләр.

Сөякләргә үтәрлек салкын җил исә. Одер суы күбекләнеп кайный. Елганың аргы ягын безнең самолетлар өзлексез бомбага тоталар. Гитлерчылар төннәрен понтоннар аша бу якка танклар, туплар, җәяүле гаскәрләр озаталар. Кызыл йолдызлы корыч лачыннар Одер өстен төнен дә тыныч тотмыйлар: понтоннар җимерелә, паромнар чәлпәрәмә килә. Кыскасы, Одер елгасының һәр ике ярында да, елганың уртасында да мәхшәр. Әйе, фронт биредән якын инде...

Рифгатләр елганың һәр ике ярын да ике көн дәвамында җентекләп күзәттеләр. Яр буендагы ныгытмалар да, елгага керү урыннары да төгәл итеп картага төшерелде...

Кайту юлында зур бәлага очрый яздылар. Сазлыкны чыккач, картада күрсәтелгән буенча, немецларның хәрби часте урнашкан булырга тиеш иде. Читләтеп узу өчен төн җиткәнен көтәргә булдылар. Әмма караңгы төшкәнне көтәргә туры килмәде: якында гына русча сөйләшкән тавышлар ишетелде. Димәк, фронт күчкән, безнекеләр инде бу тирәгә килеп җиткән. Һәм шулай булып чыкты да — бу тирәгә күрше 38 нче армиянең артиллерия часте урнашкан икән.

Әмма алар безнең разведчикларны бик кырыс каршы алдылар. Баштанаяк коралсызландырдылар, хәтта полк штабына илтүдән дә баш тарттылар.

Көн-төн пычрак ерып, юлсыз-нисез һөҗүм итеп килгән, инде Польша җирен азат иткәндә дә никадәр иптәшләрен югалткан сугышчыларның ачулары чиктән ашкан иде. Безнең разведчикларны алар немец шпионнары дип белделәр, әйбәтләп сөйләшергә дә теләмәделәр.

— Сазлыккарак алып керик тә, теге дөньяга озатыйк үзләрен,— диде яшь кенә бер артиллерист сержантка. Һәм Яникка төртеп күрсәтте.— Менә монысы хәтта русча да белми. Шпион икәнлекләре күренеп тора. Нәрсәгә командирларның башларын әйләндерергә...

Аны башкалары да хуплады, берсе хәтта түзмәде, бар көченә Яникнык яңагына кундырды.

Артык кызып киткән солдатлар, бәлки, чыннан да разведчикларны атып та еккан булырлар иде, шау-шуга килеп җиткән өлкән лейтенант аларны коткарды.

Конвойга ике солдат билгеләде, полк штабына илтергә кушты.

Штаб юлында да төркем-төркем сугышчылар очрады.

— Кемнәр болар?

— Шпионнар. Комбат полк штабына илтергә кушты.

— Сволочьлар. Илтеп йөрмә үзләрен... Курыксаң, бир миңа. Үзем генә җаннарын җәһәннәмгә җибәрим...

— Юк, ярамый...

Әлбәттә, полк штабында барысы да бик тиз хәл ителде...

Әйе, бик кыен хәлләргә очрыйлар иде разведчиклар. Ләкин барысына да түзәргә кирәк. Үзеңнең шәхси кимсетелүеңне дә, ачуыңны да, теләгеңне дә онытырга туры килә. Аларның хезмәте шәхси кыюлыкны, батырлыкны күрсәтү өчен түгел, ә киңрәк, зуррак масштабта, ул армия кадәр армия командованиесе өчен кирәк. Бәлки, алар алып кайткан мәгълүматлар бөтен фронт өчен мөһимдер.

Нәрсә ул болар каршында шәхси кимсетелү?..

Ә разведкада Рифгат кыю һәм тәвәккәл, шул ук вакытта җитди; җитез һәм чыдам, әмма дуамал түгел иде. Шуның өчен яшьрәк разведчиклар гына түгел, картлары, тәҗрибәлеләре дә Рифгат белән дошман тылына чыгуны, һичшиксез, уңышка юрыйлар иде. «Җиңел куллы Гайнуллин»,— ди торганнар иде аның турында.— Аның белән йөрсәң, башың исән кайтыр...»

Польша, Чехословакия җирләрен фашист илбасарларыннан азат итүе өчен барган сугышлар вакытында әллә ничә тапкыр дошман тылына чыкты ул. Рифгатләр алып кайткан мәгълүматлар 60 нчы армиянең Висла — Одер операциясендәге уңышлы һөҗүм хәрәкәтләре, немец-фашист гаскәрләренең «Үзәк» группировкасы составындагы армияләрен тар-мар итү өчен мөһим роль уйнады. Менә шуңа күрә дә разведчик Рифгат Гайнуллинның тугандаш Польша һәм Чехословакия халыкларын немец-фашист коллыгыннан азат итү өчен барган сугышларда күрсәткән батырлыкларына хөкүмәтебез зур бәя бирде: ул Икенче, Беренче дәрәҗә Дан орденнары һәм Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнде.

Унсигез тапкыр фронт аша кичеп, барысы йөз илле көн, тирән дошман тылында киеренке разведка күзәтүләре алып барган, совет гаскәр-

ләренең уңышлы һөҗүмнәре өчен кыйммәтле мәгълүматлар һәм дистәләгән «тел» алып кайткан өлкән сержант Рифгат Гайнуллин чыннан да хөкүмәтебезнең бу югары бүләкләренә лаек иде.

1945 елның 9 маенда немец-фашист гаскәрләренең капитуляция ясаулары турында Рифгат Судет тауларында разведка вакытында рация аша ишетте.

Әмма фашистларның Чехословакия территориясенә урнашкан «Үзәк» группировкасы, барлык яктан чолганып алынган булуына карамастан, каршылык күрсәтүне дәвам итә иде әле. Ләкин аның төп көчләре таркалган иде инде. 10—12 майда бу армияләрнең дә күп көчләре коралларын ташларга мәҗбүр булды...

* * *

...Алабуга шәһәренең үзәк урамы Тойма елгасының биек ярына килеп терәлә. Биек һәм текә үр өстенә сугышларда җиңеп чыккан совет солдатына һәйкәл-монумент куелган. Шунда ук мәңгелек дан уты яна. Иртәнге кояшның беренче нурлары кулына автомат тоткан солдат статуясына төшә. Ә мәңгелек ут, көн туса да, төн җитсә дә, горур җемелди, еракта калган дәһшәтле көннәрне бер минутка да онытмаска, уяу булырга чакырып, яна да яна...

Шуннан ерак та түгел — шәһәрнең үзәк мәйданы. Уртадагы Ленин һәйкәленең һәр ике ягында — шәһәрдәге атаклы кешеләрнең рәсемнәре. Сул якта — хезмәт батырлары: нефтьчеләр, колхозчылар, механизаторлар; ә уң якта — Бөек Ватан сугышы геройлары, ветераннар. Алар арасында ап-ак чәчле, җитди һәм кыю карашлы кырык биш-илле яшьләрендәге кешенең рәсеме аеруча игътибарны үзенә тарта. Күкрәгенә Сугышчан Кызыл Байрак ордены, Беренче, Икенче, Өченче Дәрәҗә Дан орденнары, Кызыл Йолдыз ордены һәм бик күп медальләр таккан.

Әйе, ул — Рифгат Гайнуллин. Әйе, ул хәзер Алабугада яши, эшли...

1947 елны хәрби хезмәттән демобилизацияләнгәч, Рифгат Гайнуллин туган авылына — Барҗыга кайта. Башта колхозда эшли, аннары клуб мөдире булып керә. Тиздән сугыш ветераны, коммунист егетне КПССның Красный Бор район комитетына пропагандист итеп чакыралар.

Казанда партия мәктәбен тәмамлагач, Рифгатне ул вакыттагы Морт районына парткабинет мөдире итеп җибәрәләр. Озак та үтми, ул КПСС район комитетының өченче секретаре итеп сайлана. Төрле районнарда җаваплы партия эшендә эшли һәм шул елларда КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый.

Хәзер ул — Алабуга дәүләт педагогия институтының өлкән укытучысы...

Үзәктән шактый читтә — нефтьчеләр поселогында яшәсә дә, Рифгат Гайнуллин институттан кайтышлый яки ял көннәрендә бирегә — Тойма ярындагы биек тау өстенә килергә ярата. Каршыда — тирән чокырның аръягында, тагы да биегрәк тау түбәсендә — «шайтан шәһәре»нең ялгыз манарасы Камадан узган теплоход пассажирларына бу тирәләрнең борынгы хатирәсен сөйли. Түбәндә — Тойма суы Кама белән кушылган үзәндә — күлләр ялтырап ята, сул яктан — Кама аръягыннан җиңелчә зәңгәр томанга төренгән Чаллы шәһәре, КамГЭС поселогының биек йортлары күренә. Ә уңда — Түбән Кама шәһәре. Бу шәһәрдә аның энесе — Камил Гайнуллин яши. Ул — экскаваторчы, атаклы егет — республиканың атказанган төзүчесе, «Октябрь революциясе» һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры. Кече энесе — Вәкил яшәгән урын да моннан әллә ни ерак түгел. Ул күрше Удмурт республикасында нефтьче булып эшли — бораулау мастеры...

Әйе, Рифгат Гайнуллин Тойма суы буендагы бу биек тау түбәсенә килеп, ерактагы Кама киңлекләре белән ялгыз гына хозурланырга ярата. Һәм, монда килгән саен, Алабуга шәһәреннән китеп, сугышларда һәлак булган совет солдатлары истәлегенә куелган монументка һәм мәңгелек дан утына карап уйлана...

Сугыш беткәнгә инде күп еллар узды. Вакыт агымы күп нәрсәләрне хәтердән юып ташлады. Әмма ул көннәрне онытмый Рифгат... Ничек онытасың: һәр авылдан, һәр шәһәрдән ничәмә-ничә типсә тимер өзәрлек егетләр, ирләр сугыш кырларында мәңгегә ятып калды. Дөрес, Рифгат үлмәде, сугыш кырларында гомере өзелмәде аның. Ләкин ул анда яшьлеген калдырды. Яшьлек хыялларына, уен-көлкегә бирелеп һәм иң тәүге мәхәббәт хисләре белән исереп, егет булып йөрер чаклары иде бит... Юк, Рифгат моңа үкенми, киресенчә, горурлана гына. Яшьлек иртәсендә егет булып йөри алмаса да, халыклар авыр сынау кичергәндә Ватан каршында, туган җир каршында егетлек күрсәтә алды ул.

Егетлек ашкыны белән узган авыр яшьлек юлларын тагын узасы килә аның, Украинадагы, Польшадагы, Чехословакиядәге, Германиядәге таныш авылларны, шәһәрләрне, алардагы үзгәрешләрне күрәсе килә. Җәяүләп түгел, үзенең «Москвич»ына утырып...

Дөрес, бу тормышка ашмаслык хыял түгел. Һәр җирдә, һәр шәһәрдә, һәр илдә колач җәеп, якты йөз белән каршы алачаклар аны. Әмма алда аңа кадәр тагын бер зур бурыч тора әле — якын арада кандидатлык диссертациясен яклыйсы бар...

**Газиз Иделле**

# БЕРЕНЧЕ ЗУР СӘЯХӘТ

СҮЗ БАШЫ



Бу сәяхәт турында язмый калу мөмкин түгел, һәм хәзер инде аны тулырак, тәфсиллерәк итеп тә язарга кирәк,— шундый карарга килдем мин, озак уйлана торгач.

Чөнки беренче зур сәяхәт ул. Бик истәлекле. Тарихи. Горький исеме белән бәйле.

Хәзер генә бит бу бер дә гаҗәп түгел. Ватаныбыз куәте елдан-ел үсә, ныгый. Үз республикабызның һәм СССР төзелүнең илле еллыкларын бөтен дөньяны таң калдырырлык әнә нинди уңышлар-җиңүләр белән каршыладык! Шулар нәтиҗәсендә, инде безгә, безнең иҗади эшебезгә дә бөтен шартлар, киң мөмкинлекләр тудырылган. Язучыларыбыз, сәнгать эшлеклеләребез, журналистларыбыз,— олылары да, кечеләре дә,— республикабыз районнарында гына түгел, илебез буйлап та туктаусыз йөриләр. Украина һәм Урал, Үзбәкстан һәм Себер, Белоруссия һәм Казагыстан, Латвия һәм Кыргызстан, Ерак Көнчыгыш һәм Әрмәнстан...— йөрмәгән, күрмәгән җирләр аз калгандыр. Шулай, халыклар дуслыгы, әдәбиятлар дуслыгы тирән тамыр җәя. Офыклар киңәя. Хәтта күп кенә чит илләрдә дә йөреп кайтулар булып тора. Искә төшкәннәрен генә санап китсәң дә... Польша һәм Финляндия, ГДР һәм Сүрия, Монголия һәм Төркия, Румыния һәм ФРГ, Болгария һәм Ливан, Чехословакия һәм Куба, Корея һәм Бельгия... Самолетларда, океан лайнерларында...

Ә кайдан һәм ничек башланды болар?

Минем бу язмаларым нәкъ менә шул турыда, зур сәяхәтләребезнең беренче адымнары турында.

Бу беречче зур сәяхәтебез турында мин менә бүген, аңа инде кырык елдан артык вакыт үтеп киткәч язам һәм үз вакытында газета-журнал битләрендә басылган очерк-репортажлардан да, тагын башка төрле чыганаклардан да файдаланып, күңелемдә аны яңадан кабатлыйм, күз алдымнан үткәрәм, күргәннәремне-ишеткәннәремне, кичергән хисләремне яңартам.

Бер үк вакытта бу үземнең яшьлегемә дә сәяхәт була икән әле. Инде олыгайган аң, акыл, белем белән яшьлеккә сәяхәт. Ә мондый хәлнең әйбәт үзен-

---

Истәлек кыскартып басыла.

өлекләре дә булмый калмый. Ул чагында тиешенчә, кирәгенчә күрми-белми калган, яки күреп тә аларга төпле бәя биреп җиткерә алмаган нәрсәләр бүген инде бик яхшы танышлар,— алар турында мин инде ул чакта күргән-белгән, хис иткәннәремә бүген укып-өйрәнеп белгәннәремне дә куша-өсти барам.

Автор

Август, 1972.

# I. Максим Горький киңәше белән

Барыбыз да бик уңайлы каюталарга урнашып беттек. Аккош кебек ак матур пароход соңгы гудокларын биреп, пристаньнан кузгалып китте. Хушлашулар, кул болгаулар, яулык селкүләр...

Казан артта калды. Ә алда — зур сәяхәт юлы! Йөрәкләр җилкенә, ниндидер сабырсызлык та, алдагы ниндидер билгесезлек хисләре дә кузгалып куя; шатлану да, беркадәр борчылу да, пароходыбыз артыннан калмый очып йөргән акчарлаклар кебек, безнең белән ияреп баралар... Шундый озын юлны ничек үтәрбез, кайларда булырбыз, нәрсәләр күрербез, кемнәр белән очрашырбыз, нинди нәтиҗәләр белән әйләнеп кайтырбыз?..

Бу — язучылар экскурсиясе. 1929 елның август ае. Маршрут: Казан — Әстерхан— Махачкала — Баку — Тифлис — Батум — Ялта — Симферополь — Харьков — Мәскәү — Казан. Заманына күрә — баш әйләндергеч озын юл, төрле шәһәрләр, төрле республикалар, төрле халыклар, төрле табигать күренешләре...

Экскурсиядә катнашучылар исемлегенә игътибар итегез: Галимҗан Нигъмәти (җитәкче), Шәриф Камал, Гомәр Гали, Кәрим Тинчурин, Гумир Толымбайский, Мөхәммәт Гали, Кави Нәҗми, Һади Такташ, Гадел Кутуй, Закир Гали, Салих Сәйдәш, Сәрвәр Әдһәмова, Исмәгыйл Рәми, Шакир Шамильский, Зариф Бәшири, Гавриил Беляев, Лев Рубинштейн, яшьләрдән — Мирсәй Әмир, Демьян Фәтхи һәм бу язмаларның авторы. Әдәбиятыбызның, сәнгатебезнең якты йолдызлары — киң танылган өлкән язучылар, шагыйрьләр, драматурглар, тәнкыйтьчеләр, композитор, артист һәм журналистлар. Һәм шулар арасында—әдәбиятка яңа гына аяк атлап килә торган безнең кебек яшь язучылар. Үз эченә әдәбият-сәнгатебезнең төрле катлау көчләрен туплаган шундый зур төркем белән ясалган шундый озын юллы экскурсия — культурабыз тарихында беренче буларак, һичшиксез, зур әһәмиятле һәм һич тә онытылмаслык олы вакыйга ул. Чөнки бу сәяхәт якын дустыбыз һәм бөек остазыбыз Максим Горький киңәше белән башланып китте, заманында ул үзе булган урыннар аша үтте һәм Мәскәүдә аның янында булу, очрашу-сөйләшү белән тәгәлләнде.

Мин бу бөек язучының, бөтен дөньяга киң танылган титан художникның әсәрләре белән инде таныша башлаган булсам да, үзен моңарчы күрә алганым юк иде. Аның гаҗәеп авыр һәм катлаулы да, шул ук вакытта сокландыргыч бай һәм игелекле дә тормыш-иҗат юлы миңа тулысынча таныш иде дип шулай ук һич тә әйтә алмыйм. Ул вакытта шәһәребездә хәзерге мәгълүм Горький музее да юк иде әле. Ул 1940 елда гына оештырылды һәм, сүз уңаенда әйтеп китмичә булмый: бетмәс-төкәнмәс энергияле Мария Николаевна Елизарова тырышлыгы белән бу музей елдан-ел киңәя-байый бара һәм илебезнең төрле почмакларыннан, чит илләрдән килгән экскурсантларны, туристларны үзенә тарта торган гаять әһәмиятле культура учакларыбызның берсенә әверелде.

Горький!.. Әле бала чагымда ук, русчаны аз-маз сукалый башлаганда, минем кулыма ничектер юка гына бер китап килеп эләккәнен хәтерлим. «Челкаш». Китап-

ның да, геройның да иseме шулай иде. Автор турында уйлаган да юк ул чакта, ә минә Челкаш үзе һәм авыл егете Гаврила истә калган. Авыр тормыш аркасында тайгак юлга кереп киткән, угрылык белән шөгыльләнүче сукбай Челкашның бик оста күрсәтелгән уйлары һәм эшләре, киң диңгез күренешләре күз алдыннан озак китми торды. Челкаш үзе кыек юлда йөри, ә үзе ничек ирек сөюче кешеl Ә минә авыл егете Гаврила бозык кеше дә түгел, ә эчке рухи дөньясы белән Челкаш Гавриладан күп өстен тора. Башта ул хәл ничектер сәер сыман да тоела. Әмма ныклап уйласаң, монда бик зур һәм тирән идея ята икән! Фаҗигале язмыш колы булган Челкашта бик яхшы кешелек сыйфатлары сакланып калган икән әле: ул хосусый милекчелеккә, комсызлыкка дошман!

Ул чагында, беренче укыганда, миндә мондый фикер йөртүләр, әсәрне, образларны болай «анализлавым» булмаган, әлбәттә. Инде минә байтак еллар үткәч, «Челкаш»ны кабат берничә тапкыр уку нәтиҗәсендә туган уйларым болар.

Горькийның «Балачак», «Кешеләр арасында», «Минем университетларым» кебек автобиографик әсәрләре миндә аеруча көчле тәэсир калдырды. Бигрәк тә — Казан чорына багышланган хикәя һәм повестьлары. Аларны мин әледән-әле кулга алып карарга да гадәтләнеп киткәнмен [1].

Әйе, әсәрләрен яратып укысам да, ул елларда Алексей Максимовичны күргәнем юк иде әле. Аның җанлы образы минем хыялымда гына яши иде. Сәяхәттә катнашучы башка олы язучылар исә бу яктан да бәхетлеләр: аларның күбесе моннан бер ел элек Максим Горькийны күрү, аның белән очрашу-сөйләшү бәхетен татыганнар. Ничек булган бу?

...1928 елны, нәкъ шушы август аенда, без кузгалып киткән Казан пристанена «Урицкий» исемле пароход килеп туктый һәм ул үзе белән бик кадерле кунак алып килә: Горький Казанда!

Мин ул чакта Казанда булмый калганмын, отпуск алып, ялга чыгып киткәнмен. Кем белгән бит! Нәкъ шул айда Горькийның Казанга киләчәге билгеле булса, ял белән исәпләшеп торыр идеммени! Минем өчен генә түгел, күпләр өчен бу шулай көтелмәгән, алдан билгеле булмаган вакыйга булгандыр дип уйлыйм. Чөнки Алексей Максимович, мәгълүм булганча, какшаган сәламәтлеген ныгыту өчен, Владимир Ильич киңәше белән, чит илләргә киткән иде. Анда алты ел булды ул. Чехословакия, Германия һәм соңра Италия курортларында дәваланганнан соң, 1928 елның май азагында (28 майда) Ватаныбызга, Мәскәүгә кайтып төште һәм менә август башында ук (4 августта) — ул инде Казанда! Яшьлек елларында үзенең кырыс тормыш университетын үткән һәм, үзе әйткәнчә, рухи яктан туган шәһәре Казанга әнә ничек ашыккан ул!

Республикабызның югары оешмалары тарафыннан экскурсия мәсьәләсе уңай хәл кылынгач та, бигрәк тә аның составы билгеләнгәч һәм шулар исемлегенә яшьләрдән мин дә кертелгәч, сораштыра башлыйм, газета подшивкаларын актарам. Ул чакта Татарстан хөкүмәте вәкилләре Горькийны Кама тамагында ук хөрмәтләп каршы алганнар икән.

Кешеләр Казан пристанена агылган. Бик күп халык җыелган анда. Пароход пристаньга килеп туктар-туктамас — кадерле кунакны котлаулар, кул чабулар белән бөтен тирә-як гөрләп торган. Шәһәрдә җәмәгатьчелек белән беренче очрашу шул ук көнне кич җиде сәгатьтә, Бауман урамындагы Зур драма театры бинасында булган. Теләгән барлык кешене дә театр сыйдыра алмаган, әлбәттә. Әмма күпмедер язучылар анда була алганнар. Гадел Кутуй, Габдрахман Минский кебек өлгер, кыю егетләр исә пристаньда чакта ук пароходка кереп, Алексей Максимовичны котлаганнар һәм аңа үзләре эшли торган «Авыл яшьләре» журналының Горькийга багышланган санын тапшырганнар.

---

[1] Сәрвәр ханым Әдһәмова тарафыннан татарчага тәрҗемә итеп басылган шундый бер томга бик дулкынланып язган рецензиям дә матбугатта басылып чыкты («Совет әдәбияты» журналы. 1949 ел. № 5).

Ә менә Кави Нәҗми барыннан кыюрак, тәвәккәлрәк булып чыккан! Бу очрашуда ул Алексей Максимовичка үзенең «Шобага» исемле хикәясенең русчага тәрҗемәсен бүләк иткән. Алексей Максимович Мәскәүгә кайту белән аны укып та чыккан һәм Кави Нәҗмигә бу хикәясе турында фикерләрен әйтеп хат та язып җибәргән! (Бу хат М. Горький әсәрләренең 30 нчы томында урнаштырылган.)

Икенче көнне исә аеруча истә калырлык вакыйга була: Татар мәдәнияте йорты (хәзерге ТЮЗ бинасы) залына язучылар, журналистлар, эшче хәбәрчеләр җыела. Анда алар үзләренең бөек остазлары Максим Горький белән очрашалар. Шунда үзара дусларча бик җылы, җанлы әңгәмәләр була. Горький илдә үзе күргән уңышлар турында бик сокланып сөйли, «Наши достижения» исемле журнал чыгара башларга һәм анда уңышларыбыз турында киң итеп, матур итеп язарга кирәклеге турында сөйли, безнең уңышлар турында бөтен дөнья белергә тиеш, ди. Аннары халыклар дуслыгын чагылдырган милли әдәбиятлар альманахы чыгара башларга бик вакыт җиткәнен әйтә. Бер-беребезне әле тиешенчә яхшы белмибез, ә бу бик кирәк, ди. Татар язучыларына ул тагын бер практик киңәш бирә: сез илебездә күбрәк, ешрак сәяхәт итегез, күпне күрергә, күпне белергә тырышыгыз, чын язучы өчен андый сәяхәтләр бик файдалы була, ди.

Моңдый акыллы киңәшкә колак салмый мөмкинме соң!

Һәм бер елдан соң ул сәяхәт башланып та китә.

## 2. Ул елларда

1929 ел. Түбәләр күккә тигән чак: «Безнең юл», «Авыл яшьләре», «Азат хатын» журналларында, газеталарда беренче хикәяләрем, очеркларым басылып чыкты. («Кабул булмаган корбаннар», «Сәҗидәкәй», «Икмәк һәм хатын» һ. б.) Мине дә яшь язучы дип йөртә башладылар. Бу яңа исемгә бәйле булып, нинди дер зур җаваплылык белән борчылу хисләре дә, бер үк вакытта моңарчы булмаган горурлык та хәзер инде, үзләрен физик сиздереп, Казан урамнарында минем белән бергә йөриләр. Алар әле җилкәгә авыр йөк булып менеп басалар, әле әллә кайларга еракка, биеккә очырып алып китә торган канатларым булып әверелəләр. Ничек кенә булмасын — ә күңелгә рәхәт! Уен түгел — яшь язучы! Түбәләр күккә тими хәле юк.

Яшьлеккә хас булган шундый исерткеч уйлардан айныйсың да, тирә-ягыңа җентеклəбрәк карыйсың, күктән җиргә төшәсең. Күк дигәне дә аның әле — һи, безнең ишеләрнең күге нәрсә ул! Инде канатлары ныгыганнан-ныгый барган яшь совет әдәбиятыбызның гомум күге, әй-яй, әнә нинди чагыштыргысыз биектә икән инде.

Исемнәр, аларның иҗат җәүһәрләре...

Әнә, озын сары чәчле, зур зәңгәр күзле, калын иренле, гел елмаеп, атлаган саен тирә-ягына шатлык таратып, хәтта «айга да шлем кидереп» йөрүче Такташка кара син. «Җир уллары» белән күтәргән шау-шуы әле тынып та җитмәгән, «Нота», «Провокатор», «Чемберлинга җавап нотасы» белән гүләп ала ул һәм безнең барыбызны да ярсытып, уяулыкка өнди, көрәшкә әйди. «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын язып, куәтле уйлар, тирән хисләр ташкыны белән үлемсез Ленин исемен, Ленин байрагын тиңсез биекләргә күтәрә. Бу политик һәм поэтик гүзәл әсәрләренә өстәп, тагын аның бай таланты белән иҗат ителгән «Давылдан соң», «Күмелгән кораллар», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Мокамай», «Алсу», «Нәни шаярулар» кебек энҗеләре гел укучы кулында, уенда, күңел түрендә.

Сәхнәләрдә Кәрим ага Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр», «Ил», Шәриф ага Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Ут», Фәтхи ага Бурнашның «Таһир-Зөһрә», «Хәсәен Мирза», «Камали карт» пьесалары шаулап бара. Афишаларда яшьлек дәрте белән үткен, кызыклы итеп язылган пьеса авторлары Гадел Кутуй, Риза Ишморат, Габдрахман Минский исемнәре дә еш кына күренә башлый. Китап киштәләрендә, укучы кулларында Галимҗан ага Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Казакъ

кызы», «Тирән тамырлар», Шәриф ага Камалның яңа гына басылып чыккан «Таң атканда» романнары, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Фатих Сәйфи-Казанлы кебек үзенчәлекле талант ияләренең төрле жанрда язылган яңадан-яңа әсәрләре... Революция һәм гражданнар сугышы комиссарлары һәм солдатлары Шамил Усманов, Кави Нәҗми, Гомәр Гали, Афзал Шамов, Гумир Толымбайский, Мәхмүд Максудлар хәзер инде үзләренең хикәя һәм пьесалары, шигырь һәм нәсерләре белән укучыларның игътибарын яулап алып, үзләренең көрәшче-сугышчы сыйфатларын шулай әдәбият фронтында да бик нәтиҗәле, тәэсирле итеп күрсәтеп килəләр...

Кыскасы, прогрессив иҗатлары белән патша Россиясендә үк үз халкына турылыклы хезмәт иткән һәм Октябрь революциясен котлап каршы алып, талантларын тулысынча яшь Совет Ватанына багышлаган мәшһүр исемнәр белән янәшә, революция дулкынында күтәрелеп чыккан яңа яшь көчләрнең әдәбият-сәнгать мәйданында терихи зур һәм изге эш алып барулары белән характерлы еллар иде бу. Әдәбиятыбыз күге түбәсенең һаман-һаман биеккә күтәрелә барган еллары иде.

Минем һәм минем яшьтәш каләмдәшләрем өчен, ягъни яңа гына тернәкләнеп килә торган яшь каләмнәр өчен исә алар — әле-гә саналган исемнәр — шулай ук буй житмәслек югарыда торалар кебек, без аларның һәркайсын үзебезнең остазыбыз итеп таныйбыз. Һәм менә шуларның алдынгы вәкилләре белән бергә безгә дә, миңа да, ил буйлап экскурсиядә йөрергә, айлар буе гел янәшә булырга, аралашырга, бер һаваны суларга, бер табыннан ашарга туры килү... Баш әйләндергеч бәхетле язмыш дими нәрсә дисең моны...

Ләкин шул ук вакытта безнең алдыбызда тагын бер хакыйкать ачылып китә. Ул да булса, әдәби кичәләрдән, матбугатта басылып килә торган мәкаләләрдән, очрашып сөйләшүләрдән, яңа язылган әсәрләрне тикшерүдә (әле тыңлаучы булып кына) катнашулардан алган тәэсоратлар... Ул зур остазларыбыз бик тыйнак һәм үз-үзләренә таләпчәннәр икән, үзләрен бер дә алай зур итеп санамыйлар икән... Ирешелгәннән канәгатьләнү, масаю диган нәрсә дә юк аларда. Уңышлар турында гына түгел, кимчелекләр турында, аларны бетерү һәм алда торган зур бурычларны хәл кылуга омтылу турында сүз күбрәк ишетелә. Кызу-кызу бәхәсләр алып барыла. Ә чыннан да шулай кирәк бит ул! Артка карап түгел, алга карап яшәү — эшләүнең асылы шулдыр бит. Тормыш тәҗрибәсе шуңа өйрәтә, хөкүмәтебез, партиябез шуңа өйрәтә лабаса.

Ә әдәбиятка партиянең игътибары бик зур. Ленин әйтеп-язып калдырган васыятьләрнең берсе бу.

Татарстан өлкә партия оешмасы язучыларның эше, тормышы, иҗаты белән гел кызыксынып тора. «Татар матур әдәбияты фронтының хәзерге хәле һәм партиянең бу юлдагы бурычлары» турында өлкә комитеты тарафыннан 1929 ел май аенда кабул ителгән тезисларының әһәмияте зур булды. Анда, күп кенә бик тә вакытлы һәм файдалы күрсәтмәләр җөмләсендә, әдәбиятта халыклар дуслыгын чагылдыру, язучыларны интернационализм рухында тәрбияләү чараларына да аеруча басым ясала. Бу эштәге кимчелекләр күрсәтеп үтелә һәм аларны бетерү-булдырмау чаралары билгеләнә.

Татар әдәбияты һәм әдипләр хәзергә үз тирәләрендә генә әйләнәләр, диелә тезисларның бер пунктында. Алар арасында интернациональлек тәрбиясе конкрет юлга салынып җитмәгән. Хәтта рус әдәбиятыннан татарчага һәм татарчадан русчага тәрҗемәләр дә юк дәрәҗәсендә. Көнчыгыш күрше республика һәм өлкәләрнең әдәбияты, әдипләре белән мөнәсәбәт куелмаган диелрлек.

Бик конкрет чаралар да билгеләнә ул тезисларда. Мәсәлән, «Әдип, шагыйрь һәр вакыт тормышның киң катлавы белән танышып, өйрәнеп торырга тиеш. Әнә шул бәгланыш юлларыннан итеп, татар язучыларына авылларга, күмәк хуҗалыкларга, эшче, промышленность районнарына, күрше республика һәм өлкәләргә, хәтта чит илләргә чаклы барып танышырга мөмкинлек тудырырга, моның өчен аларның матди якларын тәэмин итеп, командировкалар бирергә, озаграк сроклы экскурсияләр оештырырга һәм башка шундый чаралар күрелергә тиеш».

Бу сүзләр кәгазьдә генә калмый, Татарстан партия һәм хөкүмәт оешмалары махсус карарлар да кабул итә, шулардан берсе — әлеге безнең экскурсия турында. Вакыты, маршруты, составы билгеләнә, кирәкле күләмдә акча җибәрелә.

10 август. «Кызыл Татарстан» газетасының бер бите шушы экскурсиягә багышланган. Бөтен бит буена эре хәрефләр белән аншлаг: «Пролетариат матур әдәбитын һәм сәнгатен үстерү өчен халыкара элемтә юлында.

Бүген татар пролетариат язучылары ассоциациясе, татар совет язучылары җәмгыяте членнары һәм сәнгать көчләре СССРның көнчыгыш, көньяк җөмһүриятләренә экскурсиягә чыгалар».

Бу биттә экскурсиянең максаты һәм әһәмияте турында Галимҗан Нигъмәти, Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәш, Гадел Кутуй мәкаләләре урнаштырылган, катнашучыларның исемлеге, кыскача әдәби характеристикалары һәм рәсемнәре бирелгән, экскурсиянең маршруты күрсәтелгән.

Юлга чыгар алдыннан, иртән сәгать унда «Кызыл Татарстан» редакциясенә җыйналдык. Ул чакта хәзерге Матбугат йорты юк әле. Редакцияләр Ленин урамындагы Икенче Советлар йорты дип аталып йөргән бинада (үзәк почтамтка каршы) урнашканнар. Редактор Сафа Борһан кабинеты әллә ни зур булмаса да, ничектер барыбыз да сыеп беттек. Казандагы соңгы сөйләшүләр, киңәшләр шунда булды. Аннары барыбызны бергә рәсемгә төшереп алдылар, фотография шул ук бинаның аскы катында урнашкан иде...

Безне үзенең якты, җылы почмагына алган «Год революции» исемле пароход көндезге сәгать бердә Казан пристаненнан кузгалып китте.

Һавалар кызу тора. Берәүнең дә каютада бикләнеп утырасы килми. Әйберләрне (алар күп түгел, нибары берәр чемодан) урнаштырдык та палубага чыктык. Монда һава саф, җиләс, сулавы җиңел, рәхәт! Яр буйларында бер-берен алмаштырып торган матур күренешләр дә сокландыра безне. Әле текә яр, әле киң болын, әле куе урман, әле авыл, әле шәһәр... Боларның барысы күңелдә нинди дә булса эз калдырмый үтми. Я шунда ук, я каюталарга кергәч тә, блокнотлар өстендә каләмнәр кыштырдый башлый. Уйлап карасаң, Горький киңәше белән башланган бу сәяхәтебез үзенең бик күп башка яклары белән дә Горькийга, аның исеменә бәйләнгән булып чыга бит әле. Менә, пристаньга килеп төшү, пароходка утыру белән үк...

Казанда чагында шушы пристаньда ул грузчик булып эшләгән, ә аңа кадәр, малай чагында, шушындый пароходларның берсендә Идел, Кама буйлап йөзеп йөргән. Кем булып? — Кухняда бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы савыт-саба юучы булып... «Шушындый пароходларның берсендә» дип ялгыш әйткәнмен, әкрен йөри торган, кечерәк кенә иске бер пароход була ул. Исеме «Добрый» була һәм ул ирониялe яңгырый, чөнки эче һәм эше катылык, бозыклык, явызлыктан гыйбарәт була. Җыен вак-төяк һәм шикле кешеләр генә утырган, ахры, аңа, чөнки бер ук вакытта ул буксир хезмәтен дә үти — тимер богаулы арестантлар төялгән рәшәткәле баржаны сөйрәп бара. Ә пароходтагы матрослар да, кухня эшчеләре дә, пассажирлары да юләрлек белән кыргыйлык җыелмасы булган кешеләр була һәм аларның орышу-сугышуларын күреп, төрле оятсыз сүзләрен ишетеп, баржадагы бичара тоткыннарның газапларын күреп, яшь Алешаның җаны сыкрый...

Казаннан кузгалып китүгә 2—3 сәгать үткәч, Иделнең уң як ярында зәңгәр гөмбәзле чиркәве һәм шуңа тоташып тезелеп киткән салам һәм такта түбәле йортлары белән бер авыл күренде. Идел буйларында күп очрый торган авыллардан әллә ни аерылып тормаса да, олы абыйларыбыз һәм аларга ияреп без дә бу авылга аеруча игътибар итми калмадык. Шулай булмыйча! Бу бит Горький исеме белән бәйләнгән мәгълүм Красновидово авылы.

Зур пароходлар бу Красновидово пристанена туктамый — ул авыл озакламый артта калды, һәм Алексей Максимовичның «Минем университетларым» исемле әсәренең ахыргы битләре яңадан хәтергә төште.

Деренков булычныенда эшләгән, рухи һәм физик газаплар белән изелгән бер чоры... Шундый көннәрнең берендә, пекарнядан магазинга килеп кергәч тә, Горький таныш булмаган бер кешене очрата. Дәресрәге, бу кеше — украин Михайло Антонович Ромась — үзе Горькийны очратырга дип монда килгән икән. Ул аны үзенә — Красновидовога чакыра, миңа кибеттә булышырсың ди, буш вакытларыңда укырга миндә китаплар күп, ди.

Горький риза була һәм аңа иярә.

Ромась бу авылда күз буяу өчен генә кибет тота, асылда исә ул — сөргеннәрдә булган революционер,— авыл халкы арасында аң-белем, хаклык тарату белән шөгыльләнә, мужикларны, вак бакчачыларны артельгә оештыру, спекулянтлар, байлар изүе астыннан котылу кирәклеген аңлата. Горький аңа бу эшләрдә якыннан торып булыша. Сабыр табигатьле акыллы Ромасьны ул бик яратып китә. Шунда бик күп укый да: Ромась китапханәсендә табигать фәннәре турында төрле китаплар һәм Писарев, Добролюбов, Чернышевский, Пушкин, Некрасов, Гончаров әсәрләре була.

Авылның карагруһлары, байлар, поплар Ромасьны, Горькийны дошман күрәләр, террор оештыралар, кибетләренә, йортларына ут төртеп яндыралар. Көчле янгын эчендә калган Горький үлемнән чак котыла һәм шуннан соң, бу кабахәт тормыш шартлары белән аяусыз көрәшергә кирәклек турындагы уйларын күңелендә инде ничәнче тапкыр кабатлап, яңадан юлга чыгып китә: Идел буйлап түбәнгә, Каспийга һәм тагын арыракка... хәзер без барасы юллар...

Юлга чыгу белән үк Горький турында шулай дип уйландырган Красновидово авылын, ялгышмасам, беренче булып күрүче һәм безгә күрсәтүче — Галимҗан ага Нигъмәти булды бугай. Ул безнең экскурсиябезнең җитәкчесе булуыннан да түгел иде бу. Ул бит, без яшьләр кебек, Горькийга табынучы гына түгел, ә минем уемча, гомумән, безнең арабызда бу бөек язучының тормышын һәм иҗатын иң күп һәм тирәнтен белүче әдип. Аның Горький иҗатына багышланган махсус әдәби-тәнкыйть хезмәтләре булуына таянып әйтәм моны.

Галимҗан Нигъмәти. Зур әдип, тәнкыйтьче, әдәбиятчы, бу өлкәдә зур авторитет. Ә үзе шундый садә. Мин аңа сокланып, зур ихтирам белән карыйм, күзәтәм. Ул, берүзе булганда, читтән караганда гел уйчан булып күренә, инде шунда ук берәр кеше белән сөйләшә башладымы,— ә ул бик җылы, ягымлы итеп сөйләшә,— аның йөзендә елмаю сызыклары хасил була, кинәт үзгәреп китә, сиңа бик якын, күптәнге танышың булып, дустың булып күренә, сиңа төбәлгән елмаюлы күзләре синнән дә шундый ук елмаю, җылылык таләп итә кебек. Бераз туктап тора да борынын тартып куя (аның шундый сәер гадәте дә бар). Нинди генә хәл булмасын, ул үзен гел тыныч тотар, чыраен сытмас, тавышын күтәрмәс, бөрелеп сугылмас. Җитди чакларында да эчке җылылык чагыла аның чыраенда...

Моңа кадәр миңа аның белән (гомумән, бу сәяхәттә катнашучы күпчелек олы кешеләр белән) болай якыннан аралашырга бер дә туры килмәгән иде. Күзәтүләрем — шушы сәяхәт барышында гына. Уңае килгәндә, алда ук әйтеп куйыйм, соныннан да Галимҗан ага Нигъмәтигә карата миндә туган ул яхшы хисләр үзгәрмәде. Ул минем «Пумала башлар» исемле беренче җыентыгымны 1930 елда үзе карап бастырып чыгарды. Нәшриятта эшли иде ул. Мондый яхшылыкны, мондый ярдәмне оныту һич мөмкин түгел, чөнки язучы биографиясендә беренче китап — авыр һәм озын, кадерле һәм мактаулы юлның беренче җитди адымы бит.

## 3. Идел куенында

...Пароход киң Идел суын ярып, артта күбекле дулкыннар калдырып, һаман алга бара. Идел! Җиде мең километрга диярлек сузылган бөек, матур су юлы, Европаның иң зур елгасы, Россиянең олы урамы! Монда җәй буе кызу хәрәкәт. Кешеләр тулы пароходлар, төрле мал-мөлкәт төягән эреле-вaклы баржалар, озынга сузылган саллар өледән-өле очрап тора. Пароходлар гудоклары белән сәламләшәләр, кешеләр палубалардан бер-берсенә кул болгап, яулык селкеп калалар. Мондый эчкерсез мөлаемлык хәрәкәтләренә без дә кушылабыз. Идел, шулай, таныш булмаган кешеләрне дә бер-беренә якынайта, бер-беренә тарта икән. Үз тирәсенә һәм үзенә килеп коя торган кече туган елгалары тирәсенә урнашып гомер итүче бик күп халык-

ларның (рус, татар, башкорт, чуваш, мари, мордва, удмурт һ. б.) үзара дуслык һәм туганлыклары шул Иделнең киң һәм җылы кочагында бергә ныгып килә түгелме соң!

Менә Кама тамагын да узып киттек. Монда, Кама елгасы килеп кушылгач, Идел тагын да мәһабәтрәк булып китә, көч-куәте арта аның һәм матурланганнан-матурлана бара ул.

Без инде икенче, өченче көн юлда. Картага күз төшерәбез. Вак-төяк борылышларны искә алмаганда, Идел, Казаннан алып Самарага (хәзерге Куйбышевка) хәтле, туры юнәлеш белән көньякка таба ага. Без моны көндез кояшка, төнлә йолдызларга карап та чамалыйбыз. Тик менә бер урында ул үз юлында элмәк сыман бер матур борылыш ясап куя. Бу — Самара борылышы. Пароходыбыз, сулъяк ярдагы Ставрополь шәһәре турысына килеп җиткәч тә, үз юлында горур булып басып торган текә таулар тезмәсенә килеп бәрелә яза... һәм урыны-урыны белән уннарча километрга җәелеп торган Идел бу урында ярты километргача тараеп кала, агышын үзгәртеп, көнчыгышка карап китә, аннары яңадан көньякка борыла, бу юнәлештә озак бармый, төньякка таба борыла һәм Сызрань шәһәреннән соң яңадан үзенең туры юлына төшә — көньякка омтыла. Бер-ике җөмләдә генә әйтелеп киткән бу борылыш үзе алай кечкенә түгел — 200 километрга сузыла ул (ә борылышны алып ташлап, Ставропольдән Сызраньга туры юл сузсаң — аңа нибары 20 километр гына була икән!).

Казанда чакта Идел буйларына килеп чыкканда, каршы ярдагы Ослан тауларына карап еш кына соклана идем. Туган шәһәрем Әстерхан тирәсе тоташ тигезлектән, сахра-далалардан гыйбарәт булганга, бу Ослан миңа шулай тәэсир итә булгандыр, ихтимал. Үзе әллә ни дә түгел, югыйсә, ә менә нишлисең — тигезлектә матур калкып күңелгә хуш булып торган ямьле бер урын ул. Күзләргә ял биреп торучы яшеллеккә чумган пейзаж, тау итәгендәге авыллары, алма бакчалары сине үзләренә гел тартып торалар сыман. Ул елларда олы язучыларыбызның кайберләре җәйге ялларын да семьялары белән шунда (Югары Осланда, Түбән Осланда) үткәрәләр иде.

Ә менә хәзер без Жигули тауларына бәрелә язып, бәрелә язып барганда, аның матурлыгы һәм мәһабәтлеге алдында сокланмый кала алмадык.

Күбебезнең бу Жигули тауларын да беренче күрүе түгел, әлбәттә. Ләкин шунысы бар бит: матурлык дигән нәрсәнең аның һәр күрүеңдә яңадан-яңа яклары ачыла тора, шуңа күрә дә аны кабат карыйсың-күрәсең килә.

Жигули, текә ярлары белән Иделгә терәлеп, мәһабәт күкрәген киереп торган баһадир сыман күренә. Тауның биеклеге урыны-урыны белән 370 метрга җитә. Хикмәт аның бу биеклегендә дә түгел. Аннан да биегрәк, аннан да мәһабәтрәк таулар күп безнең илебездә. Ләкин аларның кайсысын (мин үзем күрә алганнарын, әлбәттә) бу Жигули белән тиңләргә мөмкин! Узган гасырларда Идел буйларындагы мәгълүм крестьян хәрәкәтләре белән, Степан Разин исеме белән бәйләнгән, үзе турында җырлар, легендалар тудырган тарихи урын ул Жигули. Бу турыда энциклопедик белемле булуы белән арабызда аерылып торган Кави Нәҗми сөйләп китә. Аңа шагыйрь Такташ кушылмый кала алмый. Жигули турындагы җырларны, легендаларны искә төшерә ул. Пароход барышында Жигули безгә барлык матурлыгын, барлык сокландыргыч сыйфатларын төрле яклап күрсәтергә өлгерә. Әйтерсең лә күз алдыбыздан җай гына, салмак кына булып гаҗәеп гигант кинокадрлар үтә. Менә ул, пароход ярга төртелеп үк барган минутларда, ялангач, текә биек кыя булып, кызгылт, каралҗым, саргылт-аксыл төсләргә буялган үзенчәлекле матур мозаик стена булып күренә. Ә пароход ярдан ераклашканда, түбәсе яшел урман белән капланган, аркылысына-буена күз җитмәслек гаять зур бөтен бер тау булып горур басып тора. Менә ул бер бөтен түгел, ә тирән ерганаклар, тарлавыклар белән телгәләнеп ташланган аерым-аерым таулар тезмәсе булып күренә. Әйтерсең лә яшел-зәңгәр сыртлы таш дулкыннар, чайкала-чайкала килеп, Идел буйларының гаҗәеп матурлыгына хәйран булганнар да шулай кинәт бер урында тынып катып калганнар. Вакыт-вакыт хыял аларны катып калган итеп түгел, ә зәңгәр күк, якты кояш алдында гел шулай чайкалып-дулкынланып торган итеп күз алдына китереп бастыра. Бу тирәләрдәге матурлыкның кешегә тәэсире шундый көчле!

— Әнә нинди даһи художник бит ул табигать,— ди арабыздан кемдер. Юк, моны безгә таныш булмаган бер юлчы әйтә икән, ул үзе дә художниктыр, я шагыйрьдер, миңа шулай тоелды. Хәер, миңа гынамы икән, күңелләрне, хисләрне биләп алган бу гаҗәп төрле манзаралар алдында хәзер һәркем — художник, шагыйрь...

Жигули турында сөйләгәндә аның табигый байлыклар чыганагы икәнлеген дә онытырга һич тә ярамый, әлбәттә. Югыйсә, бу — аның шул ук матурлыгын кимсетү дә булыр иде. Беренче урында — аның нефть байлыгы. Тагын, төзелеш өчен, гомумән, крайның һәм илнең экономик үсеше өчен бик тә кирәк булган төрле кыйммәтле казылма байлыклар: известняк, асфальт, күкерт, гипс, сланецлар, фосфоритлар... Жигули тауларында һәм бөтен Самара борылышы районында елдан-ел күбрәк чыгарыла торган бу материалларның социалистик төзелешебездә лаеклы урын алып торулары билгеле. Алга сикереп булса да әйтми үтү ярамас: нәкъ менә шушы урында, Иделнең Жигули таулары арасына кысылып-тараеп калган, суы тирәнәеп, агымы көчәеп торган урында мәшһүр Куйбышев ГЭСы төзелде дә бит! Бу куәтле һәм матур корылма Самара борылышы, Жигули таулары матурлыгын тагын да арттырып, бик еракларга балкып тора! Нур өстенә нур булып төшә.

Юлда, Иделдә без тукталган зур шәһәрләрнең берсе Самара (хәзерге Куйбышев) булды. Бу шәһәр әнә шул Жигули районында, Самара борылышының урта бер җирендә,— нәкъ түрендә дип әйтсәк тә ярый,— урнашкан. Якшәмбе көн булуга карамастан, монда безне матбугат вәкилләре каршы алды. Ничектер шул арада бик тиз пароходта иптәшләрчә аш мәҗлесе дә оештырылган булып чыкты (моның инициаторы безме, алармы икәнен генә хәтерли алмыйм). Сүз, әлбәттә, күбрәк әдәбият турында, безнең маршрут турында барды. Без сөйләгәнне алар, алар сөйләгәнне без кызыксынып тыңладык. Күбрәк без сораштырабыз. Чөнки бу шәһәр безнең өчен тагын бер ягы белән кадерле: 1895—97 елларда монда Максим Горький яшь, «Самарская газета» редакциясендә эшли, үзенең үткен фельетоннарын, хикәяләрен, очеркларын бастыра. Башта якшәмбе көннәрне генә, соңрак һәр көн саен диярлек басылып чыга торган бу әсәрләрендә ул актуаль политик мәсьәләләр күтәрә, шәһәр хуҗаларының, байларның комсызлыгын, кабахәтлеген фаш итә, эшчеләрнең, крестьяннарның, хезмәткәрләрнең интересларын яклый. Горькийның «Лачын турында җыр», «Кеэ көне», «Изергиль карчык» һ. б. мәгълүм хикәяләре дә беренче тапкыр шул Самара газетасында басылып чыгалар. Алар арасыннан хәзер аның сайланма әсәрләре томнарына кергәннәре генә дә кырыкка якын! Шулай итеп, бу Самара Горький иҗатында аның башлангыч чорлары өчен әһәмиятле урын алып тора.

Пароход бу пристаньда берничә сәгать торганлыктан, бераз гына шәһәргә дә чыгып йөри алдык. Матур, төзек, чиста урамнар, яшеллеккә чумган бакчалар, скверлар. Горький эзләре буйлап атлап киттек сыман.

Ләкин шулай да шәһәр ничектер бушап-тынып калган кебек булып күренде. Моны безгә бик тиз аңлатып бирделәр: бүген якшәмбе, көн бик эссе, ә мондый көннәрдә халык шәһәрдән читкә китеп ял итә, «кул астында гына» булган табигать кочагына, урманнарга, Идел буйларындагы матур дачаларга, пляжларга куча. Чыннан да, бу шәһәр тирәсендәге табигатьнең муллыгы-гүзәллеге, күңелгә бик тә хушлыгы белән мактанырлык та шул. Яр буенда, тау башында яшел куе агачлар эчендә урнашкан дачалар, ял йортлары, коттеджлар читтән караганда ук күз явын алып торалар: аларда ял итү, тирә-як табигать иркенә бирелеп хозурлану түгел, хәтта менә хәзер аларны үтеп барышлый пароходтан күзәтү дә шундый рәхәт тоела. Гомумән, Идел буенда ял йортлары, дачалар бик күп. Әмма Самара тирәсендәгеләр барыннан да өстен, диләр. Мин үзем моңа ышанам, чөнки соңыннан, армия сафларында хезмәт иткән елларымда, мин бу тирәләрдә еш кына булгаладым, ял иткәләдем һәм һәр юлы бик канәгать булып кала идем.

Самара шәһәрендә булу, аның урамнарын айкап йөрү барыбыздан да бигрәк Кутуйга көчле тәэсир иткәнен әйтмичә үтә алмыйм. Бу аның йөзенә үк чыккан иде ул чакта. Әйтерсең ул үз шәһәрендә, Казанда йөри. Күзләре зур ачылган, але елмая, але уйчанлана ул. Мондагы һәрбер урам, һәрбер бина аның өчен күптән таныш кебек...

Ә, әйе шул, чыннан да, Кутуйның үз шәһәре бит бу. Аның биографиясе искә төште. Яшьлек еллары (1917—1922 еллар) шушы Самарада үткән ич аның. Шунда укыган, беренче тапкыр олы әдәбият чишмәсеннән авыз иткән: күренекле рус язучысы А. Неверов җитәкчелегендәге әдәби түгәрәкнең актив членнарыннан берсе булган. Үзе дә каләм сыный башлаган. Аның беренче шигыре 1920 елда «Эшкә» исемле газетада шушы Самара шәһәрендә басылып чыккан булу факты үзе ни тора!

Ул еш кына Маяковскийның «Сул марш»ын искә төшерә. Аның ялкынлы иҗатының көчле тәэсирен дә Кутуй беренче башлап шушы Самарада тойган, соңыннан да аның белән мавыгуы, аңардан тырышып өйрәнүе барыбызга да мәгълүм. Кайбер шигырьләрен, шул җөмләдән «Сул марш»ны да, татарчага тәрҗемә иткән. Замандашлары хәтерлиләр, бу марш-шигырьне ул концертларда, әдәби кичәләрдә сәхнәдән үзе бик оста укый торган иде.

Казанда чакта да Кутуйны мин күргәли-очраштыргалый идем, чыгышларын да еш кына сокланып тыңларга туры килә иде, ә менә хәзер, бу сәяхәттә — бергә... Аннан соң да байтак еллар аралашу... Миңа Иделле псевдонимым табып бирүче дә шул Кутуй булды бит. Бу турыда Габдрахман Минский язып та чыкты («Казан утлары». 1965 ел. № 12). Шуңа күрә аны биредә кабатлап тормыйм, тик Кутуйның минем истә калган кайбер сыйфатлары турында гына, сүз уңаенда, әйтеп китү урынсыз булмас кебек... Олырак язучылар арасында дип әйтмим дә инде, үзенең яшьтәшләре арасында да (үзеннән яшьрәкләр арасында да) аның кебек җитез, хәрәкәтчән, өлгер, әтрафлы белемле кешене мин моңарчы белмим. Күзләре... Ук күзләр. Караганда чәнчеп ала торган диярлек шундый үткен күзләре хәтердә нык калган. Күзләрнең, гомумән, нинди йөздә булуы әһәмиятле икән. Тупас, ямьсез, шөкәтсез чырайлы кешедә мондый күзләр — куркыныч. Ә Гаделнең йөзе, чырае күбрәк көлеп-елмаеп тора иде. Көлмәгәндә, елмаймаганда да ул күзләр шулай ук үткен килеш калып, тик нәрсәнедер белергә, үтәли күрергә теләүләре белән аерылып торалар иде. Кешеләргә дә, тирә-якка да сынаулы караш. Җитдилек, уйчанлык белән шат күңеллелек бер үк вакытта бергә тоташа аламы, юкмы, белмим. Ә менә хосусан Кутуй чыраенда алар тоташа гына түгел, ничектер бер-бере белән аерылгысыз бәйләнгән булып, икесе бер сыйфат тәшкил итәләр иде кебек. Аның бик җитди мәсьәләләр турында сөйләгәндә дә, хәтта трибунадан ялкынлы речь тотканда да (ә ул чын мәгънәсендә трибун иде!) йөзендә, нигдидер, күпләр өчен, ихтимал, яшерен булган, ә аны якыннан танып белгәннәр өчен ачык бәрелеп торган сыман елмаю сызыклары күренә иде. Башкалар турында әйтә алмыйм, мин үзем шуны күрә идем. Шулай ук күтәренке кәефле чагында, шаярып-елмаеп торган чакларында да аның чыраенда җитдилек, тирән уйланучанлык чагылып торганын күрмичә калу мөмкин түгел иде кебек...

## 4. Экспромт концерт

Шундый зур сәяхәт башланган икән — ул мөмкинлекләр сыйдырган кадәр файдалы үтәргә тиеш. Бу өлкәдә өлкәннәребезнең, җитәкчеләребезнең мәшәкатьләре җитәрлек. Алар (Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали, Кави Нәҗми...) безне еш кына үз яннарына җыеп, блокнотларын ачалар, сөйлиләр, аңлаталар, искә төшерәләр...

Ә безнең төрле чагыбыз була... Музыкант һәм язучылар, артист һәм шагыйрьләр... Шулай булгач, бигрәк тә шундый озын юл шартларында, Идел кочагында, табигый ки, поэзия, лирика, музыка тәэсиренә бирелеп киткән чаклар да була. Шундый минутларыбыздан берсендә, кемдер, әйдәгез, егетләр, әйбәт кенә бер концерт оештырып җибәрик, диде. Кайсыбызның уена килгәндер бу, хәтерләмим. Хәер, моның әһәмияте дә юк, чөнки кемнең тәкъдиме булса да, бу шартларда ул барыбызның да уртак фикерен әйткән булып чыкты. Шунда ук бу тәкъдимне эләктереп алып, куәтләдек. Төшке аштан соң, кичкә табарак, салонга җыелдык та, шунда экспромт рәвештә генә кызыклы концертыбыз башланып китте. Музыкасы

яшь алмый торган Сәйдәш пианино янына утырды, көй артыннан көй ага... «Зәңгәр шәл»дән, «Наемщик»тан... «Күзләр»дән... Маршлар, аерым җырлар... Менә Сәрвәр ханым Әдһәмова үзенең яшеренеп яткан талантын ачып җибәрә — җыр артыннан җыр суза, хәтта казакъ көйләренә казакъча итеп тә җырлады, әйбәт, моңлы итеп җырлады. Аннары Такташның, Кутуйның, моңарчы да кат-кат ишетелгән булуларына карамастан, «Нәни шаярулар»ы, «Сул марш» һәм «Пулеметчылар»ы, тагын шундый популяр шигырьләре безне поэзия дөньясына алып кереп китте...

Концерт үзебез өчен генә дип оештырылган булса да, пароходтагы байтак халык, аны тыңларга дип, бик тиз арада салонга килеп тулды. Бу исә музыкант һәм артистларыбызга яңа дәрт көнә өстәде. Номерлар өстәлә торды, кабатлана торды.

Дәррәү алкышлар белән барган бу үзенчәлекле, күңелле тамаша, ниһаять, тәмамланып, халык һәм безнең дә бер өлешебез палубага чыгып таралгач та әле Сәйдәш музыкасы тиз туктамады. Тирә-якка татар, рус, башкорт моңнары мул тарелып, безне генә түгел, пароходтагы күп кенә бүтәннәрнең дә күңелен һаман-һаман яулап алуын дәвам итә, хыял канатлары тага: һәркем үзе теләгән дөньяга очып китә сыман, рухи сафлана, баеый.

Әнә, бер ягында — яшеллеккә чумган, төрле төстәге чәчәкләр белән бизәлгән киң кырлар-болыннар, икенче ягында — такыр башлы текә таулар, яшел түбәтәйле кыялар, ә уртада безнә Идел суын ерып, җай гына алга алып бара торган пароход... Кичке эңгер-меңгер... Кояшның актыккы нурлары ачык күк йөзендә, офык тирәсендәрәк йөзеп йөргән кисәк-кисәк ак болытларны алсу-кызыл төсләргә буяп калдырган...

Һәм шул вакыт салонда музыка яңгырап тора, юк, салонда гына калмый ул, киң Иделгә, очсыз-кырыйсыз болыннарга, далаларга, яр буйларында безне озатып кала торган авылларга, шәһәрләргә барып җитә,— барыбызны да тагын да алгарак, югарырак, яктыгарак әйди сыман...

...Идел акмый, музыка ага, пароход түгел, музыка киң колач салып йөзә, ул шундый гали, шундый көчле, шундый бөек һәм серле, сихерле, һәм шул мизгелдә бу гаҗәеп моң дулкыннары алдында үземнең бик-бик кечкенә булып калганлыгымны сизәм сыман һәм моңа бер дә гарьләнмим, аның сихри бөеклеге алдында баш иеп җиргә тезләнәм... Шулай гынамы? Юк, түгел. Музыка шунда ук серле дулкыннары өстенә мине күтәреп ала да биеккә ыргыла, мин күтәреләм, һаман күтәреләм, йомшак, җылы дулкыннар өстендә рәхәт чайкалып күкләргә ашам...

...Мондый хыялый кичерешләр тирә-ягыбызда булып торган гүзәл, бай табигать күренешләренә тәнгәл килүеннәндер, ихтимал... Чөнки калкулыклары, таулары, кыялары бер-беренә тоташып диярлек гел шушылай сузылып торган уң як ярга якынлашканда безнең дәү пароходыбыз ничектер бәп-бәләкәй булып кала, ә инде түбән, яссы ук ярга таба авышканда — ярлар урыны-урыны белән бөтенләй күренмичә дә кала һәм пароход суда да түгел, кайдадыр югарыда, биектә йөзеп-очып бара кебек тәэсир калдыра.

Һәрхәлдә, музыканың шундый сихри көчен, уй-хисләргә тәэсирен бу шартларда кабат һәм бик тулы сиздем мин.

Мин генәме икән?

Барыбыз өчен дә ничектер уйланыбрак, хыялланыбрак калган шундый минутлар иде, ахры, болар.

Идел үзе дә шулай бик күп уйландыручан бит. Аның үзенең дә үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында да уйланасың.

Идел — дуслык елгасы ул, аның тирә-якларында төрле милләт халыклары яши, эшли, үзара туганнарча аралаша. Ул ундүрт өлкә һәм автономияле республикалар җире буйлап ага. Идел белән төрле чорларның атаклы исемнәре нык бәйләнгән: Ленин һәм Горький, Чернышевский һәм Разин, Некрасов һәм Азин, Тукай һәм Иванов, Шевченко һәм Киров, Гафури һәм Шаляпин... Бик күп алар.

Бер генә мизгелгә читенеш ясап, бүгенгә кенгә кайтам.

Әле шушы араларда гына мин тагын бер тапкыр Горький музеен карап чыктым. Анда хәзер «Горький һәм Шаляпин» дигән яңа бүлек ачылган. Бик оригиналь һәм

бай эчтәлекле ул. Феодор Иванович Шаляпин безнең Казанда туган, бала чагы Горькийныкы кебек үк авыр тормыш шартларында үткән, итекче, токарь ярдәмчесе, грузчик һ. б. кебек эшләрдә булган, чиркәү хорларында җырлап йөргән. Яшьтән үк театрга, сәнгатькә гашыйк булган ул, соңра зур җырчы булып үскән һәм даны бөтен дөньяга таралган. Горький белән бик якын дус булган алар... Музейның аңа багышланган бүлегендә — тарихи рәсемнәр, фотолар, афишалар, шәхси әйберләре, төрле вакыйгалар, кичерешләр турындагы үз сүзләре, аның турында зур кешеләрнең фикерләре... Шаляпинның зур рәсеме астына язып куелган аның шушы сүзләре миңа аеруча нык тәэсир итте:

«Мин кайда гына үлсәм дә, хәтта чит илләрдә дөнья куйсам да, минем гәүдәмне Иделдә, нәкъ яр буенда калкып торган биек бер урынга күмсеннәр. Аның янынна җилкәнле көймәләр, саллар, баржалар йөзеп үтсен, гади рус кешеләренең җырлары ишетелсен, пароход гудоклары яңгырасын, җил шаулап иссен, кичләрен яр карлыгачлары һаваны сызгыртып очып йөрсеннәр — Иделнең әнә шундый бер урынына күмсеннәр мине». (Кызы Ирина Федоровнага язган хатыннан.)

Катлаулы язмыш, тормыш дулкыннары Шаляпинны чит илләргә илтеп ташлады, шулай да ул үз иленең патриоты булып калды. Туган илен, Идел буйларын сагынып, Ватанына кайтырга омтылулар ясаган булса да, ни сәбәптәндер, моңа ирешә алмады ул. Аның әлеге васыяте дә үтәлми калды,— гәүдәсе ерак Франциядә күмелгән аның (1938 елда Парижда үлә).

...Шунда, музей залында ук, кинәт минем башымда менә мондый бер уй да килеп туган иде: заманында Горькийның якын дусларыннан булган, Ватаныбызның музыкаль-драма сәнгатен моңарчы булмаган зур югарылыкка күтәргән искиткеч олы талант иясенең ихлас күңелдән, йөрәк түреннән моңланып-ургылып чыккан бу васыятен үтәү әле дә соң түгелдер, бәлки? Узган гасырлар азагында Англия туфрагында күмелгән талантлы рус шагыйре, публицисты, революционер-философ Николай Платонович Огаревның гәүдәсен әле моннан берничә ел элек үз Ватаныбызга күчереп җирләдек бит. Шундый ук мөкатдәс бер чараны, халыкларыбыз тарафыннан һәр даим тирән хөрмәт ителә торган тиңдәшсез сәнгать остасы Федор Иванович Шаляпинга карата да кулланып булмасмы икән?

...Уйлар, уйлар...

## 5. Көтелмәгән очрашу

Көннең күп өлеше палубада, җиләс һавада үтә. Берәүләр креслога утырып газета, китап укый, икенчеләре — кырыйда басып, тирә-якның гел алмашынып торган күренешләрен сокланып күзәтә, өченчеләре — палуба буйлап, берәмләп тә, култыклашып та «әкрен басып, вак-вак атлап» йөреп тора... Безнең экскурсия кешеләрен дә шул төркемнәрнең һәркайсында очратырга мөмкин. Юлчыларның күбесе белән танышып та беттек инде. Куллар бирешеп, дусларча озак сөйләшеп утырырлык якын танышулар түгел иде бу. Әмма көн саен палубада булсын, ашханәдә булсын, гел очрашып торганлыктан, һәркайсының төсе-бите, кием-салымы, гореф-гадәте, үз-үзен тотышы дигәндәй шактый таныш иде инде. Безнең үзенчәлекле коллективка аеруча игътибар да гел сизелеп тора иде. Безнең киң танылган Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Кави Нәҗми кебек олы әдипләребез, һөнәрләрен инде күрсәтеп тә өлгергән Сәлих Сәйдәш, Һади Такташ, кешеләр белән тиз һәм җиңел аралашучы Гадел Кутуй белән баш иеп, җылы елмаеп исәнләшүләр, тегене-моны сөйләшергә, әңгәмәдә катнашырга теләүчеләр аеруча күзгә бәрелә. Пассажирлар составының алмашынуы без барган классларда әллә ни сизелми, юлдагы пристаньнарда төшеп калучылар, утыручылар аз. Күпчелеге рейсның ахырына — Әстерханга чаклы баралар булса кирәк; җәй айлары бит, ял вакыты, ә ялны шушылай пароходта, Иделдә үткәрүнең тәмен-рәхәтен халык күптән белә инде.

Яңа пайда булган юлчылар безнең игътибарны җәлеп итми калмый. Шундыйлардан берәү безне аеруча кызыксындырды. Әнә ул, салмак кына атлап, палубага

чыгып басты. Тышкы кыяфәте, йөзе-чырае белән беренче карашта ук ул күпләрдән нык аерылып тора. Өстендә — инде искерә-уңа башлаганы күренеп торган күн куртка, башында көрән кубанка бүрек (шундый эссе җәй көннәрендә!). Дегеттәй кап-кара куе сакалы битенең күп өлешен каплап алган һәм бүреге кырыйларыннан чыгып торган шундый ук кап-кара чәчләре белән бергә укмашып кушылган, кайда сакал, кайда чәч — тиз генә аера да алмассың... Елтырап торган үткен карашлы каралҗым күзләрен еракларга текәп, тыныч кына басып тора...

Кем соң бу? Ят та, таныш та кебек үзе. Аны без кайдадыр күргән-очраткан да идек түгелме соң? Тукта... әйе, аны без үзен түгел, ә газеталардагы рәсемен күргәләгән идек ләбаса! Кинәт хәтер ачылып китте: бу кеше — Халатов ич, дөньядагы иң бай, иң куәтле нәшриятларның берсе булган РСФСР дәүләт нәшриятының мөдире, дәүләт эшлеклесе, атаклы Артемий Багратович Халатов!

Ә тышкы кыяфәте?.. Ләкин... инде бер танып алгач, соңыннан, Халатовны элегрәк тә күргәләргә туры килгән олы иптәшләребезнең аңлатуларын да ишеткәч, аны башкача күз алдына китерүнең гомумән мөмкин түгел икәнлегенә дә шулай ук тәмам ышандык. Күрәсең, һәрбер кешенең үзенә генә хас сәер гадәтләре була торгандыр. Аның белән һәр көн очрашып-аралашып йөрүче мәскәүлеләр өчен ул бер дә сәер күренми, киресенчә, аны бүтән киемнәрдә күрү хәтта аптырашта калдыра икән.

Сүз уңаенда, шушындый бер эпизодны да (үзе тарихи ул!) китереп үтик.

«Литературная Россия» газетасының Максим Горькийның туүына йөз ел тулуга багышланып чыккан 1968 елгы 13 санында язучы С. Евгеновның «Мәскәүлеләр Горькийны каршы алалар» дигән зур гына истәлеген мин бик кызыксынып укыган идем. Ул истәлектә Максим Горькийның чит илләрдә алты ел дәваланудан соң 1928 елның май аенда Советлар Союзына кайтуы һәм Мәскәүдә ничек тантаналы каршы алынуы бик тәфсилле итеп язылган. Анда шушындый юллар да бар иде:

«...Ерактан, тимер юл полотносында, пар һәм төтен бөркеп, пухылдап килә торган паровоз күренде... Горький кайтып килә, тиздән без аны күрәчәкбез. Менә поезд без басып торган платформага килеп җитте. Күз алдыннан бер-бер артлы вагоннар үтеп бара һәм алар берен-беренә теркәгән беркеткечләрен зыңылдатып-чыңлатып, әкрен генә туктап калалар. Безгә якында гына тукталган вагоннарның берсеннән алгы басмага ниндидер бер «атаклы чит ил кешесе» килеп чыга: сакалы бик пөхтә-ыспай итеп кыркылган, аның өстенә корыч төсле бик тә шәп модалы җәйге пальто кигән, башында шундый ук төстәге фетр эшләпә.

— Я, хода! Бу — Артемий Багратыч түгелме соң? Һич тә танырлык түгел үзен!

Шунда төрле яктан:

— Исәнме, Халатов!

— Ә Горький кайда?

— Кубанкаңны кая куйдың? — кебек сүзләр ява башлый.

Мәскәүлеләр Халатовны кышын да, җәен дә искерәк күн курткадан һәм көрән кубанкадан күрәләр иде, аларны ул беркайчан да, беркайда да салмый иде. Менә хәзер дә эшләпәдән үзе, ләкин, мөгаен, гадәттәгечә кубанкадан мин, дип уйлый торгандыр. Ә аның шулай кояз киенүенең сәбәбе: Германиядә Кельн шәһәрендә ачылган Халыкара күргәзмәнең совет павильонына ул комиссар итеп билгеләнгән һәм Горькийны Германиядән ул каршы алырга дип шул ук киемнәрдән барган. Әнә безгә башын чайкый ул, хәйләкәр генә итеп елмая, янәсе, менә күрегез мин нинди, сезгә Горькийны апкайттым, ә аны тиз ук күрсәтергә ашыкмыйм әле!

Вагон эченә Орджоникидзе, Луначарский, Енукидзе, Ярославский кереп киткәләр.

Һәм, ниһаять, аннан Горький үзе килеп чыга».

Әнә шундый атаклы да, бик ягымлы һәм гади дә кеше ул Халатов.

Җитәкчеләребез аны күрүгә кинәт җанланып киттеләр. Башта Нигъмәти, Кави, Камал, Гомәр аның янына барып күрештеләр, үзләрен таныштырдылар. Аннары — без...

Кызыклы, күңелле очрашу иде бу. Без моңа бик шатландык. Юлда беръюлы шундый зур төркем татар язучыларын очратуга Артемий Багратович та шундый ук

хисләр кичерде булса кирәк — йөзе өледән-әле елмаеп торды аның. Бик житди һәм эшлекле дә, олы җанлы, сөйкемле дә кеше булып чыкты ул.

Безнең экскурсия җитәкчеләре белән әңгәмәләрнең берсендә ул, маршрутыбыз белән җентекләп танышкач, юлыбызның бик озын, эшебезнең-мәшәкатебезнең дә зур булачагын искәртеп, Ялтага тукталганда, шунда Кырым һавасында, диңгез буенда, азрак ял итеп алырга кирәклеген әйткән һәм үзеннән кечерәк кенә бер язу да биргән, «Гаспра» санаториясына барырсыз, шунда сезне бер атна-ун көнгә урнаштырырлар, ул безнең галимнәр санаториясы, дигән. (Соңыннан белдек: Халатов бер үк вакытта Цекубу дигән оешманың — галимнәрнең тормыш-көнкүрешен яхшырту Үзәк Комиссиясенең — рәисе дә икән.) Аның бу тәкъдимен без бик теләп кабул иттек. Чөнки Ялтада беркадәр вакытка тукталу, анда дәваланып ятучы Галимҗан ага Ибраһимов белән очрашу чарасы безнең маршрутта алдан ук билгеләнеп куелган иде.

Халатов белән юлда ике тәүлек чамасы бергә булдык без. Артемий Багратович иң кадерле кунагыбыз булды. Озакка сузылган әңгәмәләрдә күп һәм төрле мәсьәләләр телгә алынды.

...Әдәбият, нәшрият эшләре, гонорар мәсьәләләре... Казан язучылары, нинди яңа кызыклы китаплар басылып чыга... Мәскәү язучылары, аларның иҗатлары..: Безне аеруча Максим Горький кызыксындыра. Артемий Багратович аңа иң якын кешеләрнең берсе бит. Нәшрият буенча гына да түгел, дәүләт эшлеклесе буларак та... Һәр ике яктан тартынусыз сораулар, аларга тәфсилле, кызыклы җаваплар...

Кыскасы, бер дә көтелмәгәндә шундый шатлыклы, файдалы очрашу булды бу. Артемий Багратович безнең бу сәяхәтебезне бик яхшы уйланылган чара дип тапты, хуплады. Максим Горький киңәше-тәкъдиме белән оештырылган булуын да белгәч, тагын да җанланып китте, Мәскәүдә безне тиешенчә каршы алуны оештырырга булды. Горький белән очраштыру эшендә дә булышачагын әйтте.

Артемий Багратович Саратов шәһәрендә төшеп калды. Бик җылы саубуллаштык. Аның белән алдагы эшлекле рәсми очрашу — озын юлыбызның азагында — Мәскәүдә булачак.

Дәвамы бар

**Ибраһим Нуруллин,**
*филология фәннәре докторы*

# АЯК БЕЛӘН ЙӨРҮГӘ НИ ҖИТӘ?

*Бүгенге проза турында сөйләшәбез*

Журналыбыз үзенең быелтыргы 9 нчы санында күренекле тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның «Тема, идея, әдәби осталык» исемле мәкаләсен тәкъдим итеп, бүгенге проза мәсьәләләрен уртага салды да әйтте: мәгез, бәхәсләшегез. Бик бәхәсләшер идек, әмма мәкалә моның өчен җитәрлек азык бирми шикелле. Мисал итеп алынган әсәрләргә — «Тын елга буенда» (С. Рафиков) һәм «Ут һәм Су» (Ә. Баянов) романнарына, «Чикләвек төше» (Г. Ахунов), «Идел хикәяте» (Г. Әпсәләмов), «Мәйдан» (Ф. Хөсни), «Ялыкмаслар» (Б. Камалов) повестьларына — тәнкыйтьче дөрес бәя биргән. Шушы әсәрләр уңае белән күтәргән мәсьәләләренең күбесен шулай ук дөрес хәл иткән (һәрхәлдә, миңа шулай тоела).

Шулай да мәкаләдә бәхәсләшерлек урыннар бар. Мин анда хата фикер үк димим — һәрхәлдә, ялгыш аңларга мөмкинлек калдыра торган раслаулар таптым.

Менә безне сагайта торган беренче җөмлә: «...классиклар югарылыгына күтәрелү өчен, аларны кабатлау (?) гына җитми, башкача язарга, заманга хас сурәтләү чаралары эзләргә һәм табарга кирәк». Классикларны кабатлау турындагы сүзләргә бәйләнеп тормыйк, биредә «техник» хата киткән булырга тиеш. Чөнки әдәби иҗатта беркемне дә, шул исәптән классикларны да, кабатларга ярамаганны тәнкыйтьче яхшы беләдер. Ә менә «башкача язарга кирәк» дигәнне ничек аңларга? Бүгенге модернистлар һәм модернизм теоретиклары да шулай диләр бит: классик реализм инде искерде, аның алымнары һәм принциплары, форма һәм жанрлары XX гасыр чынбарлыгын сурәтләү өчен ярамый.

Р. Мостафин, әлбәттә, бу кадәресен үк әйтергә җыенмый. Шулай да мәкаләдә реализмның чиксез зур мөмкинлекләренә шикләнеп карауга юл ача торган сүзләр ычкындырып ташлаган. «Соңгы елларда,— дип яза тәнкыйтьче,— безнең әдәбиятта тышкы охшашлыкка нигезләнгән традицион хикәяләү стилендәге проза өстенлек итә». Юк, ди ул, мин бу стильгә дә каршы түгел. Тик аның белән генә чикләнмисе иде. Әнә бит Көнбатыш әдәбиятында «реаль булмаган, фантастик алымнар» белән язучылар да байтак. Хәтта Бальзак та «Шагрень күне» романында фантастик алым кулланган. Безнең Ф. Әмирхан да «Фәтхулла хәзрәт» повестенда фантастикага мөрәҗәгать иткән. Г. Колахметов та «Ике фикер» пьесасында Давытның иске һәм яңа фикерләрен адәм кыяфәтендә сәхнәгә мендереп җибәргән.

Әйе, болар барысы да дөрес. Әмма шунысын да онытмыйк: Бальзакның «Кешелек комедиясе»н тәшкил итә торган 92 әсәренең (күбесе роман) тик берсендә, әлегә «Шагрень күне» романында гына, шартлы-фантастик алым кулланылган. Л. Толстой яисә И. Тургеневта мондый алым бөтенләй юк. А. Толстой һәм М. Шолохов, А. Фадеев һәм К. Федин әсәрләрендә дә андыйларны очратмыйбыз бугай.

Классиклардагы мондый «бертөрлелек», тәнкыйтьче сүзе белән әйтсәк, «тышкы охшашлыкка нигезләнгән традицион хикәяләү

стиле» үз заманының укучыларын ничек туйдырмаган икән? Ярар, ул заман укучыларының зәвыклары таррак булсын, ди. Ә инде XX гасырның соңгы чирегенә кереп бара торган укучы ул «искергән» әсәрләрне ник кулдан төшерми укый?

«Фәтхулла хәзрәт» исә, мисал буларак, ялгыш килеп кергән. Аңа калса, «Гаргантюа һәм Пантагрюэль», «Гулливер сәяхәте» әсәрләре янсә М. Е. Салтыков-Щедринның башында ми урынына орган булган градоначальник образы да бар ич. Ләкин бит болар сатирик әсәрләр. Сатираның бер үзенчәлеге исә чынбарлыкның реаль пропорцияләрен үзгәртеп сурәтләүгә кайтып кала.

«Ике фикер» пьесасына да ышыкланырга урын юк. Театр сәнгате, үзегезгә мәгълүм, сүз сәнгате белән чагыштырганда, шартлылыкка күбрәк урын бирә. Шуңа да карамастан, А. Н. Островский янсә безнең Г. Камал, мәсәлән, шартлы алымнарга ихтыяҗ сизмәгәннәр.

Адәм баласы, турайганнан бирле, аяк белән йөри. Инде килеп, берәү: «Алай йөрү инде искерде һәм туйдырды, кул белән йөрергә вакыт», дип чыкса, белмим, кем генә моңа җитди карар һәм бу кешене чын новатор итеп санар икән. Дөрес, кул белән йөрү дә кайвакыт үзен аклый. Әйтик, циркта янсә спорт залында. Ә инде берәү, оригиналь булам дип, урамда кул белән йөреп китсә, без аңа, ким дигәндә, болай дияр идек: оста йөрисең, тик ерак бара алырсың микән?

Әнә шуның шикелле, «тышкы охшашлыкка нигезләнгән традицион хикәяләү стиле», фән теле белән әйтсәк, тормышны үз формасында, үз кыяфәтендә чагылдыру принцибы моңарчы реализмның «табигый хәле», олы юлы булып килде һәм, шикләнми әйтергә мөмкин, киләчәктә дә ул шулай булачак. Аерым очракларда язучылар билгеле бер максат белән сатира төренә кермәгән әсәрләрдә дә шартлы алымнарга мөрәҗәгать итәләр икән һәм бу алым аклана икән, анысы — бүтән мәсьәлә.

Ә инде тормышның үз формасы белән эш итә торган реализмның мөмкинлекләрен шик астына алып, прозаны алга җибәрү өчен шартлы-фантастик алымнар кулланырга чакыруны, теләсәгез ни әйтегез, мин аңлый алмыйм.

Классикларны һәм, гомумән, талантлы язучыларны кабатлау дигәндә ике нәрсә бутала булса кирәк. Чынбарлыкны сәнгатьчә чагылдыруның гомуми принцибы һәм аны кабатлау — бер нәрсә. Конкрет әсәрнең конкрет типларын янсә кулланылган алым һәм сурәтләү чараларын кабатлау — бөтенләй бүтән нәрсә.

Беренче төр «кабатлау», ягъни тормышны үз кыяфәтендә чагылдыру принцибына нигезләнеп иҗат итү, бер дә начар эш түгел. Бу юнәлеш, тиешле шартлар булганда, зур уңышларга китерә ала һәм китерәчәк. Икенче төр кабатлауны исә без кире кагабыз, һәм ул әдәбиятның үсешен тоткарлый дибез. Р. Мостафин дөрес билгеләп үткәнчә, 1971 елгы прозаның йомшаклыгы да шунда: язучылар әдәбиятыбызда булып үткән типларны һәм алымнарны кабатлыйлар, идея-художество ачышлары юк дәрәҗәсендә.

Г. Ахуновның «Чикләвек төше» повестен алыйк. Тәнкыйтьчегә кушылып, мин бу әсәрне 1971 елда дөнья күргән әсәрләр арасында чагыштырмача иң уңышлысы дип саныйм. Шулай да повестьта кабатлаулар шактый күп.

Хикәяләү рәвеше һәм интонациясе белән ул иң элек Ә. Еникиның «Йөрәк сере» повестен хәтерләтә. Әсәрнең төп герое Халикъ, ягъни артта калган колхозны күтәрүче председатель образы, бер яктан, А. Расихның «Язгы авазлар» романындагы Ифрат Аллаһияровка, икенче яктан, Солтан Фәхретдиновка барып тоташа.

«Чикләвек төше» повестен чынлап торып җентекләсәң, кайбер бүтән әсәрләрнең дә эзен табып булыр иде. Халикъ, мәсәлән, исереп килгән Мөбәрәкшаны тибеп ега. Шуннан тегесе нишли? Икенче көнне председательдән гафу үтенә һәм, күпмедер вакыттан соң, төзәлеп, Халикъның уң кулына әверелә. Бу — «Педагогик поэма»дан. Задорновның да төзәлүе Макаренко аның «яңак төбенә менеп төшкәч» башлана бит. Бер урында автор үз-үзен кабатлавын да абайламый калган. Бер персонажы турында ул болай ди: «Буе-сыны бар, **нәсел айгырларын** егып салырлык тазалыгы бар». «Хәзинә» романын ачып укыйбыз: «...гайрәте белән **нәсел айгырларын** сугып үтерә ала торган электр тогы».

Күп кенә проза әсәрләрен укыганда, Тукайның юмористик очеркындагы бер эпизод хәтергә килә.

Тукай бер иптәше белән ресторанга барган икән дә, швейцар аларны: «Сезне кертмибез», дип каршылаган.

— Ни өчен?

— Өс-башыгыз начар...

Шуннан болар, бүрекләрен алыштырып, яңадан килгәннәр. Швейцар, аларга күз генә сирпеп алып:

— Сезгә әйтелде бит инде, әфәнделәр,— дигән, имеш.

Бүреген алыштырып кигән шундый персонажларны 1971 елда чыккан бүтән әсәрләрдә дә шактый күп табабыз. Әлеге швейцар тәҗрибәсенә ия булмаган беркатлы укучы аларны, ихтимал, яңа типлар сыйфатында кабул итә торгандыр. Әмма үткен күзле тәнкыйтьчене алдый алмыйсың. Менә ул бер үк елда, бер үк журналда басылган ике әсәрдәге ике персонажның бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаганлыгын дәлилләп күрсәтә. Сүз биредә «Тын елга буенда» романындагы Васил һәм «Ут һәм Су»дагы Фәез турында бара.

Зур таләпләр белән килгәндә, 1971 елгы әсәрләр арасында чагыштырмача уңышлысы булган «Ялыкмаслар» повестендагы Хафиз Кадергуловны да оригиналь тип итеп карап булмый. Дөрес, әсәрнең үзәгенә куелганга һәм җентеклерәк күрсәтелгәнгә, райком секретаре образы шактый җылы тәэсир калдыра. Бу яктан Р. Мостафин белән килешергә кирәк. Әмма Хафиз кебек гаять сабыр, басынкы, уйлап кына сөйли торган, акыллы, өйрәтергә һәвәс, чигәсенә чал төшкән партия җитәкчесе образларын әдәбиятта күп мәртәбәләр күргән идек инде. Тәнкыйтьченең мин бер сүзен аңлый алмадым. Моңарчы, ди ул, партия җитәкчесе образы төссез-чырайсыз булып чыга иде, чөнки «язучылар гадәттә ике генә төрле буяудан: я деготь кебек кара, я сөт кебек ак буяулардан гына файдаланалар иде». Безнең әдәбиятта мин кара буяу белән генә бирелгән партия җитәкчесе образын белмим. Ике буяуны катыштырып ясалганнары да сирәк булса кирәк. Ә менә ак буяу белән генә ялтыратылганнары исә — рәттән. Партия җитәкчесе образларының төссез, чырайсыз чыгуына китергән сәбәп, минемчә, язучыларның тормышның үзеннән килеп түгел, бәлки партия работнигы нинди булырга тиеш дигән принциптан чыгып эш итүләрендә кайтып кала.

Чын сәнгать әсәре һәр вакыт — зурмы, кечкенәме — ачыш ул. Ачыш исә, беренче чиратта **яңа, оригиналь** тип рәвешендә була. Менә татар әдәбияты тарихындагы идея-художество ачышларының тулы булмаган «галереясе». Г. Ибраһимовның Шаһи карты һәм Фәхрие, Ф. Әмирханның Габделбасыйры һәм Хөяты, Г. Кутуйның Галиясе һәм Г. Бәшировның Нәфисәсе, М. Әмирнең Гаязы һәм И. Газиның Федюшкины, Ә. Еникиның Зөфәр Сабитовы һәм А. Расихның Заһид Сафичы, Р. Төхфәтуллинның Нәбие һәм Н. Фәттахның Һаруны һ. б.

Ә бит бу әсәрләрнең һәркайсы «традицион стильдә», ягъни тормышның үз кыяфәтендә язылган. Әгәр болар янына яңа типларны эченә алган, димәк, яңа мәсьәләләр күтәргән һәм шундый ук «традицион стильдә» язылган әсәрләр тезелеп китсә, укылыр идеме алар? Ничек кенә әле! Һәм биредә гаҗәпләнергә урын юк: укучының игътибары тормышка, аның яңа күренешләренә, яңа мәсьәләләренә, шул мәсьәләләрне гәүдәләндергән яңа типларга юнәлә. Форма «шаккатыризмы» исә аны бик аз кызыксындыра. Әлеге тормышны, кешеләрне, обстановканы бөтен җанлылыгы белән күз алдына бастырырга хезмәт итеп тә, үзе **сизелми** торган форманы гына без яхшы форма дип саныйбыз.

Шулай итеп, без мондый нәтиҗәгә килдек: бәла прозаикларның «традицион стильдә», ягъни тормышны аның үз кыяфәтендә күрсәтү принцибына нигезләнеп язуларында түгел. Бәла күп кенә язучыларыбызның тормышка тирән үтеп керә алмауларында, иҗтимагый үсешнең яңа тенденцияләрен тотып алып, проблема төсендә куя белмәүләрендә, шул тенденцияләрнең гәүдәләнеше булган яңа типларны иҗат итүгә көчләре җитмәүдә.

Моннан инде прозаикларның игътибарын кай якка юнәлтү тиешлеге дә ачыклана булса кирәк.

Көнбатыш Европа әдәбиятларындагы шартлы һәм фантастик алымнар белән азыкландырып прозаны алга таба әйдәүнең тиешле нәтиҗә бирмәячәге көн кебек ачык. Моның хәтта зарар китерүе мөмкин. Эзләнүне, эчтәлектән бигрәк, форма өлкәсенә юнәлтүдән башка нәрсә түгел бу. Ә моннан формализмга да бер адым гына кала.

Ерак барасы юк, үзебездә үк бүтәннәргә охшамауны, оригинальлекне төп максат итеп алып, форма өлкәсендә шикле экспериментлар белән мавыгу көчәеп китте. Япон Танакаларын яисә Фредерик Гарсиа Лорка шигырьләрен укып, шигъри кроссвордлар белән сөйләүчеләребез юкмыни? Метерлинк яисә Ибсен алымнарын механик үзләштереп, драматургиябезгә «яңалык» кертергә тырышучыларыбыз да булмады түгел. Прозабыз да модадан читтә калмады кебек. Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романы,

мәсәлән, әнә шул турыда сөйли. Анда без кыз да, елга да дип аңларлык серле сурәтләрне дә, төп геройның саташуга охшашлы уйлануларын да, авторның Фәез исеменнән әйтелгән парадоксларын да, хикәяләүнең күнегелмәгән күп кенә алымнарын да очратабыз. Әмма форма оригинальлеге эчтәлек оригинальсезлеген каплап җиткерә алмый. Моны Р. Мостафин да танырга мәҗбүр: «Ә. Баянов та әзер штамп һәм схемалардан котыла алмаган»,— ди ул.

Димәк, прозаикларның, аеруча яшьләрнең игътибарын башлыча эчтәлек оригинальлеге мәсьәләсенә юнәлтү дөресрәк булыр. Чын мәгънәсендә идея-художество ачышы итеп саналырлык әсәр тудыру өчен нәрсә кирәк соң? Бу сорауга билгеле сүзләр белән җавап бирергә туры килә: тормышны белү, яңаны коруда гражданин буларак катнашу, киләчәк өчен үзеңне җаваплы итеп сизү һәм күргән-белгәнеңне философча гомумиләштерә белү. Әмма моның белән генә дә эш бетми әле. Тагын бер «кечкентәй» генә нәрсә кирәк. Ул да булса ... талант.

Гаҗәеп хәл, әдәби тәнкыйтьтә дә, әдәбият белемендә дә талант мәсьәләсенә кергәннән аз игътибар ителә. Мәгълүм булганча, иң камил корал да, остасы кулына эләкмәсә, юньле нәрсә тудыра алмый. Шуның шикелле, художниклык таланты җитенкерәмәгән язучыны тормышны биш бармагы кебек белү дә, эрудиция дә, дөньяга дөрес караш та, сыналган иҗат методыбыз да коткара алмый.

Р. Мостафин әлеге мәкаләдә талант мәсьәләсенә кагыла, ләкин, әрсез чебеннән котылырга теләгәндәй, селтәнеп кенә уза. «Кайберәүләр бөтен эш талантка бәйләнгән дип котылмакчы булалар,— дип яза ул.— Янәсе, Пушкин, Тукай яисә Лев Толстой кебек талант туса, әдәбият шунда ук алга сикерәчәк. Бу дөрес караш түгел». Әйе, даһилар сирәк туа. Әмма талантлар турында моны әйтеп булмый. Халкыбыз талантларны, әгәр артыграк тудырмаса, һич тә элеккегедән ким тудырмый. Әнә шуларның күпме өлеше генә әдәбиятка килә икән? Мәгълүм булганча, талантлы яшь кеше кулына каләм алсын өчен, аның нин дидер «әдәби атмосфера»га элөгүе кирәк. Шулай булмаганда, ул бүтән һөнәр сайларга һәм үзендә әдәби талант барлыгын белмәгән килеш гомер юлын узарга мөмкин. Әдәби атмосферага эләгү мөмкинлеге исә балалар бакчасы һәм мәктәптән үк башлана. Бу — мәсьәләнең бер ягы һәм ул үзенә игътибар итүне сорый.

Әдәбиятка талантлар кергәннән азрак килә икән, табигать бушлыкны яратмый дигәндәй, аларның урынын бик тиз талантсызлар билэп ала. Урта кул әсәрләр күпләп чыгып тора икән, моңа бер дә гаҗәпләнергә урын юк. Тәнкыйть исә, шул исәптән танылган талант ияләре, никтер турысын әйтергә, туганкай, синең күңелеңә «ходайдан килә торган очкын» салынмаган, башка һөнәр сайлый күр, дип әйтергә тартыналар. Бусы мәсьәләнең икенче ягы.

Ахыр сүз шул: талантларны эзләү, табу, дөрес тәрбияләү, алар алдына зур таләпләр кую, халтурага, тәсссез-чырайсыз әсәрләргә каршы аяусыз көрәш алып бару,— менә нәрсә безнең прозаның алга китешенә күпмедер этәргеч ясарга мөмкин.

□□□□□□□□□□□

Мансур Вәлиев

# БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЙЛАРЫ

Язучының эше бер көчле радиостанцияныке кебек бугай. Язучы да бит тормыш дулкыннарын үзенә кабул итә, җыя да, аннары аларны көчәйтеп һәм чистартып безнең күңелләргә тапшыра. Аннан без бүгенге көннең иң дөрес, иң чын тавышын — заман тавышын ишетергә телибез. Күрәсең, коммунизм төзеп килүче җәмгыятьтә әдәбиятның тоткан урыны да аның шушы мактаулы вазифасы белән аңлатыладыр.

Ләкин «Казан утлары» битләрендә башланып киткән сөйләшүдә катнашучылар ничектер прозаның шул ягына — аның бүгенге тормыш белән мөнәсәбәтенә, әсәрләрдә куела һәм хәл ителә торган проблемаларның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуына һәм ни дәрәҗәдә бүгенге әдәбият рухына җавап бирүенә тиешенчә тукталмыйлар кебек.

Бу мәкаләдә мин шушы мәсьәләләрнең бүгенге көндә иң актив иҗат итүче ике язучының иҗатында ничек чагылуына тукталмакчы булам.

## Ялыкмас кешеләр

Барлас Камалов безнең әдәбиятта иң актив язучы. Соңгы берничә елда гына да аның бер-бер артлы «Күршеләр», «Күңел кыңгыраулары» һәм «Ялыкмаслар» дигән китаплары басылып чыкты. Болардан башка Барлас Камалов тагын республика газеталарында иң күп хикәяләр бастыручы дисәк тә ялгыш булмас. Аның хикәяләре һәр вакыт ап-ачык конфликт, туры характерлар һәм җиңел тел белән, шул көн өчен кирәкле темага язылган булыр. Гомумән, бүгенге китап укучы өчен Барлас Камалов исеме үтә нык таныш.

Аның соңгы повесте «Ялыкмаслар», исеменнән үк күренгәнчә, бүгенге көннең иң көчле кешесен — коммунист образын тудыруга багышланган. Юк, Хафиз Кадергулов гади коммунист кына да түгел — партия райкомының беренче секретаре, җитәкче. Авторның шундый җаваплы бурыч алуы, әлбәттә, үзе үк геройлык кебек. Һәм аның язучылык бу батырлыгы безнең тәнкыйть күзеннән дә читтә калмады. Зур әһәмияткә ия булган теманы яктырткан бу әсәр бүгенге проза турында бара торган сөйләшүдә дә искә алынды. Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин әсәрнең төп герое турында «Кадергулов барыннан да элек — әйбәт кеше, юк, ул бөтенесен гафу итә, кеше белән мөнәсәбәтләре бозылудан куркып яши торган юаш кеше түгел, ә эшлекле, принципиаль, кирәк чакта рәхимсез һәм каты куллы да була белүче чын коммунист»,— дип язды. (К. У. № 9. 1972 ел.) Р. Сверигин да авторны нигездә уңай яктан билгеләп үтә.

Тик әсәрне ныклабрак тикшерә башласаң, мәкалә авторлары үз бәяләрен гомумирәк һәм берьяклырак бирәләр дигән тәэсир кала. Ә менә Хафиз Кадергулов дөньяда беркем тарафыннан үтелмәгән тарих юлыннан беренче булып баручы җәмгыятебезнең җитәкче көче буларак, җәмгыять алдына килеп баскан иң үткен пробле-

маларны дөрес хәл итүнең төп авырлыгы, бөтен җаваплылыгы үзенә төшкән кеше буларак нинди уйлар, нинди борчулар белән яши? Ә бит бүгенге илебез әдәбиятыннан әнә шундый бик күп җитәкчеләр, чын мәгънәсендә массаларны әйдәп баручы булырлык кешеләр белән очраштык инде. Алар белән таныш булган бүгенге укучыга Барлас Камаловның Хафизы нинди яңалык алып килә соң? Шундый таләп белән әсәрне тагын бер кат күздән кичерик.

Хафизны без беренче тапкыр «Ватан» колхозында уракка төшү тантанасына басуга җыелган халык арасында күреп калабыз. «Әнә шулай, үзенең авылдашларын онытмый ул», дип куя Барлас Камалов әсәр башындагы бу эпизодта. Аның белән ныклап танышуны без алдагы битләрдән көтә башлыйбыз. Бу кешедә безгә тирән эчке дөньялы, бүгенге тормышның иң катлаулы проблемаларын хәл итәрлек рух көче, акылы булган шәхес ачылуын көтәбез. Авторның повесть исемен «Ялыкмаслар» дип куюы да укучының игътибарын әнә шундый көчле шәхескә юнәлдерә.

Ләкин геройның үзе белән таныша башлагач, безгә ул бүтәнчәрәк ачыла. Һәрхәлдә, аның үзенең уйлары бездә шундый тәэсир калдыра. «Гөлстан» колхозыннан район үзәгенә кайтып барышлый, Хафиз менә ничек уйлый: «Алай булса да, район буенча бөртекле һәм кузаклы ашлык әле беркайчан да булмаганча әйбәт чыга. Моны маңгай тирен түккән игенче хезмәтенең татлы җимеше димичә, ни дисең?! Вакытында туңга сөрү, мул итеп кар тоту, язгы суларны туплау, орлыкның гәрәбәдәен генә чәчү, җир сыеның һәртөрлесен туфракка күп кертү, чүп үләнгә каршы көрәш, урып-җыюны кыска тоту — һәммәсен кирәгенчә эшләү нәтиҗәсе бу. Нәкъ шуның аркасында игенченең куйган көче, тамызган тире заяга китми калды...» Юк, без көткән Хафиз уйлары түгел бу. Монда автор, күрәсең, героеның никадәр эш оештырган булуын, аның хезмәтен күрсәтергә тели. Ләкин әнә шул максатына ул ирешә алмый, чөнки укучы боларны кешенең табигый, чын уе буларак кабул итми, ул аңа колхоз идарәсендә төзелә торган агротехник эшләр планы кебек тоела.

Мондый фактларны Барлас Камалов повестеның башка урыннарында да һәм бүтән әсәрләрендә дә очраткан идек. Менә «Күршеләр»дәге Ләмига үләр алдыннан улына нинди хат язып калдыра: «Илгә хезмәт итәргә дигәндә әтиеңә охшарсың дип уйлыйм. Ул җәмгыять интересларын шәхси теләк һәм омтылышлардан һәр чак өстен куя белә. Һәр вакыт туры сүзле, принципиаль. Кешелекле, ярдәмле. Билгеле, аның йомшаклыклары да булуы ихтимал, ләкин бу әле ул ихтыярсыз кеше дигән сүз түгел...» Хатын кеше үзенең иренә шундый рәсми характеристика язуына бер дә ышанасы килми. Анда кешелек хисләре бер дә булмады микәнни? Юк, әсәрдән аңлашылганча, Ләмиганың мәхәббәте дә булган, ләкин автор аны хатта гына күрсәтә алмый.

Фатих Хөснинең «Мәйдан»ында да көннәрдән бер көнне колхоз председателе Ахунҗанов болай уйлый: «Чыгасы тирес тә чыкты, кыр эшләре дә түгәрәкләнде, Шайтан тавыннан әре-әре ташлар да актарыла башлады (колхоз таш чыгаруга керешкән), спектакль дә ярыйсы үтте (председатель анда катнашкан иде бит), ә шулай да... Ә шулай да Ахунҗановның күңеле урынына утырып җитми». Әйтерсең бүгенге китап укучылар колхоз председателе шушы эшләрдән генә ямь табып яши дип, ялгыш уйлыйлар да, автор аларның уен үз герое белән тәэзәтеп куя. Юк шул, күптән инде укучылар хәзерге җитәкчеләрне алай беркатлы итеп уйламыйлар.

Хәзер, дөньяны фән-техника революциясе шаулаткан, тормышта машиналарның роле искиткеч нык арткан чакта, аларның тормышта рациональ алымнарны көчәйтү тенденциясенә капма-каршы буларак бүгенге әдәбиятта һәм гомумән сәнгатьтә кешенең иң үзәк хисләре, аның кешелеген билгели торган төп сыйфатлары өчен көрәш бара. Бүгенге олы әдәбият шуларны игътибар үзәгенә куя һәм шуларны югары сәнгать ысуллары белән раслау аша тормышта гуманизм принципларын ныгыту өчен көрәшә. Әдәбият чын кешеләр өчен көрәшә. Бу кешеләр 30 еллар әдәбиятындагы «күн тужуркалар» булмаган кебек, үз кабыкларына бикләнеп, бер стакан су эчендәге давылда бәргәләнүчеләр дә түгел. Алар югары интеллектуаль дөньялы, һәм аларның хезмәтләре, иҗтимагый эшчәнлекләре дә әнә шул эчке дөньяларының аерылгысыз өлеше, яшәү атрибуты. Аларның бүген зур эш башкарулары, заманның авыр йөген тартып барулары да ул кешеләрнең эчендә ниндидер бер көчле заряд булганга. Әнә шуңа күрә заманның җитәкче көчләрен сурәтләгәндә, бүгенге әдәбият сөючеләр

аларның эчке зарядын — рухи дөньяларын язучының дөрес аңлавына һәм әсәрендә дөрес чагылдыруына, аның аңлавы бүгенге укучы күңеле югарылыгындамы икәненә бик нык әһәмият бирәләр. Югарыда телгә алынган әсәрләрдә язучыларның үз геройларының эчке дөньяларын шулай ачулары — бүгенге геройны кәкре көзгедән күрсәтү кебек.

Хәзер повесть герое Хафизның тормышын алга таба күзәтик. Менә ул райкомга кайтып җитә. Бу инде аның төп урыны, геройның күп төрле эшчәнлегенең тыгыз җепләре тоенләгән җир. Хафиз характерындагы иң әһәмиятле җепнең очын да автор безгә шушында бирер кебек тоела. Ул көнне райком секретаре янына дүрт кеше керә. Нинди йомышлар белән йөриләр соң алар? Бер карт зиратны койма белән әйләндереп алу турында, ә икенчесе — пенсиясен җайга салу турында, аннары ике хатын балаларын яслегә урнаштыру турында һәм Мәгъсүмә исемлесе (бусы Хафизны иң дулкынландырганы) үзенең ташлап киткән улы турында сөйләшү өчен киләләр. Ә райкомнан өенә кайтып барышлый райком секретаре «хәер, шәхси кайгылар коммунизмда да булыр» дип уйлана. Кая соң әле монда райком секретареның җитәкчелек роле? Бүгенге партия җитәкчесен иң борчыган, иң уйландырган проблемалар шулармыни соң? Ә бәлки аларны автор соңга таба сурәтлидер. Менә Хафиз бюрода утыра, партиягә алалар. Тик бу эпизод та Хафизга берниндидә яңа штрих өстәми. Аннары аның янына бабасы килә. Хәбәрче егетне кыйнап закон каршына баскан улын яклауны сорый ул Хафиздан. Язучы шуның белән райком секретареның принципиальлеген сынарга тели. Ләкин әгәр дә Хафиз моның кадәр дә принципиаль булмаса, аның беренче секретарь булып торуы ук дөрес булмас иде. Яшь укытучылар, Гөләндәм, Елена белән мөнәсәбәтләре дә Хафизны бүгенге көн райком секретаре буларак яңа яктан ача алмыйлар. Гомумән, әсәрдә Хафизның җитәкчелек сыйфатлары түгел, ә кешелек сыйфатлары гына ачыла. Мондый яхшы сыйфатларны бүтән хезмәт башкаручы кешеләрдән дә шуның кадәр үк табып булыр иде. Күрүебезчә, автор героен тормыш чуарлыгыннан, аның вәкылкыларыннан арындырып, бүгенге көн әдәбияты сорый торган әдәби образга кадәр күтәреп җиткерә алмаган.

Барлас Камалов повестенда геройлар бик күп төрле темаларга сүз кузгаталар. Аларны җир шарындагы политик вакыйгалар да кызыксындыра, биосферага куркыныч янау, кошларны саклау, әдәбиятта уңай һәм тискәре герой турында да сөйләшәләр. Ләкин болар күп чагында сүз генә булып калалар. Әсәрнең табигый агышы, тукымасы булып китә алмыйлар, шуңа күрә аларның хәл ителү тирәнлеге дә сай, укучыда нинди дер тәэсир калдырырлык түгел. Бу елда басылган әсәрләрдәге җиңелчәлек тенденциясе иң калку булып «Ялыкмаслар»да гәүдәләнә. Бу әсәр уңае белән К. Паустовский сүзләрен китерәсе килә: «Сез шактый житез язучы һәм бу мине куркыта». К. Паустовский сүзләре башкалар өчен дә гыйбрәтле кебек.

Ничек кенә пародоксаль булса да, үзенең мәкаләсендә (К. У. № 2. 1973 ел) бу хәлгә ярсып каршы чыккан Фатих Хөсни иҗатында да шундый күренешне күрергә була. «Ялыкмаслар» белән бер елны басылган «Мәйдан»да конфликт гаять беркатлы кешеләр белән «көчле» председатель арасында бара да, ахырда тегеләр җиңелә һәм эпилогта автор: «Ә менә табигать кирелекләре белән көрәштә әле кайвакытларда егылгалап та куйгалыйбыз. Димәк, тынычланырга урын юк, исереп калырга урын юк, мускулларны бушатмаска, көчне йомшатмаска, мәйдан гел алда, көрәш гел дәвам итә», дип нәтиҗә ясап куя. Автор фикеренчә, хәзер көрәш табигать белән кешеләр арасында гына бара. Ә бит партиянең XXIV съезды карарларыннан ук билгеле булганча, безнең җәмгыятьтә коммунистик мөнәсәбәтләр урнаштыру, яңа кеше тәрбияләү өчен зур көрәш бара. Бу көрәшкә табигать белән көрәшүгә караганда күп артыграк көч куярга кирәк. Тормыштагы тирәнрәк һәм дәвамлырак көчләрне күреп җиткермәү бирелә ялгыш нәтиҗә ясарга урын калдыра.

Күргәнебезчә, сөйләшүдә катнашучылар тарафыннан әйбәт кенә дип узылган әсәрләрдә дә җитди генә кимчелекләр бар. Фатих Хөсни тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның 1971 елны тәссез ел диюенә бик каршы булса да, ирексездән Р. Мостафин фикере белән килешергә туры килә. Ул ел җитди көчләрнең тын алу елы булды, күрәсең.

Кешенең шәхес булып өлгереп җитүен аның урнашкан характеры буенча, дөньяга, тормышка үз карашлары, аңлы мөнәсәбәте буенча билгеләсәк, язучының чын художник булып җитлеккәнлеген әсәрләрендә ул сайлап алган һәм чишә торган проблема, ул проблеманың җәмгыять үсеше өчен бүгенге көндә никадәр әһәмиятле булуына карап фикер йөртәбез. Язучының бер әсәрендә колхоз турында, икенче әсәрендә эшчеләр тормышы, ә өченчесендә исә укытучылар яки врачлар турында язуын күргәч, без аны тормыштагы проблемалар диңгезенең бер читеннән икенче читенә сугылуы дип кабул итәбез. Икенче язучы иҗатының башында ук тормышның үзәгеннән бер проблема суырып алып, шуны әсәрдән-әсәргә тулырак, күп яклырак һәм тирәнрәк, ышанычлырак итеп чишә килсә, һәм бу чишү җавабы күптән билгеле мәсьәләне чишү кебек булмыйча, синең тормышың, эзләнүчән акылың белән киңәштә барса, бу вакытта инде без төпле язучы белән очрашуыбызны тоябыз, ышанычлы дус белән танышкандай куанабыз.

Аяз Гыйләҗев — әнә шундый, бүгенге проблемалар катлаулыгында үз юлы, үз юнәлеше булган язучы. Аның юлы әдәбиятка яңа чор кешеләрен — элекке еллар әдәбияты күзлегеннән караганда, гади булмаган кешеләрне алып килә. Язучының бу юлын замандашыбыз йөрәген, аның характерын, психологиясен зур планда өйрәнү юлы дип атарга мөмкин. Ул юл «Өч аршин җир» биеклегеннән башланып «Бәрәү», «Урамнар артында яшел болын»нар аша «Урталыкта» повестена кадәр килә. «Урамнар артында яшел болын» романында тормышта үзенең ышанычлы юлын тапкан замандашыбыз Идрис яшь буын язмышы борчуына төшкән булса, шуның белән үзе дә ныгыса, җәмгыятьнең прогрессив көче буларак активрак һәм кискенрәк хәрәкәт итә башласа, «Урталыкта» повестенда исә язучы бүгенге кешене тагын да тирәннәнрәк белергә тели. Идрис кебек үз эшендә дәртләнеп йөргән кешене иң авыр кыенлык — иҗат эшендә уңышсызлык, үзе ышанган идеясен практик төстә расльй алмавы, тәҗрибәнең уңышсыз чыгуы белән сынап карый.

Төп герой Сәгыйт 1928 елда туган, сугыш һәм сугыштан соңгы чорның бөтен кыенлыгын үз җилкәсендә татыган булса да, кешенең рухи көчен сыный торган тормыш сынавын үтә алмый, авыр йөген ярты юлда ташлап, җиңел юлдан кереп китә. Ә анда аны инде күптән дачалар, «чат витамин гына булган кара карлыганнар», балачагасы турында кайгырту, хатынының вак-төяк йомышлары артыннан чабу һәм ял көннәрендә йомшак Идел кочагы, аны тормыш мәшәкатьләреннән аерып эчкә, вак утрауларга алып китә торган фырт көймәсе көтә.

Әйе, бүгенге тормыштагы бу юл безгә нык таныш. Ул юлдан күпләр бара әле. Тыныч чорның тигез ритмы аларны яраткан көймәләрендә вак дулкыннар өстендә тирбәтә, оета, йоклата. Ә көймәләрен ярдан һаман да ераккарак, кешеләрдән, аларның кайгыларыннан читкәрәк куа.

Бәлки Сәгыйт тә әнә шулай оеп кына дөнья рәхәтлегенә иялләнеп киткән булыр иде. Ләкин дөньяда Баязит абый бар. Әсәрнең бер герое әйткәнчә, «Ленин гвардиясе солдатлары», тормышның мәгънәлелеген билгеләүче тере критерийлар бар. Ләкин тормышта онытгысыз яшьлек Рузалия дә бар. Сәгыйт абыйсы эше белән дәртләнеп йөргәндә ул аңа ышана, аңа гашыйк, үзе дә алар юлыннан, тынгысызлар юлыннан китәргә атлыгып тора. Ә хәзер Сәгыйт тормышның тыныч юлына кереп киткәч, ул — аптырашта. Шулай итеп, язучының бер кеше тормышындагы вакыйганы күрсәтүе әсәрдә тирән социаль төс ала — Сәгыйт буыннар арасын тоташтыручы бәҗра сымак күз алдына килеп баса. Эш аның ныкмы, йомшакмы икәнендә. Заманның көрәш мәйданында үзенә төшкән авыр рольне башкарып чыгарлыкмы? Баязит абыйларның идеяләре аның канына, йөрәгенә ни дәрәҗәдә сеңгән, тормыш иманына әйләнгәнме? Аның өчен Сәгыйт онытылып көрәшергә өзерме? Яки очраган берәр кыенлык аны үз кыйблалсыннан борачакмы?

Бүгенге көннең үткен һәм тирән шушы проблемасы әсәрдә Сәгыйтнең ике юл уртасында торган чагындагы психологик халәтен сурәтләү аша башкарыла. Повестьның исемен «Урталыкта» дип куюю төп игътибарны шуңа юнәлтә. Безнең күз алдына

бүген әнә шундый ике юл уртасында торучылар, аларның эчке дөньялары, фикер каршылыклары һәм үз-үзләре белән көрәшләре килеп баса. Повесть ахырында Сәгыйтнең совхоз алмасын җыярга китеп баруын күңел аның яңадан үзенең якты, зур идеаллар белән балкыган дөньясына кире кайтуы дип кабул итә. Бу фикер әдәби әсәр рамкасыннан гына чыгып, тормышның урталыгында торучыларга чакыру да булып яңгырый.

Геройга әнә шулай зур социаль нагрузка йөкләү, аны көннең үткен проблемаларына үзәгенә кую, әлбәттә, язучыдан көчле фикерләү сәләте, кыюлык һәм художник осталыгы таләп итә. Үзендә шундый сыйфатлар булган Аяз Гыйләҗев повестен нигездә уңышлы башкарып чыккан. Ләкин әсәрнең кайбер урыннарында язучының ашыга төшкәнлеге сизелә. Мәсәлән, Сәгыйтнең уйлануларында берникадәр декларативлык һәм характер үзенчәлегеннән органик рәвештә чыкмый торган фикерләүләр очраштыргалый. Бу хәл озак уйланып, җитди иҗат итүче язучыга соңгы елларда әдәбиятыбызда шактый сизелә башлаган җиңел активлыкның шаукымы булса кирәк.

Ләкин повестьта мондый кимчелекләрнең булуы — язучының заманыбыз кешеләрен ныклап өйрәнүче олы әдәбиятның үсеш юлыннан аерылуы дигән сүз түгел. Киресенчә, Аяз Гыйләҗев үз әсәрләре белән безнең әдәбиятны чорыбыз әдәбиятының магистраль юлына нык якынайтты. Фатих Хөсни исә «Без кешенең эчке кулмәкләрендә казыну чорында яшәмибез» дип, язучыны чор иҗатыннан аерылуда гаепли. Юк, эчке күлмәктә казыну түгел, ә әдәбиятның төп объекты булган кеше күңелен өйрәнү бу. Илебез әдәбиятында да шушы тенденция көчәя бара. М. Слуцкисның «Җажда» романы кебек әсәрләр шуңа күрә бүгенге укучыда популярлык казандылар. Әлбәттә, Аяз Гыйләҗев әсәрләрен Фатих Хөсни әсәрләре белән чагыштырырга ярамый, алар икесе ике аспекттагы әсәрләр. Фатих Хөснинең каләмдәшенә зур гаеп ташлавы да объектив фикер булудан бигрәк, үз әсәрләрен бик яраткан язучының субъектив карашы буларак аңлашыла.

* * *

Әйе, әдәбиятта охшаш художниклар булмый. Карашлар, художестволы фикерләү үзенчәлеге һәркемнеке үзенчә. Ләкин чын образ тудыру бөтен кеше өчен дә уртак таләп. Язучы көн темасына мөрәҗәгать итеп безнең заман кешесен тасвирларга алына икән, ул нинди генә хезмәт кешесен күрсәтсә дә, герое яшәгән тормышны тирән аңлап, аның үсү перспективаларын күреп иҗат итсә генә бүгенге көн укучыларының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә алырлык әдәби образ тудырачак.

## Шамил Бикчурин

# ОЧЕРКНЫҢ АСЫЛЫ

Татар әдәбиятында, аерым алганда, «Казан утлары» журналында соңгы елларда очеркларга игътибар сизелерлек көчәйде, дип әйтергә була. Үзенең күләме һәм географиясе, тематикасы һәм әдәби эшләнеше ягыннан булсын, очерк жанры эзлекле төстә әдәбиятның алгы сафына чыгып килә. «Казан утлары» журналы былтыр угыз табаклап очерк һәм публицистик мәкалә бастырган булган. Бу елның сигез санында басылган әдәби очеркларның гына күләме дә ун табакка җитә яза. Инде шулар янына «Публицистика», «Истәлекләр» дигән рубрикалар астында чыккан материалларны да китереп кушсаң, бу сан бик күпкә зураер иде.

Хикмәт, әлбәттә, күләмдә түгел, очеркларның сыйфаты үсүдә. Очерк кешеләрнең катлаулы язмышларын, рухи дөньясын, уй-хисләрен тирәнрәк чагылдыру юнәлешендә үсеп бара. Һәм, чыннан да, әгәр без чорыбызның данлы кешеләре, аларның героик эшләре, гыйбрәтле тормышлары турында белергә теләсәк, беренче чиратта, очеркларга мөрәҗәгать итәбез. Иң оператив жанр буларак, очерк әдәбиятка яңа геройлар алып килә, вакыйгалар ташкыны эченнән иң әһәмиятле тема һәм проблемаларны күтәреп чыга.

Очеркның географиясенә килгәндә исә, соңгы бер-ике елда ул нефть якларыннан, Зәй ГРЭСыннан, Түбән Кама шәһәреннән Чаллыга — КамАЗ төзелешенә күчеп килде. «Казан утлары» журналының без тикшерә торган сигез санында басылган очеркларның күбесе гигант автозавод төзүчеләр турында. Мин монда иң элек Равил Вәлиевнең 2—3—4 саннарда басылган «Каурыйлар чыныкканда» исемле очерклар циклына тукталыр идем. Яшь автор Равил Вәлиев, белгәнебезчә, университетның журналистлар бүлеген тәмамлаганнан соң, Чаллыга килеп, гади ташчы булып төзелешкә эшкә керә. Эшчеләр белән бергә яши, шунда көндәлекләр алып бара, соңыннан шулар нигезендә әлеге очеркларын яза. Мин КамАЗ төзелешенә багышланган очерклар арасыннан Равил Вәлиевнең очеркларын иң яхшылары дияр идем. Автозавод төзүчеләре тормышын үзе яхшы белгән, аларның кайгы-шатлыкларын бергә кичерешкән кеше генә шундый матур очерклар тудырырга мөмкин. Аның очерклары — билгеле бер сюжетка, композициягә корылган чын сәнгать әсәрләре. Монда без Вазих Мәүлихов җитәкчелегендәге комсомол-яшьләр бригадасы, андагы ташчыларның образлары белән танышабыз. Автор безне гүя ниндидер тылсымлы көч белән үзенә ияртеп, үзе белән бергә йөртә: бригада кешеләре белән, аларның эшләре, характерлары белән таныштыра, төзүчеләр алдында торган кыенлыкларны һәм аларны җиңеп чыгу юлларын күрсәтә. Яхшы очерк язу өчен, характерлы вакыйгаларны, фактларны табу, әсәрнең сюжетын, композициясен төзи белү генә җитми. Моның өчен әле әдәби осталык та кирәк. Равил Вәлиевтә бусы да бар. Мисал өчен мин аның очерклар циклыннан берничә үрнәк китерер идем.

«Очкарик» булып «очкарик»ның эчмәве, бары стакан кырыена иренен генә тиереп куюы тегенең җен ачуын чыгарды. Ул алдан тутырып куелган чемоданын тиз-тиз генә карават астыннан тартып чыгарды һәм:

— Эшкә барасылары бар, имеш! Пат-

риотлар, имеш! Чиләнегез, КамАЗ төзибез дип җаныгыз чыксын! Туган ил сезне онытмас! — дия-дия, ишеккә таба юнәлде.

Ул ишекне шундый каты итеп япты, аның артыннан ишек йозагындагы ачкыч чыңлап идәнгә төшеп калды. Әйтерсең шулай чыңылдап, ишектәге йозак ачкычы түгел, ә әлеге «герой» егетнең йөрәгенә табылырга тиешле, әмма, күрәсең, табылып бетмәгән күңел ачкычы төшеп югалды...

Бер кулына кара чемодан тоткан әзмәвердәй егетнең — җиңел тормыш эзләп китеп баручы безнең көннәр «доброволец Батыргали агай»ның алпан-тилпән атлап, кәҗә сукмагыннан шул баткак сазлык эченә кереп китүен шөйләп калдым.

Кеше китте. Эш урынын ташлап, дусларының ышанычын таптап, дезертир кебек китте!

Беләм, ул бу сазлыкны үтәр. Ә менә тормыш сазлыклары белән нишләргә? Исән-сау гына үтеп чыга алырмы ул аларны? Әллә күке кебек оя саен йомырка салып йөреп, тормыш баткагында бөтенләй күмелеп калырмы?» («Казан утлары». 2 сан. 154—155 битләр.)

Күрәсез, автор шушы бер күренешне тасвирлау өчен никадәр детальләр, чагыштырулар тапкан. Ә мондый детальләр Равил Вәлиев очеркларында бик күп һәм аларның барысы да төгәл: я кешенең характерын, я эсәрнең эчтәлеген ачып бирүгә юнәлдерелгән.

Кешенең биографиясен биргәндә ул, очеркны җиңел яза торган кайбер авторларыбыз кебек: «ул фәләненче елда туган, фәлән эштә эшләгән» дип кенә калмый. Кирәк вакытта биографияне персонажның үз характерыннан таба:

«Хуш исле наратлыкны үткәч, «Камснаб» идарәсе складларына таба сузылган тимер юлны чыгарга кирәк иде. Менә ул да артта калды. «Пош-ш, пош-ш-ш!» сулап, тәзү материаллары төялгән тимер юл составы үтеп китте.

— Кара әле, син ничек уйлыйсың?.. — дип, Хәбирдән төнге сменада ничек эшләячәгебез турында нидер сорарга җыенып авызымны ачкан идем дә, янымда аның юклыгын тоеп, кинәт туктап калдым. Артыма борылып карасам, аяклары ерып шпалга баскан да, чандыр гәүдәсе белән тимер юлда тырпаеп, ерагая барган паровозга моңсуланып карап тора Хәбир.

— Әйдә инде, нәрсә торагаш булып каттың анда?.. — дип кычкырам аңа.

Юк, кымшанмый да!..

Шул чак, кылт итеп, Чаллыга КамАЗ төзешергә килгәнче Хәбирнең Казанда паровоз машинисты булып эшләве исемә төште. Ул бит тимер юлчылар мәктәбен бетергән. Ул бит һөнәре буенча тимер юл кешесе!

— Паровоз исе килә, — диде Хәбир, һаман да күзләрен горизонт читенә китеп тоташкан корыч тасмадан алмыйча.— Сагындыра, шайтан алгыры...» (3 сан. 127 бит.).

Шушы эпизод аша Равил кешенең үз һөнәренә карата булган күпме җылылыгын, мәхәббәтен, сагышын бирә алган.

Штаб начальнигы Валерий Стекольщиковның, бер җөмлә әйткән саен, теле белән авыз эчендә бераз нидер әвәләп торуын да, төзелеш начальнигы Аркадий Владимировичның «бармаклары, чапкан ат тояклары тавышын хәтерләтеп, өстәл өстендә биешеп» алуларын да, «дядя Коля»ның телеграмм баганасы кебек озын гәүдәсен дә, хәрби өйрәнүләргә чыккан ракета установкаларын хәтерләткән күтәрү краннарын да, күәтле машиналарның, катюшалар залпына охшатып, субай сугуларын да — барысын да күрә, ишетә белә автор. Дөресе, тормыш ритмын тоя, чынбарлыкны тоя.

Журналның беренче санында Диас Вәлиевнең «Хәрәкәттә бәрәкәт» исемле очеркы чыкты. Әлбәттә, әдәби сурәтләү көче ягыннан аның очеркы Равил Вәлиев очеркларыннан шактый кайтыш. Ул аерым кешеләр, аларның язмышлары, характерлары турында язмый. Аның бурычы: Камадагы гигант төзелешнең коламын, заводның һәм шәһәрнең үсеш перспективаларын күрсәтү, андагы кыенлыкларны ачып салу. Шуңа күрә дә автор әсәренең башына: «КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Раис Беляев, Кама автозаводы төзелеше начальнигының беренче урынбасары Евгений Никонорович Бабенчук һәм «Гидропроект» институтының техник бүлеге баш белгече Иосиф Сергеевич Завалишин белән аңгәмә» дип куйган. Нигә, әдәби очерк өчен, бәлки, бу яңа алымдыр?..

Әдәбиятның бүтән жанрлары кебек үк, очерк та тормышны сурәтләүнең төрле алымнарыннан һәм ысулларыннан файдаланырга хаклы. Юл язмалары, очерк-портрет, экономик һәм публицистик очерклар, фәнни һәм биографик

очерклар, проблемалы очерклар, гомумиләштерелгән очерклар — болар барысы да очерк жанрының чикләнмәгән булуы турында сөйлиләр. Танылган язучыбыз Ибраһим Гази үзенең бер мәкаләсендә аларны хәтта очерк-хикәяләргә һәм очерк-повестьларга да бүлеп күрсәткән иде. Мин үзем, мәсәлән, әдәби очеркны хикәя элементлары да, публицистика элементлары да булган синтетик бер жанр дип аңлыйм.

Ничек кенә булмасын, формасы, стиле, алымнары ягыннан никадәр генә төрле булмасын, әдәбиятның башка жанрлары кебек үк, очеркның да төп объекты кеше булырга тиеш, нигезендә кешеләр язмышы ятарга тиеш. Чөнки әдәбият үзе, М. Горький әйткәнчә, кеше турындагы фән. Бу җәһәттән караганда, Диас Вәлиев очеркы нык оттыра. Автор кешеләрдән, аларның көндәлек тормышыннан читләшә, төзелеш белән танышлыгы да җитәкче работниклар белән әңгәмә ясаудан узмый. Ә бит автор очеркын башлаганда: «Блокнотларда өзек-өзек язмалар күп. Әлбәттә, аларны теркәп бару өчен уннарча километрларга сузылган төзелеш мәйданында күп йөрергә, куәтле «КРАЗ»лар, «БелАз»лар, «МАЗ»лар үтеп киткәндә болытларга кадәр күтәрелә торган Чаллы тузанын йотарга, дистәләгән кеше белән сөйләшергә, аларның тормышларын өйрәнергә туры килде» дип, байтак нәрсәләр вәгъдә иткән иде. Кызганыч, әсәрдән без аларны күрә алмадык.

КамАЗ кешеләре турындагы очеркларның өченчесе Барлас Камаловныкы. Очерк журналның 8 санында «Ул һаман солдат» дигән исем белән басылган. Монда сүз СССР махсус монтаж эшләре министрлыгының Кама автомобиль заводын төзү буенча баш идарә начальнигы (исемен генә карагыз!) Зөфәр Садретдинов турында бара. Күрәсез, автор күсәкнең бик зурысын күтәргән, ләкин әйтер идем, суга алмаган. Хәер, автор үзе дә ы/ нәрсә вәгъдә итми.

«Моңа кадәр кеше белән танышуымны анкетадан башлаганым юк иде, хәерле булсын»... — дип, укучыдан гафу үтенгәндәй генә башлый. Ләкин укучыдан гафу үтенеп кенә файда юк, Барлас Камалов үзенең очеркында, чыннан да, анкетадан ерак китә, Зөфәр Садретдиновның кабинетыннан чыга алмаган. Хикәя һәм повестьларының композиция сюжетларын оста кора торган, теле ювелир дәрәҗәсенә җиткереп эшли белгән язучы Барлас Камалов очеркларга килгәндә, ни өчендер, гафу ителмәслек хөрмәтсезлек күрсәтә. Ахры, бу аның очеркларга икенче, өченче сорт жанр дип кенә каравыннан килә торгандыр.

Мин КамАЗ турындагы очеркларга озаграк тукталдым. Чөнки КамАЗ төзелеше хәзер бөтен илебезгә билгеле. Ул язучылардан да үзенә аерым игътибар сорый, анда эшләүче кешеләрнең тормышларын, омтылышларын даими яктыртып баруны таләп итә.

Моннан унбиш-егерме еллар элек язучылар күбрәк тасвирый очеркларга мөрәҗәгать итә торганнар иде. Соңгы елларда очерк-портретлар күбәеп бара. Бу соңгыларының гадәти юл язмаларыннан беркадәр өстенлекләре дә бар кебек. Юл язмаларында, ягъни тасвирый очеркларда, автор күргән-белгәннәрен, ишеткәннәрен үтеп барышлый гына сурәтләп китсә, очерк-портретларда ул аерым кешеләрнең тормышына тирән кереп, аны нык өйрәнеп, белеп яза. Журналның быелгы саннарында нәкъ менә шундый очерклар өстенлек итә. 4 нче санда Валентина Гудкованың «Профессор Мөштәри һәм аның мәктәбе», Марсель Зариповның «Диссертация» исемле очерклары, 5 нче санда шул ук М. Зариповның «Тылсымлы нур» исемле очеркы басылган. 6 нчы санда Малик Хәмитовның «Бәхетле язмыш», Мәгъсүм Насыйбуллинның «Прокурор», Зәки Әхмәтҗановның «Герой каберендә чәчәкләр» исемле очерклары белән очрашабыз. Боларның һәркайсы очерк-портрет жанрына карый.

Күрәсез, очерк-портретлар бик күп. Журналга кергән 14 очеркның 7 се шул төркемгә карый. Һәм шушы 7 очеркның 4 се галимнәр турында. Дөрес, галимнәр турында да язарга кирәк. Ләкин шунысы күңелне борчый, журналның быелгы саннарында авыл хуҗалыгы турындагы очерклар бөтенләй диярлек очрамый. Шулай ук безнең укучыларга күрсәтерлек кыр батырларыбыз, механизаторларыбыз, алдынгы терлекчеләребез юкмыни? Яки авыл кешеләре алдына куелган зур бурычлар, хәл итәсе проблемалар беттемени? Кая бездә авылны тирәнтен белүче язучылар? Моннан унбиш еллар элек, нефть районнарында яшәүче яшь

язучылар алдында чыгыш ясап Ибраһим Гази болай диган иде:

«Сез нефтьне хәзер әйбәт чыгара беләсез. Сезнең бораулаучыларыгыз да шәп эшли, вышкачыларыгыз да буровойларны дөрес утырталар, алдынгыларыгыз да күп. Гомумән, сез нефтьчеләр турында яза беләсез. Ләкин алфавитта 38 хәреф бит. Сезнең алфавитта «Н» хәрефе бар — нефтьчеләр. «Т» хәрефе дә бар — техника. Ә кая сезнең «А» хәрефегез? Әйтик, аш пешерүчеләрегез, артистларыгыз. Кая «б» хәрефегез? Больницаларыгыз, балалар ясельләре, библиотекаларыгыз... «В» хәрефегез, «Г» хәрефегез, «У» хәрефегез кая?..»

Моның белән нәрсә әйтәсем килә? Безгә, очеркистларга, колач киңлеге җитми. Тематикабыз шактый тар. Әйтик, шул ук КамАЗ төзелешендә дә әйбәт ташчыларыбыз, буяучы-штукатурчыларыбыз бар. Ә без аларны онытабыз. Безгә хәзер КамАЗдагы башка төр профессия кешеләре, шунда ук хезмәтләре белән автозавод салучыларга турыдан-туры булышучы, аш пешерүче, җырлаучы-биюче һәм төзелешнең гыйльми эшләрен алып баручы кешеләр турында да язарга кирәктер. Мәрхүм И. Гази сүзләрен искә төшерсәк, күрербез: бу — бер КамАЗ кешеләренә генә дә кагылмый.

Инде килеп, журналдагы калган очерклар хакында берничә сүз. Мин монда Мәгъсүм Насыйбуллинның «Прокурор» очеркын аеруча уңышлы дип әйтеп китәр идем. Очеркның беренче юлларын укыга шикләнеп тә куясың: «Ходаем, бу инде тагын детектив нәрсә алган да, безне суд һәм прокуратура эшләренең «баш җитмәс», четрекле вакыйга-хәлләренә кертеп адаштырмакчы буладыр», дисең. Ләкин үз очеркында Насыйбуллин мәсьәләгә сак килә. Укучыны әкрен генә прокурор Шәйхетдиновның холкы, гадәтләре, характеры белән таныштыра. Безне прокурорлар турындагы ялгыш фикерләребездән арындырырга тырыша һәм шуны уңышлы гына башкарып та чыга. Күрсәнә, прокурор да кеше икән, ул әнә күршедәге егет булып җиткән малайның иптәшләре белән аралашмыйча, беркая чыкмыйча, хәтта кызлар янына да бармыйча, моңаеп утыруын сизә. Егетнең күзенә тумыштан ак сауган икән. Прокурор моны бер вакытта да, хәтта командировка белән республика прокуратурасына килгәндә дә истән чыгармый, һәм соңыннан, аңа ярдәм итеп, егетне бу мәңгелек хәсрәттән коткара. Дөрес, бу очеркта прокурорның үз вазифасыннан тыш эшләгән бары бер генә яхшылыгы яктыртыла, калган яхшылыклары җинаятьне табуда расланa. Ләкин шушы деталь әсәрне детектив булудан коткара, әдәби очеркка тартым итә.

Марсель Зариповның «Диссертация» очеркы бик кызыклы язылган. Бер карагандa, ул галимнәр турындагы очеркка охшый. Чөнки монда Зариповның төп герое — райком секретаре — кандидатлык диссертациясе яклый. Очеркның төп сюжеты да шул диссертациянең эчтәлеген ачып салуга корылган. Ләкин төп игътибарны автор диссертациянең үзенә түгел, бүгенге колхоз авылы проблемаларына юнәлдерә. М. Зариповның журналга кергән һәр ике очеркы әйбәт тәэсир калдыра. Автор, дөреслекне эзләп, укучы белән, персонаж белән, хәтта үз-үзе белән бәхәскә керә, шуның белән укучыда очеркка карата кызыксыну уята.

Бая әйткәнемчә, портрет-очерклар аерым кешеләрнең тормышын тирәнтен яктыртулары ягыннан отышлы булсалар да, алар кайнап торган тормыштан аерым бер кешене генә «суырып» алалар. Шул яктан шактый оттыралар. Башлыча автор, бер кешенең генә биографиясенә игътибар биреп, персонаж тирәсендәге мохитны, аның белән бәйле вакыйгаларны, дөньяны оныта. Ул гына да түгел (монысы бәләнең иң зурысы), әсәрдә җанлы, чын кешенең үзен хәрәкәттә күрсәтеп бирү урынына, аның биографиясен сөйләп бирү юлына баса. Монда инде очеркны Марсель Зариповның эрудициясе дә, Малик Хәмитовның оста корган композициясе дә, Валентина Гудкованың кешене тирән өйрәнеп язуы да коткармый.

Очерклар турында сүз чыккач, тагын шуны да әйтергә кирәк, очерк та, башка әдәби әсәрләр кебек үк, теләсә нинди материал җирлегендә язылa алмый. Ул бүгенге тормышыбызның, Фатих ага Хөсни әйтмешли, кайнап, бөтерелеп торган урыныннан гына табыла. Юкса, соңгы вакытларда очеркистлар, материал очерк өчен яраклымы-юкмы, аны тикшереп тормыйча, күзләренә ни бәрелсә, шул турыда, юлларында кем очраса, шуның турында яза башладылар. Бер карагандa, алынган кешесе дә әйбәт кебек, аның гыйльми дәрәҗәсе, тоткан посты да зур, орден-медальләре дә күп. Ләкин бер

нәрсә юк — очерклык материал, әйтер сүз, вакыйга, язмыш. Димәк, теләсә кем турында, теләсә нәрсә турында очерк язарга ярамый икән.

Шушы уңайдан әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләргә дә бер-ике сүз әйтеп китәсе килә. Безнең татар очеркларының тарихы зур, ул — безнең бөтен прозабызның бабасы. Рус әдипләре үз прозаларын, әйтик, 15 гасырда Һиндстанга сәяхәт иткән Афанасий Никитинның «Өч диңгез артына сәяхәт» исемле очеркыннан башлап китәләр икән, без дә үзебезнең прозаны Исмәгыйль Бикмөхәммәтовның 1762 елда Һиндстанга сәяхәте вакытындагы юл язмаларыннан башлана дип әйтә алабыз. Ә 18 гасырның батыр сәяхәтчесе Гобәйдулла Әмировның Һиндстан очерклары 1825 елда рус телендә дөнья күрә. Заһир Бигиевнең 1893 елда чыккан сәяхәтнамәсе, Каюм Насыйри язмалары, башка бик күпләрнең матур-матур сәяхәтнамәләре һәм, соңгырак чорларга килсәк, Сафа Борһан, Гомәр Гали, Муса Җәлил, Гадел Кутуй очерклары кемнәрне генә сокландырмый икән. Шушындый зур очерк тарихыбыз була торып та аны белмәү, аны халыкка җиткермәү — гафу ителмәслек сүлпәнлек. Ул гынамы соң, кайсы тәнкыйтьче бу көнгә кадәр очерклар турында бер төпле сүз әйткәне, я булмаса, матбугатта чыгыш ясаганы бар? Очерк әле хәзер дә ятим жанр булып кала бирә.

Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият һәм сәнгать тәнкыйте турында» күптән түгел чыккан карары заманыбызның иң алгы позициясендә көрәшүче очерк жанрына да тәнкыйтьчеләрнең игътибарын юнәлдерер дип ышанасы килә.

# АРГАМАКЛАР ЮЛДА АРМАСЫН

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов поэзиягә «кыңгыраулар таккан атлар» белән җилдереп килеп кермәде. Туган ягының яшел тугайларында көтү көткән, нефть каласы Әлмәттә яңа йортлар төзешкәндә ташлар күтәреп беләкләре талган бу егет үзенең хис һәм тойгыларын кәгазь битләренә башкаларга сиздермичә генә күңерде, язганнарын газета һәм журнал редакцияләренә кыяр-кыймас кына юллады. Кулына корал тотып, Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә, ил һәм халык алдында үзен тагын да җаваплырак итеп тою, авыр походларда һәм хезмәттә җырның иң тугрылыклы юлдаш икәнлеген аңлау, Казан дәүләт университетында укып, югары белемгә ия булу аның күзләрен ачып, иҗат офыкларын киңәйтеп җибәрде. Шуннан соң аның шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә, коллектив җыентыкларда торган саен ешрак күренә башлады. Беренче җыентыгының поэзия сөючеләр тарафыннан җылы кабул ителүе яшь шагыйрьнең күңеленә яңа канатлар өстәде, аны элеккегә караганда да тырышыбрак, дәртләнебрәк иҗат итәргә рухландырды.

Күптән түгел Татарстан китап нәшрияты Рәшит Әхмәтҗановның «Ак канатлар»[1] исемле яңа җыентыгын бастырып чыгарды. Җыентык авторның лирик хисләр белән сугарылган сиксәнгә якын шигырен эченә ала. Шагыйрь озын язарга, кайбер яшь әдипләребез шикелле, кирәксе-кирәкмәсә дә, образлар һәм детальләрне катлауландырырга, җөмләләр матур булсын өчен генә сүз уйнатырга яратмый. Шигырьдә әйтергә теләгән фикерен ул үзенә генә хас булган сурәтләү чаралары ярдәмендә нагрузкалы, тыгыз юлларга сыйдырырга тырыша. Бу хакта шагыйрь җыентыкны ачып җибәргән «Керләр чайкый әнкәй» дигән шигырендә үзе дә бик дөрес искәртеп үтә:

Керләр чайкый әнкәй, кырләр чайкый,
Уе китә сулар төбенә.
Әйтерсең ул шулай диңгез айкый,
Телбизәкләр эзләп телемә.

...Тел югалтса егет — ил югалткан,
Сүз югалтса — иле оялган.
Ә чын сүзләр безнең иреннәрдә
Ничә кабат канга буялган.

Шагыйрьнең әнә шундый чын сүзләрдән тукылган шигырьләре укучыны битараф калдыра алмый, аны уйланырга, үзенең үткәненә, бүгенгә һәм иртәгәсе көненә аек акыл белән карарга мәҗбүр итә. «Юк озатмыйм», «Уем тирән», «Сугыштан кайталмаган егет сүзләре», «Кошлар очып уза», «Тайгадагы учак», «Мәңгелекне дәвам итәбез», «Әй, сеңелем» кебек шигырьләрендә Рәшит Әхмәтҗанов тормыштагы төрле хәлләрне кешеләр йөрәгә аша уздырып тасвирлый. Менә шуңа күрә дә ул шигырьләр күңелгә үзләреннән-үзләре агып керәләр, хәтергә тирән уелып калалар. Шагыйрь күп кенә очракларда үзе белгән, үзе

[1] Рәшит Әхмәтҗанов. Ак канатлар. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1972. Тиражы 3000. Бәясе 22 тиен. Редакторы М. Хәсәен.

күргән һәм беренче карашка кечкенә булып тоелган бер вакыйганы тотып ала да, шуңа таянып, зур гомумиләштерү көченә ия булган олы фикер әйтә. Менә бер мисал. Сазлыклар ерып килә-килә арган юлчылар, ял итәргә туктагач, агач төбенә учак ягалар. Учак, ялкыннарын өскә үрләтеп, шактый озак яна. Ләкин кинәт һәркемнең йөрәген әрнеттереп, өстә ниндидер кошчыкның үз-үзен кая куярга белмичә, шашынып-ярсынып агач ботакларына бәргәләнә башлавы лирик геройның бәгырен телгәли. Һич көтмәгәндә күз алдына килеп баскан бу фаҗигале күренешнең сәбәбен автор җанны тетрәндерерлек итеп ике-өч строфада әйтеп бирә:

И, Сандугач, хәсрәтеңне
Әйтә күрмә дусларыма.
Үзем генә йөрәгемне
Кысыйм салып учларыма.

Кайгыларың коелмасмы,
Ела, кошчык, кагын, очын!..
Бу агачта оя́ң булган,
Балаң янган, сандугачым.

Шигырьне шушы урында тәмамларга да бик мөмкин булган булыр иде. Әмма шагыйрьнең әле әйтеп бетерәсе, башкаларның да колагына ишеттерәсе тагын берничә гыйбрәтле сүзе-киңәше бар. Ул сүзләрен автор шигырьдәге фикерне тагын да көчәйтү, тәэсирлерәк итү өчен ахыргы строфага калдыра:

...Соңгы күмер, утлы күзләр
Булып миңа гел карыйсың...
Сандугачлар янган утта
Җылынырга ярыймы соң?!

Уйлана, фикер йөртә белгән кешегә бу юллар бик күп нәрсә турында сөйли. Афоризм булып яңгырарлык мондый канатлы сүзләрне Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләрендә шактый күп очратырга мөмкин. Аның бу җыентыкка кергән шигырьләрендәге «туган җирдә дошман каберләре... каберләрдән ирләр үч алмый», «сезнең җанда кояш бар шикелле, күңелегездә сезнең таң алды», «үзебезгә безнең сиздермичә, безне дә бит утка ягалар», «кыюлар ятып еламый кешеләр йөрәгенә», «туган илгә кайтыр аккошларга тамчылап күл җыя сагышым», «туган илдә кызлар җырламаса, егетләргә гомер нәрсәгә», «ак канат биргән идең дә, каралтты аны кайгым», «далаларны узгач, диңгез табыла безнең кебек йөргән юлчыга» шикелле тирән мәгънәле җөмләләрне истә калдыру өчен аларны кат-кат укып торасы юк. Бер тапкыр уку белән алар үзләре үк тел очына эленеп калалар. Әйе, Рәшит Әхмәтҗанов сүзнең кадерен белә, аның зур көчкә ия булуын яхшы аңлый һәм тел белән бик сак эш итә.

Шагыйрьнең кайбер каләмдәшләре арасында: «Ник соң ул зуррак күләмле әсәрләр тудыру өстендә эшләми икән?» — дигән сорауны ишетергә туры килә. Бер карaганда, бу сорау урынлы да кебек. Әмма, тәптәнрәк уйласаң, Рәшит Әхмәтҗановның озын язарга үз-үзен көчләп мәҗбүр итмәве һич тә гаҗәп түгел. Кайберәүләр гомуми сүзләр тезмәсеннән торган шигырь юлларын дилбегә буе сузып та әйтеп бирә алмаган тегe-яки бу фикерне ул өч-дүрт строфада ачып бирергә тырыша. Хәзергә аңа, барыннан да элек, шигырьнең төп үзенчәлеген аңлап эш итү — үзенең якса лирик геройның хис һәм кичерешләрен оста тотып алынган поэтик детальләр аша укучы күңеленә җиткерә белү кыйммәт. Шигъри осталыкка өйрәнгән һәм җитәрлек тәҗрибә туплаган әдипнең киләчәктә зуррак күләмле әйбәт әсәрләр тудырырга да көченнән килер. Җыентыкта урын алган «Уем тирән», «Балаларын эзли аналар», «Вожатыйлар», «Бәйрәм» шигырьләре аның инде әнә шул юнәлештә кыю гына адымнар ясавы турында сөйли. Һәм бу юлда шагыйрьнең уңышка ирешәчәгенә шикләнмәскә мөмкин. Моңа аның көче дә, тырышлыгы да җитәрлек. Үз исеменнән сөйләп, бер шигырендә ул менә болай ди:

Ташлар белән үтә танышлык бар,
Берәүләрнең карап күзенә,
Сөйлим әле ташлар ярып тапкан
Дәреслекне салып сүземә.

Туган туфрак яшәү көче миңа,
Һәр граммы яшәү запасы.
Таулар биек диеп уфтанганның
Килми микән ташлар ватасы?!

Туган туфрагыннан яшәү көче һәм илһам алып, үзе әйтмешли, сүзенә тормыш дәреслеген салып иҗат иткән шагыйрьнең «Ак канатлар» җыентыгын зур канәгатьләнү белән укыйсың. Ләкин андагы шигырьләрнең бөтенесе дә бер үк дәрәҗәдә әйбәт эшләнгән, аларның берсенә дә тел-теш тидерерлек түгел дисәк, бу һич тә дәреслеккә туры килмәс иде. Китапта әле тиешле

кондициягә килеп җитмәгән, кәгазь битенә күчкәнчегә кадәр күңел җылысы белән җитәрлек сугарылмаган шигырьләр дә юк түгел. Андый шигырьләрне җыентыктан берәм-берәм чүпләп алып, авторның үзенә кире кайтарып бирәсе килә. Шома гына язылган булсалар да, «Инде без дә китәбез бит», «Карлар ява», «Кагылулар, сугылулар булса», «Нишләдең син, нишләттең син илем күгең», «Оял, дөнья, кодрәтеңне күргән күздән», «Бу далада эзләр, эзләр», «Яр сөйгәннәр моңлы була», «Гомер шулай инде, энем», «Аккош йоклаган су кебек тыныч идем», «Җәй. Кызу. Гөлләр күзендә...» дип башланып киткән шигырьләр Рәшит Әхмәтҗанов тарафыннан түгел, әйтерсең лә бөтенләй башка кеше кулы белән язылганнар. Поэзиядә моңарчы инде бик күп тапкырлар әйтелгән фикерләр кабатланганлыктан, ул шигырьләрдә шагыйрьнең үз тавышы кечерәеп, тоныкланып кала. Фикер ярлылыгы, фикер сайлыгы исә «илдә батыр булу әйбәт... кая барсаң, шунда, егет, батыр бул», «оныгсаң да, энем, мине, онытма син туган илне», дип башкаларга үгет-нәсихәт бирү белән чикләнүгә китерә. Билгеле булганча, маңгайга әллә каян бәрелеп торган коры сүзләр белән акыл бирүгә корылган андый шигырьләрнең хискә дә, акылга да тәэсире бик бәләкәй. Җыентыктагы әнә шундый уңышсыз шигырьләрне укыганда, безне бары тик бернәрсә юата: киләчәктә моның ише йомшак шигырьләрдән арыну өчен Рәшит Әхмәтҗановның тулы мөмкинлекләре бар. Бүгенге көндә аның иҗаты күтәрелеш, үсеш чорында. Алда аңа ләззәтле һәм газаплы кичерешләрдән соң туа торган берсеннән-берсе уңышлырак шигырьләр юлдаш булсын. Шагыйрьне поэзия дип аталган чиксез зур дөньяга алып чыккан «йөрәк бәйрәмнәренең кыңгырауларг таккан» аргамаклары ярты юлда арып калмасыннар.

**Рәшит ГӘРӘЙ.**

# МӘГЪРИФӘТ НУРЛАРЫ ЭЗЛӘП...

Нинди шартларда, кайсы факторлар тәэсирендә алдынгы татар җәмәгатьчелеге марксизмга таба борылыш ясады? Бу борылыш ясалу өчен нинди идеяләрнең таралуы һәм үсүе кирәк булды? Сәвия ханым Михайлова үзенең күптән түгел университет нәшриятында чыккан яңа китабында[1] әнә шул мәсьәләләрне ачыкларга тырыша. Шундый максат белән ул 1800—1861 еллар эчендә татар дөньясында алдынгы фикер үсешен, мәгърифәтчелекнең формалашу һәм үсү процессын тикшерә.

Китап авторның үзенең кереш сүзеннән, профессор Р. Нәфиковның кыскача мәкаләсеннән һәм 3 бүлектән тора. Бүлекләр «Казан университеты һәм аның татарларга, Идел буеның башка халыкларына мәгърифәт кертүдәге роле», «Хәлфиннәр семьясының мәгърифәтчелек эшчәнлеге» һәм «XIX гасырның 30—60 елларында алдынгы татар иҗтимагый фикере һәм аның татарларны агартудагы роле» дип исемләнгәннәр. Бу бүлекләрдә Сәвия ханым Михайлова бүгенге фән өчен зур әһәмияте булган күп кенә проблемалар куя һәм ышандырырлык дәлилләр, нык фәнни эзлеклелек белән аларны уңышлы хәл итә. Хезмәтнең кайбер өлешләре фәндә инде ачыкланган дип йөртелә торган мәсьәләләргә җитди генә яңалык та өстиләр.

Мәсәлән, моңа кадәр еш кына: татарлар революциягә кадәр бөтенләй надан яшәгәннәр, алар арасында бер-ике дистә генә югары белемле кеше булган кебек сүзләрне ишетергә туры килә иде. Ә С. Михайлова үзенең эзләнүләре нәтиҗәсендә 1804—1904 елларда гына да Казан университетында 92 татар студенты укыганлыгын раслый. 1905 елдан соң исә аларның саны тагын да күбәйгән дип уйларга кирәк. В. И. Ленин файдаланган хезмәтләрдә[1] дә татарлар арасында 1910 елга Россиядә югары белем алган — 200, ә Көнбатыш Европада югары уку йортын тәмамлап кайткан 20 кеше булуы әйтелә. Бу саннар, әлбәттә, патша Россиясендәге татарларның тормышын идеаллаштыру өчен китерелми. Фәнни белемле кешеләр, әлбәттә, аз булганнар. Ләкин халкыбызның культурасын өйрәнгәндә аның үсешендәге һәрбер фактка дөрес бәя бирү кирәк. С. Михайлова үзенең китабында әнә шундый объектив һәм фәнни карашны алга сөрә.

Монография мәгърифәтчелекнең формалашуы һәм үсүе патша самодержавиесенең дискриминация политикасы астында, феодаль-крепостнойлык строеның иң кыен шартларында барганлыгын эзлекле һәм тирән итеп ачып бирә. Аның татар мәгърифәтчеләренең үлемсез эшчәнлеген яктырткан битләре авторның: әнә шундый шартларда да алдынгы фикер үсеше буыннан-буынга күчә, көчәя бара, дигән фикеренә ышанычлы аргумент булып торалар. Алар укучыга А. Ваһапов, С. Кукляшев, М. Мәхмутов, Х. Фәезханов кебек укымышлылар һәм Хәлфиннәр турында бик күп файдалы материал бирә. Авторның фикерләренә кушылып, безнең тагын шуны әйтәсебез килә: В. И. Ленин рус мәгърифәтчелеген характерлаучы төп өч сыйфатны күрсәткән иде. Шуларның берсе — аң-белемне, азатлыкны, Россия тормышын һәрьяклап европалаштыруны кайнар яклау. Мәгъри-

---

[1] С. Михайлова. Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья. Изд. КГУ. 1972.

[1] В. И. Ленин. Полн. собр. соч. Том 28. Стр. 514.

фәтчелекнең бу сыйфаты XVIII гасыр татар җәмгыятендә дә ап-ачык күренә. Китапта күрсәтелгәнчә, С. Хәлфин — шул хәрәкәтнең күренекле вәкиле. 1797 елда аның фикердәшләре Екатерина комиссиясенә наказ итеп менә нәрсә яздылар: «Кем табигате буенча нәрсәгә омтылса, ул шуңар сәләтле: һәр дәрәҗәдәге кеше иген игүгә күнегергә мөмкин, шулай ук башкалар үзләрен сәүдә өлкәсендә файдалана алалар. Кешенең **туганнан** бирле **азатлыгы** һәрберендә рухи тынычлык булдыра, ул **имин** тормышны **көчләү** юлы белән түгел, ә үз **ирке** белән табарга тиеш»[1]. (Курсивлар безнеке.) Бу сүзләр крепостнойлыкны куралмаучылар тарафыннан феодаль бәйлелеккә каршы, В. И. Ленин әйткәнчә, Россия тормышын европалаштыруны һәм халык азатлыгын кискен рәвештә таләп итеп язылган иде. Димәк, алардан күренгәнчә, Россиядә крепостнойлык чәчәк аткан вакытта шәхси иминлек таләп итүче татарлар үзләренең «туганнан бирле азат» кеше булуларын яхшы аңлаганнар.

XVIII гасырның икенче яртысында татар җәмәгатьчелегендә мәгърифәтчелекнең башка сыйфатлары да шактый үскән. Шуларның берсе — фәнни белемнәр тарату. Бу өлкәдә эшләгән кешеләр турында да китапта кызыклы материаллар бар. Мортаза Тәвкилев 1754 елда Абулгази Баһадир ханның «Монголлар һәм татарлар тарихы» дигән әсәрен тикшерә. Ул әсәрнең Петербург һәм Мәскәү нөсхәләрен чагыштырып чыга һәм фәнни искәрмәләр бирел бара. Уфа губернасы Күккуян авылы имамы Нигъмәт олан ибне Мәксүт шул тарихның 1772 елда күчерелгән нөсхәсеннән үзенә күчермә эшли. Әстерхандагы татар мәктәбе мөдәррисе Ахун-Ходжа аның бу күчермәсе ахырына үз искәрмәләрен язып куя. Халык арасында таралган мондый тарихи материалларны галимнәр, әлбәттә, дөньяга чыгарырга тырышканнар. С. Михайлованың бу китабында күрсәтелгәнчә, Абулгази тарихы да И. Хәлфин тарафыннан 1825 елда беренче мәртәбә бастырылып чыгарыла.

Дәүләтнең милли-колониаль изүе көчле, крепостнойлык режимының юк диярлек булуы татар мәгърифәтчелеге үсүенә бераз башкарак төсмер биргән. Шуңа күрә без әдәбият тарихына күз салсак та, анда крепостнойлыкка каршы ялкынлы публицистик чыгышларны һәм башка әсәрләрне аз күрәбез. Сүз уңаенда, авторның бер тезисына карата, үз фикеребезне дә белдереп китик. XVIII—XIX гасырларда, бармак белән генә санарлык дворяннардан һәм бүтән сословиеләргә чыккан сирәк кенә кешеләрдән башка, барлык татарлар да — ясаклылар да, йомышлылар да (шулар эченнән сәүдәгәрләр, муллалар һ. б.) — «податный оклад»ка яки җан башыннан налог түләүче дәүләт крестьяннары рәтенә кертелгәннәр. Завод хуҗасы һәм бургомистр булуына карамастан, Мөхәмматрәхим Хәлфин дә шул ук податный окладта булган. Податный окладтан төшереп калдыруны яки кешенә икенче урынга күчерүне бары тик сенат кына эшли алган. Ревизияләр 15—20 елга бер генә булып торганлыктан, аерым кешеләрнең подать түләүче общинадан чыгуы озак елларга сузыла торган була. Мөхәммәтгали Мәхмүдовның общинадан чыгуы белән дә шулай килеп чыга. Ләкин бу хәл һич тә крепостнойлыкны аңлатмый. Мондый феодаль бәйлелек барлык дәүләт крестьяннарына да таралган иде.

Сәвия ханым Михайлованың бу китабындагы һәрбер бүлек бик күп файдалы материалга бай, алар укучыда зур кызыксыну тудыралар, белемен киңәйтәләр. Кайбер моментлар иске карашларны яңартып кына калмыйлар, ә бәлки тулы бер яңа проблемаларны ачып салалар. Мәсәлән, декабристлар хәрәкәтендә татарларның катнашуы турында моңа кадәр тарихта бөтенләй билгеле түгел иде диярлек. Иптәш Михайлова татарларның әнә шул бөек вакыйгалардан читтә калмавы, аңа турыдан-туры катнашулары турында кызыклы фактлар китерә. «Чыгышы буенча татар» А. А. Бурнашев «Төньяк җәмгыяте»нең составына кергән һәм 14 декабрь көнне восстание алдыннан К. Рылеевта үткәрелгән киңәшмәдә катнашкан. Рамазан Семенов 14 декабрь көнне восстаниедә булган, яраланып кулга эләккәч, Петропавел крепостена ябылган. Көньякта баш күтәргән Чернигов полкында, Муравьев-Апостолга якын торган Галеев Фамилят кебек кече татар офицерлары, М. Баязитов, Ф. Заитов, И. Биктимеров кебек рядовойлар булган.

XIX йөзнең 60 елларында Казанда татар студентларының революцион хәрәкәте турында язып та автор тарихның яңа бер сәхифәсен ачкан, диясе килә. М. Ниязовның татарларга рус телен өйрәтү өчен мәктәп ачу турындагы 1821 елгы проект материаллары, Исмәгыйль һәм Шагин-Гәрәй Хәлфиннәрнең укытучылык эшчәнлек-

[1] Сборник Русского Исторического Общества — 115, стр. 375.

ләре турында белешмәләр, Ибраһим Хәлфинның татарлар арасында беренче буларак мәгърифәтчелек идеяләрен формалаштыруы һәм шуларны тормышка ашыру өчен бөтен гомере буенча тырышуы турындагы битләр, XIX гасырның 60 елларындагы революцион хәрәкәт турында тарихта яктыртылмаган яңа материаллар — болар барысы да С. Михайлова хезмәтенең әһәмиятен нык арттыралар. Китапта китерелгән мондый фактлар, гомумән алганда, XIX йөзнең беренче яртысында татарлар арасында алдынгы фикер үсеше өчен җирлек булганлыгы һәм алдагы революцион көрәшләр өчен тәҗрибә туплау икәнлеге турында да сөйлиләр.

Язманың ахырында тагын бер нәрсәгә тукталасыбыз килә. Ул — «беренче» сүзен куллану турында. Автор үз китабында бу сүзне саграк кулланырга чакыра, чөнки берәр кешегә карата «ул беренче булган» дип әйтү, аңа кадәр бу эш бөтенләй булмаган дигән сүз. Шул ук таләптән чыгып караганда, безнең дә авторга берникадәр дәгъвабыз бар. Китапта «Сәгыйть Хәлфин татар теленең беренче дөньяви укытучысы иде» дип әйтелә. Хәлбуки, татар теленең аңарчы да дөньяви мәктәпләрдә укытылу фактлары, XVIII гасырның беренче яртысында ук татар теле буенча махсус мәктәпләр булуы да билгеле. Бу чорның безгә кадәр килеп җиткән эш кәгазьләре, васыятьнамәләре, Пугачевка кушылган крестьяннарның үз куллары белән язылган төрле язмалар — барысы да татарча, халык теле белән язылганнар. Аларда гарәп, фарсы сүзләре аз очрый. Бу факт бездә шундый уй тудыра: димәк, татар теле азмы-күпме күләмдә ул вакытта ук мәктәп-мәдрәсәләрдә укытылган. Шуның өстенә, XVII—XVIII гасырда татар теле Россиягә көнчыгыш илләре белән аралашу коралы булып хезмәт иткән, ә моның өчен илгә татар телендә укый-яза белүче чиновниклар кирәк булган. Шундый мәктәпләрнең берсен XVIII гасырның 30 елларында В. Н. Татищев оештыруы, анда татар телен Әстерхан «галим ахуны» укытуы мәгълүм. Ә 1740 еллардан башлап Уфада һәм Оренбургта «Татарская школа» эшләгән. Анда татарча укырга, язарга һәм русчадан татарчага тәрҗемә итәргә өйрәтүне максат итеп куйганнар. Гасырның икенче яртысында инде татар теле 20 гә якын уку йортында укытыла торган булган. Монда тагын шуны өстәргә кирәк. С. Хәлфин үзе дә татар телен мәдрәсәдә укып өйрәнгән һәм аның китабын да «Казан имамнары карап хуп күргәннең соңында» гына чыгарганнар.

Китапта тагын, А. Ваһапов Казан татарларының телен мөстәкыйль тел дип санап, аны өйрәнүгә **беренче** буларак әһәмият бирде дип әйтелә. Ә бит Казан татарларының телен мөстәкыйль дип санау XVI гасыр чыганакларыннан ук күренә (С. Герберштейн, А. Курбский). XVII—XVIII гасырның официаль документлары Казан татарларын «татар» дип йөртелгән башка этник группалардан (безнең санау буенча 20 дән артык исемдәге татарлар булган) һәр вакыт аерып йөртәләр.

Күргәнебезчә, автор үзе дә «беренче» сүзен кайчагында урынсызрак куллана.

Ләкин аңа да карамастан, Сәвия ханым Михайлова бу китабы белән үзенең армый-талмый эзләнүче яшь галим икәнлеген күрсәтте. Аның хезмәте — культурабыз, иҗтимагый фикер тарихын һәм гомумән тарихыбызны өйрәнүгә зур өлеш.

**Сәлам АЛИШЕВ.**

# ЕГЫЛМАС ИНДЕ СЫНАЛГАН ҖАН...

*Шагыйрь Яков Емельяновның тууына 125 ел тулу уңае белән*

Яков Емельянов исеме киң катлау татар укучыларына 1935 елда, аның кайбер шигырьләре «Совет әдәбияты» журналында (9—10 саннар) басылып чыккач кына мәгълүм булды. Керәшен татарлары арасында исә аның иҗаты инде XIX гасырда ук шактый популяр булган. Алар үз араларыннан чыккан шагыйрьне, олылап, «җырчы Җәкәү» дип йөрткәннәр. Әлбәттә, халыкның шагыйрьне шулай үз итүе юкка гына булмаган. Я. Емельянов әсәрләрендә халык үзенең иң тирән хисләре: авыр тормышка, социаль тигезсезлеккә карата нәфрәте һәм киләчәк якты көннәргә булган ышанычы сурәтләнүен тойган. Шагыйрьнең поэзиядә билгеләгән урынын билгеләп, әдәбият галиме Хатип ага Госман бик хаклы рәвештә болай дип яза: «Аның әсәрләрендә халыкның социаль тигезсезлеккә каршы күтәрелгән стихияле ачу тойгысы гәүдәләнде. Чиркәү Емельяновны электән килә торган татар язма поэзиясе традицияләреннән аерып куйды. Аның каравы, Емельянов татар халкының борынгыдан килә торган авыз иҗатыннан, телдән әйтелә торган поэзиясеннән, тирәнрәк чумырып, бай традиция алды, бу поэзиядә башка шагыйрьләр күрә белмәгән яңа мөмкинлекләрне ачты, ачыграк әйткәндә, татар иркле шигыренең орлыгын табып чыгарды һәм үстерә башлады».

...Яков Емельянов 1848 елда хәзерге Балык бистәсе районының Алан авылында туа. Алан ул вакыттагы татар авылларыннан бер ягы белән дә аерылып тормаган диярлек. Һәр күңелле, җор табигатьле Алан кешеләре, кара казакиләрен, пима-эшләпәләрен, ак туналарын киеп, кичләрен җыенга чыга торган булганнар. Яшьләре түгәрәк уеннары оештырган. Картлары, өй нигезләренә тезелеп утырып, аларның читтән генә күзәтеп торган булганнар. Шундый җәйге җыеннарда көйгә салып бәетләр җырлаган, сүз осталары әкиятләр сөйләгән, мир картлары халык риваятьләрен искә төшереп, аларны яшьрәк буынның хәтеренә сеңдереп калырга тырышкан.

Яшь Яков әнә шулай халык җырларын, авылдашлары арасында таралган әкият, легендаларны ишетеп үсә, шул чакта ук аның йөрәгенә соңыннан туачак ялкынлы шигырьләренең орлыклары салына башлый. Ләкин усал язмыш бу орлыкларга шытып чыгарга юл куймый. Тугыз яше тулар-тулмас Яковны, көчләп, удельное училищега бирәләр.

— Елама, тиле, менә күрерсең Җәкәүеңнән болыч писаре ясап кайтарырлар,— дип «юата» Яковның әнисен авыл старостасы. Мамадыш өязенең Җүкәче авылындагы волость писарьләре әзерли торган бу училищега Яковның үзенең артык исе китми. Училищены тәмамлагач, бер авылдашы аннан:

— Я, Җәкәү, хәзер кем булырга уйлыйсың? — дип сорый.

— Авылыма кайтам, укытучы булырга телим,— ди Емельянов.

Мондый җавапка теге хәйран кала: ничек инде укытучы? Әлифбасын онытып бетергән Алан кешеләрен ничек укытмак кирәк?!

— Әйе,— дип дәресли Яков.— Үзем ише авыл малайларын укытырга телим.

Ләкин аның бу изге нияте тормышка ашмый кала. Зур эшне юлга салырга ярдәм итәрдәй кешеләр табылмый. Алай гына да түгел: «укытырга документың юк» дип, аның үзенә дә адым саен каршы төшәләр. Ләкин, үзе мәктәп ача алмаса да, Яков Емельянов ул чагында инде халыкка белем бирү өчен тырышучыларның барлыгын белә. Яковны барыннан да бигрәк керәшен татарлары өчен укытучылар хәзерли торган Тимофеев мәктәбе үзенә тарта. Чөнки аңа укыту өчен документ кирәк. Шундый максат белән, 1864 елда Яков Емельянов, Казанга килеп, Тимофеев мәктәбендә укый башлый. Укытуның саф татар телендә булуы, егетләрнең һәм кызларның бергә укулары белем алуга күптән сусаган Яковка башка нык ошый. Бирердә ул ана телендә язарга өйрәнә, үз телендә чыккан китапларны күрә.

Тора-бара ул үзе дә шигырьләр язгалаган һәм русча китаплар чыгарган Тимофеев белән дуслашып китә. Емельянов аның аркылы заманның күренекле кешеләре: казакъ мәгърифәтчесе Алтынсарин һәм татар галимнәре Фәезханов, Хәлфин, Насыйриларның хезмәтләре белән таныша. Алар яшь шагыйрьнең дөньяга карашын киңәйтәләр, аны иҗат эшенә рухландыралар.

Тимофеев мәктәбе бер Яков өчен генә түгел, анда укучы башка бик күпләргә дә заманның алдынгы карашлы кешесе булып формалашырга булыша. Яков Емельяновның сабакташлары арасыннан удмурт әлифбасын төзүче Борис Гаврилов, казакъ далаларында беренче мәктәп ачучы Игнатий Тимофеев кебек мәгърифәтчеләр чыгуы бер дә гаҗәп түгел. Патша хөкүмәтенең ныклы күзәтүе астында торуына, тикшереп китүчеләр тарафыннан «самодержавие рухында тәрбияләү» яхшы бара дип бәя алуына да карамастан, Тимофеев мәктәбенең шундый алдынгы карашлы укымышлылар чыгара алуы игътибарга лаек, әлбәттә.

Ниһаять, Яков Емельянов морадына ирешкән кебек була. 1869 елда ул укытучы булып туган ягына — Урей Чаллысы авылына кайта. Ләкин бирердә дә Емельянов иркенләп эшләп китә алмый, аның эшчәнлеген хөкүмәтнең 60—70 елларда бик көчәеп киткән руслаштыру политикасы бүлә. Бу елларда Ильминский кебек патша ялчылары нечкәртелгән методларга күчәләр — татарларның үз араларыннан руханилар хәзерләргә керешәләр. 1874 елда Яков Емельяновны да Казанга чакырып алып, Духовная академиягә керергә кыстыйлар. Емельянов бу академиягә керә һәм аннан дьякон булып чыга. Ә 1880 елда ул инде протопоп була.

Билгеле, аның югары дин әһеле булып китүен, чиркәү белән тулысынча килешүе дип аңларга ярамый. Емельянов үз чорындагы иҗтимагый тәртипләр белән, чиркәү белән канәгать була алмый. Аның урыннан-урынга күчеп йөрүе дә шул турыда сөйли. 70 елларда ул Вятка губернасының керәшен авылларында эшләсә, соңга таба Мамадыш өязендәге Чура авылына күчә. Озакламый Тәңкәгә, аннары Шомыртбашка килә. Ә үләр алдыннан, руханилыкка бөтенләй кул селтәп, яңадан Урей Чаллысына укытучы булып кайта. Бу елларда шагыйрь күңелендә кайнаган хисләр турында «Ярлы тормыш», «Әләк», «Олысыманлык» һәм «Саран бай» шигырьләре бик ачык сөйлиләр. Ә Татарстан Үзәк архивының Ильминский фондындагы доносларда күренгәнчә, Яков Емельянов «каһәрләнгән поплар» исемлегенә кертелгән була. Менә бу шигырен шагыйрь шундый доносларны күздә тотып язган, күрәсең:

Тор гадел,
Йөр шиксез,
Бул изге,
Кыл яхшы,
Уйла туры,
Сөйләш чын —
Буяр әләк!
Кайгыр, көен,
Интек, инәл,
Җыла, тилмер,

Уйла, шәйлә,
Уеңны җәймә,
Телеңне бәйлә —
Ябышыр әләк!
Каладан — илгә,
Җирдән — сугә,
Суыктан — утка,
Төшлектән — төнгә,
Таудан — атауга —
Куч, кая —
Табар әләк!
Шушы яман
Тинтәк башлы,
Иң акылсыз
Чак каргадан
Бик тизеннән
Котылмасак —
Итәр харап!

Ләкин шундый гыйбрәтле сүзләрне әйтә алган шагыйрь үзе мондый кабахәт атмосферадан котылу юлларын таба алмый. 1893 елның 2 февралендә әле 45 кә дә җитмәгән килеш Урей Чаллысында үлеп китә. Аны җирләргә, табуты янында бәш иярга ерак-ерак авыллардан бик күп кеше килә.

Хәзер безне шундый сорау кызыксындыра: ә шагыйрь шигырьләренең язмышы ничек соң? Алар Яков Емельянов үзе исән чагында халыкка барып җитә алганнармы?

Яков Емельяновның беренче шигырьләр җыентыгы 1867 елда оештырылган «Братство св. Гурия» җәмгыяте тарафыннан рус хәрефләре белән басылып чыга. Шуңа күрә гарәп шрифтында укучы татарлар бу китап белән үз вакытында таныша алмыйлар. Ә чиркәү җыентыкның татарларны дин рухында тәрбияләүгә бернинди файдасы булмаганлыгын тиз аңлый. Казан епархиясе викарие шагыйрьнең бу җыентыгы турында «керәшеннәрнең аңын уятып, аларның татарлык хисен генә көчәйттә» дип яза.

Әлбәттә, мондый сүзләрдән соң, Яков Емельяновның 1884 елда икенче җыентык чыгару теләге тормышка ашмый — китап тулысынча конфискацияләнә. Шагыйрьнең иҗатын тикшергән А. Н. Григорьев сүзләренә караганда, бу җыентыкта:

Балкы, кояш, ялтыра!
Җирнең йөзе яңарсын.
Иртәнге кырау, соңгы салкын
Ашлык төшеп алмасын...—

рухындагы, якты өмет белән сугарылган шигырьләр дә булырга тиеш. Кызганычка каршы, әлегә кадәр бу җыентыкның табылганы юк. Ләкин А. Н. Григорьевның анда көчле оптимистик шигырьләр булырга тиеш дигән фикере, һичшиксез, дөрес. Чөнки тормышының соңгы елларында Яков Емельянов, дин юлын ташлап, чын мәгънәсендә халыкка хезмәт итә башлый. Шул елларда ул халыкның ныклыгына, аның якты киләчәгенә ышанып, «егылмас инде сыналган җан» дип яза.

Емельяновның «сыналган җанлы» халкына әле шагыйрь үлгәннән соң да күп кыенлыклар кичерергә туры килде. Роман Даулей кебек, керәшен татарлары арасыннан чыккан укымышлыларның үз ана телләрендә газета яки журнал оештырырга тырышулары хәтта Беренче рус революциясе елларында да уңышлы тәгәлләнмәде. Клерикаль настроениеләр белән сугарылган миссионерлар керәшен татарларын ничек кенә булса да үз тәэсирләре астында калдырырга, аларның аңын томалап тотуга бөтен көчләрен куйганнар. Ләкин яңа революцион күтәрелеш еллары керәшен татарларына да вакытлы матбугат бирде. Аның битләрендә Емельянов традициясен дәвам итүче халык улларының әсәрләре басыла, талантлы шагыйрьләр күренә башлый. Шулардан иң күренеклесе, Яков Емельяновның шигъри эстафетасын турыдан-туры кабул итүче — Давид Григорьев. Ул керәшен татарлары арасында беренче булып Хәсән Ямашев, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Мулланур Вахитовларның исемен пропагандалаучы кеше. Дөрес, аның да тормышы һәм иҗаты

катлаулы. Григорьевның туры юлдан тайпылган, миссионерлык настроениеләренә бирелеп киткән чаклары да булган. Ләкин Февраль революциясен ул руханилык эшеннән баш тартып каршылый, ә Совет власте елларында интернационализм идеяләрен таратуга күп көч куя.

Кил, кытай, һиндияле,
Кил, гарәп, англичан,
Кил, япон, кил, герман,
Кил, поляк һәм француз.
Изелгән, интеккән,
Бар эшче, бар крестьян
Күр безне, кил бире,
Бул иптәш, кулың суз,—

дип дәшә ул хәлиткеч көрәш елларында.

Безгә Давид Григорьевның «Театр пьесалары», «Сандугач», «Пролетариат куәте» һ. б. китаплары билгеле. Болардан тыш, ул күп кенә коллектив җыентыкларда катнашкан, газеталарның иң актив хәбәрчеләреннән булган.

Күргәнебезчә, халык Яков Емельянов традицияләрен дәвам итүчеләрне, үз халкының рухы белән яшәүчеләрне, аның бәхете өчен Емельяновча көрәшүчеләрне тудырып торган. Ә алар Емельянов кебекләрнең үлемсезлеген раслыйлар.

**Максим ГЛУХОВ.**

Сәлим Шәйдуллин

# РОМАНТИК ГЕРОЙ ЭЗЕННӘН

## I

Озак вакытлар әдәбият галимнәре романтизмның яшәү дәверен XIX—XX гасырлар белән чикләп килделәр. Бу, әлбәттә, берьяклы караш иде. Соңгы елларда әдәбият белемендә исә, реализм белән бергә, романтизмның да тарихи кыса-чикләрен киңәйтү мәсьәләсе принципиаль төс алып бара. Күп кенә галимнәр романтизм элементларының бик борынгыдан яшәп килүен язып чыктылар. «Романтик тойгылы язучылар,— ди, мәсәлән, Н. А. Гуляев,— XIX йөзгә кадәр дә булган, тик алар үз методларын төшенмәгән хәлдә иҗат иткәннәр»[1]. Болай дигәндә ул, билгеле, программасыз «метод»ны, ягъни романтизмның әдәби юнәлеш буларак формалашканга кадәрге билге-төсмерләрен күздә тота.

Соңгы вакытларда романтизмның аерым төсмерләрен тикшерүгә багышланган махсус хезмәтләр дә очрый башлады. Шуның бер үрнәген, мәсәлән, Көнчыгыш әдәбиятларындагы иҗат методларын өйрәнүдә күрергә мөмкин. Яңарыш чоры әдәбиятын тикшерүчеләр элегрәк аның реализмына гына басым ясап сөйләгән булсалар, Н. И. Конрад фикерләренә караганда, ул чор әдәбиятында романтизм да булырга тиеш. Үзенең «Юлбарыс тиресе ябынган батыр» һәм Яңарыш романтизмы мәсьәләсе» дигән хезмәтендә ул Ш. Руставели поэмасын Фирдәүсинең «Шаһ-намә» (XI йөз), Гурганиның «Вис һәм Рамин» (XI йөз), Низаминың «Хөсрәү вә Ширин» һәм «Ләйлә вә Мәҗнүн» (XII йөз), Нәвоиның «Фәрһад вә Ширин», «Ләйлә вә Мәҗнүн» (XV йөз), Боярдоның «Гашыйк Роланд» (XV йөз), Ариостоның «Акылдан язган Роланд» (XVI йөз) һәм Тассоның «Азат ителгән Иерусалим» (XVI йөз) дигән әсәрләре белән бер рәткә куеп карый. Бу әсәрләрнең романтик характерда булуларын искәртеп, Н. И. Конрад Көнбатыш һәм Көнчыгыш Яңарышындагы романтизмнарның төп охшашлыгын түбәндәгечә аңлата: «Киләчәк тикшеренүләр безгә Яңарыш романтизмының асылын ачып бирер һәм, ихтимал, аны «героик романтизм» буларак билгеләр. Шулай ук, ихтимал, Көнбатышта да, Көнчыгышта да бу романтизмның иң типик геройларыннан берсе итеп «мәҗнүн» танылыр»[2].

Романтизмны бу юнәлештә өйрәнүне татар әдәбият белеме дә читләтеп үтә алмады. Иҗат методларын типологик өйрәнү юлында ирешелгән яңа казанышларга таянып, Г. Халит, мәсәлән, безнең әдәбиятта да романтизм төсмерләренең урта гасырларда ук күренә башлаганлыгын искәртеп чыкты[3]. Шулай да бездә бу мәсьәләнә

[1] Н. Гуляев. О спорном в теории романтизма. «Русская литература» журналы. 1966 ел. 1 сан. 72 бит.

[2] Н. И. Конрад.«Витязь в тигровой шкуре» и вопрос о ренессансном романтизме. «Народы Азии и Африки» журналы. 1966 ел. 6 сан. 79 бит.

[3] Гали Халит. Тукай и его современники. Рус телендә. Казан. 1966 ел. 208 бит.

өйрәнү тиешле югарылыкка куелган дип булмый әле. XIX йөз азаклары һәм XX йөз башы татар әдәбиятындагы романтизм турында кыйммәтле генә фикерләр әйтелсә дә[1], борынгы татар поэзиясендә урын алган романтизм төсмерләрен махсус өйрәнү мәсьәләсенә әлегә кадәр ныклы игътибар бирелгәне юк. Уйланулар рәвешендә язылган бу мәкаләдә исә татар романтизмының белгечләребез игътибарыннан читтәрәк калып килгән әнә шул якларын күзәтергә, ягъни XIII—XIX йөзләр татар поэзиясендәге романтик билге-элементлар хәрәкәтен тикшерергә омтылу максат итеп куела.

Н. И. Конрадның искә алынган хезмәтеннән күренүенчә, Яңарыш чоры әдәбиятларындагы романтизмда мәхәббәтне илаһилаштыру, «героик» башлангыч, геройларны гадәттән тыш хәлгә кую, хыял һәм фантастикага бирелү, реаль күренешләрне идеаллаштыру кебек билге-элементлар актив кулланылган; мәҗнүн образы типик герой дәрәҗәсендә йөртелгән, идеаль һәм реаль башлангычларның үзара аралашып-үрелеп килү очраклары булган. Әлбәттә, болар Яңарыш чорында кинәттән генә килеп чыкмыйлар; аларның күп кенә төсмерләре Урта гасыр әдәбиятларында ук яралып, эволюцион үсеш-үзгәрешләр кичерә килгәннәр; Яңарыш чорында исә, мәгълүм социаль-тарихи сәбәпләр нәтиҗәсендә, активлашканнар, алгарак чыкканнар.

Безнең әдәбиятның Болгар дәүләте чорыннан ук Көнчыгыш халыклары әдәбияты белән тыгыз бәйләнештә булып килгәнлеген истә тотып, югарыда әйтелгән фикерләр яктылыгыннан карасак, әлеге романтик элемент һәм образларны теге яки бу дәрәҗәдә борынгы татар әдәбиятында да очратырбыз. Колгалинең «Йосыф вә Зөләйха»[2] (XIII йөз) поэмасында, мәсәлән, романтизмның бигрәк тә Фирдәүси, Низами һәм Руставели иҗатларында күренгән сыйфатлары шактый табылырга мөмкин. Бер үк Йосыф-Зөләйха темасына Көнчыгышның бик күп күренекле әдипләре игътибар иткән икән, бу үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Урта гасыр әдәбиятларында бер үк тема, сюжет һәм образларның бер шагыйрь иҗатыннан икенчесенекенә күчеп йөрүен ничек аңлатырга соң? К. Маркс һәм Ф. Энгельс хезмәтләреннән күренгәнчә, борынгы дәверләрдә, ягъни җитештерү ысулы, җитештерү мөнәсәбәтләре әле «примитив булган һәм үсеш алмаган» чорларда, экономика һәм культура үсешендә «хәлиткеч роль»не[3] традиция уйнаган.

«Хәлиткеч роль» уйнаган шундый традицияләрнең берсе борынгы татар шагыйрьләренең нәкъ менә мәхәббәт проблемасына булган мөнәсәбәтләрендә күренә дә. Ә бу проблеманы чишкәндә алар еш кына әлеге дә баягы мәҗнүн образына мөраҗәгать итәләр. Дөрес, «Йосыф вә Зөләйха» әсәрендә мәҗнүн характеры, телгә алынган башка поэмалардагы шикелле, егет образында түгел, бәлки хатын-кыз образында гәүдәләндерелә. Зөләйханы да, Роланд яки Тариэл кебек үк, көчле мәхәббәт ялкыны биләп ала: ул, ашау-эчүдән, йокыдан язып, авыруга сабыша, Йосыфны эзләп Мисырга килә... Бирелә мәхәббәт проблемасының чишелеше дә Ш. Руставели поэмасына якынрак тора: финал гашыйкларның бәхетле кушылуы, Зөләйханың үз теләгенә ирешүе белән тәмамлана. Шулай ук «Йосыф вә Зөләйха»дагы фантастика күренешләре һәм мәҗнүн образының берминди ирония, юмор элементлары белән сугарылмыйча, «җитди рәвештә» тасвирланган булуы да бу ике поэма арасында күпмедер уртаклык барлыгы турында сөйли. Геройларны гадәттән тыш хәлгә куюда, реаль күренешләрне идеаллаштыруда, реаль һәм идеаль башлангычларның аралашып-үрелеп баруында да, әйткәнебезчә, мондый уртаклыкны теге яки бу дәрәҗәдә күрергә була.

Ә менә «героик» башлангыч мәсьәләсенә килгәндә, эш бүтәнчәрәк тора. «Йосыф вә Зөләйха» поэмасында мондый башлангыч, егетнең, мәхәббәт янсә физик көченнән бигрәк, акыл көчендә чагыла. Әсәрдә мәҗнүн характерының нәкъ менә хатын-кыз образында бирелүе дә, безнеңчә, шуның белән аңлатылса кирәк. Дөрес, «героик»

---

[1] Моңа мисалларны Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Х. Госман, Г. Халит, И. Нуруллин, Й. Нигъмәтуллина һәм башка галимнәрнең хезмәтләреннән бик күпләп китерергә була.

[2] Бу әсәрнең исеме төрле урында төрлечә («Кыйссаи Йосыф», «Йосыф-Зөләйха кыйссасы», «Йосыф вә Зөләйха» һ. б.) язылып килгән. Без аны, киң катлау укучыларга аеруча таныш булган «Татар поэзиясе антологиясе» (Казан, 1956) һәм «Борынгы татар әдәбияты» (Казан, 1963) исемле хезмәтләрдә кулланылганча, «Йосыф вә Зөләйха» дип алабыз.

[3] К. Маркс и Ф. Энгельс. Сочинения. Рус телендә. 2 басма. 25 том. 356 бит.

башлангыч Зөләйха образында да шактый зур урын ала. Мисал итеп аның мәхәббәткә ирешү юлында күрсәткән кыюлыгы, турылыклылыгы, сабырлыгы һәм кайгы-газапларга чыдамлы булуы кебек сыйфатларын китерергә мөмкин. Әмма хикмәт шунда: Зөләйханың бөтен гүзәл сыйфатлары Йосыфның героик характерына һәм югары мораль сыйфатларына буйсындырылган.

Әсәрдәге вакыйгалар барышыннан аңлашылганча, Колгали үз чорының төп героик характерын Йосыфның пәйгамбәрлек сыйфатлары һәм миссиясе аша күрсәтергә тели. Бу миссия һәм сыйфатлар Йосыфның алла кушуы буенча халык теләкләрен үтәп йөрүче изге зат итеп бирелүендә күренә. Ләкин Йосыф, алла ярдәм итеп торуга да карамастан, үз максатына җиңел генә ирешә алмый. Базарларда сатып йөртелгән гади кол хәленнән халык теләкләрен канәгатьләндерә алырдай пәйгамбәр-патша дәрәҗәсенә килеп җиткәнче, ул гаять авыр, газаплы юл үтә. Шунда аның характер ныклыгы һәм мораль сыйфатлары сынала.

Әмма тормыш юлында күп кенә тоткарлыклар, кыенлыклар очратса да, патша булып алгач, Йосыф белән аның тирәлеге арасында каршылык бетә, тулы гармония бәрлыкка килә, тормыш агымы Йосыф теләгәнчә бара башлый. Масьәләнең бу ягы инде Колгали карашларындагы дини-дидактик тенденцияләргә бәйләнгән. Билгеле булганча, романтик әсәрләр гадәттә чынбарлыкка карата канәгатьсезлек тойгылары уятырдай шартларда туалар. Бу канәгатьсезлек,— ди, мәсәлән, У. Р. Фохт,— төрле нигезгә — «мораль (Жуковский), социаль (Рылеев), психологик (Фет)» — корылырга һәм төрле дәрәҗәдә — «абсолют, чагыштырма һ. б.» — чагылырга мөмкин[1]. Колгалинең үз чорындагы иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән канәгатьсезлегенә килгәндә исә, без бу канәгатьсезлекнең нәкъ менә, У. Р. Фохт әйткәнчә, чагыштырма дәрәҗәдә булуын һәм мораль нигезгә корылганлыгын күрәбез.

Борынгы татар шагыйренең дөньяны тигезләү турындагы идеалы — чикләнгән идеал, әлбәттә. Әгәр шулай әйтергә ярасә, аның «кысасы», «түшәме» бар. Шагыйрьнең идеалы кайдадыр күктә «утырган» алладан югарырак күтәрелми, дин куйган кысалардан читкә чыга алмый. Ул чор шагыйре үзен алланың колы итеп кенә түгел, бәлки патшаның да хезмәтчесе рәвешендә хис итә, җирдәге иң бөек, иң гадел затны пәйгамбәрлек сыйфатларына ия булган патша образында күрергә тели. Шуңа да Колгали пәйгамбәренең тирәлек белән гармониягә керә һәм тормышны үзгәртү бәхетенә ирешә алуы гаҗәп түгел. Феодализм дәверендә мәйданга чыккан пәйгамбәр-патша образы белән капитализм чорында формалашып җиткән пәйгамбәр-шагыйрь образы арасындагы төп аерымлыкларның берсен әнә шулай аңлатырга мөмкин булыр иде.

Әмма моннан Колгали поэмасында дини мотивлар өстенлек итә диген нәтиҗә чыкмый әле. Дөрес, «Йосыф вә Зөләйха» — дини сюжетка нигезләнгән, дини легендалардан килә торган әсәр. Шулай да биредәге дини һәм дөньяви хисләр бәрелешендә соңгысының җиңеп чыкканлыгын күрми мөмкин түгел. Ә бу дөньявилык тенденциясе исә нәкъ менә прогрессив романтизм, халыкчан гуманизм һәм реализм сыйфатларына бәйләнгән. Әйткәнебезчә, «Йосыф вә Зөләйха» поэмасында реалистик элементларны да шактый табарга мөмкин. Мәсәлән, Бәширнең кызганычлы тормышы феодализм чорында сатып йөртелгән меңнәрчә колларның трагик хәлләрен гәүдәләндергән типик күренеш булып тора. Йосыфның үз хәле дә башта Бәшир яки меңләгән бүтән колларның тормышыннан аерылмый диярлек.

Шулай итеп, Колгали әсәрендә без төрле иҗат методларының яралгыларын, төсмерләрен очратабыз. Биредә, В. Г. Белинский сүзләре белән әйтсәк, реаль һәм идеаль башлангычларның кушылуын да, Г. Н. Поспелов әйткәнчә, стихияле романтик агым[2] тенденцияләрен дә, дини-дидактик һәм рационализм принципларын да табарбыз. Димәк, бик борыннан ук романтизм һәм рационализм принциплары, чорның,

---

[1] У. Р. Фохт. Некоторые вопросы теории романтизма. «Проблемы романтизма» исемле җыентык. Мәскәү. 1967 ел. 83 бит.

[2] Г. Н. Поспелов. Что же такое романтизм? «Проблемы романтизма» исемле җыентык. Мәскәү. 1967 ел. 63 бит.

иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең үзенчәлегенә карап, үзара «дуслар», «союздашлар» рәвешендә дә яшәргә мөмкиннәр икән.

Югарыда без пәйгамбәр-патша образының мәйданга чыгуы шагыйрьнең яшәп килгән тәртипләр белән өлешчә каршылыкка керә башлавына һәм аңарда дөньяны тигезләү идеалы тууга бәйләнгән булуын күрдек. Мәхәббәт өчен көрәш идеалы яралуга да, мәхәббәтне илаһилаштыруга һәм мәҗнүн образының мәйданга чыгуына да, әлбәттә, шул ук иҗтимагый мөнәсәбәтләрдәге үзгәрешләр (әйтик, индивидуаль җенси мәхәббәт барлыкка килүе) сәбәп иде.

## 2

Романтизмның билгеләре һәр вакыт үсеш-хәрәкәттә булып, аларның кайберләре бер чорда өстенлек алырга, алгарак чыгарга, ә икенче бер чорда пассивлашырга яисә бөтенләй төшеп калырга мөмкин. Бу исә гомумән романтизм үзе генә түгел, бәлки аның һәрбер билге-элементы үсеш-үзгәрештә каралырга тиеш дигән сүз. Әдәби хәрәкәтнең бер агымы буларак, романтизм үзе һич тә тулаем югалмый, ул бары теге яки бу чорда, күпчелек билге-элементлары пассивлашу яисә төшеп калу сәбәпле, хакимлек дәрәҗәсен генә югалтырга мөмкин. Әмма хакимлеген югалтканнан соң да әле аның аерым билге-элементлары яңа шартларда куәт алырга, яңа эчтәлек, яңа сыйфатлар белән баетылырга сәләтлеләр. Үзеннән-үзе аңлашыла ки, романтизмны бу рәвешле өйрәнгәндә, җитештерү мөнәсәбәтләренең асылы, җәмгыятьнең үсеше, үзгәреше, иҗтимагый-политик тәртипләрнең алышыну үзенчәлекләре кебек мәсьәләләргә дә нык игътибар итәргә кирәк.

Романтизмның Колгали поэмасында табылган билге-элементлары һәм образлары татар поэзиясендә алга таба ничек үзгәрәләр, нинди яңа сыйфатлар белән баетылалар, үстереләләр? Түбәндә без шушы проблеманың кайбер моментларына беркадәр кагылырга уйлыйбыз[1].

Мәгълүм булганча, XIII йөзнең беренче яртысында, башка бик күп халыклар шикелле, болгарлар да катлаулы тарихи шартларга килеп керәләр. Гореф-гадәтләрен һәм телләрен саклаган хәлдә, алар политик яктан Алтын Урдага буйсынып, аның изүе астында яши башлыйлар. Бу хәл аларның мәдәни үсешендә дә үзгәрешләр тудырмый калмый, билгеле. XIII йөзнең икенче яртысыннан башлап татар әдәбияты, гомум кешелек гуманизмы, мәхәббәт кебек темаларны дәвам иттерү белән бергә, гаделлек һәм акылга хөрлек таләп итү, явызлыкка каршы көрәш юнәлешендә үсеп китә. Мисал өчен шул чорда аеруча популярлык казанган әсәрләрдән Сайядиның «Дастан Бабахан» поэмасына тукталырга мөмкин. Биредә романтик элементлар шактый үзенчәлекле кулланылган. Бу, барыннан да элек, шагыйрьнең патша сараена мөнәсәбәтендә һәм мәхәббәт геройларының характерын сурәтләвендә күренә. Сайяди инде идарәчеләрдән пәйгамбәрлек сыйфатлары эзләми, киресенчә, аларга күпмедер дәрәҗәдә тәнкыйть күзе белән карый; патша сараендагы каршылыкларны, шаһның кансызлыгын, явыз характерлы булуын тасвирлый. Пәйгамбәрлек миссиясе шулай ук Таһир образында да чагылыш тапмый. Таһирның героик сыйфатлары, Йосыфныкыннан аермалы буларак, гыйлем көчендә яисә пәйгамбәрчә эш итә белүдә түгел, ә барыннан да элек — мәхәббәт көчендә һәм физик батырлыгында. Ул, намуслы, турылыклы кеше булу өстенә, оста һәм гайрәтле сугышчы, илне дошманнардан саклаучы да. Монда инде Көнбатышның рыцарьлык романнарында очрый торган романтик сыйфат күпмедер дәрәҗәдә сизелеп китә.

Сайяди поэмасында мәхәббәт һәм шәхес иреге проблемаларының чишелеше дә үзенчәлекле. Биредә шәхес иреге һәм ирекле мәхәббәт өчен көрәш сызыгы «Йосыф вә Зөләйха»дагы кебек гармоник рәвештә түгел, ә трагедия белән тәмамлана. Әсәрдә

---

[1] Кыска гына мәкаләдә XIII—XIX йөзләр арасында иҗат ителгән шигъри әсәрләрнең барысына да тукталу мөмкин түгел. Шуңа күрә, романтик билге-элементлар хәрәкәтен күзәткәндә, без күбрәк шул чор әсәрләре арасында манаралар кебек калкып торган, үзендә борынгы татар поэзиясенең иң характерлы тенденцияләрен туплаган һәм бүтән шагыйрьләр иҗатына аеруча көчле йогынтысы тигән әсәрләргә таянып эш итү дөресрәк булыр дип санадык.

Таһир белән Зөһрәнең үлеме феодаль чынбарлыкка, гаделсезлеккә каршы протест булып яңгырый; мәхәббәтнең үлемнән дә көчлерәк икәнлеге раслана.

Шул рәвешчә, «Дастан Бабахан» поэмасында, геройның пәйгамбәрлек миссиясе төшеп калу белән бергә, мәхәббәт һәм шәхес иреге өчен көрәш, шәхес белән чынбарлык арасындагы каршылык тирәнрәк чагыла, «героик» башлангыч яңа сыйфатлар белән баетыла. Шул ук вакытта Сайяди әсәрендә дини мотивларның һәм фантастика элементларының кимрәк, ә реаль башлангычның зуррак урын алганлыгы да күренә.

Сайяди поэмасында яңа тенденцияләр урын алу һәм мәхәббәт иреге өчен көрәш идеалы алгарак куелуның башлыча ике сәбәбе бар. Беренчедән, «Дастан Бабахан»ның сюжеты, Колгали әсәреннән аермалы буларак, халык легендасыннан килә. Икенчедән, югарыда искәрткәнебезчә, Сайяди яшәгән чор иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә килеп чыккан үзгәрешләр белән характерлы. «Хосусый милек җәмәгать милке өстеннән өстенлек алгач һәм мирасta, кызыксыну белән берлектә, аталык хокукы һәм моногамия хакимлек итү дәрәҗәсен алгач,— ди Ф. Энгельс,— никахлану эше бөтенләе белән экономик характердагы карашларга бәйле була башлады»[1]. Бу хәл феодализм җәмгыятендә, мәхәббәткә һәм хатын-кызга карата яңа, прогрессив мөнәсәбәтләр барлыкка килүе белән бергә, хатын-кызларны тупас кимсетү, эксплуатацияләү күренешләрен дә китереп чыгара. Хәзер инде, хатын-кызлар белән бергә, ирнең дә шәхси сыйфатларына карап түгел, ә мал-мөлкәтенә карап бәя бирелә башлый. Шул рәвешле, феодализм чорында хатын-кызга карата мөнәсәбәттә ике төрле тенденция: прогрессив (индивидуаль җенси мәхәббәт үсеше) һәм регрессив (никахка мал-мөлкәт килешүе итеп карау) тенденцияләр формалаша. Колгали дәверендә бу тенденцияләрнең беренчесе мәйданга чыгып та, икенчесе әле ныклы үсеш алып өлгермәгән булса, Сайяди чорында инде икенче тенденция көчлерәк тамыр җәя. Алтын Урда һәм ислам дине изүе астында яшәгән татарлар тормышында моның аеруча нык сизелүе табигый хәл иде.

Явыз идарәчеләргә тәнкыйть күзе белән карау, кан коюлы сугышларны гаепләү һәм мәхәббәт иреге өчен көрәш идеалын алгарак кую тенденциясе шул чорның башка зур шагыйрьләре иҗатында да бик ачык сизелә. Мәсәлән, Котби үзенең «Хөсрәү вә Ширин»ында турыдан-туры болай язган:

Бу гыйшкым берлә башлап дастанны,
Салабәт[2] гыйшыкка өндәдем җиһанны[3].

Яисә менә Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» исемле поэмасында Сөһәйлнең Гөлдерсенгә әйткән сүзләре:

Җаным мең булса да — сиңа, сөйгән яр!
Шушы дуслыктан артык җирдә ни бар?![4]

Кыскасы, Колгалинең «Йосыф вә Зөләйха»сында дәүләт эшләре, ил белән идарә итү беренче, ә мәхәббәт мәсьәләсе икенче планрак куеп сурәтләнгән булса (Зөләйханың көчле мәхәббәте дәүләт-идарә эшләре җайга салынганга кадәр Йосыф тарафыннан кабул ителмичә торуы фактын хәтерләгез!), әлеге ике әсәрдә, Сайяди поэмасындагы кебек үк, мәхәббәт проблемасы үзәктә тора; саф мәхәббәт бар нәрсәдән югары, һәртөрле байлыклардан, дәрәҗәләрдән һәм кануннардан өстен куела. Моңа ышану өчен, шаһ кызы Гөлдерсеннең зиннәтле сарайны ташлап сөйгән егете Сөһәйл белән бергә сахрага качуы, Ширинның патшалыктан ваз кичеп, Иранга — Хөсрәү янына килүе кебек вакыйгаларны искә төшерү дә җитсә кирәк. Тагын да мөһимрәге, Котби һәм С. Сараи әсәрләренең финалы да, нәкъ «Дастан Бабахан»дагы шикелле, трагик рәвештә тәмамлана: мәхәббәт герое («Хөсрәү вә Ширин»да — Ширин,

---

[1] Ф. Энгельс. Семьяның, хосусый милекнең һәм дәүләтнең килеп чыгуы. Таткнигоиздат. 1952 ел. 95 бит.
[2] Салабәт — көчле.
[3] Борынгы татар әдәбияты. Казан. 1963 ел. 185 бит.
[4] «Казан утлары» журналы. 1972 ел. 6 сан. 137 бит. Н. Арсланов тәрҗемәсе.

«Сәһәйл вә Гөлдерсен»дә — Сәһәйл), явыз тирәлек тарафыннан һәлак ителгән сөеклесенең гәүдәсе өстенә ятып, үз-үзен хәнҗәр белән кадап үтерә... Бу фактлар үзләре генә дә Алтын Урда чорында ирекле мәхәббәт идеалының ни дәрәҗәдә алга сөрелгән булуын раслыйлар.

Әлбәттә, югарыда сөйләгәннәрдән Алтын Урда чоры әдәбиятында яхшы патша проблемасы бөтенләй төшеп, югалып калган икән дигән фикер аңлашылмаска тиеш. Ул заманда язылган күп санлы әдәби әсәрләр һәм кулъязмалар арасыннан уңай яки тискәре сыйфатлары күпертеп сурәтләнгән патша образларын да, турыдан-туры дини мәгънәсендә кулланылган пәйгамбәр образларын да шактый табарга мөмкин. Әмма без андый образлар турында түгел, ә пәйгамбәр-патша, ягъни романтик мәгънәдәге пәйгамбәрлек миссиясенә ия булган — дөньяны тигезләргә омтылган — идеаль идарәче образы хакында сүз алып барабыз. Хәлбуки, авторлар тарафыннан макталган һәрбер патша яки турыдан-туры Корьәннән күчерелгән пәйгамбәр образы романтик герой була алмый.

Казан ханлыгы чорында (XV—XVI йөзләр), мәхәббәт культы һәм әкиятчелек-фантастика кебек билге-элементлар икенче планга этәрелеп, яңадан әлеге пәйгамбәр сыйфатлы патша образы алга чыга. Моның сәбәбе, барыннан да элек, Казан ханлыгының эчке яктан таркала баруы, хакимлекне бүлешү өчен ханнар һәм феодаллар арасында үзара көрәш кискенләшеп китүе һәм гади хезмәт ияләренең эксплуатациялэнүе нәтиҗәсендә шагыйрьләрнең тормышта тигезлек, татулык урнаштыру идеалын үзәккә куюларына бәйләнгән.

Бу тенденция шул чорның күренекле шагыйре Мөхәммәдьяр поэмаларында аеруча көчле чагыла. Шагыйрь үзенең гуманистик карашларын, гомум кешелек өчен файдалы булган фикерләрен дә алла, пәйгамбәр яки шундый сыйфатларга ия булган идеаль хөкемдар образына бәйләп үткәрә. Аның «Нуры содур» исемле поэмасындагы «Муса хикәяте»ндә, мәсәлән, бик шәфкатьле пәйгамбәр образы үрнәк итеп куела.

Әмма Мөхәммәдьярның идеаль патша образына якын килүендә үзенчәлекләр дә юк түгел. Беренчедән, аның пәйгамбәр сыйфатлы герое күп очракта тормышчан вакыйгалар аша гәүдәләндерелә: түбән катлау вәкилләренә, кимсетелгәннәргә аерым мәхәббәт белән карый, беренче чиратта, шуларның язмышын җиңеләйтергә омтыла. Башкача әйтсәк, Мөхәммәдьяр поэмаларында «Йосыф вә Зөләйха» әсәрендә үк күтәрелгән «патша һәм кимсетелгәннәр гармониясе» мәсьәләсенә күбрәк басым ясала. Икенчедән, Мөхәммәдьяр иҗатында, Колгали һәм Сайяди поэмалары белән чагыштырганда, мәхәббәтне илаһилаштыру, мәҗнүнчелек элементы бөтенләй диярлек югалып, мажаралы сюжет, әкиятчелек-фантастика элементлары шактый кими, зиннәтле сарай, сихри бакча шикелле күренешләрне сурәтләүгә азрак урын бирелә; аның каравы, Колгали заманыннан ук килгән дидактизм принциплары активлаша, аң-белем һәм мәгърифәтнең әһәмияте ныграк күпертелеп, романтизм-дидактизм синтезы көчәя төшә. Өченче яктан, Мөхәммәдьяр әсәрләренә яңа романтик төсмерләр дә килеп керә. Болай дигәндә, без романтизмның сәнгать культы дигән яралгыларын да күздә тотабыз. Мондый тенденцияне, мәсәлән, «Төхфәи мәрдән» поэмасындагы Һарун образының бирелешендә күрергә була. Һарун шаһ үзенең сараенда тиран моңы һәм гаделлеге белән танылган, әмма түбән катлау вәкиле булган Хушнәвага зур ихтирам саклый, аның эчкерсез таланты, халыкчан моңы, музыкасы алдында баш ия. Моңа кадәр аллалар, пәйгамбәрләрдән бүтән беркем каршында да баш бөгәргә гадәтләнмәгән патша хәтле патшаны гади сәнгать иясе алдында баш идерү, әлбәттә, сәнгатьнең тормыштагы роле күпмедер дәрәҗәдә арттырып күрсәтелүе һәм пәйгамбәр-патша образының яңа романтик сыйфатка баетылуы турында сөйли.

XVI—XVIII йөзләрдәге татар поэзиясендә яңа прогрессив романтик билгеләр һәм образлар барлыкка килми генә түгел, бәлки элегрәк мәйданга чыкканнары да бик нык пассивлаша. Моның да сере шулай ук җәмгыятьтә килеп чыккан яңа тәртипләргә һәм татар шагыйрьләренең дөньяга карашларындагы торгынлыкка бәйләнгән булса кирәк. Мәгълүм ки, Казан ханлыгы рус дәүләте составына кергәч, рус дөньясында туган иҗтимагый фикерләр, культура яңалыклары татар җәмгыятенә дә күчә башлый. Ләкин бу прогрессив хәрәкәт җиңел генә, каршылыксыз гына бармый. Милли-колониаль изү политикасын үткәргән Мәскәү патшалары һәм феодаллары вак милләтләр-

нең, шул исәптән татарларның да, культура үсешен тоткарлыйлар. Ә татар шагыйрьләре, кайбер дин башлыкларына тәнкыйть күзе белән карау югарылыгына күтәрелсәләр дә, гомумән ислам диненә, аллага мөнәсәбәтләре белән нигездә Колгали дәрәҗәсендә калып килделәр. Шуңа күрә бу чор татар поэзиясендә, прогрессив романтик герой буларак, пәйгамбәр-патша образының кабат пассивлашуы һич тә гаҗәп түгел.

XVII—XVIII йөзләрдәге татар поэзиясендә мәйданга чыккан суфизм агымын әдәбият белгечләре хаклы рәвештә аскетизмның ислам дине белән үрелеп формалашкан бер төре дип атыйлар. Аскетизм белән консерватив романтизм арасында күп кенә охшашлыклар барлыгы да шулай ук мәгълүм. Мәсәлән, җир тормышын вакытлы дип санап, аны «теге дөньяга» каршы кую, язмыш каршында үз-үзеңне гадәттән тыш түбәнәйтү, дөньядан бизү кебек принципларда консерватив романтизмның кайбер сыйфатларын күрү кыен түгел. Димәк, шуннан чыгып, XVII—XVIII йөзләрдәге суфичылык поэзиясе (әйтик, Аллаһъяр, Мәүлә Колый һ. б. шигырьләре) нигезендә консерватив романтизмның кайбер төсмерләре яралды, романтизмның XX йөз башы татар әдәбиятында үсеш алачак консерватив тармагы өчен билгеле бер дәрәҗәдә җирлек хәзерләнде дип тә әйтә алабыз.

## 3

XIX йөзнең беренче яртысында башланган гомуми уяну хәрәкәте җирлегендә тормышны тигезләү, акыл һәм шәхес ирекe өчен көрәш идеаллары кабат игътибар үзәгенә куела. Татар поэзиясендә электән килгән дөньяви, гуманистик традицияләр һәм Мөхәммәдьяр иҗатында чагылган мәгърифәтчелек тенденцияләре алга таба үстерелә, тирәнәйтелә бара. Романтизмның суфичылык дәверендә «югалып» торган прогрессив билгеләре (мәсәлән, мәхәббәт культы) кабат җанлана, яңа сыйфатлар белән баетыла. Бу тенденция бигрәк тә Г. Кандалыйның җир кызларына дан җырлаган шигырьләрендә ачык чагыла («Бәлалмадым», «Сәхипҗамал», «Фәрхисәрур» һ. б.). Х. Госман аңлатуынча, Кандалый «беренчедән, борынгы дөньяви поэзия традицияләрен яңарта, икенчедән, аларны үз заманы биргән яңалыклар белән баета»[1]. Аның поэзиясендә «дини хис асылда юкка чыга, кешегә соклану, кешегә мәхәббәт хисе тантана итә»[2]. Кандалый романтизмының асылы, безнеңчә, нәкъ менә шул «мәхәббәт хисе тантана итү»дә күренә. Шул ук вакытта Г. Кандалый шигырьләрендә мәхәббәт тигезлеге һәм идеаль герой проблемасы үзенчәрәк хәл ителә. Аныңча, инде чын егетлек гадел патша яки батырлык, рыцарьлык сыйфатларында түгел, ә гомумән белемле, укымышлы кеше булуда. Калган бөтен матур сыйфатлар шушы сыйфаттан үсеп чыга. Кандалый фикеренчә, иң сөйкемле, гүзәл кыз мәхәббәтенә фәкать шундый егет кенә лаек булырга тиеш. Бу инде Мөхәммәдьяр иҗатыннан килгән мәгърифәтчелек төсмерләренең яңа шартларда үстерелүе, мәгърифәтчелек һәм романтизм билгеләренең көчлерәк аралаша баруы, әгәр шулай әйтергә ярәса, татар поэзиясендә **мәгърифәтчелек романтизмы** формалаша башлавы диген сүз иде.

XIX гасырның икенче яртысында, җәмгыятьтә капиталистик мөнәсәбәтләр көчәю сәбәпле, татар романтизмы яңа үзгәрешләр кичерә, мәгърифәтчелек романтизмы формалашып җитә. Белгечләр бу чор татар әдәбиятында хакимлек иткән иҗат методын хаклы рәвештә мәгърифәтчелек реализмы дип атыйлар. Әмма шушы төп юнәлешнең үз эчендә әле тагын романтизм принциплары зур урын алганлыгын да күрмичә калып булмый. Мәгърифәтчелек романтизмы дигәндә, без мәгърифәтчелек реализмы эчендә хәрәкәт иткән әнә шул романтик принциплар, билге-элементлар системасын күздә тотабыз. Бу мәсьәләгә, ягъни бүтән иҗат принциплары белән аралашкан реализм проблемасына, заманында Г. Сәгъди дә игътибар иткән. XIX йөз азакларын күздә тотып, ул болай диген: «Татар матур әдәбиятында рационализм, сентиментализм катыш реализм адымы башлана»[3]. Соңгы елларда бу фикерне тагын да конкретрак,

[1] Г. Кандалый. Шигырьләр. Казан. 1960 ел. 11 бит.
[2] Шунда ук, 14 бит.
[3] Г. Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Казан. 1926 ел. 76 бит.

ачыграк әйтеп чыгучылар да булды. Мәсәлән, Й. Нигъмәтуллина фикеренчә, татар мәгърифәтчелек реализмының үз эчендә ике төрле «әдәби сызык» бар. Боларның берсе критик юнәлештә, ягъни чынбарлыкны тәнкыйтьләү, фаш итү юнәлешендә хәрәкәт итсә, икенчесе «турыдан-туры идеалны, мәгърифәтчелек романтикасын чагылдырырга омтылу»[1] белән характерлана. Татар мәгърифәтчелек реализмы һәм аның эчендәге романтизм элементлары турында сөйләгәндә, Й. Нигъмәтуллина, әлбәттә, проза әдәбиятын — Ф. Кәрими, Ф. Халиди, Р. Фәхретдинов, М. Акъегетзадә, З. Һади, З. Бигиев кебек мәгърифәтче язучыларның әсәрләрен күздә тота.

Игътибар белән карасак, әлеге ике сызыкның, ягъни прогрессив романтизм һәм мәгърифәтчелек реализмы принциплары үрелеп, аралашып бирелү тенденциясенең, поэзия өлкәсендә дә чагылыш тапканлыгын күрербез. Мисал өчен Курмашиның Сайяди поэмасыннан файдаланып язылган «Таһир илә Зөһрә кыйссасы»на тукталыйк. Бу әсәрдә кулланылган иҗат принципларын шикләнмичә шул чор татар мәгърифәтчелек романтизмының үрнәге итеп карарга мөмкин. Бирелә «Дастан Бабахан»дагы кире образларның үзгәртелүенә бәйләнешле урыннар барысы да диярлек мәгърифәтчелек идеалыннан чыгып эшләнгән. Тормышта тигезлек һәм татулык урнаштыру, мәхәббәт һәм шәхес иреге өчен көрәш — авторның төп идеалы. Кешеләрнең һәркайсы югары мораль сыйфатлы, мәгърифәтле, һөнәрле һәм сәламәт әхлаклы булырга тиеш. Әлеге идеалга, Курмаши фикеренчә, шул чакта гына ирешергә мөмкин. Әсәрдә хан, ханча һәм Кара гарәп образларының баштанаяк тискәре итеп бирелүләре шуның белән аңлатыла. Курмаши поэмасындагы бу өч образдан бер генә уңай сыйфат та таба алмыйбыз. Чөнки алар әшәкелек, әхлаксызлык үрнәге итеп бирелгәннәр. Бу исә нәкъ менә мәгърифәтчелек реализмы принциплары белән эшләнгән. Шундый ук принцип романтизмга да чит түгел иде.

Уңай геройлар образын тасвирлаганда да Курмаши романтик мотивларны тирәнәйтә торган күп кенә детальләр, яңа эпизодлар кертә. Мәсьәләнең бу ягы инде прогрессив романтик геройларның характерын калкытыбрак, ягъни акны агартыбрак сурәтләү принцибына бәйләнгән. Мондый үзгәреш, мәсәлән, Таһир образында ике төрле юнәлештә гәүдәләнә. Беренчесе — фантастика элементларын мул куллану ярдәмендә аның батырлык, рыцарьлык сыйфатларын арттыру (мәсәлән, берүзе сигезәр йөз сугышчыны кырып салу күренеше һ. б. ш.). Икенче юнәлеш Таһирның (шулай ук Зөһрәнең дә) күңел нечкәлеген, хис-кичерешләрендәге сентименталь күренешләрне көчәйтүдә чагыла. Зөһрә белән аның үзара назым әйтешүләре, кара-каршы җырлашулары һәм бик еш кына кайгыру-елашулары шул хакта сөйли. Курмашиның Таһиры «саф һәм сүрелмәс мәхәббәт герое» (Х. Госман) булу белән бергә, ифрат талантлы җырчы, музыка коралында оста уйнаучы һәм назымчы да. Монда инде күпмедер дәрәҗәдә сәнгатьне илаһилаштыру билгесе чагыла. Бу деталь шулай ук геройның Сайяди әсәреннән килгән чын егетлек сыйфатларын арттыру, баету нияте белән кертелгән.

Романтизмның XIX гасыр татар әдәбиятына тәрҗемәләр аша кергән традицияләрен дә, әлбәттә, мәгърифәтчелек хәрәкәтеннән аерып карау кыен. Бу чор әдип-шагыйрьләре тәрҗемә мәсьәләсендә дә күбрәк Көнчыгыш әдәбиятына бәйләнгән һәм мәгърифәтчелек идеяләренә якынрак торган әсәрләргә мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, 1901 елда Ф. Халиди тәрҗемәсендә татар укучылары үз ана телләрендә «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасын да укый башлыйлар»[2]. Шулай ук бу чорда А. С. Пушкинның Көнчыгыш әдәбияты тәэсирендә иҗат ителгән «Бахчасарай фонтаны», «Романс», «Делибаш» исемле әсәрләре һәм төрек язучысы Н. Кәмалның «Бичара бала» дигән романтик пьесасы татарчага тәрҗемә ителгәнлеге мәгълүм.

XIX гасырның икенче яртысында татар әдип-шагыйрьләре, табигый, шәхес белән изүче җәмгыять арасындагы «абсолют» каршылыкны чагылдырган романтик әсәрләр тудыра алмадылар әле. Яңа формалашып килгән буржуаз мөнәсәбәтләр белән ныклы

---

[1] Ю. Г. Нигматуллина. Национальное своеобразие эстетического идеала. Рус телендә. Казан университеты нәшрияты. 1970 ел. 61 бит.

[2] М. Х. Гайнуллин. Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан. 1968 ел. 120 бит.

каршылыкка кереп җитмәү сәбәпле, аларның төп игътибарлары иске тәртипләрне бетерү өчен көрәшкә юнәлдерелгән һәм шәхес-җәмгыять каршылыкларын сурәтләү мәсьәләсендә, югарыда әйткәнебезчә, әле һаман да «мораль нигез»дән чыгып бетә алмыйлар иде. Г. Халит аңлатуынча, «фольклор мирасына игътибар көчәю һәм кеше шәхесен богаулаган патриархаль-феодаль калдыкларга каршы көрәш»[1] бу чорда мәйданга килгән романтик әсәрләрнең җирлеге, чыганагы булып торды.

Шулай итеп, без татар поэзиясенең Колгалидән алып Әхмәт Курмашига кадәрге дәверен кыскача карап чыктык һәм безнең әдәбиятта романтизм традицияләре, XIX йөздән генә башланмыйча, бик ерактан, борынгы чорлардан ук килгәнлеген күрдек. Ләкин моның белән без һич тә борынгы татар поэзиясендә саф романтик әсәрләр иҗат ителгән дияргә дә, программалы романтик иҗат методы яисә романтизм юнәлеше булган дип нәтиҗә чыгарырга да җыенмыйбыз. Монда без, барыннан да элек, романтизмның кайбер билге-элементлары һәм образлары борынгы татар поэзиясендә үк мәйданга чыгып һәм төрле иҗат принциплары белән аралашып, заман белән бергә үсеш-үзгәрешләр кичерә килгәнлекләрен искәртергә теләдек. Ул чор татар поэзиясендәге романтизм күренешләрен фәкать романтика төшенчәсенә генә кайтарып калдыру шулай ук дөрес булмас иде. Шуңа күрә бу күренешне, Г. Н. Поспелов әйткәнчә, программалы иҗат методына таба үсә торган **стихияле романтик агым** дип атау урынлырак булыр кебек.

Үз заманында В. Г. Белинский түбәндәге юлларны язып калдырган: «Урта гасырлар романтизмы үлмәде һәм югалмады; киресенчә, ул безнең заман җәмгыятендә дә, ләкин инде үзгәргән һәм кыйммәтен югалткан хәлдә, патшалык итә; ә киләчәк аңа тагын да зуррак үзгәрешләр хәзерли»[2]. Бөек тәнкыйтьченең бу фикерләрен, безнеңчә, татар романтизмының үсеш юлына карата да кулланырга мөмкин. Безнең әдәбияттагы романтизм да урта гасырлардан XX йөзгә кадәр стихияле әдәби агым рәвешендә үсеш-үзгәрешләр кичереп килде. Ә XX йөз башларында инде ул яңа үзгәрешләр кичерергә, яңа үсеш баскычларына күтәрелергә тиеш булды.

---

[1] Г. Халит. Күрсәтелгән хезмәт. 207 бит.
[2] В. Г. Белинский. Полн. собр. соч. VII том. 157 бит.

## Гөлсинә Мөхәммәдова

# РУС СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ ИҖАТЫНДА ТАТАР ОБРАЗЛАРЫ

Бу теманы татарлар арасында озак еллар яшәп, татар халкының истә калырлык образларын тудырган бөек Горькийдан башлап китәргә кирәк иде. Әмма тәнкыйтьчеләребез, әдәбият белгечләребез тарафыннан М. Горький иҗатының бу өлкәсе берникадәр яктыртылган булганлыктан, без әлеге проблеманы рус совет әдәбиятының соңгырак буын вәкилләре — Л. Леонов, А. Коптяева һәм Ф. Панферов иҗатларында карап үтмәкче булабыз.

Леонид Леоновның 1935 елда басылып чыккан «Океанга юл» романы илебездә социализм төзү чорында тимер юл эшчеләре тормышын күрсәтүгә багышланган. Язучы әдәби образлар аша хезмәт иясеренең героик эш башкаруларын, хезмәт төшенчәсенең яңа, киң мәгънә ала баруын, аның кешеләрне тәрбияләвен һәм, бер үк вакытта, коммунизм төзү идеяләре белән янган кешеләрнең үз араларына кереп яшеренгән дошманнар белән кискен сыйнфый көрәш алып бару процессын сурәтли. Башка образлар белән рәттән, әсәргә татар Сәйфулла образын да кертү язучыга романның идеясен тулырак ачарга мөмкинлек биргән.

Укучы Сәйфулла белән беренче мәртәбә ныклап депо комсомолларының җыелышында таныша. Яшьләр үзләренең паровозын йөртүне, алдынгы эшче буларак, Сәйфуллага ышанып тапшыралар. Алты ел элек депога акча эшләп китү нияте белән генә килгән авыл егете Сәйфулла өчен исә бу — бик зур шатлык. Машинист булу бит аның күптәнге хыялы иде. Сәйфулланың Мәхүп әби өендә шашынып «Эпипә»гә биюе аша автор аның моңа ничек шатлануын бик оста бирә. Монда Сәйфулла үзе генә түгел, бу — депо яшьләренең күңелле кичәсе. Сәйфулланың биюен сокланып күзәтеп торган иптәшләре арасында аның сөйгән кызы Катя да бар. Шул кыз бит инде, Сәйфулла машинист итеп билгеләнгәч, бөтен җыелыш алдында аның күкрәгенә кызыл тасма кадаган иде. Хәзер үзе дә, менә шушы кызыл тасма кебек, Сәйфулланың йөрәк түренә урнашып бара. Сәйфулла моңа сөенеп, чын бәхетнең килүе итеп карый. Һәм менә шул бәхетне тагын да ныгытырга теләгәндәй, ул очынып-очынып «Эпипә»гә баса. Ләкин Сәйфулланың очынуына икенче сәбәп тә бар — ул әнә шулай җилкенеп үзенең үткәненнән тәмам аерылмакчы, аның белән бөтенләйгә хушлашмакчы була. Бу хушлашу Сәйфуллага үзе эзләп тапкан матуррак, мәгънәлерәк яңа тормыш белән кавышу өчен кирәк. Алты ел депода эшләү дәверендә Сәйфулла инде күмәк хезмәтнең мәгънәсен аңларга, кешеләр белән бер булып эшләргә өйрәнгән. Яңа, зуррак максатлар белән очрашу аның моңа кадәрге вак омтылышларын күмеп китә башлаган. Шуңа күрә, авылда калган сөйгән кызы Мәрьям күз алдына килгән чакларда, ул аның белән һәр вакыт бәхәсләшә, бу бәхәстә дә гел үзенең өстенлеген сизеп тора.

Сәйфулланың үзен иң бәхетле сизгән минутында — биегән чагында да Мәрьям аның исенә төшеп ала. Тик Мәрьямнең сабырлыгы, үзен язмыш кулына тапшырып, тормышны үзгәртүгә битараф каравы Сәйфулла күз алдында кызның шәүләсен тоныкайта, еракларак этәрә. Кешеләргә, шул исәптән сөйгәненә дә, югарырак ноктадан карарга өйрәнгән егетнең соклану тулы карашы — Катя Решеткинада. Туган авылы Әлдермештә ул дөнья күргән кешеләрдән «марҗа»лар турында төрле ямьсез сүзләр ишеткән булса да, аларга берникадәр шикләнү катыш-куркыбрак караган булса да, Сәйфулла барыбер Катяда үзенең ышанычлы иптәшен, акыллы кызны таба. Юк, аның йөрәге җиңел күбәләк түгел. Мәрьямнән аерылу аның өчен газаплы, авыр, үзәкне өзә торган аерылу. Катя турында уйлап йөргәндә дә кинәт Мәрьямнең тәрәзә төбендә үзен көтеп утыруын күз алдына китерә ул. Шундый авыр чакларында кызга ярдәм итәргә теләгәндәй, ул аңа, күңеленнән, китаплар укырга киңәш итә.

Болар барысы да безнә Сәйфулланың кичерешләре бер кызны икенчегә алыштырудан гына түгел, ә шәхси, күңел кичерешләренең социаль мөнәсәбәтләр, үзгәргән социаль карашлар белән нык үрелгән драма икәнлегенә ышандыралар.

Ниһаять, кайчандыр ерак Татарстандагы Әлдермеш авылыннан вакытлыча дип кенә килгән Сәйфулла, онытылып, җаны-тәне белән бирелеп эшкә тотына, яңа тормыш юлыннан китә. Паровоз, деподагы бүтән комсомол яшьләрнеке кебек үк аның да тормыш бизәгенә, олы куанычына әверелә. Яшьләр транспортның тоткарлыксыз йөрүе өчен зур ярыш ачып җибәрәләр.

Һәм менә яшь машинист дүртенче рейсын ясаганда көтелмәгән хәл — катастрофа. Көчле буранда, Сарзан үткелен уздык дигәндә генә, суы бетеп, паровоз эштән чыга. Бу — депо начальнигы булып урнашкан элекке ак офицер Глеб Протоклитовның явызлыгы нәтиҗәсе. Машинист итеп билгеләнгәнче Сәйфулланың бер ел слесарь булып эшләргә тиешлеген дә, аның паровозда пар бүленү кагыйдәләрен юньләп белеп бетермәвен дә Протоклитов кына белгән иде бит. Тик яшьләр, энтузиазмга бирелеп, сизгерлекне киметәләр. Аларның тәҗрибәсезлегеннән дошман үзенчә файдалана.

Паровозны эштән чыгаруны Сәйфулла дөньядагы иң зур җинаять дип карый.

— «Эх, харап булдым бит!» — дип кычкырып, бүреген идәнгә атып бәрүе аның шул минуттагы халәтен безгә тулысы белән ачып бирә. Чыннан да «харап булды» түгел, ә үзем «харап булдым», үзем беттем! Бу сүзләр Сәйфулла тормышында паровозның никадәр якын һәм кадерле әйбер булып әверелгәнлеген безгә бик ачык күрсәтеп тора.

Сарзан үткелендәге бәхетсезлек вакытында Сәйфулла кулларын пешерә. Ләкин ул чагында үзе моны сизми дә. Тик бераздан, кайгы әзрәк еракләшә башлагач кына, ул кулларының әрнүен тоя башлый. Бу аның кичерешләренең, кайгыруының никадәр көчле булуы турында сөйли.

Сәйфулланың иң кайгылы көнендә авылдан әнисе Бибикамал килеп төшә. Бер яктан, ул улы Сәйфулланы кызгана, аңа ярдәм итәргә тырыша һәм, шул ук вакытта, улын иптәшләреннән, эшеннән аерып, кире авылга алып кайтып китәргә дә тели. Аларның Сәйфулла рейска киткәнче һәм авария булып рейстан кайткач булган ике сөйләшүе характерлы. Баштагысында Сәйфулла — үз-үзенә, деподагы эшенә нык ышанган кеше. Әнисенең Әлдермеш турында сөйләве, авылдагы хуҗалык эшләре белән кызыктырырга теләве Сәйфуллага артык тәэсир итми. Аларның сөйләшүе, каян гына башланса да, ахырда һәр вакыт Сәйфулланың деподагы эшенә, иптәшләренә барып тоташа. Әнисе аннан:

— Аракы эчмисеңме? — дип сорый.

Ә ул:

— Юк, әнкәй, безгә Ленин кушмый! — дип җавап бирә.

Мондагы «без» сүзе генә дә элекке крестьян егетенең аңында никадәр үзгәрешләр булып узганын, хәзер инде аның «мин» дип кенә түгел, ә «без» дип сөйләшергә, коллектив исеменнән эш йөртергә өйрәнгәнен ачык чагылдыра торган деталь. Улындагы шушы үзгәрешне сизгән Бибикамал: «Яңа җирдә яңа чәчәкләр үсә икән шул», дип куя. Бу сүзләрдән соң инде барысы да ачык, бүтән сөйләшүгә урын да юк кебек. Ләкин Сарзан үткелендә булган бәхетсезлек Сәйфулла күңелен яңадан актарып ташлый. Хәзер инде әнисенең күчтәнәчкә алып килгән кабартмалары да, үлгән әтисенең сәгате дә, әнисе өстендәге начар киемнәр дә һәм, ниһаять, вакытлыча чигенеп торып, хәзер яңадан күз алдына килгән Мәрьям да — барысы да Сәйфулланы авылга тарта, шунда чакыра. «Ул үзе алты ел буе үткән юлны хәзер шулай тиз

кирегә үтә алуына шаккатты», ди автор, геройның уйларын аңлатып.

Бу уйлар зур авария алдыннан бөтенләй югалып, элекке хыялларын, шулар хакына күпме намуслы хезмәт куюын, ә бу хезмәтне депода һич тә югалтмаячакларын бер мәлгә бөтенләй башыннан чыгарган Сәйфулланыкы. Паровозны яндыру — аңа биредәге бөтен тормышын яндыру кебек. Аның беркатлы күңеле әнә шундый нәтиҗә ясый һәм деподан китәргә, комсомол билетын кире тапшырырга, дигән карарга килә. «Ал моны,— диде ул, таушалып беткән, бармак эзләре калган комсомол кенәгәсен сузып.— Ләкин шул чак моны гына кайтарып бирергә тиеш түгеллеге исенә төште. Ул ашыга-ашыга кесәләрен актарырга тотынды һәм мондый документны, тормышка, иптәшләре дуслыгына хокукны югалтудан куркуы бер мизгелгә аның йөзендә ниндидер ямьсез бер үзгәреш тудырды».

Әйе, Сәйфулла хатасы өчен иң зур җәза итеп деподан китүне сайласа да, ул үз күңеленең депо белән бәйләнгән җепләрен тиз генә өзә алмый әле. Менә берничә эпизод: «Өйалдына кемдер керде һәм ул иптәшләре аны чакырырга килгәннәрдер дип уйлады...» Ләкин бу өмет акланмый кала. Шуннан соң Сәйфулла, үзе дә сизмәстән, авылга китүен озаккарак сузарлык сәбәпләр эзли башлый. Ул акчасын да акрын гына саный. Авылга кайтырга бүләкләр алу турында уйлаган булса да, үзе никтер яшереп аракы сатучы Медведева янына барып чыга. Кайгысын аракы белән юмакчы була.

Шуннан соң язучы Сәйфулланың кар өстендә биюе турында яза. Хәтерлисездер, бу безнең алда аның икенче тапкыр биюе. Сәйфулланың беренче биюендә без аның үз-үзенә ышанганлыгын, хәрәкәтләрендә матурлык күргән булсак, бу биюе бөтенләй башка характерда: хәрәкәтләре буталчык, ачулы. Катяның килеп чыгуы гына аны бераз тынычландырып җибәрә. Һәм бу очрашу ахырда Сәйфулла язмышы өчен хәлиткеч нәрсәгә әверелә — егет депода слесарь булып кала. Күңелдән без аның яңадан машинист булачагына һәм илнең озын юллары буйлап күп рейслар ясаячагына ышанабыз.

Язучы Сәйфулланы үз әсәрендә шундый драматик ситуацияләр аркылы үткәрә — алар белән танышкач, безнең күз алдына бер татар егетенең генә тормышы, аның гына алдынгы эшче булып әверелүе түгел, ә бөтен татар халкының яңа социаль үзгәреш кичерүе; башка милләт вәкилләре белән бергә, коммунизмга барган җәмгыятьнең революцион көче булып үсеп, өлгереп җитүе аңлашыла. Сәйфуллага деподагы дусларының ярдәм итеп, киңәш биреп торулары, аңа «татар» дип кимсетеп карамыйча, гадел мөнәсәбәттә булулары да — халыклар арасындагы дуслык һәм ышанганлыкның әдәби образ аша әсәрдәге дәрес чагылышы булып тора.

Романда берәр генә урында күренеп китсәләр дә, Габдрахман һәм Мәхүп әби образлары да истә калырлык итеп эшләнгән. Габдрахман образы, романдагы исемсез татар малярларының образлары кебек үк, үз эшенә мөнәсәбәттә ачыла. Буфетчы Габдрахман эшен чиксез яратып башкара, ул үз-үзенә һәм башкаларга карата таләпчән дә, киң күңелле дә.

Автор шулай ук Мәхүп әбинең дә җанлы, тәэсир көченә ия булган образын иҗат иткән. Аның татар карчыгы икәнлеген рус сүзләрен татар сүзләре белән аралаштырып сөйләвендә генә түгел, фикер йөртүендә дә күрәбез. Исемсез татар малярлары, Сәйфулла, Габдрахман образларында тасвирланган хезмәт сөючәнлек, тырышлык өстенә, Мәхүп әби образы аша автор укучыга татар халкының сәләтлелеге, чисталыгы турында шактый күп нәрсә сөйли. Мәхүп әбинең өендәге җиһазларны, тәртип һәм чисталыкны сурәтләгәннән соң, Л. Леонов «ул — искитмәле исемсез рәссам — матурлыкның нәрсә икәнен яхшы аңлый» дип нәтиҗә ясый.

Күргәнебезчә, тормышны социалистик реализм позицияләрендә торып чагылдырган зур художник ул елларда ук инде татар халкының милли характерын үстерү, баету өчен зур мөмкинлекләр барлыгын күрә һәм шуны сәнгатьчә образларда гәүдәләндерә.

Антонина Коптяева да «Җир бүләге» исемле романында Ярулла Низамов семьясы һәм Зарифа Насыйбуллина образлары аша татар халкы арасында яңа гадәтләрнең туу процессын күрсәтергә тели.

Ләкин «Җир бүләге» романында язучы геройларның эчке дөньяларын нигездә гаилә-көнкүреш мохитендә генә сурәтли. Ярулланың артта калган карашларыннан азмы-күпме арына баруы да шул яссылыкта гына ачыла.

Ярулла эштә алдынгылардан санала. Дингә дә бик исе китми. Ләкин аның психологиясендә әле иске гадәтләр хакимлек

итә. Аның үзен ата-анасы кечләп диярлек Нәҗия дигән кызга өйләндерә. Ә Ярулланың күңеле исә бөтенләй башка кешедә — Зарифа исемле чая кызда була. Ул кыз Ярулланың йөрәген гомер буе сызландырып тора. Ләкин, шуңа да карамастан, эш үз кызын кияүгә бирү мәсьәләсенә килеп җиткәч, Ярулла кызының хисләре белән исәпләшеп тормый.

Ярулла кече улы Әхмәтшаны да үз дигәнечә өйләндерергә тели. Әмма улы әтисенең бу деспотлыгына түзеп тора алмый — өйдән бөтенләй чыгып китә. Күреп үткәнебезчә, тормышка мондый аңлы, актив мөнәсәбәтне Сәйфулла образында Леонид Леонов та гәүдәләндергән иде. Тик ул аны әерым сюжет сызыгы итеп кенә алмаган иде.

Федор Панферовның «Уйлану» романы — күп проблемалы әсәр. Романның төп фикере — Совет властеның крестьянга нәрсә биргәнлеген әдәби образлар ярдәмендә ачыклау. Көтүче Ибраһим Явлейкин гаиләсен сурәтләү авторга әсәрнең идеясен ачып бирү өчен хезмәт итәргә тиеш иде, ләкин ул әсәрдә язучының изге нияте булып кына калган.

Менә Ибраһимның кызы — Мәрьям. Аның Мәскәүдә Авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлап яңа токымнар чыгаруына, сарыклардан йон кыркып алуда югары уңышка ирешү өчен әтисенә булышуына ышанмаска мөмкин дә түгел кебек. Тик бәла шунда, боларның барысы турында да башка персонажлар гына сөйли. Алар Мәрьямнең үз характерында күренмиләр. Үз-үзен тотышы, дөньяга карашы, килешкилбәте белән Мәрьям яңа гына урта мәктәпне тәмамлап чыккан яшь кызны хәтерләтә. Шулай итеп, безнең каршыбызда әйтерсең лә ике образ басып тора. Берсен автор һәм башка персонажларның сүзләре аша күз алдына китерсәк, икенчесен Мәрьямнең үз хәрәкәтләре һәм үз кичерешләре аша күрәбез.

Шундый ук икегә бүленү Ибраһим Явлейкин образы өчен дә хас. Башка персонажларның сөйләвенә караганда, ул — тәҗрибәле көтүче, яхшы ир һәм ата, дуслыкның кадерен белә торган шәп кеше. Егор Пряхинның сарык көтүе үлгәч, беренче булып аңа ярдәмгә Ибраһим килә. Ул һәр нәрсәгә дәүләт күзлегеннән карый. Ибраһим болай уйлый: әгәр Егор Пряхинга совхоз сарыкларының бер өлешен бүлеп бирсәң, Егорның сарык көтүе булачак, ләкин аңа карап дәүләткә бернинди файда килмәячәк — бу бары әйберне бер кесәдән алып икенчесенә салу гына булачак. Шуңа күрә Ибраһим көтүчеләргә үз хуҗалыкларыннан унар баш сарык бирергә тәкъдим итә. Ә үзе Егорга хуҗалыгындагы нәселле тәкәләрне бирә.

Ләкин Ибраһим белән якынрак таныша башлагач, тирәннән уйлап эш итүче җитди агай урынына, бөтенләй икенче кешегә тап буласың. Мәсәлән, Ибраһим Явлейкин болай фикер йөртә: «Күп бармак — колхоз. Шулаймы? Егорка үлдеме? Көтүчеләр — күп бармак. Шулаймы?» Әлбәттә, сүзләрнең мондый конструкциясе Ибраһим Явлейкин образын кечерәйтә. Ә Егор Пряхинны ул ярышка менә ничек чакыра: «Тартышачакбыз — ну... Алга, алга, Егорка!» Егор Пряхин кунакка килгәч, үзенең шатлыгын ул түбәндәгечә белдерә: «Егорька! Милка, сладка, ух!».

Шулай итеп, персонажның сөйләме аның эчке дөньясын, характерын ачып бирүгә ярдәм итү генә түгел, аны бозып күрсәтә. Чөнки автор персонажның сөйләм телен бозу юлы белән аның башка милләттән икәнлегенә басым ясарга тели.

Керәш — татар халкының милли үзенчәлекләрен...

Керәш — татар халкының милли уеннарыннан берсе. Ә. Ф. Панферов аны әсәренә ничек кертә? Ибраһимга кунаклар килә. Аларны хөрмәтләп каршылыйсы урынга, Ибраһим Егор белән көрәшергә керешә. Бу очракта да милли үзенчәлеккә басым ясау образны түбәнәйтүгә китерә.

Без карап үткән өч романның да төп материалы — совет чынбарлыгы. Л. Леоновның «Океанга юл» романында депо эшчеләренең тормышы чагылса, А. Коптяеваның «Җир бүләге»ндә — Татарстан нефтьчеләре, Ф. Панферовның «Уйлану» әсәрендә Идел буендагы колхоз тормышы сурәтләнә. Өч язучы да романнарындагы персонажлар системасына татар образларын кертеп, Совет властеның татарларга нәрсә бирүен күрсәтүне бурыч итеп куйганнар. Алынган проблема уртак, әмма аның сәнгатьчә гәүдәләнеше төрлечә. Сәбәп нәрсәдә соң?

Безнең карашыбызча, бу, беренчедән, өлеге романнардагы татар образларының әсәр тукымасына төрлечә килеп керүләрендә. Л. Леоновта татар персонажлары әсәрнең идеясен ачып бирүгә буйсындырылганнар, сюжет үсешендә аларның һәр кайсының функциясе ачык билгеләнгән. Ә Ф. Панферов һәм А. Коптяевада татар образлары, әсәрнең идеясен ачып бирүгә хезмәт итүдән бигрәк, ул идеяне иллюстра-

циялəү өчен алынганнар. Л. Леоновта милли үзенчәлек образ тудыру чарасы булып тора, ә Ф. Панферов белән А. Коптяевада персонажның кайсы милләттән булуын күрсәтү өчен генә кулланыла.

Икенче сәбәп — авторларның үз геройларының эчке дөньясына ни дәрәҗәдә үтеп керүендә. Л. Леонов персонажларның кичерешләрен, тирәнтен яшеренгән тойгыларын мөмкин кадәр тулырак итеп ачып бирергә омтыла. А. Коптяева исә геройның тормыш-көнкүрешен, гаиләдәге мөнәсәбәтләрне сурәтләү белән чикләнә. Геройларның производство эшчәнлеге турында сүз кузгалса, аларның психологик кичерешләре кысрыклап чыгарыла. Ф. Панферовта образлар иҗат иткәндә төп игътибар персонажларның портретын язуга, башка геройларның сүзләренә нигезләнеп аларга характеристика бирүгә юнәлдерелә.

Әлеге әсәрләрдәге татар образларын иҗат итүдә персонажларның сөйләм теле дә зур роль уйный. Л. Леонов романында геройларның сөйләве аларның әхлакый йөзләрен, эмоциональ кичерешләрен гәүдәләндерә торган чара булып тора. Антонина Коптяева исә персонажлар телен йомшак индивидуальләштерә. Ә Федор Панферовка килгәндә, ул персонажларның сөйләмнәре аша аларның кайсы милләттән икәнлекләрен күрсәтергә тели.

Шулай итеп, милләтләр арасындагы үзара якынаю, бер-берсен баету һәм бергәләп үсешнең яңа баскычына күтәрелү процессын дөрес чагылдыру өчен, язучы теге яки бу милләтнең үзенә генә хас булган үзенчәлекләрен тирәнтен белергә, персонажларның кайсы милләттән икәнлеген әйтеп үтү белән генә чикләнмәскә тиеш. Башка милләт вәкилләренең образларын тудырганда да әдәби иҗатның гомуми һәм мәҗбүри законнары үз көчендә кала.

## Хөрмәтле каләмдәшебез, дустыбыз «Чаян»!

*Сиңа да 50 яшь тулды. Нәрсә дигән сүз ул илле?*
*Егермедә егеткә көч кирә.*
*Утызда егет кулыннан эш килә.*
*Табигать егеткә кырыкта акыл һәм зирәклек бирә.*
*Илледә ир егет эшләгән эшләре өчен данга күмелә.*

*«Чаян» иптәш! Син туган көнеңнән башлап, ир егет булып үсеп җиткән ИЛЛЕ яшеңә тикле, көч-гайрәт белән, табигый акыл һәм зирәклек белән, ил шатлыгына шатланып, ил кайгысын кайгыртып яшәдең: коммунизм төзүче совет кешеләренең зур һәм изге эшенә аяк чалучыларны: мулла-мунтагайны, кулан-куштанны, ялкау-сөрхәнтәйне, җилбәзәк-җилкуарны, бюрократ-благайны һәм башка, һәм башка чүп-чараманны «Чаян» каләме белән кадап, көн яктысына чыгардың, «Чаян» угы белән көйдереп үтердең.*

*Рәхмәт Сиңа шуның өчен!*

*Син Ә. Исхак, Ә. Фәйзи, М. Әмир, Ш. Мөдәррис, З. Нури, Г. Афзал, Ш. Галиев кебек юморист-сатирикларны үстердең.*

*Рәхмәт Сиңа шуның өчен!*

*Без — «Казан утлары» — Сине олуг бәйрәмең белән котлыйбыз. «Чаян» угларына «Казан утлары» ялкынын да өстәп, тагын да көчлерәк, тагын да усалрак булып яшәвеңне телибез.*

*«Казан утлары» редколлегиясе хөрмәтле юбилярыбыз «Чаян»ның 50 еллыгы хөрмәтенә журналыбызның юмор-сатира бүлеген «Чаян бүлеге» дип исемләргә карар бирде.*

*Без бу бүлекне, Синең ярдәмең белән, «Чаян»га лаек итеп алып барырга тырышырбыз.*

*Каләмне каләмгә кушып,*
*дусларча кочаклап:*

**«КАЗАН УТЛАРЫ» РЕДАКЦИЯСЕ.**

# ХАЛЫК ҺӘМ ДИН

Һәр халык дингә, руханиларга каршы юнәлтелгән мәзәкләргә, шаян анекдотларга бай, алар йөзләрчә, меңнәрчә еллардан бирле буыннан-буынга күчеп киләләр. Язучы Гариф Гобәй тәрҗемәсендә шуларның кайбер үрнәкләрен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.

## *РУС ХАЛЫК ӘКИЯТЕ*

## ШАЙТАН БЕЛӘН АЛЛА БӘХӘСЕ

Көннәрдән бер көн шайтан кырда нишләргә белми аптырап йөри иде, алланы очратты. Сөйләшеп киттеләр. Шайтан, аллага шикаять итеп, мине кешеләр һич юкка тиргиләр, ә сине мактап бетерә алмыйлар, ди.

Алла шайтанга:

— Син кешеләргә гел явызлык кына эшләргә карыйсың, сине шуның өчен тиргиләр, ә мине яхшылыгым өчен мактыйлар,— ди.

— Дөрес түгел,— ди шайтан.

— Дөрес.

— Әйдә, сынап карыйбыз.

Алла риза була. Болар бер урманга керәләр. Инеш буенда сыерлар утлап йөри икән. Яр читеннән барган бер сыер, аягы таеп, ярдан егылып төшеп, пычракка кереп бата.

Крестьяннар йөгереп килә. Ә алла белән шайтан шыпырт кына күзәтеп утыралар. Крестьяннарның берсе сыер янына килеп:

— Кая китереп керткән бит, у-у, шайтан тәре! — ди.

Шайтан алланың кабыргасына төртеп:

— Ишеттеңме? — ди.— Мин бит синең белән идем, бер нишләмәдем, ә мине тиргиләр.

— Әйе, ишеттем,— ди алла.

Кешеләр, тырыша торгач, сыерны баткактан өстерәп чыгаралар. Сыер хуҗасы бүреген салып бер чукынып ала да:

— Мең шөкерләр сиңа, аллам, сыерымны чыгарырга булыштың,— ди.

— Ишеттеңме? — ди шайтан аллага,— син булышмадың бит, нигә алар сиңа рәхмәт әйтәләр?

— Ә мин каян белим,— ди алла.

## *УКРАИН ХАЛЫК МӘЗӘГЕ*

## ИЗГЕЛӘР «БУЛЫШТЫ»

Бер абзый шәһәргә китеп бара иде. Юлда көчле буран купты. Адашып йөри торгач, абзый аты белән бер кипкән елгага барып төште. Но, но!..— дип куа бу атын. Аты кузгалмый да. Абзый уйлапуйлап торды да, бәлки булышыр дип, бер изгегә дога кылды. Ә ат — каккан казыкмыни!..

«Тукта, Мәрьям анага дога кылып карыйм әле»,— диде абзый. Ә ат һаман кузгалмый. «Хатын-кыз ничек ярдәм итсен инде, җит-

мәсә, кулында сабый баласы... Кырык изгегә мөрәҗәгать итеп карыйм әле...»

Менә ул кырык изгегә дога кылды, атына бик каты «Но-о!» — дип кычкырды һәм каезларга кереште. Ат арбаны бер якка каерып кузгалырга теләгән иде, тәртә шартлап сынды. Абзый кырык изгегә ачуыннан:

— У-у, шайтан алгырлары!.. Изгеләр! — дип тиргәнә башлады.— Үзегез изге булып йөргән буласыз, үзегез шуның да җаен белмисез!.. Бөтенегез бер тәртәгә ятмасагыз соң! Егермегезгә бер тәртәгә, егермегезгә икенчесенә ятарга иде.

## *БЕЛОРУС ХАЛЫК ӘКИЯТЕ*

# МУЖИК ГӨНАҺ КЫЛДЫ

Берзаман фәкыйрь генә мужик поп янына килде.

— Хатыным синең яныңа тәүбә кылырга җибәрде. Ләкин нәрсәдән тәүбә кылырга белмим, бер гөнаһым да юк.

— Кеше үтергәнең бармы?

— Юк.

— Урлаганың?

— Юк.

— Зина кылганың?

— Юк.

Поп котырынып:

— Ә гыйбадәт кыласыңмы? — дип сорый.

— Юк.

— Үзең, гөнаһым юк, дисең. Гыйбадәт кылмаган кеше гөнаһсыз була димени... Бар, кайт та өч көн рәттән гыйбадәт кыл.

Мужик тыңлый. Дүртенче көнне поп сорый мужиктан:

— Я, эшләр ничек?

— Начар,— ди мужик.— Гөнаһ эш кылдым.

— Ничек?

— Шулай. Мин, юләр, син кушканча, гыйбадәт кылып яттым. Ә миңа игенемне урырга кирәк булган икән.

## *КЫТАЙ ХАЛЫК МӘЗӘГЕ*

# БУДДАЛАР БӘХӘСЕ

Бер карчык кызыл балчыктан әвәләгән ике будда асрый. Карчык, гыйбадәт кылган саен, алардан ярдәм сорап ялвара. Бер тапкыр аның оныгы:

— Әби, син бу балчык сыннарга ни дип табынасың? — дип сорый.

Әбисе ачуланып:

— Дәшмә! — ди.— Үзләре ишетмәсен, ачуларын китерерсең.

Көннәрдән бер көн малай, уйнап йөргәндә, сыннарның берсен төшереп вата. Әбисе ачуланып малайга ташлана.

— Бер будданы ваткансың бит, юньсез!

— Мин түгел,— ди малай.— Алар үзләре. Башта талаштылар. Аннары тегесе моныеының башына таяк белән шалт берне! Әйләнеп кенә төште.

— Ялганлама. Алар сугыша алмыйлар.

— Ә талаша да, сугыша да алмагач, алар ничек сиңа ярдәм итә алалар соң?

## Гамил Афзал

# ЭПИГРАММАЛАР

*Нәкый Исәнбәткә*

Хуҗа Насретдингә шәрик кеше —
Нәкый агай йөри ялан баш,
Үткәннәрдән алган шәриф эше
Килер заманнарга замандаш.

*«Намус»лы авторга*

Мин тәүфыйклы егет, мал да табам,
Кысып кына торам бу кесәмне,
Мин аермам аны, Гомәр агам,
Кияүгә бирчәле Нәфисәңне!

*Сибгат Хәкимгә*

Туры юлдан чапкан пар атларны
Нинди җеннәр куа торгандыр,
Мактау көтеп яткан братларны
Бер җылы сүз әйтеп куандыр.

*Гариф Гобәйгә*

«Маякчы кызы»н алды да
Корьәнхафиз булды Гобәй,
Саваплы да, оҗмахлы да,
Хурлар белән, әйдә, гуляй!

*Фатих Хөснигә*

Корычтан көбәсен кия,
Янына укларын өя,
Тисә тиенгә дә тия,
Тимәсә ботакка тия,
Тимәсә дә үзен сөя.

*Шәүкәт Галиевкә*

Берәүләр эченнән тынды,
Берәүләр сөйләшерләр:
— Шәүкәт тә начальник булды...
— «Бар икән күрәселәр...»

## ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР



МИРСӘЕТ ЯРУЛЛИН.



РЕНАТ ХАРИС.

Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премияләр комитеты карары нигезендә 1972 ел премияләре «Кеше» ораториясе өчен композитор Мирсәет Яруллин белән шагыйрь Ренат Харисқа, концерт-башкару эшчәнлеге өчен Казанның В. И. Ленин исемендәге культура сарае татар халык хорына бирелде.

## ТЕЛ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Узган елның 25 декабрендә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында татар әдәби теле мәсьәләләренә багышланган зур җыелыш булды. Язучылар союзы оештырган бу җыелышта әдипләр, тел белгечләре, журналистлар катнашты.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе шагыйрь Зәки Нури ачкан ул җыелышта язучы Х. Сарьян, филология фәннәре докторы В. Хаков, филология фәннәре кандидатлары Ф. Фасеев, И. Бәширова, Б. Мифтахов, К. Сабиров әдәби телнең төрле мәсьәләләренә караган докладлар сөйләделәр. Аннары фикер алышулар булды һәм мондый җыелышларны әледән-әле оештырып торуның кирәклеге әйтелде.

## ГИГАНТ ПЛАСТИНКА

СССРның илле еллыгына багышлап, Бөтенсоюз «Мелодия» фирмасы озак уйный торган гигант пластинкалар чыгарырга кереште. «СССР халыклары сәнгате» сериясендә чыгарыла башлаган, 33 данә тәшкил иткән ул пластинкаларга илебезнең союздаш һәм автономияле республикалары халыкларының көй һәм җырлары тупланган. Шулар арасында Татарстан сәнгатенә багышланган пластинка да бар. Бер сәгать буена тоташ уйнала торган бу пластинкага халкыбызның борынгы көйләре дә, композиторларыбызның хәзерге көйләре дә язылган. Пластинка СССРның халык артисты композитор Нәҗип Җиһановның «Минем республикам» исемле җыры белән башлана. Бу җыр Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры хоры һәм Татарстан АССРның җыр һәм бию ансамбле тарафыннан башкарыла. Пластинкага композиторларыбызның зур күләмле әсәрләреннән Рөстәм Яхинның «Үникке батыр турында баллада», Ринат Еникеевның «Ак дулкыннар», Заһид Хәбибуллинның «Скрипка һәм фортепьяно өчен поэмалар»ы һәм Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Солтан Габәши, Александр Ключарев җырлары урнаштырылган. Ул җырлар атаклы җырчыларыбыздан Әлфия Афзалова, Илһам Шакиров, Эмил Җәлалетдинов, Венера Шәрипова һәм Азат Аббасов җырлаганда язып алынган.

## ЯҢА КИНОТЕАТР

Түбән Камада яңа кинотеатр эшли башлады. Ул 800 урынлы. Анда иң камил кино-

аппаратлар куелган. Бу — республикабызда махсус төзелгән беренче киң форматлы кинотеатр.

### ФАЙДАЛЫ КИҢӘШМӘ

Бөтенроссия театр җәмгыяте идарәсе президиумының киңәйтелгән утырышы Ярославль шәһәрендә уздырылды. СССР һәм РСФСР Язучылары союзы белән берлектә үткәрелгән бу киңәшмә совет театр сәнгатенең актуаль проблемаларына багышланган иде. Киңәшмәдә партия работниклары, театр эшлеклеләре, язучылар катнашты. Татарстан вәкиле яшь драматург Диас Вәлиев үзенең чыгышында республика театрларының язучылар белән элемтәсе турында сөйләде.

### ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Узган ел ахырында Мәскәү шәһәренең Мосстрой культура һәм техника йортында татар әдәбияты һәм җыры кичәсе үткәрелде. Кичәдә шагыйрьләрдән Михаил Львов, Илдар Юзеев, Дифгат Сирай, башлап язучы Әхмәт Саттаров, композитор Фасил Әхмәтов чыгыш ясадылар. Аннары Татарстанның атказанган артисты Фәйзи Йосыпов, культура институты студентлары һәм башкаланың үзешчән сәнгать көчләре катнашы белән концерт бирелде.

* * *

Шундый ук кичә Мәскәүнең Н. А. Некрасов исемендәге китапханәсендә дә үткәрелде. Гариф Ахунов бүгенге татар әдәбияты һәм «Казан утлары» журналының 1973 елга планнары турында сөйләде. Рафаэль Мостафин 1972 елда Көнбатыш Германиянең Мюнхен шәһәрендә булып, анда Муса Җәлил тормышына бәйләнешле яңа материаллар табып кайтуын хәбәр итте. Илдар Юзеев «Язылмаган поэма» исемле әсәрен укыды.

Кичәнең икенче бүлегендә композитор Фасил Әхмәтов, рәссам Әхмәт Китаев, Мәскәү филармониясенең нәфис сүз осталары һәм җырчылары концерт бирделәр.

* * *

Казан Актерлар йортында РСФСР Культура министрлыгыннан килгән махсус комиссия членнары белән Татарстан театр белгечләре, театр тәнкыйтьчеләренең иҗади очрашуы булды. Анда чыгыш ясаган И. Илялова, Б. Гыйззәт, Х. Гобәйдуллин һәм Е. Золотарев иптәшләр кунакларга Казан һәм республикабыз театрлары бүген хәл итә торган мәсьәләләр, алар алдында торган бурычлар турында сөйләделәр. Кайбер спектакльләргә анализлар ясадылар, театр өчен кадрлар хәзерләү, репертуар мәсьәләләренә кагылдылар.

* * *

Казанның дәүләт сәүдәсе хезмәткәрләре клубында әдәбият һәм җыр кичәсе үткәрелде. СССРның илле еллыгына багышлап үткәрелгән ул кичәдә татар әдипләреннән Галимҗан Латыйп, Сәет Шәкүров, Гариф Ахунов, Гөлшат Зәйнашева, Хәсән Сарьян, Фаил Шәфигуллин, Вакыйф Нуруллин, Рәдиф Гатауллин, рус шагыйрьләре Николай Беляев, Марк Зарецкий катнаштылар һәм совет сәүдәсе хезмәткәрләренә үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

Кичәнең икенче өлешендә татар дәүләт филармониясе артистлары көче белән концерт бирелде.

* * *

Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин һәм шагыйрь Шамил Маннапов Казандагы 71 нче урта мәктәп укучылары белән очраштылар. Р. Мостафин Муса Җәлил һәм җәлилчеләрнең тоткынлыкта фашистларга каршы көрәше, шул көрәшне раслый торган яңа табылган мәгълүматлар һәм «Муса Җәлил» теплоходында сәяхәттә йөргән вакыттагы тәэсирләре хакында сүз алып барды. Ш. Маннапов үзенең яңа шигырьләрен укыды.

* * *

Язучы Аяз Гыйләҗев ноябрь аенда Оренбург шәһәрендә иҗат командировкасында булды. Хөсәен Ямашев исемендәге татар китапханәсендә укучылар белән очрашты. Татар әдәбиятының бүгенге казанышлары турында сөйләде, китап сөючеләрнең күп санлы сорауларына җавап бирде. Ул шулай ук «Россия» культура сарае каршындагы татар үзешчән сәнгате түгәрәге членнары белән дә очрашып, аларның репетицияләрен карады һәм, драматург буларак, киңәшләр бирде.

* * *

КПССның Төмән өлкә комитеты чакыруы буенча язучы Гариф Гобәй Төмән өлкәсенең татар атеистлары семинарында катнашып кайтты. Ул анда «Коръән серләре»нең язылу тарихы һәм шул әсәренең төзәтелгән һәм тулыландырылган варианты турында сөйләде һәм атеистларының күп санлы сорауларына җавап бирде.

### СӘХНӘ ВЕТЕРАНЫ

Декабрь аенда Казан шәһәренең Актерлар йортында татар театр сәнгатенә зур өлеш керткән өлкән буын вәкиле, Татарстанның халык артисты Касыйм Шамилгә 80 яшь тулган көнне бәйрәм иттеләр.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фатих Шәрәфиев юбилярның иҗат юлы турында доклад ясады. Касыйм ага Шамилнең замандашлары, сәхнәдәш дусла-

ры күнелле исталекләр сөйләделәр. Соңыннан концерт булды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Музыка сәнгатен үстерүдә һәм пропагандалауда күрсәткән хезмәтләре өчен, Татарстан АССРның Дәүләт симфоник оркестры художество җитәкчесе һәм баш дирижеры **Натан Григорьевич Рахлинга Татарстан АССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

## ИҢ КЕЧКЕНӘ КИТАПЛАР

Мәскәүнең В. И. Ленин исемендәге дәүләт китапханәсендә кечкенә форматлы китаплар күргәзмәсе ачылды. Күргәзмәгә куелгән дүрт йөзгә якын китап арасында татар шагыйрьләре Сибгат Хәкимнең «Ленин турында», Зәки Нуриның «Биш учак» исемле Казанда басылып чыккан китаплары да урын алган.

## ЯШЬЛӘР ӨЧЕН КИТАПЛАР

Мәскәүнең «Юность» гостиницасында яшьләр өчен чыгарылган китапларның халыкара күргәзмәсе булды. Үзебезнең илдә һәм башка социалистик илләрдә басылган күп санлы китаплар белән бергә күргәзмә залларында Гариф Гобәй, Әхмәт Ерикәй, Рафаэль Мостафин һ. б. язучыларның китаплары да бар иде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Узган елның 19 декабрендә Әлмәт бүлегенең отчет-сайлау җыелышы булды. Башта бу бүлекнең җаваплы секретаре булып эшләп килгән шагыйрь Равил Фәйзуллинның соңгы елларда бүлектә башкарылган эшләр турындагы докладын тыңладылар. «Әлмәт бүлеге, — диде ул, — хәзерге вакытта 15 СССР язучылар союзы членын һәм иллеләп яшь язучыны берләштерә. Бу оешма татар әдәбиятына сизелерлек өлеш кертерлек сәләтле отрядка әверелде. Соңгы ике ел эчендә генә дә нефть якларында яшәүче әдипләрнең Татарстан китап нәшриятында 16 китабы басылып чыкты.

Доклад буенча фикер алышуларда Әлмәттә яшәүче язучылардан Рафаил Төхфәтуллин, Шамил Бикчурин, Юныс Әминов, Гамил Афзал, Саҗидә Сөләйманова, Сәет Кальметов һәм Энже Мөэминовалар катнашып, бүлек эшенең уңай һәм кимчелекле якларын күрсәттеләр, киләчәктә эшне яхшырту буенча үзләренең тәкъдимнәрен, киңәшләрен әйттеләр.

Әлмәт бүлегенең бу җыелышында Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Зәки Нури, идарә члены, Тукай премиясе лауреаты шагыйрь Хәсән Туфан да чыгыш ясадылар. Зәки Нури үзенең чыгышында әдәбият-сәнгать алдына партия куйган бурычлар турында сөйләде, нефть якларында яшәүче язучыларның иҗатларына анализ ясады.

Соңыннан бүлекнең яңа бюросы сайланды. Аның составына Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин, Юныс Әминов кертелде. Әлмәт бүлегенең җаваплы секретаре итеп Әдип Маликов сайланды.

Бүлекнең отчет-сайлау җыелышында КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре С. Хәкимова, партия өлкә комитетының культура бүлеге инструкторы И. Хәйруллин иптәшләр дә катнашты.

* * *

Прозаик Азат Ганиевның иҗатын тикшерүгә багышланган киңәшмә уздырылды. Киңәшмәгә Равил Фәйзуллин, Гамил Афзал, Әдип Маликов, Сәет Кальметов, Махмут Хәсәнов, Саҗидә Сөләйманова, Рафаил Төхфәтуллин, Шамил Бикчурин, Юныс Әминов һәм Альберт Хәсәновлар катнашты. Алар А. Ганиев иҗатының үзенчәлекле якларын билгеләп үттеләр, яшь автор иҗатында үзләрен шатландырган һәм борчыган нәрсәләр турында фикерләрен әйттеләр.

* * *

Язучылар Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова, Гамил Афзал, Рафаил Төхфәтуллин, Юныс Әминов, яшь язучылардан Һава Сафина, Венера Туктарова, Фәһимә Галиева «Азат хатын» журналы редколлегиясенең күчмә утырышында катнаштылар. Журналда басылган әсәрләргә карата фикерләрен әйттеләр, журналны тагын да яхшырту юнәлешендә тәкъдимнәр керттеләр.

Журналның баш редакторы Асия Хәсәнова бу кызыклы һәм файдалы очрашу өчен язучыларга рәхмәт белдерде.

* * *

Тәнкыйтьче Фатих Урманчеевның иҗатын тикшерүгә багышланган утырыш булды. Чыгыш ясаган Р. Фәйзуллин, Ю. Әминов, Ш. Бикчурин, Р. Төхфәтуллин, А. Ганиевлар Ф. Урманчеевның әдәби тәнкыйть өлкәсендә актив эшләвен билгеләп үттеләр. Ф. Урманчеевны Язучылар союзына членлыкка тәкъдим итәргә дигән карарга килделәр.

* * *

Әлмәт язучылары әдәбият сөючеләр белән әледән-әле очрашып торалар. Соңгы айларда гына да район мәктәпләрендә уннарча әдәби кичәләр уздырылды.

Язучы Әдип Маликов, мәсәлән, Муса Җәлил эшчеләр поселогы һәм Иске Михайловка авылының сигезьеллык мәктәпләрендә, Әлмәт шәһәренең профессиональ-техник училищесында укучылар белән очрашты. «Салкын Алан» әсәре буенча үткәрелгән укучылар конференцияләрендә катнашты.

Шагыйрь Гамил Афзал Азнакай эшчеләр поселогы 1 нче интернат мәктәбендә, Әлмәт шәһәренең 13 нче мәктәп укучылары янында булды. Рафаил Төхфәтуллин Әлмәт шәһәренең 10 һәм 14 номерлы мәктәпләрендә укучылар белән очрашты. Драматург Юныс Әминов Әлмәт шәһәренең 10 һәм 13 номерлы мәктәпләрендә, 1 нче номерлы профессиональ-техник училищесында уздырылган әдәби кичәләрдә катнаштылар.

## ГАСТРОЛЬ УҢЫШЛЫ ҮТТЕ

Татарстан АССРның Дәүләт симфоник оркестры Мәскәүдә гастрольдә булып кайтты. СССРның халык артисты Натан Рахлин җитәкчелегендәге бу оркестр коллективы башкалабыз хезмәт ияләре алдында төрле милләт музыкантлары әсәрләреннән төзелгән программа белән чыгышлар ясады. Аның П. И. Чайковский исемендәге концерт залында һәм консерваториянең зур залында үткәрелгән концертларын Мәскәү тамашачылары яратып тыңладылар. «Советская культура» газетасында республикабызның дәүләт симфоник оркестрына уңай бәя бирелгән мәкалә дә басылып чыкты.

* * *

СССР Фәннәр Академиясенең А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты 1970 елда чыгарган «Горький һәм СССР халыклары әдәбияты» (Горький и литература народов СССР) исемле җыентыкта республикабыз галиме — филология фәннәре докторы, профессор Мөхәммәт Гайнуллинның «Татар әдәбияты һәм Горький» исемле мәкаләсе басылган иде. Әлеге институт тарафыннан Н. А. Некрасовның 150 еллыгына багышлап 1972 елда чыгарылган «Некрасов һәм СССР халыклары әдәбияты» исемле китапта нсә шул ук галимнең «Некрасов һәм татар әдәбияты» исемле мәкаләсе урнаштырылган.

## ТЫРЫШ ХЕЗМӘТ НӘТИҖӘСЕ

Сугыш чорында тукталып торганнан соң янадан чыгарыла башлаган «Азат хатын» журналына редактор итеп 1957 елда Асия Фәрит кызы Хәсәнова билгеләнгән иде. Менә шуннан башлап бүгенгәчә бу журнал Асия ханым җитәкчелегендә басылып килә. Һәм аның укучылар арасында популярлыгы елдан-ел арта бара. 1958 елда 10 000 данә тираж белән чыккан «Азат хатын» журналы быел 308 000 данә тираж белән басыла.

Журналның шулай популяр булуы аның баш редакторы Асия Хәсәнованың тырышлыгы белән дә бик нык бәйләнгән. Аның бу тырышлыгын хөкүмәтебез югары бәяләде. Совет матбугаты өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре өчен, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1973 елның 29 январенда игълан ителгән Указы нигезендә «Азат хатын» журналының баш редакторы **Асия Фәрит кызы Хәсәноваra РСФСРның** атказанган **культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

## КИТАП УКУЧЫЛАР ЯНЫНДА

Казанда яшәүче рус язучылары Михаил Скороходов, Юрий Михайлов һәм җырчы Камил Басыйров «Татсельстрой» эшчеләре клубында китап укучылар белән очраштылар.

* * *

Шагыйрьләрдән Равил Фәйзуллин һәм Лидия Григорьева «Васильево» санаториясында ял итүчеләр алдында чыгыш ясадылар.

* * *

Гәрәй Рәхим, Равил Фәйзуллин һәм Рөстәм Мингалимов Казанда хезмәт итүче солдатлар белән очрашып, аларга үзләренең совет сугышчыларына багышланган әсәрләрен укыдылар, татар советы әдәбияты турында сөйләделәр.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Журналыбызның бишенче санында Габдрахман Әпсәләмовның «Кук күкрәр» романының дәвамын бирәбез.

Поэзия сөючеләргә өлкән шагыйребез Нури Арслановның «Латвия язмалары» дигән шигырьләр циклын тәкъдим итәбез. Рәшит Гәрәй, Роберт Миңнуллин, Шамил Маннапов, Хәкимҗан Халиковларның шигырьләрен дә укырсыз.

Шәһит Гарифуллинның журналыбызның бу санындагы «Хәмит батыр һәм аның балалары» очеркы, исеменнән үк күренгәнчә, Социалистик Хезмәт Герое Хәмит Юсупов һәм аның балаларына — КамАЗ салучыларга — багышлана. Җәүдәт Кәлимуллинның «Япь-яшь кенә булса да...» дигән очеркында РСФСР Верховный Советы депутаты Рокыя Гарифуллинаның заводтагы эше һәм депутат буларак эшчәнлеге яктыртыла.

Очерклары белән сезгә күптән таныш Мәгъсүм Насыйбуллинның «Тормыш әйрәтә, вакыт күрсәтә» дигән очеркы урнаштырыла. Очеркта милиция работникларының авыр һәм мактаулы хезмәте, аларның намуслы кешеләр ярдәмендә чын җинаятьчеләрне фаш итүләре яктыртыла.

Журналыбызның бишенче санында тәнкыйтькә зур урын бирелде.

Казан дәүләт университеты профессоры, филология фәннәре докторы, таләпчән педагог, тәнкыйтьче Ибраһим Нуруллинга 50 яшь тула. Рафаэль Мостафинның «Тормыш дәреслеге хакында» дип исемләнгән мәкаләсе юбилярга багышланган.

Роберт Әхмәтҗановның «Заман утлары» дигән мәкаләсе «Казан утлары»ның 1972 елгы 1—8 саннарында басылган шигъри әсәрләребез турында.

Фатих Урманчиевның «Бүгенге тәнкыйть мәсьәләләре»ндә тәнкыйтьнең бүгенге торышына анализ ясала.

Бүгенге проза турында сөйләшүне тәнкыйтьче Флүн Мусин дәвам итә.

«Әдәбият белеме» бүлегенә филология фәннәре докторы Мансур Хәсәновның «Интернационализмның данлы традицияләре» дигән мәкаләсе урнаштырыла.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары биреләчәк.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210